# казан утлары

3

МАРТ-1975

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**3**

МАРТ
1975


## Бу санда


Х. ХӘЙРУЛЛИН. Картлык... кемгә шатлык! Повесть . . . 3
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Төрле дәфтәрләрдән. Шигырьләр . . . 61

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

Ш. РӘКЫЙПОВ. «Мәңге сакларга!» . . . 68
Г. БАКИРОВ. Ул елларда . . . 79
М. КӘРИМОВ. Бездән алда яшәдегез. Шигырьләр. 90
П. ЛУКНИЦКИЙ. Нева «уч төбе» . . . 92
М. МИЛЬШТЕЙН. Фәрит. «Җен карчыгы» . . . 100

К. БУЛАТОВА. Борынгыдан урман, суларга бай. Шигырьләр . . . 103
В. ТУКТАРОВА. Ни диеп шаулыйсыз. Шигырьләр. 105
Э. ГЫЙРФАНОВА. Кояшлы яңгыр кебек. Шигырьләр . . . 106
Х. МӨДӘРИСОВА. Тәрәзәмне каерып давыл керде. Шигырьләр . . . 107

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . 109
З. ШӘФИГУЛЛИН. Бөреләр ачылганда . . . 112
К. ТИМБИКОВА. Әминә келәмнәре . . . 120

АБДУЛЛА ӘХМӘТКӘ 70 ЯШЬ

А. ӘХМӘТ. Зәңгәр конверт. Хикәя . . . 128

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Р. ПАТКАНЯН. Тургай . . . 134
С. ВАГУНИ. Солдат итеге . . . 135
А. ГРАШИ. Төнге баллада . . . 135
Г. ЭМИН. Алар күпләр . . . 136
С. КАПУТИКЯН. Син мине озата барганда . . . 136
А. ПОГОСЯН. Реквием . . . 137

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Г. ХАЛИТ. Иҗат методы һәм стиль мәсьәләләре 138



КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һәм
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ МИРАС

Әнвәр Давыдов . . . . . . . . . . . . . . 149

СӘНГАТЬ

М. НИГЪМӘТҖАНОВ. Олы максатка йөз тотып . 174

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Җ. ДӘРЗАМАНОВ. Солдат булдым. Шигырьләр . 180
З. ГОМӘРОВА. Бабай тарта шалканны. Шигырьләр 181
Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . 182

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Ф. ЯРУЛЛИН. Сөбханалла! Шигырьләр . . . . 185
Г. АФЗАЛ. Очкыннар. Шигырьләр . . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 188

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-69.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хаким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир

Техник редакторлары *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 29/XI-1974 ел. Басарга кул куелды 23/I-1975 ел. ПФ 09002. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91549 экз. Заказ Ю-344. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1975 ел.

Хәниф Хәйруллин

# КАРТЛЫК... КЕМГӘ ШАТЛЫК?

ПОВЕСТЬ

## 1



Тоташ ике ай буена күк гөмбәзе ник бер ачык чырай күрсәтсен — сәләмә болытларыннан җир өстенә салкын күз яшен койды да торды. Тәмам тинтерәтте: бассаң басар, торсаң торыр урын калмады. Инде ноябрьның яртысы житеп килә, ә аяк астының кайчан ныгып китәренә һаман өмет юк. Гөл балчыгыдай җирләр кайнап суына барган сумалага охшап бетте: әз генә җылытып җибәрү белән аның өстеннән тотендәй аксыл томан күтәрелә. Юлларның бөтенләй рәте китте. Хәтта шосседа да урыны-урыны белән әллә нинди чоңгыллар барлыкка килде. Әвен чаклы зур машина көпчәкләре балчык сыланган юлларның ташларын суырып-суырып алды. Ә авыл тирәсе юлларын инде әйткән дә юк. Атлар буш арба сөйрәп ике-өч километр баруга хәлдән таялар: камыт, ыңгырчак асларыннан ак күбекләр бөркеп чыга.

Фермадагы малларның хәле мөшкелләнде. Әле ярый: күбесенең өстенә янгыр явып тормый. Симертүдәге үгезләр генә саз изә: аларга утарлар житми. Озатылып бетәргә тиеш иде дә бит алар, менә нигәдер сузылды. Бу пычракта ишле малга саламын, печәнен, фуражын житәрлек, мал тамагы туярлык итеп китерү мең бәлагә әйләнде. Кичәге идарә утырышында да сүз гел шул турыда булды. Әле икенче елын гына эшләүче колхоз председателе — озын буйлы, карга канатыдай шома чәчле, калын кара кашлары борын өстенә килеп тоташкан, какча алсу йөзле Мисбах Ганиев салам китерүгә куәтле «ДТ»ларны билгеләде. Ләкин трактор арбаларының пычрак ярып рәтләре беткән булып чыкты. Бүген барлык механизаторлар, паркка җыелып, әнә шул арбаларны ремонтлап мәш киләләр булырга тиеш. Ә маллар алдында шырпылы салам юк. Башаклык онны җылы суга гына бутап бирделәр. Әле ярый, склады, тегермәне ферма белән рәттән генә.

«Көннәр коры торганда ферма янына сөйрәтик саламны, дилем»,— дип пышылдады Хәсән картның салкыннан агарып киткән юка иреннәре. Юк, колак салмады Мисбах аның сүзенә. «Басуда эскертлибез, аяк астын катыруга эскерте белән генә сөйрәтәбез аны, Хәсән абый».— диде. Башка елларны шулай эшлиләр иде дә бит, ел белән ел арасында нинди аерма булмый. Менә сөйрәтеп кара хәзер».

Дуңгыз балаларына сөт ташый Хәсән. Еракган түгел. Аларның колхозы район үзәгенә урнашкан. Сөт-май комбинаты белән ферма арасы өч чакрымнан да артмас. Әле ындыр артлап чирәмнән генә атлатып бара ул кола биясен. Инде монда да рәт бетеп бара. Салам китергән «Беларусь»лар бөтен җирне ермачлап бетергәннәр. Халык мал йөртә торган уч төбе хәтле ындыр арты болыны да харап була болай булгач. Мондый урыннарны киләсе ел әрем, билчән басып китәчәк. Борынына бөтереп тыгарлык печәннәрне эзлә син аннары. «Юк, монда да тәртип кирәк, сессиядә авыл Советы председателенә үтәрлек итеп әйтми булмас бу хакта. Халык малы ризыгын өзү бит бу».

Хәсән карт, шулай дип уйлап, кола биясенә бер чөңгереп куйды. Ат, колакларын шомрайтып, хуҗасына борылып карады да адымнарын тизләтте, үзәнлеккә җиту белән юырта ук башлады. Кайда атлап, кайда юыртып барырга кирәгенә кола бия инде күптән күнегеп беткән. Менә ул үрне ашыкмый гына менде, таш юлга чыккач, җай гына юртып китте. Тимер күпергә якынлашканда, Хәсән үзенең чордашы Асыл картны куып җитте. Ул да ат белән. Өстендә башлыклы кожан. Арбасы яныннан атлый. Башлыгы астыннан очлаеп килгән җиз сакалы ялтырый. Күкәй тартмалары төягән. Хәсән карт моны күреп бер мәл аптырабрак калды. «Йомырка планы үтәлде, хәтта артыгы белән, быелгыларын җыеп барабыз да аннары гыйнварга чыккач тапшырабыз», дип йөри иде бит әле председатель. Райкомнан хәбәр салганнардыр инде, дөрес, нигә әзер күкәйне җыеп ятарга, бозыла-нитә башлый бит ул». Хәсән картның башыннан әнә шундый уй үтте. Асыл карт белән тигезләнгәч тә ул кожан башлыгын артка чөебрәк җибәрде һәм:

— Кордаш, кая юл тоттың? — дип сорады. Арба яныннан лач-лоч пычрак ерып барган Асыл карт аңа аксыл кашлары астындагы кызыл күзенең агы белән карады һәм авызындагы вак тәмәкесен лачт итеп җиргә төкерде дә:

— Күкәй лә бу! — диде.— Заготконтор складына чыгар дигән иде ферма мөдире. Җүнле әдәмнең эте дә урамга чыкмаган көнне мондый эшкә кем бар? Асыл бар. Чит колхоз өчен йөр инде шулай чиләнеп!..

— Ничек чит колхоз өчен?

— Күрше «Үрнәк» өчен китә ди бу күкәйләр...

— Кем әйтте?

— Кемдерби... Күз алдында күз буалар... Йөрисең шунда идарә члены, партком әгъзасы булып... Кем әйтсен, завферма. Ә приказын кем биргәндер, белмим. Ләкин син түгеллегенә иман китерәм, бигайбә... Эзлә дөреслекне, табарсың, тоттырыр койрыгыннан, ләкин ул да сабынлаган...

Асыл карт тәмәкедән саргаеп беткән сирәк, кабан тешләрен ыржайтып каһкаһәле итеп көлде дә:

— Гомер буе дөреслек эзләдең, таптыңмы? Йөрисең инде шунда, эт печән ашамас, сарыкка ирек бирмәс,— диде.

Хәсән карт аңа җавап кайтармады, ачу белән кола биясенә чөңгерде, ат Асыл картны узып китте. Аннан соң гына Хәсән Асыл картның тетмәсен тетте, эченнән генә сүгенде. «Куана, контр!.. Көн-төн фермада йөреп, шул хәбәрне Асылдан ишет инде, ә? Юк, ялгышасың, Мисбах, туган, ялгышасың. Үзең дә алдыйсың, башкаларны да алдарга өйрәтәсең. Болай ярамый, ярамый...» — диде ул үз-үзенә.

Май заводы ишегалдына ат белән керерлек түгел иде. Ул атын капка төбендәрәк туктатты да аертылган сөтне мичкәгә чиләкләп ташыды. Шактый вакыт алды бу. Үзе ташыды, үзенең башында һаман бер уй кайнады: «Нишләп болай соң әле бу, башын алсаң, койрыгы ябыша, койрыгын алсаң, башы ябыша... Былтыр да, быел да әнә үгезләр белән нишләдек?..»

Май заводы яныннан кузгалып киткәч, атын авыл хуҗалыгы идарәсенә таба борды. Кола бия, дилбегәне тарткан саен: «Нишләвең бу, әллә юлны буташтырдыңмы, картлач?» дигәндәй, башын ике-өч тапкыр артка таба борып карады. Юк, картлачка нindидер уй ингән. Әнә аның башы түбән иелгән, юка иреннәрен бөрештергән, ак бәс сарган дай кашлары җыерылган, борын читендәге борчак чаклы миңенең дә төсләре үзгәргән кебек. Кожанының башлыгын да кимәгән. Бүрегенең колакчыннары күтәрелгән. Йөзенә сирпеп салкын яңгыр ява. Аның әнә очы кебек вак тамчылары, кара чалу мыегы очларына җыелып, тамып-тамып төшәләр. Ләкин ул аларның берсен дә сизми. Ара-тирә, бияләен салып, битен сыпырып куя. Менә ул дилбегәне сак кына тартты. Кола бия туктады. Хәсән карт арбадан ипләп кенә төште, дилбегәсен ике катлап ат сыртына ташлады да район авыл хуҗалыгы идарәсенә кереп китте. Кола бия аны күзләре белән озатып калды.

Тиз борылып чыкты Хәсән карт. Барысы да колхозларга таралып беткәннәр. Обком вәкиле килгән дигәннәр иде, шул уңай беләндер инде. Сәгать уннар тулганда дуңгыз фермасына көчкә кайтып житте Хәсән карт. Сөт бушаткан арада ферма өеннән Асыл карт та килеп чыкты. Ул инде өс-башларын алыштырган. Аягында галошы белән пимасы. Өстенә тышлы тун бөркәнгән. Ул күкшәйгән Хәсән картка мыскыллы караш ташлады да ферма өенә кереп китте. Шунда яши ул.

Хәсән карт йөзен чытты, ачу белән Асыл карт артыннан ябылган ишеккә таба йодрык күрсәтте, йөрәге: «Әмма ул да сабынлаган, диме, мин контр булып та синнән әйбәт яшим, диме? У-у! Контр! Сабынламый торсыннар әле!.. Яшисең менә!.. Синең кебек яшәгәнче...» дип үрсәләнде.

Асыл картның саргайган сирәк тешләре, ябалакныкыдай кызыл күзләре, жиз кылгандай очлы сакалы көне буе аның күз алдыннан китмәде.

2

Әйе, бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый, диләр. Хак икән. Хәсән дә, Асыл да Минзәлә елгасы буендагы шушы авылның бер башы текә тауларга барып тоташкан аръяк урамында туып үстеләр. Житмәсә әле, бер урамда, бер очта. Асылның да атасы хәлле кеше түгел иде. Хәсәннәрне инде әйткән дә юк. Асылларның, ни әйтсәң дә, сыерлары бар иде. Ә аларның сыеры кайчан булганны да хәтерләүче юк. Хәсәннең атасы гомер буе Астафий алпавытның Минзәлә елгасына салынган ике ташлы тегермәнендә ясипкәче булып эшләде. Бер генә душ жирләре бар иде. Ул Чишмәле тау астында, Асыллар жире белән ызандаш иде. Аларның да жирләре шул бер душ тирәсеннән артмагандыр. Хәсәннең дә, Асылның да аталары гомер буе дус яшәделәр, чәчү вакытында да, урак өстендә дә бергәләшеп бил бөктеләр. Ике гаилә бер туганнар кебек иде инде менә. Асылның атасы япон сугышында, әллә нинди Маньчжур далаларында ятып калды. Асыл, атасы үлгәннән соң, үзеннән кече өч сеңелесен, күкрәк чире белән кан төкергән анасын тәрбияләү өчен, башын Кәүжиякнең кара бае Габдрахманга тоташтан биш елга сатты. Җәй көне көтү көтте, кышын бай малларын карады. Беренче Герман сугышы чыгасы елны Асылны, ул вакытта инде өрлек

кебек егетне, чана белән китереп ташладылар. Аның карар җире юк иде: кул-аяклары сынган, авызыннан күбекләнеп кан килә. Хәсән үз кулы белән күтәреп кертеп салды Асылны. Шушы кышны аның анасы гүр иясе булды. Җәйгә чыкканда өч сеңелесе дә шешенеп ачка үлделәр. Асыл гына тернәкләнде. Соңыннан сөйләделәр: Асыл анасына да, сеңелләренә дә ризыкка кагылдырмаган. Үрмәләп йөри башлау белән, күрше-күлән, бу мескен бетмәсен, йөрәк ялгасын, аякка басмасмы, ичмаса, дип китергән калган аш-су, каты-котыны үз мендәр астына җыеп ята торган булган.

Габдрахман байның сабан туйларын тоткан юртагын Шәкүр карак шайкасына биреп җибәргән булган икән. Моны сизгәннәр һәм Асылны Габдрахман бай, кое сиртмәсенә бәйләп, үзе өч тапкыр күтәртеп җиргә лапылдатып төшергән...

Шулай да кызганды Хәсән Асылны. Бик өзелгән чакларында, тегермәнгә төшеп, әтисеннән ясипкә оны алып кайтып биргәләде. Асыл әнә шулай сынган сөякләрен җыя алмый ятканда беренче бөтен дөнья сугышы чыкты. Хәсәннең атасын сугышка алдылар. Ул анасы, ике энекәше белән торып калды. Бу вакытта аңа әле яңа уналты яшь тулып килә иде. Ә Асыл аннан ике яшькә олырак. Дөньялар болганган, ана улны, ата кызны белмәгән ул елларда, үзләренең тормышы авыр булуга карамастан, Хәсән Асылны ташламады. Атасы урынында ясипкәче булып эшләү хәл-әхвәл алырга мөмкинлек тудыра иде. Ашлык белән сәүдә итүче кулакларның оннарын чәлгәләштерделәр. Аннан алпавыт Астафий, сугышка дип, казнага дип, җир астындагы амбарларында ничәмә еллар яткан ашлыгын тарттыра башлады. Бер чәкүшкә күрсә күзе майлана торган тегерменче озын Низамины көйләп-җайлап, казна ипиенә дә куллары сузылды. Хәсәннең әвеш-тәвеш китергән шушы ярдәме белән Асыл да тернәкләде: көзгә култык таягы белән урамга чыга башлады, кан йөткерүдән туктады. Әйтерең юк, көч бар иде анда, юкка гына җеннән яралган дими бит аны халык. Бер ялгызы көне-төне өйдә ятуымы, шул ялгызлыкта читтән киңәш-табышсыз килеш үз башына уйлануларымы, ни булса да булды Асылга, нәрсәдер тәэсир итте. Аның күзләрендә нур бетте, маңгае җыерылды, ул кешеләргә ачу белән карый башлады. Хәлен белергә килгән, нәрсә дә булса керткән Хәсәнгә гаҗәпсенеп карап тора иде.

— И Хәсән, Хәсән, дөньяда барлык кешеләр дә синең кебек булсачы!.. Түгел шул, түгел!.. Бу дөньяда кешеләр бер-берсенә бүре, бүре... Үзең ашамасаң, өлгермәсәң, ул барыбер кайчан булса да сине тотып ашаячак. Әләгерсең әле син дә минем кебек, әләгерсең,— дия торган иде. Хәсән аның нур иңә башлаган йөзенә карап тора-тора да болай дия иде:

— Барлык кеше дә бүре булса, син инде әллә кайчан аяк сузган булыр идең. Тегермәндә эшләүчеләр әллә минем сиңа он китергәнне белмиләр дисеңме? Алар фатихасы белән килә сиңа ризык, Асыл абый...

Моңа Асыл кызып китә һәм:

— Тоттыралар фатихаларын учлап — үзең җор булмасаң! Син үзең мотлак! — дип кычкыра аннары.— Ышанма син кешеләргә, Хәсән, Габдрахман бай нишләтте мине? Дүрт ел эшләп, ни бирде ул миңа? Әнкәй белән сеңелкәшләргә ел әйләнәсенә җитәрлек умачлык та бирмәде бит. Ә ел буе мал арасында яшә... Урыным кайда иде минем? Җәен түшәгем — туплау, кышын — бәрәннәр өендәге печән сәндерәсе. Дөньясыннан туеп, ничә тапкыр муенга бау салып караганны беләсеңме син? Менә шундый хәлгә үзең төш тә, аннан минем белән сөйләшерсең. Корбан бәйрәме көнне генә авызга адәм рәтле ризык эләгә. Ә ул бәйрәм елга ничә була? — Асыл андый минутларда аллаларын, гүр такталарын искә ала-ала җиде катлы итеп сүгенә, аннары тагын зарланырга тотына:— Өстә — Габдрахман байның иске-москысы, ике

атнага бер кием чабата, туздырсаң, хет яланаяк йөр, көз-яз бозлавыкларында өч-дүрт көндә туза бит ул чабата. Аякны ыштыр белән урап, киндерә белән бәйләп йөри идем, ышансаң. У-у! Әз генә аякка басыйм, ат өстендә йөри ала башлыйм әле! Габдрахман байның нәселен корытам, бөтен нигезен кара күмер итәм мин аның, менә күрерсең!.. Җайлый башлаган идем дә инде... Әйттем бит мин сиңа кеше кешегә бүре дип, эт адәмгә юлыктым. Ике атын аткарган идем Габдрахман байның, шома киткәннәр иде — көймә килә, эзе юк кебек. Юртакка килгән кеше Габдрахман байны да, мине дә утыртып китте. Юртакны каядыр илтеп урнаштыргач, Габдрахман байга килеп, югалган атларының очын табып бирәм, бер атлык рәт бир дигән. Ике ат, бер юртакны кайтарып, алар урынына бер ат биреп котылмакчы була Габдрахман бай һәм ризалык бирә. Ә теге — Шәкүр карак азгыны — мине дә сата. Габдрахман байның тагын бер атына атланып тая... Тагын ни кирәк? Минем кебек бер йолкыш бит инде ул, ат карагы. Ә үзе — үзе кебек үк җәфа чиккән мине Габдрахман байга сатып китте. Нәрсә бу? Шул, кешенең кешегә бүре булуы! Ярлының байларга бүре кебек каравы аңлашылсын да ди инде, ә монда бит үз братың баш ашый...

Шундый чакларда Асылның борын элпәләре кабарып-кабарып китә, күзләрен кан баса, ярсудан һәм ачудан ул тешләрен шыгырдатып куя.

Кыш чыгуга Асыл аякка басты, култык таякларын ташлап, чатанлап кәкре башлы таяк белән йөри башлады. Малай вакытта башкалардан бер ягы белән дә аерылмаган Асылның гүя каны алмашынды. Ул үзеннән көчсезләрне адым саен кыерсытты, алардан көлде. Хәлле кешеләрне, байларны күрү белән күзләрен кан баса иде. Хәсән ул чакта ук сизенде: Асыл төннәрен йокламый иде. Берничә тапкыр аның ишегенә сугылып карады Хәсән. Ләкин ул йозаклы була иде. Кичке уеннарда, аулак өйләрдә дә күренмәде Асыл. Әмма тирә-як авылларда бер-бер артлы шомлы хәбәрләр таралды: я байларның ындыр артындагы кибәннәре яна, я иң яхшы айгырлар, юртакларга кызыл камыт кигерелә. Шул елны алар авылындагы иң зур бай Нәбиулла Хаҗиларының да сабан туйга дип хәзерләнгән чаптарларын лапас өрлегенә асып суеп чыктылар. Асыл... шуның эше иде бу.

1917 елның март башларында авылда колактан-колакка адәм ышанмаслык сүзләр таралды:

— Патшаны төшергәннәр икән...

— Үзебезнең мөселманнардан Корылтай дәүләте төзелә, имеш...

— Байларның, башкортларның җирләрен алалар, ди...

Бу сүзне курыкмыйча кычкырып әйтүчеләр дә табыла башлады.

Җепшек кар явып торган бер көнне Астафий тегермәне янына бөтен авыл халкы җыелды. Астыртын гына йөргән Аманаев хәлфә шунда бөтен халык алдында патшаның тәхеттән ваз кичүен белдерде, әллә нинди учредительныйлар турында сөйләде, шуның фәрманы булмыйча җир-суга, байларның мал-мөлкәтенә кагылырга кушмады. Шул чак чәчрәп Асыл килеп чыкты, лар өстендә халыкны авызына каратып сайраучы хәлфәне җилән итәгеннән сөйрәп төшерде, үзе аның урынына менеп басты һәм тамак төбеннән гөбердәп чыккан калын, көчле тавыш белән кычкырды:

— Җәмәгать! Бу козгын сөйләгәнгә ярхәмикә алла дип торасызмы? Сөйләр ул, кем хисабына яшәсә, шулар җырын җырлар ул.— Асыл, теткәләнеп беткән тунының изүләрен ачып, бүреген бер салды, бер киде, күзләреннән ут чәчеп, тагын акырып җибәрде:— Мине, егерме яшьлек егетне, кем тере гарип ясады? Кәүҗиякнең кара башкорты, бае — Габдрахман, безнең авыл Нәбиулла Хаҗилары! Кан түкерүдән әле кайчан гына туктадым мин? Патша төшеп, үзебезгә слабуда булгач та шуларга түзеп торыйкмы? Ишетсеннәр ул кабахәтләр! Нәселләрен

корытмасам, исемем Асыл булмасын! Минем яклылар, җыен таралгач та безгә чыгабыз. Шунда киңәшербез нишләргәсен!..

Ул, шулай дип, лар өстеннән сикереп төште. Ризатдин староста сүз алды:

— Җәмагать, Асыл — иблис авызы белән сөйли, аның сүзенә берүк колак сала күрмәгез. Соңыннан әллә ниләр күрербез. Сабанга төшкәнче тыныч кына көтик. Аннары берәр җае чыгар әле.— Ул шулай дигән генә иде, авылның башкисәр Морат старостага күсәк белән тондырды. Староста, ауган көлтә кебек, җиргә мәтәлде. Китте гауга, китте шау-шу. Җыенның рәте чуалды. Асыл староста утырып килгән чанага менеп басты да карлыккан тавышы белән тагын:

— Кемнәр минем яклы, әйдәгез! — дип акырды.

Чанага жиде-сигез кеше менеп басты. Алар арасында Морат та бар иде. Моны күреп халык тәшвишкә төште. Асылы гына бер хәл, ә Морат белән икесе, бу инде — авыл өстенә иңгән фаҗига. Икесе дә башкисәр, авызыңны чамалап ачмасаң, итәгеңне җыеп йөрмәсәң — фани дөньяларга кулыңны селтә дигән сүз.

Халык җыеннан таралды, Хәсән кайтышлый Асылга сугылды. Ул килеп кергәндә ишегалдында казык башына бәйләнгән өч ат, старостаның үрәчәле чанага жиккән юртагы тора иде. Өч тәрәзәле бәләкәй генә өйнең ишеген ачып керүгә, сүгенгән тавышлар яңгырады. Асыл белән Морат бәхәсләшәләр. Өстәлгә ике сугым пычагы кадап куелган. Асыл авызыннан төкерекләр чәчеп жикеренә:

— Иң элек Кәүҗияккә барабыз. Габдрахман байның үзен, бөтен малларын суябыз!.. Мин әйткән сүз закон түгелмени сиңа?..

— Кеше суярга син мине кем дип беләсең?.. Малларын суеп-кырып бетерәбез, анысына риза...

— Алайса, син минем шайка түгел, сыпырт... Үзеңне шушында суймас борын!

Асыл кан баскан күзләре белән өстәлдәге пычакка үрелде. Морат шунда ук аның беләгеннән эләктереп алды, пычак идәнгә төшеп кадалды. Асыл, ыңгырашып, тешләрен шыгырдатты. Бер кулы белән өстәлдәге стаканга үрелде һәм алып эчеп тә җибәрде. Өйдәгеләр барысы да исерек иде. Тик Морат кына әле акылында кебек күренә. Хәсәнне башлап ул күрде. Авызын ерып аңа дәште:

— Безнең шайкагамы? Әйдә, төшереп ал, Нәбиулла Хаҗие кабагында аракы житәрлек, тагын апкайтырбыз,— диде. Күпме каршы килеп караса да, Морат ай-вайга куймады, бер йомрыны эчертеп бетерде. Аракы җылысы бөтен тәненә таралгач, Хәсәннең дә каны уйный башлады. Житмәсә, Асыл аның йөрәгенә чәнчеп әйтеп ташламасынмы:

— Маңкасы кипмәгән малайлар белән ни кыласың, алмыйм мин аны шайкага...

— Синең шайкага кушылмыйм да мин.

— Кушылырыең да, куркак бит син, куян йөрәк!

— Кем, минме?

— Кит моннан, инәңне эт яламаган нәрсә!..

Хәсән үзе дә сизмәстән Асылга салып җибәрде. Асыл тәрәзә янагына килеп сыланды. Куәте барын сизә иде Хәсән, ләкин Асыл хәтле Асылга беркайчан да кул күтәрер кебек тоймый иде ул үзен. Дөрес — шүрли иде. Шул бер йомры аракы женен кузгатты да куйды бит. Асыл өстәлдә кадалып торган икенче сугым пычагына үрелде. Ләкин бу юлы да Морат алдан житеште — пычакны бәреп төшерде. Егетләр түшәмнәрне дер селкетеп көлделәр.

— Ха-ха! Атаманга эләкте дә соң!..

Асыл көлмәген урталай аерып төшерде, үзен шытырдатып тоткан Мораттан ычкынырга теләп, Хәсән өстенә омтылды. Ләкин Моратның тимер кыршау кебек кулларына моңа кадәр авылда гына түгел, тирә-

юньдә дә чыдаучы кеше юк иде. Ул, Асылны тынычландырырга теләп, юмалый башлады:

— Әйдә, атаман буласың килсә, тышка чыгабыз да хәрәмдәшсез көрәшәбез. Мин көрәшмим. Кем җиңә — шул атаман була.

Бу сүзләр Асылның иң авырткан җиренә тиде һәм ул ишеккә карап кычкырды:

— Әйдәгез!..

Өерелеп өйдән чыктылар. Көрәш башланды. Асыл да куәтле иде шул. Барысын да, Хәсәнне дә хәрәмдәшсез лапылдатып сыртына салды. Теләсә-теләмәсәләр дә, Асылны атаман итеп сайладылар. Морат, үзе теләп, күзләрен кыса-кыса, Асылның уң кулы булды. Хәсән Асыл шайкасына әнә шулай килеп эләкте.

Икенче көнне алар, уникe егет, ат менеп, Кәүҗияккә киттеләр. Ярты төн авышканчы Иске Әлмәт каенлыгында көтеп тордылар. Әтәчләр кычкыра башлагач, дәррәү кузгалдылар. Кәүҗияккә ындыр артлатып, озын бер тыкрыктан килеп керделәр. Габдрахман бай ихатасын урап алдылар. Асыл биек таш койма өстеннән ишегалдына төште, капка бастырыкларын тавыш-тынсыз гына ычкындырды. Тәрәзә яннарына сак куйды һәм ишек кага башлады. Күп тә үтмәде, өйалдыннан саңгырау тавыш ишетелде:

— Кем йөри анда җиде төн уртасында?..

Габдрахманның туксан тугызлырак малае иде бу.

— Ач, Мөхәммәтҗан! Асыл бу. Җаныгызны алырга килдем!

Җавап бирүче булмады, шартлап өй ишеге келәләре бикләнде. Асыл егетләргә әмер бирде:

— Бер малны да калдырмый суярга!

Сугым пычагы белән коралланган егетләр лапасларга, сарайларга ташландылар. Ишегалдында җан ачысы белән өзгәләнеп сыер мөгрәгән, ат кешнәгән, сарык бәэлдәгән авазлар яңгырады. Кайсы чалынган, кайсы кадалган мал белән ишегалды тулды. Бугазыннан, күкрәгеннән кан сиптереп торган күзләре аларган атлар әле анда, әле монда килеп сугыла, гөрселдәп җиргә авалар. Ап-ак кар өсләре алсу канга буялып бетте. Бу кыяматкә Габдрахман бай күршеләре дә уянды, аннан да, моннан да кешеләр килеп чыга башлады. Ләкин алар Габдрахман байны яклап бер кәлимә сүз әйтмәде.

Анда-санда чапаланып, бугазыннан кан бөркеп, гыжылдап яткан сыер һәм атлардан тирә-якка бөркелгән кан исе иң беренче Хәсәнне аңына китерде. Ул башын тотты, әле Асыл, әле Морат янына барып: «Нишлибез без, бу малкайларның ни гаебе бар, китик, качыйк бу галәмәттән. Мал хакы тотачак бит безне, аңлыйсызмы шуны, башкисәрләр!» — дип ялварды. Ләкин аның сүзенә, Мораттан башка, колак салучы булмады.

Абзар тулы малларын суеп бетергәч, Асыл Габдрахман бай йортының олы тәрәзәләрен каяндыр кулына эләккән тәртә белән кырып чыкты. Аннары, ишек төбенә ике-өч кочак салам китереп ташлап, шуңа ут төртте. Бусына кәүҗиякләр дә түзмәде.

— Сез нәрсә, әллә бер Габдрахман гына янар дип уйлыйсызмы, бөтен авылга үрләсә? Ут белән шаярмагыз! — дип, өйалдының буялган нарат такталарын ялмый башлаган утны шундук сүндерделәр.

Асыллар шайкасы авылдан чыгып чапты. Кайтканда Нәбиулла Хаҗиеның кабагын бастылар. Пәси картның кибәннәренә дә ут төртмәкче булганнар иде, Морат белән Хәсән каршы килгәч, бу уйларыннан кайттылар.

Ике атна буе бөтен волостьны, аның тирәләрен, байларны, муллаларны дер селкетеп, үз кулында тотты Асыл башкисәрләре. Ә бер көн таң белән аларның барысының да кулларына богау салдылар. Ризатдин староста Минзәләгә, өяз шәһәренә хәбәр иткән. Уникe кешене

баштанаяк коралланган алты атлы казак берәм-берәм богаулап чыкты. Барысын да Минзәлә төрмәсенә илтеп яптылар. Аларга әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән анархист, бунтовщик дигән исемнәр тагып бетерделәр. Хәсән хәтерли әле: патша төшерелгән булса да, алардан сорау алучы следователь кабинетында Николай икенченең алтынланган рам эчендә сурәте тора иде. Җәй урталарына кадәр изаладылар аларны. Арыш урагына төшәр көннәрне аларны, этап белән, сугышка озаттылар. Юлда Асыл белән Морат качты. Әнә шуннан юллары аерылды аларның. Хәсән Казан гарнизонында калды. Авылдашларының кайсын кая озатып бетерделәр. Шушы гарнизонда чакта ул башлап Ленин исемен, большевиклар партиясе — Ленин партиясе икәнен ишетте. Шушы гарнизонда аны укырга-язарга өйрәттеләр. Солдатлар арасында ыгы-зыгы чак. Ләкин солдат солдат инде ул. Күбесе, Хәсән кебек, авыл гыйбады, томана. Әмма көн-төн бара торган солдат җыелышлары аларның да күзләрен ача барды. Октябрь революциясе көннәрендә Хәсән өчен кем ягында көрәшергә? дигән сорау юк иде инде. Ул беренчеләрдән булып Дворяннар йортына бәреп керде. Казан Кремлен азат итүдә катнашты. Аннары беренче татар полкы белән нинди генә юллар, ут-давыллар аша үтмәде ул!.. Алары үзе бер гомер, үзе бер язылмаган китап.

3

Асылның иңенә җылы тунын салып, кукрайган әтәч кебек басып торуы гына яңартты бу истәлекләрне. «Шул контр, шул иблис синнән көлсен әле, синнән генә түгел, эшләгән эшеңнән көлсен... Ни ди бит, «күкәй тәгәрәтешле уйныйлар» ди бит, ә! Ул куана, рәхәтләнеп көлә инде моннан. Юк, көлми тор әле!» Тамак ялгарга кайтканда да ул һаман Асылны сүкте, аның белән бәхәсләште.

Өстәлдә җырлап торган самавары белән каршы алды карчыгы Хәсәнне. Өй җылы, репродуктордан соңгы хәбәрләр тапшыралар. Хәсән итеген салып куйды да, барып, репродукторның тавышын көчәйтте. Чөнки бу бер-ике ел эчендә колагы катыланып китте аның. Өстен сала-сала, радиодан агылган сүзләрне тыңлады.

«Америка империалистлары Көньяк Вьетнамны бомбага тота башладылар. Алар җирле халыкны аяусыз кыралар». Хәсәннең йөзе кырысланды. Чәй янында да ул телен тибрәтеп бер сүз әйтмәде. Тамак ялгагач, башын бераз мендәргә төртеп тора торган иде. Бүген мич буендагы диванга таба да карамады, чынаягын каплап кую белән, чөйгә үрелде. Карчыгы — бөтерчек кебек кенә Әсма — өстәл янында чәйләгән килеш, сорап куйды:

— Әллә пермагызда берәр хәл бармы, ятып та тормадың?

— Югын юк... Корыны бушка әйләндерә башладылар. Парткомны күреп сөйләшми булмый. Фермага төшкәнче идарәгә сугылып чыгам әле.

Хәсән куян бүреген батырып киде дә чыгып китте. Һава салкынайтып җибәргән, йөзгә кадалып-кадалып вак кар сибәли. Хәсән кожанының башлыгын күтәрде дә, Ярык тау башына эленеп-эленеп киткән аксыл болытларга күз сала-сала, колхоз идарәсенә таба атлады. Ул килеп кергәндә баш бухгалтер үзе генә счет төймәләре тартып утыра иде. Хәсәнне күрү белән ул исәпләвеннән туктады һәм:

— Хуш, Хәсән абый, нинди җилләр ташлады? — дип сорады.

Хәсән урындыкка иплән кенә утырды, кожан башлыгын арткарак шуыштырды, чалу мыегын сыпырып куйды, аннары, күзләрен кыса төшеп, бухгалтерга дәште:

— Син миңа шуны әйт әле, туган: күрше «Үрнәк» колхозына ничә күкәй озаттыгыз?

Бухгалтерның йөзенә елмаю чаткылары чыкты.

— Ә сиңа нигә кирәк ул, Хәсән абзыкай?

— Төлке балакай, нигә кирәген сораштырып торма, тәгаенен генә әйт син миңа.

— Дөп-дөресенме?

— Әйе.

— Дөп-дөресе, Хәсән абзыкаем, шул: үзебез бүген алар өчен тапшырдык 12 мең 500, үзләре эшләп апкиткәннәр иде 17 меңне. Тәк, синеңчә итеп җәмигысе дисәк, була ул, Хәсән абзыкаем, 29 мең дә 500 данә йомырка! Справка-мазар язып торыйммы, юкмы, әллә болай да ышанасыңмы?

— Ярар, кәмитләнмә, значит, 30 меңләп?

— Так точно, Хәсән абзыкаем...

— Син Җәүдәтне күрмәдеңме?

— Бераз черем итеп алам да дуңгыз фермасына төшәм дигән иде.

Хәсән карт урыныннан кузгалды. Авызын ерып утырган бухгалтер егеткә бармак янады да чыгып китте. Өйләнмәгән яшь егет әле аларның бухгалтеры. Чибәр хатын-кызларга сагыз кебек сылана торган гадәте бар. Бер көн шулай ферма өенә килеп кергән иде, ял итә торган бүлмәдә бер кыз чырык-чырык килә, үзе: «Нух, дим, нишләвең бу, кит, валлаһи, кычкырам, адәм көлкесенә калдырам...» ди. Бухгалтерның ялварган тавышы да ишетелә: «Я, нигә кәҗәләнәсең, иртәгә үк загска барырбыз, бүген ни, иртәгә ни, беләсең бит, синнән башка берәү дә кирәк түгел миңа», ди. Шул чак кыз чырылдап кычкырмасынмы! Хәсән бүлмә ишеген ачты. Нух кызны караватка еккан иде. Хәсән бухгалтерның арт санына китереп типте... Нух сискәнеп китте, беравык майлы күзләрен ялтыратып карап торды да ишеккә ташланды, Хәсән аңа бармак янап калды. Бозаулар караучы яшь кенә кыз, борынын мышык-мышык тартып, бер сүз дә дәшми ишеккә юнәлде. Баш бухгалтер Хәсән картның бармак янап нигә ишарәләгәнен яхшы белә, шуңа, Хәсән абыйсы күренсә, авызын ерып кына тора.

Хәсән колхоз идарәсеннән өенә туры кайтып атын җикте дә фермага китте. Күренеп торган әллә ни эше дә юк иде, килүе, башын мендәргә төртеп тормавы ярап куйды бит. Азык эшкәртү цехында фермаларга чүпрә кудыру насосы ватылган. Савымчылар көянтә-чиләк белән чүпрә ташый иде. Хәсән картны күрү белән алар куанычларыннан кычкырып җибәрделәр.

— Гомерләрең озын була икән, Хәсән абый! Их, Хәсән абый иртәрәк килсә иде, дип кенә тора идек.

— Амин, сезнең хәер-фатиха белән, яшәгән хәтле тагын яшәсәм, үлсәм дә үкенмәс идем.

— Яшә, яшә, Хәсән абый, синең кебекләргә җәл түгел! Арбасына тимер мичкә салып, ул азык эшкәртү цехына килде. Чүпрә чанының запас кранына шланг ялгап мичкәне тутырды, аннары фермага юл тотты. Шулай дүрт-биш әйләнгәч, инде авыл өстендә, ферма ихатасындагы баганаларда электр утлары гөлтләп кабынганда, колхозның партком секретаре Җәүдәт Гайфетдинов та килеп җитте. Аны күрү белән Хәсән күңелендә Асыл картның «күкәй тәгәрәтешле уйныйлар» дигән мәсхәрәле, төрттереп әйткән сүзләре кабаттан яңарды. Ул тарантасыннан төшүче бәләкәй генә гәүдәле, кем әйтмешли, бер уч йөзенә җиңелчә генә шадралар йөгергән Гайфетдиновка бер мәл текәлеп карап торды, башыннан яшен тизлегендә уйлар йөгереп үтте. Күптән белә иде ул Җәүдәтне. Сугыштан күкрәк тулы медаль тагып кайтты ул. Бик җор, җиңел гәүдәле егет иде.

Җәүдәт атын утар баганасына бәйләп куйды да туп-туры Хәсән карт янына килде. Ике кулын биреп күреште һәм:

— Хәлләр ничек, Хәсән абзый, кәеф-шәрифләр? — диде.

— Ару, Җәүдәт туган.
— Нишләп чиләкләп, мичкә белән ташыйсыз?
— Насос ватылган диме...
— Бусы шәп түгел, менә чилән хәзер. Күпме кеше интегә.
Ул шулай дип цех эченә кереп китте. Насосны төзәтүче механиктан эшнең кай тирәдәрәк баруын белеште дә, «кичкә беткәч, ярый, техника ремонтсыз тора алмый инде ул, кешегә дә ремонт кирәк», дип сөйләнә-сөйләнә кире чыкты. Шул чак, саз ерып, үгезләр симертүче Харис килеп житте. Аның сипкел баскан йөзе ачулы, аксыл кашында ләйсән кебек вак яңгыр бөртекләре елтырый иде.
— Җәүдәт абый,— диде ул килә-килешкә,— сыртлары икегә ярылды бит инде үгезләрнең, нигә җибәрмисез аларны?
— Кайсы үгезләрне, Харис туган?
— Кайсы дип, без карый торган...
— Алар — НЗ, туган.
— Анысы ни була тагын?
— Киләсе елга тапшырабыз аларны.
— Ә без нишләргә тиеш хәзер?
— Шуларны карый торасыз инде, Харис туган.
— Ә ник хәзер тапшырмыйбыз, дүртәр центнер тарта бит алар?
— Фәрман шундый, Харис туган.
— Бу бит дөрес түгел...
— Әллә сул ягың белән тордыңмы син бүген, Харис туган, нигә кызасың? Әйдә, иплән кенә, тәмле тел генә сөйләшик, аңлашыйк.
— Кызарсың, хәзер мин икенче группа алырга тиеш. Үпкәләштән булмасын, симертелгән үгезләрне куам да чыгарам, теләсә кая куегыз!
— Кызма әле син, Харис туган...
Харис дәшмәде, кырт кына борылды да кулын селтәп китеп барды.
Хәсән карт бу чәкәләшүне игътибар белән тыңлап торды. Харис күздән югалу белән, Җәүдәт янына килде, тамагын кырып куйды да:
— Иптәш Гайфетдинов, бераз сөйләшәсе сүз бар иде,— диде.
Җәүдәт аңа таба ялт итеп борылды.
— Сөйлә, Хәсән абзый, тыңлыйм, нәрсә бар?
— Харисның сүзендә дөреслек ярылып ята бит, бу ни дигән сүз?
— Мин, Хәсән абый, синең кебек, кушканны эшлим.
— Юк, андый түгел син. Аннары үземне дә андый кешеләр рәтендә санамыйм мин. Кешеләр безгә карап яшиләр, эшлиләр.
— Соң, яшәсеннәр, син дә, мин дә начарлыкка өлге түгел бит.
— Син вопроска якынрак кил әле, үзең әйтмешли. Дөреслек турында сүз бара монда. Дөреслек! Аннан читкә тайпылырга безнең хакыбыз юк. Шифалы су кебек бит ул безнең өчен. Шуны эчүдән туктасак, көт тә тор, җегәрсезләнәбез без.
— Аңлыйм, бик тә аңлыйм, Хәсән абзый. Соң мин нишлим, бирүзем?
— Бирүзең түгел син. Мине, Харисларны кая куясың? Харис та синең, минем кебек партия әгъзасы. Билетларыбыз бер төсле бит безнең.
— Агымга каршы йөзеп кара син!..
— Хакыйкать хакына йөзәргә дә кирәк.
— Соң бит, Хәсән абый, күрсәтмә шундый булгач...
— Ә син ул күрсәтмәләрне күңелең аша үткәр.
— Минемчә, Хәсән абзый, кушкан нәрсә — безгә закон.
Хәсән чалу мыегын кул сырты белән сыпырды, тагын тамагын кырды һәм:
— Кайчак менә партиянең безнең ише карт солдаты сүзенә дә колак салу комачауламас иде сиңа, Җәүдәт туган.

Аягына суык керә башлады бугай, Җәүдәт бер урында тыпырдап алды һәм зәңгәр күзләрен Хәсән картка төбәде.

— Кемгә, кемгә, синең сүзеңә колак салмасам, мине аяз көнне яшен сугар иде, Хәсән абзый.

— Шулай булгач, нигә бу кәмит?

— Нинди кәмит тагын?

— Үгезләрне тапшырмый тору, күкәй тәгәрәтешле уйнау? Аңла, Асыл булып Асыл көлә хәзер бездән.

— Ул контр тагын ни дип тешен ыржайта?

— «Әзлә дөреслекне, табарсың, тоттырыр койрыгын, ләкин ул да сабынлаган», ди. Шул, сезнең күкәй тәгәрәтешле уйнаудан рәхәтләнеп көлә. Тапкансыз тапшыртыр кешесен дә.

— Менә бусын мин белмим, Хәсән абый. Нинди күкәй тәгәрәтешле ул тагын?

— Күрше «Үрнәк» колхозы өчен тапшырабыз икән бит күкәй.

— Тапшырмаска дип, яңа елга чаклы сакларга, аннан соң гына тапшырырга дип килешкән идек бит без председатель белән. Юк, иптәш Ганиев моны әйтмәде миңа... Акчасын безгә күчерәләрдер аның, акчасы кергәч...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, Хәсән карт аны бүлдерде:

— Асыл кебек өстәп тә җибәр, бер-береңә ярдәмләшергә кирәк бит, дип тә әйт.

— Көлмә әле, Хәсән абзый, бу андый ярдәмләшүгә керми.

— Керми шул.

— Соң нишләргә?

— Председатель яшь, мондый юлга этәрмәскә кирәк аны, иплэп сөйләш, аңлат.

— Үзебезнең күкәй планы үтәлгәч дигәндер инде ул, аннары, «Үрнәк» председателе белән әшнәләр дә бит алар.

— Ә үгезләрне ник тапшырмыйбыз?

— Район ит планын үтәде, сезне киләсе ел резервына калдырабыз, диделәр.

Хәсән картка шул җитә калды, ул ашыгып сорау бирде:

— Кайда, кем?

— Хәзерләүләр инспекциясендә. Киләсе еллык планны да арттырып үтәрсез. Артык саткан һәр центнер өчен 50 процент өстәмә килер. Иттән быел кереп бетмәгән акча киләсе елда колхоз кассасына артыгы белән керәчәк, диделәр.

Хәсән карт көрсенеп куйды, күзләре уйчанланды.

«Кемнәр генә акыл сатмый»,— дип пышылдады аның иреннәре. Хәсәнне борчыган, күңелен усак корты кебек кимереп торган уйлар җебенең очы ничек еракка сузылган булып чыкты бит әле.

Җәүдәт Гайфетдинов икенче фермаларга таба китеп барды.

Хәсән карт исә икенче көнне үк райкомга барырга ниятләде. Күңелдә туган уйларын, сорауларын сөйләргә булды. Ни дисәң дә үзенең кордашы Моратның олы малае — Вәдүт бит анда беренче секретарь. Барып баш орыр изге урын менә нинди! Вәдүт атасына охшаган — күп сөйләшмәс, әйткәне булыр. Килеше-торышы, буй-сыннары да нәкъ Морат мәрхүмнекедәй. Суйган да каплаган инде: шундый ук киң җилкәле, бит очлары алсуланып тора, маңгайга таба сузылган кара киртләч кашлы.

4

Морат белән бер елны кайттылар алар сугыштан. Коточкыч авыр елны. Нишләргә белми тинтерәп утырган кичне аларга Морат килеп керде. Башта Хәсән үз күзенә үзе ышанмыйча торды. Аннары башы

белән түшәм терәп торган Моратны кочаклап алды. Морат та аны күкрәгенә кысты.

— Исән булгач, менә без дә әйләнеп кайттык бит,— диде ул, тирән уфтанып.

— Кайтмаган булсак, мондый мәхшәрне күз күрмәс иде,— диде Хәсән, Моратны түр сәкегә утырырга кыстый-кыстый. Морат баштанаяк хәрби киемнән иде. Ул сәкегә килеп утырды, башындагы малахаен салып тез өстенә куйды.

— Я, нишләп ятасыз, сезнекеләр барсы да аманмы? — дип сорады.

Хәсән сәке түрендә йокымсырап яткан анасына таба башы белән ымлады.

— Әнкәй авыр хәлдә, өйдә сыңар күзгә сибәрлек он заты юк, сенелкәшләр тегермәнгә, борчак оны җыярга киткәннәр иде әле, Низами карт килсеннәр дигән иде.

— Да-а! — Морат шулай дип сузды, авыр итеп көрсенде.

— Авылның хәле мөшкел, Морат. Асыл ниләр генә кыланмаган. Шул бит монда ярлылар комитеты рәисе. Сөйләшеп караган идем. «Совет власте ошамыймыни сиңа, тагын Минзәлә бастругында кандала симертәсең киләмени?..» дип өскә ыжгырып килә. Бер кулы кабурада...

Беравык икесе дә тын калдылар, ләкин икесе дә бер нәрсәне — Асылның кылган этлекләре турында уйлады алар.

...Асыл Минзәлә төрмәсеннән сугышка озатылганда юлда кача да, төрле шәһәрләрдә ары-бире сугылып йөргәннән соң, 1918 елның башында авылга кайта. Волость оешып, Ризатдин старостаның кирәге бетеп, авылда Совет власте урнашкач, ул авыл активлары тирәсендә чуала башлый. Ак чехлар бу яктан узганда таш базларында яшеренеп ята. Чехлар ярлылар комитеты председателен аталар. Алар чигенгәч, Асыл качып яткан җиреннән чыга да, күп уйлап тормый, комитетны үз кулына ала. Башта ярлылар комитеты членнары моңа каршы килеп тә карыйлар. Ләкин ул каяндыр чәлдергән алтатарын өстәлгә чыгарып сала да сәркәтипкә әйтә:

— Яз, барлык бедком членнары рәис итеп бертавыштан Асыл Сәлимгәрәевне сайладылар диген.

Сәркәтип язган. Асыл барлык комитет членнарының имзаларын салдырткан. Башта ул бу язуны Мәхмүри муллага укыткан, аннан соң гына волкомга барган. Анда, барлык членнар кул куйган булгач, ышанганнар, күрәсең. Шулай итеп, бөтен авылны кулга ала Асыл ул елны.

Шулай да бер изгелек эшли Асыл ул чакны. Колчак яулары авылга якынлашу белән ул Мәхмүри муллага килә һәм, алтатарын аның маңгаена терәп, болай ди:

— Мин синдә яшеренеп ятарга тиеш, әгәр ул-бу сөйләр булсаң, иң беренче итеп яшь остабикәңнең маңгаена кургаш коям. Оста́бикәң даим минут минем янда торыр, әлбиттә, көндезен. Төнлә үзең теләсәң нишлә.

Мулла кәфендәй булып агара һәм, белгәннәрен укый-укый:

— Мелла, Асыл, берүк кан коя күрмә, иманлы авызым белән әйтәм, бер кәлимә сүз чыкмас,— ди. Хак та, мулла беркемгә дә аны-моны сиздерми. Остабикәсеннән колак кагасы килмәгәндер, күрәсең. Чибәр иде мулланың остабикәсе, яшь иде. Хәзер дә Асыл, җае туры килгәндә, мактанып ала әле. «Гел иләнде бит остабикәң Асылга. Көне буе сыйхөрмәттә ятам. Ачы балына чаклы табып китерә. Чыгарып та йөртә башладым тегене. Нәбиулла кабагыннан хәмеренә чаклы кайтарттым. Ашау байдан, хатын мулладан, үлем ходайдан дип чаршау артында чуалганда мулла абзаң кайтып кермәсенме? Сизенгән бит бәлеш козгыны. Өскә ыжгырып килә бу. Алтатарны чыгарып маңгаена гына терәдем, тәһарәте сынды мулланың. Кыйблага карап тәкбир әйтә

башлады»,— дип сөйли. Асыл авылда ни барын, акларның нәрсә эшләүләрен муллага мәчеткә килгән картлардан сораштырырга куша. Тегесе кайтып сөйләп тора. Бер көнне мулла мондый хәбәр җиткерә: авылдан унсигез егетне көчләп Колчакка солдат итеп алалар, барсын да каравыл өенә ябып куйганнар инде. Саклап ике солдат тора. Калганнары хәзер Нәбиулла Хаҗие кабагында сәрхүшләнеп беткәннәр, ди.

Асыл күп уйлап тормый, «мин хәзер борылырмын, чамала, ишек ачмасаң...» дип янап чыгып та китә. Таш койма кырыйларына сыенасыена, кешеләрнең ишегаллары аша ул башта кабакка бара. Анда исерек солдатларны күзәтеп тора. Алар күп, кабак эче тулы. Асыл, үрмәләп, кабак ишеге төбенә җитә, тимер ишекләрдәге йозакларны иплән кенә ала да башта ишекнең бер ягын әкрен генә яба, эчтә ул-бу сизмиләр, аннары икенчесен шартлатып яба да йозакны элә, аскы һәм өске бикне дә элэктереп куя. Кабакның тәрәзәсе берәү генә. Колчак солдатлары, үзләренең капкынга эләккәннәрен сизеп, тәрәзәдән урамга ата башлыйлар. Моны каравыл өе янындагы солдатлар да ишетә һәм аларның берсе тавыш килгән якка йөгерә. Асыл исә таш койма янында ятып кала. Солдат узып китү белән Асыл, ермак буйлап шуышып, өй почмагына кадәр килә. Хәвефкә төшкән солдат, мылтыгын кулына тоткан килеш, ишек янында тыз-быз йөренә. Нишләргә белми Асыл, кулы белән як-ягын кармалый. Шунда кулына бала башы чаклы таш тиеп китә. Ул аны иплән кенә ала да тагын алга шуыша. Сакта торучы солдат арты белән борылуга, тегеңә таш белән тондыра. Солдат, үкереп, җиргә ава, ләкин мылтыгының чакмасына басарга өлгерә — кара пәрдә ябынган авыл өстендә тагын мылтыктан аткан тавыш яңгырый. Асыл сикереп тора, солдатның мылтыгын тартып ала һәм шуның түтәсе белән ишекнең йозагын бәреп төшерә. Каравыл өендәгеләр, куркынып, почмакларга посалар, тавыш-тын килми. Асыл ярым пышылдап аларга дәшә:

— Чукынышып беттегезме әллә, чыгыгыз!..

Аның тавышын шунда ук таныйлар.

— Асыл!

— Синме бу, Асыл?..

Куанычларыннан нишләргә белмәгән авылдашлары ишеккә ябырыла. Монда да башы эшли Асылның:

— Хәзер чуплэп бетерәчәкләр сезне, әйдәгез минем арттан,— ди ул. Аларны Мәхмүри мулла өенә алып кайта. Кайсын мунчага, кайсын базга яшерә. Мәхмүри мулла өнсез кала, теле бәйләнә. Асыл аның алдында, алтатарын болгый-болгый, болай ди:

— Капкага кагылучы булса, үзең чыгасың, берәүне дә кертмисең. Мин артыңнан карап торам, әгәр серне ачсаң, миеңне чәчрәтеп чыгарам шушының белән,— ди.

Кабакка бикләнгән солдатлар тәрәзәнең тимер рәшәткәсен каерып чыгалар. Нәбиулла Хаҗиенда типтерүче офицерларга хәбәр итәләр. Бөтен авылда тентү китә. Йорттан йортка йөриләр. Ризатдин староста озата йөри аларны. Мәхмүри муллага да сугылалар. Ризатдинның соравына ул ышандырып җавап бирә:

— Диндарларны яшереп ятарга кем дип беләсең син мине? Башлары аяк асларына килгәннәрен күрергә насыйп итсен иде шуларның, миннән хәер-фатиха шул, Ризатдин,— ди.

Солдатлар борылып чыгып китә. Мәхмүри мулла капкаларны үзе бикли.

Каравыл өеннән качучыларны күпме эзләсәләр дә, таба алмыйлар. Ике көннән аклар авылдан чыгып китә. Егетләр дә хәзрәт өендә ябылып ятудан котылалар. Әнә нинди ягы да бар бит аның — Асылның. Каны әле бер, әле икенче якка ага торган адәм шул.

Ачлык ел башлангач, тагын ни кыланганын белми башлый ул. Ярлылар комитеты карамагына кайткан азык-төлекне күбрәк ир-атларга, хәллерәк хатын-кызларга бирдерә.

— Совет властеның терәге алар, аларны сакларга кирәк,— ди.

Авыл өстенә иңгән бу афәттән ничек котылырга белми гажизләнә халык. Ахыр чиктә, егәрлерәк үсмер егетләр сүз берләшәләр, бер караңгы төндә аны сагалап торалар да Минзәлә елгасы аша салынган күпердән чыкканда суга төртеп төшерәләр. Язгы ташу вакыты була бу. Әрсез җан булгандыр инде, котырып аккан язгы ташу да аның җанын ала алмый. Бер борылмада көчле агым аны ярга чыгарып ташлый. Асыл мүкәләп өенә кайта. Тик бу һөҗүмнән соң ул бераз басыла төшә. «Мин бит Совет власте вәкиле, ул куйган кеше, миңа ник кул күтәрәләр алар? Исән калган кешеләр өчен, исән калырдай кешеләр өчен тырышып йөрим лә мин. Неужели шуны аңламыйлар алар?» — ди.

## 5

Хәсән белән Морат авылга кайтканда Асылның авылда әнә шулай баш та, түш тә булып яшәгән чагы иде.

Морат авызын ачып иснәде, куен кесәсеннән бер ярты чыгарды.

— Күчтәнәчне авыз итик,— диде, шешәсен өстәлгә куеп. Хәсән уйга калды. Өйдә шуны эчкәч борын тидереп иснәрлек тә ризык юклыкка офтанып куйды һәм Мораттан моны яшермәде.

Морат кул селтәде.

Кырые кителгән кечкенә җамаякка салып берәрне тоттылар. Хәсәннең шунда ук күз аллары әлҗе-мөлҗе килде. Тагын берәрне җибәрергә исәпләп торганда, ишектән Хәсәннең ике сеңелесе — инде буй житкән Рәүфә белән Рәсимә елап килеп керделәр. Морат кулындагы шешәсен өстәлгә куйды һәм:

— Ни булды, апайларым? — дип сорады. Рәүфә күз кырыйларын кул сырты белән сөртә-сөртә шыңшыды:

— Асыл абый апкалды, Низами абыйны да кыйнады...

— Абыең туйдырсын сез ач бетләрне, диде.— Монысын җил иссә авардай торган Рәсимә әйтте.

Хәсәннең тамак төбенә нидер төйнәлде, күзләре дымланды. Ул бер сабыйларга, бер сәкедә бөкшәеп яткан анасына карады. Морат кинәт кенә урыныннан кузгалды. Аның да күзләре ут яна, иреннәре дерелди иде.

— Киттек! Әйдә киен!.. Буып үтерәм мин ул авыл газраилен! — диде ысылдап. Хәсәннең дә каны кызды. Алар, тыкрыктан төшеп, Астафий буасы өстеннән тегермәнгә йөгерделәр. Асыл анда юк, Низами гына, ясипкә ларына сөялеп, кан төкереп тора иде.

— Кая китте? — дип сорады аннан Морат, еш-еш сулу алып. Низами, кан укмашкан иреннәрен көчкә кыймылдатып, җавап бирде:

— Кем белгән ул сабаканы!

Алар тегермәннән чыгып киттеләр, атлый-йөгерә ярлылар комитеты йортына таба алдырдылар. Асыл шунда иде. Ишектә Моратны күрү белән, ул торып басты һәм ашыга-ашыга кабурасын ычкындыра башлады. Ләкин Морат бер генә ыргылды да Асылга сугып та җибәрде. Асыл, пыялаларны челпәрәмә китереп, ярты гәүдәсе белән тәрәзәгә килеп капланды. Хәсән аның якасыннан эләктереп алды. Асыл, тозакка эләккән җанвардай, бөтен көче белән алардан ычкынырга теләде. Ләкин Моратка чыдар адәм бар идеме соң ул чакта. Ул Асылның бер кулын эләктереп алды да шартлатып артка каерды. Асыл, үкереп, тагын йөзтүбән ауды.

— Тор, авыл газраиле!.. Мәнә сиңа да чират житте, газраил булып жаныңны алырга килдек без синең! — диде Морат.

Асылның тозакка эләгүен ишеткән комитет членнары шунда ук килеп життеләр. Алты кеше. Морат шуларның иң өлкәненә — Хәйрулла картка комитет утырышын ачарга кушты. Аннары өздереп болай диде:

— Нишләп шушыны авызлыклый алмыйбыз? Яңа рәис сайлагыз, мин моны өязнең үзенә хәтле алып китәм, хәзер үк. Ат белән бер олаучы табыгыз.

— Рәискә кем кулай булыр икән?

— Ал, Хәйрулла абзый, тезгенне үз кулыңа.

— Минем тамга да сәнәк кенә бит, туганнар...

— Кешеләргә синең гаделлек кирәк. Хәсәнне ярдәмчең итәрбез.

Түшәмнәргә карый-карый, тез башына кидереп куелган бүрекләр белән киңәшә-киңәшә, ахыр чиктә бедком рәисе итеп Хәйрулланы, аның ярдәмчесе итеп Хәсәнне сайладылар.

Асылны туп-туры Минзәлә өязе милициясенә илтеп тапшырдылар. Аны, авылга алып килеп, ачык суд белән хөкем иттеләр.

Төрмәдән ул авылга колхозлар оешып, алар инде ару гына тернәкләп киткән вакытта кайтты. Колхозга гариза язып кермәде, ләкин анда да эшләде, авыл көтүен дә көтте.

Хәсән белән Морат колхозга башлап керделәр. Морат әле берничә ел колхоз председателе дә булып эшләде.

Алар бер елны өйләнделәр.

Бер үк елны икесенең дә малайлары туды. Вәдүт әнә шуларның берсе. Хәсәннең малае Газиз исемле иде. Аталар дуслыгы малайларга күчте, алар аерылмас ахирләр булып үстеләр. Егерме дүртенче елгылар иде алар. Әнә шул Вәдүткә, Газизнең ахириенә барырга ниятләнде Хәсән карт. Малае кебек якын ул аңа. Ата сүзенә бала колак салмый калмас. Ни өчен без шул Асыл теш ыржайтып, куанып көләрлек итеп эшлибез, хәзер, бүген, шушы көннәрдә?..

## 6

Тик күптәннән күңелендә төйнәлеп килгән, бүгенге көн тормышы куйган хисләр өстенлек алды. Күңелгә кереп урнашкан, айлар, еллар буе борчып килгән уйлар аны үз бишегендә тирбәтә башлады.

Бүгенге көн мәшәкатьләре белән кайчакта ялгышкалап та китүдән, бер уйласаң, Асыл да урынлы көлә. Ә бит әле тормышның Асыл белмәгән, аның төшенә дә кермәгән күтәреләсе чирәмнәре күпме!

Әйтик, бер генә нәрсәне — хәзерге колхоз авылында хезмәтне оештыруны алыйк. Юк, күпме генә үзгәртүләр кертелсә дә, ул әле камил түгел. Соңгы елларда терлекчелектә хужалык исәбе гамәлгә ашты. Бу, бер караганда, уңай хәл, уңай нәрсә. Шунда җиң сызганып эшләгәннәрнең килере шактый зур. Ә менә кырчылыкны ал син. Алар ни исәбенә һәм ничек яши? Агрономны хурлап әйтүе түгел Хәсәннең. Башлы, үз күз алдында, үз авылларында туып үскән егет. Әмма, ни дисәң дә, аның күңелен һәр даим борчып, аңа тынгылык бирми торган берәр уй-фикере, үз омтылышы бар микән? Юк кебек, ак сакаллы профессорлардан ишеткәннәрен генә тукып йөри шикелле. Мондыйлар, шундый ыспай егетләр белән ерак барып булмас кебек тоелә Хәсәнгә.

Үз уйларын чишәргә теләп, сүз дә катып караган иде Хәсән агрономга.

— Комбайнчыларга, тракторчыларга ничек түлибез инде быел? — дигәч, ул аңа текәлеп карады да, башын кашып:

— Елдагыча, күпме эшли, 100 сумына 1 центнер инде,— диде.

— Ул бит башкаларга да шулай, еллык эшләгән сумына карап, терлек карыймы, төзүдә йөриме — барыбер. Ә менә син, туган, иген уңмаган елларны аларны ничек бәхиллисең? Аннары терлекчелек белән исәп-хисапны ничек ясарга уйлыйсың? Син бит агроном. Терлекчелекне син фураж белән дә, силосы, сенажы, чөгендере, бәрәңгесе, саламы белән дә тәэмин итәргә тиешсең, шулаймы?

— Сүз дә юк, гомер гомергә шулай инде ул.

— Ә сезгә терлекчелек ни бирә?

— Безгә бирми, ә дәүләткә ит һәм сөт сата терлекчеләр.

— Ә син ничек уйлыйсың, алар бит сездән бөтен нәрсәне бушка ала. Үзләре, күкрәк киереп, без файдага эшлибез, ә иген уңмаганрак елларда сезне, безнең сыртта яшисез, колхоз сыртын кимерәсез дип лаф оралар. Шул вакыт агроном булган бу башыңда гарьлек галәмәте уянмыймы синең?

— Үз колхозыбыз, үзебезнең касса, үзебезнең кесә, ни дисәң дә моңарчы механизаторларның обижен булганнары юк әле. Юкка баш ватмыйк әле, Хәсән абый, әнә управлениедән отчет сорыйлар,— диде агроном, муенын кул сырты белән ышкып.

Юк, әллә үзе аңлата алмады, әллә агроном аның тел төбенә төшенмәде.

Вәдүтне искә төшергәч, күңелдә күптән төйнәлгән бу уйлар Хәсән картның тагын җан тынычлыгын бозды. Ул киңәшер кеше эзләп баш ватты: Харисны күз алдына китерде — юк, ул әле мондый мәсьәләләрдә сай йөзә. Була торган эш бу дип, барысын да хуплап торырга әзер Җәүдәтне исенә төшергәч — кул селтәрдәй булды.

Озак төйнәлгән бу төенне кем алдында чишәргә? Вәдүт оланга киңәш итәргәме? Картая-картая әллә чыгырыннан чыгамы бу карт димәсме? Әллә миндәге баш анда юкмы? Ул бит укыган, дөнья гизгән, ниләр генә күрмәгән. Уйламагандыр дисеңме син бу турыда, әллә нинди уйлар йөри торгандыр әле башында. Ә мин юк белән баш тинтерәтимме? Алай дисәң, юк нәрсә түгел шул бу. Сөйләсәм, тыңлавын тыңлар инде ул. Тик менә, күзләрен кысып, үзеңә туп-туры карап елмаймас микән? Әй, шуның елмаюы...

Кинәт Хәсәннең үз күзләре кысылды. Иртән Әсмасының әйткән сүзләре кылт исенә төште. «Тагын онытам бит»,— дип уйлады ул. Хәсән чәй эчеп утыра иде, карчыгы сыер савып керде, керде дә, чиләген югары күтәреп:

— Кара, күпмегә генә калды сөте,— диде. Хәсән чынаягын тәлинкәгә иплән кенә куйды да:

— Ташланырга йөридер, бик сыкма,— диде. Карчыгы исә калын иреннәрен бөрештерде, җыерчыклар сарган күз кабаклары өскә күтәрелде.

— Ташлана ди менәтерә бу вакыттан, йөгертелгәненә дүрт ай да тулмас борын... Их, йөрисең... Башак болгатырлык та салам калмады, үзең ат белән йөргән буласың. Синдәйләрнең лапас өсләре тулы эскерт тора, ә синең бер сәнәк нәрсәң юк,— дип әрли башлады карчык. Хәсәннең куе кашлары җыерылды, ул мыек очларын чеметкәләп алды, эчелеп бетмәгән чәе өстәлдә калды, табын яныннан кузгалды да иплән кенә киенә башлады. Ишек тоткасына ябышкач, Әсмасы тагын аваз салды.

— Атасы, онытма инде, болай итеп мал асраганчы, асрамавың артык...

Хәсән моңа да җавап кайтармады. Ишекне әкрен генә ябып чыгып китте.

Таң белән пыскак яңгыр ява башлаган. Күк йөзен куе караңгы пәрдә каплаган. Авыл инде уянган. Һәр тәрәзәдән урамга якты ут көлтәләре сибелә. Әнә тау башындагы колхоз идарәсенең тәрәзәләре дә ялт

итеп тора. Председатель тәрәзәсендә дә ут бар. Хәсән шул утка таба атлады. Ул килеп кергәндә председатель машиналарга наряд бирә иде. Хәсәннең сәламен башлап ул кабул итте, кулы белән ишарәләп, утырып торырга урын күрсәтте. Хәсән утырды, дөнья күргән бүреген тез башына кунаклатты, яңгыр тамчылары җемелдәгән мыегын сыпырды да тын калды.

— Син, Рәкыйп, Казанга китәсең. Бөтенесе белешенгән, килешенгән. Тракторларга запчастьләр алып кайтасың.

— Паром йөри микән соң?

— Йөри, кичә генә «Сельхозтехника» шоферлары кайтты.

— Иптәш Ганиев, командировочный гына җитми бит, үз хисабыма булыр, аласы әйберләр дә бар балаларга, кассир аванс биреп торсын әле.

— Күпме?

— Күпме дип, бер 50—60 сум җитәр шунда.

— Алырсың...

Рәкыйп рәхмәт әйтеп чыгып китте. Ишек ябылу белән, Хәсән карт башын чайкап куйды. Юк, бирәсе түгел иде Рәкыйпкә акча. Шулай башын мескенгә салышырга өйрәнгән бәндә бит ул. Әллә син аны шул акчадан балаларына бирәр әйбер алып кайтыр дисеңме. Сөйлиләр бит: Казанга бару белән, машинасын колхозчылар йортына куя да ресторанга чаба ул, дип. Әзерләнеп, юньле киемнәрен чемоданга салып китә икән. Шул рестораннарда утыруы үзе бер гомер, белмисез кадерләрен дөньяның, дип, бергә барган шоферларны да әрли ди, җитмәсә. Тик бер вакытта да үзен-үзе белмәс хәлдә сәрхүшләнеп кайтмый ди, чукынган. Шулай да, бирмәскә кирәк иде авансны.

Шоферлар чыгып бетте. Шул чак җилләнеп Җәүдәт Гайфетдинов килеп керде. Хәсәнне күргәч, папкасын председатель өстәленә куйды да ике куллап күреште.

— Исәнме, Хәсән абзый. Әсматтәйнең хәлләре ничек? Беркөн грипплап торам дигән иде. Мәтрүшкә кирәк инде аңа, мәтрүшкә...— дип тезеп кенә киткән иде, Җәүдәтне председатель Мисбах Ганиев бүлдерде.

— Ни йомыш, Хәсән абый? — дип сорады ул, йомшак кына итеп.

Хәсән аягүрә басты, чишеп җибәргән кожан төймәләрен элэктерә-элэктерә:

— Йомыш дип, Мисбах туган, Әсма тутаң сафура бураны кузгатып тора әле анда,— дип, тамак кырып куйды.

— Ни өчен?

— Сыерга башак болгатырга да салам калмады, йөрисең инде ди...

— Бу буран — чепуха, ат белән китереп булмас, бригадирга әйтермен, менә язып куям. Өйләдән соң «Беларусь» белән китерерләр. Үзең өйдәрәк булырга тырыш,— диде председатель,— соңыннан үзең бухгалтерия белән килешерсең,— дип өстәде.

Шуннан соң Хәсән карт сөт алып кайтты, фермада тагын озак юанды. Өйлә узды, менә кич булды инде, ә аның әле һаман фермадан кайтып китә алганы юк. Атын туарып, ашарына мул гына салып, чуалган ялларын биш бармаклап тарап торганда аңа кинәт кемдер дәште:

— Саумы, Хәсән абый, нишләп торыш?

Хәсән башта сискәнеп китте. Мирсәет икән. Колхозның өченче бригада башлыгы. Элек ул озак еллар председатель дә булып торды. Колхозлар эреләндерелгәч, туган авылында бригадир булып калды. Какча йөзле, карчыганыкыдай бөкре борынлы, киң кара кашлы, кырыс кыяфәтле кеше. Әмма бик тә тынгысыз, анда да, монда да борынын тыгарга гына тора, иснәнә. Бу фермага да әллә син аны корыны бушка аудару өчен генә килгән дип беләсеңме? Үгезләр симертү буенча аның Мөдәррисе белән Харис ярышалар бит. Харисның кай тирәдә йөзгәнен,

гомумән, фермадагы хәлләрнең ничек барганын үз күзе белән күрергә, һәр нәрсәне капшап карарга килгәндер әле.

— Ару, рәхмәт, әле болай, үз алдыма хыялланып йөрү иде, Мирсәет,— диде Хәсән.

Мирсәет ике куллап күреште. Соры куян бүреген арткарак шуыштырды, кыска, юантык бармаклы кулы белән ияген ышкып алды да:

— Харис күренмәдеме? — дип сорады.

— Килеп җитәр инде, бераз капкалап алыйм дигәние.

Мирсәет беравык дәшми торды, куш чия төсле калын аскы иреннәрен тешләштереп алды да тагын сорады:

— Хәсән абый, хакмы, быел үгезләрне тапшыртмыйлар, киләсе елга калдыралар, дигән сүз?

Хәсән читкә карады, тамак кырып куйды.

— Шундый сүз йөри, ләкин кемнәргә генә файда китерер икән ул?

— Кемгә булсын, район начальствосына. Юк, Мисбахның якасыннан алам, тикмәгә ипидән тирес ясап ятарга монда! Мөдәррис шушы хәбәрне ишеткән дә куа гына бит мине, бар әле, белешеп кайт әле, анда Харислар нишләргә ниятләнә икән, ди, ай-вайга куймый. Андый фәрманны кем биргән, үгезләрне иртәгә үк шуның ишегалдына куып илтәм. Яңа елга чыкканчы асрап җыгы чыксын, ди.

— Бу турыда мин дә башны күп ваттым. Вәдүт туганга барып егылмый булмас,— диде Хәсән. Аның күзләре уйчан, маңгай сырлары тагын да ишәя төшкән кебек. Уйлый, нидер уйлый, нигәдер борчыла, бөтен йөрәге белән сызланып, моңа кадәрге йөкләрен дә барлый-барлый, иртәгәге көн турында, атар таң турында шулай онытылып, бөтен дөньясын онытып уйлый ул. Хәсәннең андый халәтен күптәннән белә Мирсәет. Шуңа ул үгезне мөгезеннән эләктерергә булды һәм туп-туры сорады:

— Ни турында баш ватасың, Хәсән абый?

Хәсән карт бер сүз дә дәшмәде. Яңадан кола биясе янына килде, аның ял асларын кашыштырды, кулын алъяпкычы түшенә ышкып алды. Аннан соң гына Мирсәеткә күтәрелеп карады да:

— Исән кеше ни генә уйламас,— диде.

— Шулай да?..

— Һәркем, ул нинди генә эштә яки постта булмасын, үз тамагын үзе туйдырсын, туйдырырлык итеп эшләсен һәм хөкүмәткә мая да калдырсын иде. Менә хәзер дә кемдер эшләгән хисабына яшәүчеләр, хөкүмәт маясында гына эшләүчеләр күбәя кебек...

Мирсәетнең соры күзләре зур булып ачылды. Ул Хәсән картка иеләрәк төште һәм:

— Хәсән абый, утыз җиденче еллар шаукымында ничек исән калдың син? — дип пышылдады.

— Чорны гаепләмә син, Мирсәет туган. Тоткан кыйбла ул чакта да борылмады. Яңа юл ярганданиләр булмый. Берәүләр сөенсә, икенчеләр көпчәгеңә таяк тыгарга тырышты. Тыга алмаса, яңа юл салучылардан үч алырга теләде. Әмма юлны барыбер ярдык, барыбер салдык... Ул кайчакта җеп белән тарткан кебек туп-туры булмыйдыр да бәлки, ләкин һаман алга сузыла, кыйблабызга таба бара. Шунысы әйбәт, шунысы шәп аның, туган.— Хәсән тамагын кырып алды һәм инде утардан чыга-чыгышлый:— Бая әйтә башлаган идем бит: кеше хисабына яшәүчеләр бар,— дип сүзен дәвам итте. Ул күңелдә төйнәлгәнен Мирсәеткә дә чиште, аның белән дә киңәште. Алар әкрен генә авылга таба атладылар. Мирсәет, бер килгәч, колхоз идарәсенә дә сугылыйм, диде. Хәсән картның бу яңа уй-фикерләрен тыңлап бетергәч, ул:

— Безнең бригада сорт участогы бит, ә фуражны кемнән юнәтерсең? — дип сорады.

— Акчаң булсын, башка бригадалардан сатып алырсың.

Мирсәет беркавым дәшми барды.

— Уйлыйм-уйлыйм да, син дигәнчә эшләгәндә монда һәр бригадада бер бухгалтерия ачарга туры килә, шул хәтле исәп-хисапка бер бригадир ничек җитешә алсын,— диде ул аннары.

Хәсән мыек астыннан гына елмайды. Ләкин җавап бирмәде. «Бусы заман өчен читен, барып чыкмас нәрсә түгел. Әлегә генә хисаплаучысы табылыр. Район үзәгендә әллә нинди машиналары булган исәпләү станциясен юкка ачып җибәрмәгәннәрдер әле»,— дип уйлады.

## 7

Кар катыш сибәләп яуган салкын яңгырда Хәсәннең дуңгызларга аертылган сөт бушатуын карап торганнан соң, Асылның күзләре кысылды, юка иреннәренә елмаю билгеләре чыкты. «Мин керәм дә диванга сузылып, түшәмгә төкереп ятам, ә син һаман йөре шунда күшегеп. Үз кадерен үзе белмәс шундый бәндәләр булыр икән дөньяда»,— дип уйлады ул һәм Хәсәнгә таба нигәдер йодрык болгады да кереп китте. Терлекчеләр йорты зур, якты, җылы. Йортның бер почмагында аның үз бүлмәсе бар. Карават, әйбәт кәнәфи куелган. Баш очында гына репродукторы сөйләп тора. Олы якта, түрдә, телевизорына чаклы бар. Ни кирәк тагын Асылга? Яшәгән урыны җылы, эше — төнлә, ара-тирә ишек ачып, бер-ике тамак кыра да шуның белән вәссәлам. Ә Хәсән, җил-буран, кар-яңгыр дими, һаман май заводы белән ике арада киләп сара. Йөрсен, үзе теләп алган чире, шуның белән китәр дә инде ул... Ни җитми диген аңа? Күптән җитмешнең өстендә бит инде. Алай гына да түгел. Хәзер Асылның үзенә сиксән якынлашып килә. Ә Хәсән аннан ике генә яшькә кече. Ул да нык, чакма ташы кебек булып чыкты. Аның да башыннан ниләр үтмәде инде. Теге сугыш, бу сугыш... Инде тамыры корыды дигәндә тагын тернәкләп китүен күр син Хәсәннең.

Ул сыеныр, барыр җире булмаганга ята инде ферма өендә. Каравылла, эшлә дип тә батырып әйтүче юк. Председатель, килсә, хәл-әхвәл, сәламәтлекне сораштыра да китеп бара. Тагын ни белешсен? Инде менә ничәмә еллар фермадан сәнәк тә югалганы юк. Кагылмыйлар хәзер колхоз малына. Иркен яши шул халык, нигә вак-төяккә кызыксын ул.

Асыл диванга ятты, аякларын сузып җибәрде, кулларын баш астына салды, күзләрен йомды. Юк, күпме тырышса да, йокы алмады аны. Күз алдына һаман Хәсән кыяфәте, аның чалу мыегы килде. Урынында берничә кат дыбырдап әйләнеп тә алды, диван пружиналары ыңгырашып шыгырдады. Ләкин Асылның керфеге коелып беткән күз кабаклары җиңелчә дерелдәүдән туктамады. Бөтен йөрәгенә ниндидер билгесез юксыну, сагыш моңы тамчылары ләпелдәп тама башлады, ул тирән итеп көрсенде дә йөзтүбән ятты...

## 8

Ябылган җиреннән ике тапкыр качып карады Асыл. Икесендә дә хәлдән таеп егылган килеш эт белән килеп таптылар. Аннары качудан өмет өзде. Өч ел тайгада урман кискәннән соң, аны кыргыз далаларына куй көтәргә җибәрделәр. Буранда бергә укмашкан көтү уртасына кереп ятты, сарык имде. Моннан качарга да була иде. Ләкин үзеннән-үзе кача алмавын яхшы аңлаган иде Асыл ул вакытта. Утыз дүртенче елга кадәр ул шунда куй көтте. Инде кунакчыл кыргызлар белән дә танышып беткән иде. Срогын тутыргач, калырга да димләделәр. Өйләнергә дә исәбе бар иде. Ләкин туган як туфрагы тартты. Соңгы елларда, аеруча кояш чыккан вакытларда чык төшкән Даулы болыннар,

киртләчләнеп торган таулар, Минзәлә елгасының ике ягы буйлап тезелеп киткән бөдрә таллар күз алдыннан китмәде. Авылдагы кешеләргә, Морат белән Хәсәннән башкасына, ул ачу сакламады. Ә аларны инде бөтен йөрәге белән күралмады. Алар булмаса, ачлык елы да үтеп китәр, аны утыртучы кеше дә булмас кебек тоелды аңа. Исән-имин кайтса, Морат, Хәсән белән исәп-хисап өзүнең әллә ничә төрен уйлап бетерде. Ләкин аларга җан кыеп кул күтәрү уена да килмәде. Чөнки кайчандыр аның гәүдәсе күренү белән, үлем ачысы сизенеп, авылдашларының үзәк өзгеч итеп кычкырулары, аларның куркудан аларган күзләре Асылга бу елларда бер минут та тынгылык бирмәде. Ә күңел түрендә, кайдадыр тирәндә яшеренеп, үч орлыгы шытымлый, ул вакыты белән яңарып-яңарып китә. Асыл үз-үзен кая куярга белми тинтери, күзләре чүл бүресенекедәй елтырый башлый. Андый чакларда ул бөтен дөньясын ләгънәтли. Һәм күз алдына Габдрахман бай килә. Шушындый ач шакал кебек идемени ул? Шул, шул туймас ачкүз аның кешеләргә изге теләк белән тулы канын эчеп бетерде, аны кешедән бүре итте. Ничек кенә мыскылламады ул аны!.. Этенә ташлаган сөякне алган өчен дә камчы белән яра иде бит...

Асылның күзләре чыланды. Ләкин ул аны сөртмәде, уфтанып куйды, ә күңелдә туган уйлар бер-бер артлы яңара торды.

Срогын тутырганда ул катгый фикергә килгән иде инде. Тиешле документлар кулга эләккәч тә ул Башкортстанның Караидел районына, таулар арасындагы кара урман уртасында адашып утырган бер авылны эзләп китте. Озын булды аның бу сәфәре, айдан артыкка сузылды.

Менә ул авыл. Чоңгылга утырган илле-алтмыш хуҗалык. Сөргенгә сөрелгән кулаклар, байлар яши биредә. Совет хөкүмәте эшләтеп ашата аларны хәзер — урман кистерә. Габдрахман бай да малае белән шушында булырга тиеш. Кәүҗияктәге бер күз күргән кешесенә язып адресын алдырган иде. Асыл авылның беренче йортына сугылды. Ачык тәрәзәдән өйгә аваз салды:

— Алла хакы өчен ярдәм-шәфкатьләрегездән ташламасагыз ла, бер генә сынык сузсагыз икән илгизәргә,— диде ул, еламсырап. Тәрәзәгә юан гына бер хатын килде һәм:

— Бетле хәерчеләр! Сәвитегез туйдырсын. Сезнең влач бит хәзер. Совет влачында да хәерчеләрне байлар туйдырырга димәгәндер,— дип, тәрәзәсен шартлатып ябып та куйды. Алга таба атлады Асыл. Капка төбендә ап-ак сакаллы бер карт утыра иде. Сәлам бирде:

— Әссәламәгаләйкем!..

— Вәгаләйкемәссәлам!..

— Өч көн инде авызыма әпәй валчыгы кергәне юк, миһербаныгыздан ташламасагыз иде, бабай, аякларым тәмам йөрмәс булды...

Асыл, шулай дип, карт янына утырды.

— Төбәгең кай як, каян җилләр ташлады, олан? — дип сорады теге, житен сакалын сыпыра-сыпыра.

— Ерактан мин, Казан ягыннан, сөрелгән ил кешесе баласымын,— диде Асыл, мескенгә сабышып. Карт уйга калды. Аннары урыныннан кузгалды. Өйгә кереп ярты ипи белән бер зур җамаяк катык күтәреп чыкты.

— Аша, ризык булсын, олан,— диде. Ачыгуы чыннан да аллага шөкер иде, ризыкны ялт иттерде Асыл, кашыгына хәтле ялады. Аннары сүзне читләтеп кенә башлады.

— Безнең Казан ягыннан кешеләр юкмы соң? — дип сорады. Карт мескен бүрек кигән башын гына селкеде. Кузгалып китәм дигәндә, ул Асылның иненнән тотты:

— Тукта әле, олан, Казан ягы кешесе дип сөйләгәне хәтердә берәүнең... Әнә, аргы очта, инеш ягы буенда аның йорты. Хәтерем ял-

гышмаса, Габдрахман атлы кеше,— диде. Асылга шул гына кирәк иде дә.

— Теге, капка төбенә әрдәнәләр аударылган өйме? — дип сорады Асыл.

— Шул, әле быел кар киткәч кенә тарттырды ул аларны. Монда да дөньяга мәңгегә килгән кеше кебек йөри әле...

Асыл, картка рәхмәт укый-укый, китеп барды. Ләкин урам буйлап китмәде, өч-дүрт өй узгач та, тыкрыктан түбән таба төшеп, бәрәңге бакчалары артына чыкты. Бакча кырыеннан ук кечкенә генә инеш ага, аның сөзәк ярлары кыргый карлыган белән капланган. Алар инде алсуланып киләләр. Инешнең икенче як ярында кара урман — карагайлар шәм кебек утыра. Асыл тирә-юньгә күз йөртеп алды. Авыл тыныч, көндезге челләдән качып йокыга талган сыман. Чишмәгә иелеп су эчкәч, Асыл, үрмәләп, бәрәңге бакчасына керде, йолкып бәрәңге җыйды, аны капчыгына тутырды. Аннары, инеш буйлап кына, Габдрахман байның яңа йорты тарафына атлады. Бәрәңге бакчасы артыннан, карлыганнар арасыннан муенын сузып, ишегалдын күзәтте. Бик озак карап торды шулай Асыл. Әмма ишегалдына чыгучы-керүче күренмәде. Башта өенә кызыл әтәч җибәрергә уйлаган иде Асыл, аннары бу фикердән кире кайтты... «Соңыннан, соңыннан да өлгерермен, барыбер нигезеңне корытмый китмәм моннан»,— дип пышылдады ул, үзе нигәдер калтырап куйды. Аннары Асыл урам башындагы калкулык артына таба атлады. Аның авылга караган ягы гына тәкә маңгаедай шәрә икән, икенче ягында, кычытканнар белән урала-урала, кура җиләге үсә. Асыл, тау итәгенә аяк басу белән, урман юлыннан килгән арба шыгырдавын ишетеп, сискәнеп китте. Киек җәнлектәй сикереп, җиләклеккә ташланды, кулларын, йөзен кычыткан чагып бетерде. Ләкин башта ул аны сизмәде. Менә урман авызында атлы кеше күренде. Ул киртәлек сөйрәтә иде. Таныды моны Асыл. Габдрахман байның теге аңгы-миңге малае иде бу. Асыл чүгәләгән җиреннән сикереп торды. Күзләрен кан басты. Алга ыргылды. Ләкин тагын үзен тыеп калды. «Бу җүләр белән кул пычратканчы, үзе дә минем хөкемдәге кеше бит ул, бичара»,— дип уйлады һәм артка чикте. Күп тә үтмәде, киртәләрен шудырып төшереп, атлы яңадан урманга кереп югалды. Кичкә кадәр дүрт юллады Габдрахман тилесе. Бишенчесендә малае янышнан Габдрахман бай да атлый иде. Габдрахман байның корсаклары шиңгән, иңнәре дә төшкән. Түгәрәк сакал җибәргән, сакалының уртасы агарган. Өстендә иске җилән, башында каешланып каткан түбәтәй. Әмма адымнары нык әле, җил-җил атлый, бераз бара да атына чөңгереп куя.

Түздә бу төнне Асыл. Кура җиләкләре арасында салкыннан бөрешә-куырыла төн үткәрде. Таң атканда, карагай агачларына кояшның беренче зөбәрҗәт нурлары эленә башлау белән, Габдрахман бай үзе генә җәяүләп урман юлы белән китеп барды. Путасына балта кыстырган. Аның үткен йөзе ялтырап-ялтырап китә. Менә ул урманга кереп югалды. Асыл качып утырган җиреннән чыкты да болан кебек юргалап аның артыннан элдерде. Юлны күздән югалтмыйча, агачлар арасыннан сак кына атлады ул. Күп тә бармады, Габдрахман байның гәүдәсе күренде. Әнә ул юлдан читкә борылды, тезләнеп, кече йомышын йомышлады. Әнә тагын юлын дәвам итте. Зур аланлыкта туктады. Киртәлеккә менә дигән зифа карагайларга карап торды, путасындагы балтасын алып, аяк астында авып яткан каен кәүсәсенә чапты. Тәмәке төрде. Карт каенның юан кәкре ботагына утырып, башын түбән иде. Тирән итеп махра суырды. Нәкъ шул чакта Асыл аның якасыннан эләктереп алды һәм каен кәүсәсенең икенче ягына сөйрәп төшерде. Көтелмәгән бу хәлдән Габдрахман бай өнсез калды. Алдында басып торган Асылны ул башта танымады. Күзләре чалып ташланган тәкәне-

кедәй җансыз калды. Менә аның йөзе иләмсез җыерылды, авызы ачылды. Ләкин сүзләре чыкмады, ачык авызда теле генә тирбәлде. Асыл балтаны алды һәм җирдә өнсез яткан Габдрахман байга кизәнде, ләкин чапмады.

— Тор! Адәм баласыннан бүре ясаучы, бәдбәхет! — диде ул байга һәм житмеш җиде катлы итеп сүгенде. Аннары:— Үз кабереңне үзеңә казытам мин син сабакыга, кеше каны эчүче! Син, кабахәт, мине нәсел-нәсәпсез калдырдың. Җиттеме вакытың, суктымы сәгатең?!. Нәселеңне корытам, дигән идемме мин сиңа теге чак,— диде дә якасыннан сөйрәп торгызды. Габдрахман бай усак яфрагы кебек дерелдн. Менә аның еламсыраган тавышы чыкты:

— Асылгәрәй улым, җанымны кыйма, гомереңә житәрлек алтын белән күмәрмен үзеңне!

Бу сүзләргә Асылның жене кузгалды. Ул Габдрахман байга салып җибәрде, тагын балтасы белән кизәнде.

— Әле һаман дөнья сасытыргамыни исәбең, алтының белән җаныңны саклап каласың киләмени? — дип, Асыл Габдрахман байның артына китереп типте.— Әйдә, атла, каберең өстен пычратып китмичә җаныма тынгы табасым юк минем.

Габдрахман бай, башын иеп, әкрен генә алга атлады. Аучылар сукмагыннан чытырманлыкка алып кереп китте Асыл аны. Бераз баргач, уң якта сазламык башланды. Аның ярларында кеше буе куе камышлар үсә, ара-тирә зур-зур түмгәкләр калкып тора. Асыл Габдрахман байны туктатты.

— Әшәке җаныңны менә шушы сазлык суырып алачак синең!

Габдрахман бай җиргә тезләнде, белгәннәрен авыз эченнән укый башлады. Сабыр итте Асыл, әйдә укысын, чукынсын үз алласы белән бергә дип, кулына балтасын тоткан килеш көтеп торды.

— Асылгәрәй улым, беләм бит мин, гомер буе рәхәт күрмәгән кеше син. Инде калган гомереңдә бал-майда йөзәсең килсә, кыйма минем җанымны, сүземне тыңла.

— Я, тагын ни әйтәсең килә, башыңны чабып ярганчы?

— Алтынга күмәм мин сине...

Асыл беравык дәшми торды, башында әллә нинди уйлар туды. Җиргә тезләнгән Габдрахман бай тирәсендә әйләнгәләде, аннары сорау бирде:

— Кайда алтының?

Габдрахман байның йөзендә өмет чаткысы кабынды.

— Монда киткәндә күмеп калдырдым мин аны. Кайда икәнлеген өйрәтермен. Мин әллә кайта алам, әллә юк. Кайтмасам, мәңге җир астында ятачак алар. Ә син, ни әйтсәң дә, заманында миңа изгелек иткән кеше. Җәл түгел сиңа.

— Кая яшердең, әйт!

— Каһымны коймассыңмы соң?

— Әйт, диләр сиңа! Ату алтының-ниең белән...

— Безнең зиратны беләсең бит... Әнә шул зиратның кыйбла ягында очы корый башлаган бер нарат булыр. Башта шул наратны тап. Аннан кыйблага таба атлап, ике каберне калдыр да өченчесе янында тукта. Баш очында очлы таш булыр...

— Я, я! — Асылның күзләре очкынланды.— Шул таш астындамы?

— Юк, шул таштан кояш баешына таба җиде адым атла. Бер кабернең нәкъ уртасына туры килерсең. Шул кабернең кыйблага караган итәгендә, өч түшәм тирәнлегендә тимер сандык булыр... Менә ачкычы...

Габдрахман бай, шулай дип, эчке ыштан бөрмәсенә көмеш чылбыр белән асылган ачкычны Асылга сузды. Чылбыр саллы һәм саф көмеш иде. Асыл аны кесәсенә салып куйды һәм каһкаһәле итеп көлде дә:

— Үзеңә-үзең ясин чыктың, Габдрахман бай, атла сазга! — дип кычкырды. Габдрахман байның күзләре иләсләнде, ул торып басты һәм, Асылга таба кулларын сузып:

— Үтермә, Асылгәрәй улым, минем гомерем болай да күп калмаган инде, түшәктә ятып үлим, гомер буе синең исәнлегеңә дога кылыр идем,— дип ялварды.

— Атла, диләр сиңа, муеныңнан чабып өзгәнче!..

Асыл аңа балтасы белән кизәнде. Габдрахман бай артын-артын сазга таба чигенде. Менә аның бер аягы инде сазда, ул батып бара. Асыл аны этеп җибәрде. Габдрахман бай чайкалып торды да сазга чалкан килеп төште һәм бөтен урманны яңгыратып кычкырып җибәрде.

— Үтерә-ә-әлә-ә-ә-р-р!.. Котка-а-ары-ы-гы-ы-ы-з!..

Аның үлем әчесе белән ачыргаланып кычкырган авазы якындагы карт карагайлар очына әләгә-әләгә әллә кайларга таралды һәм кайтаваз булып яңгырады. Габдрахман бай торып басарга теләп куллары белән әле бер, әле икенче якка таяна, таянган саен саз аны үзенә ныграк суыра бара. Бер кулын суырып алуга икенчесе кул башына кадәр чума. Менә аның хәзер башы гына күренеп тора, күзеннән мөлдерәп яшь ага, авызын киереп-киереп ача, нидер әйтергә тели.

Асыл түзмәде, күңел түрендә ниндидер кызгану хисе уянды. Ул үзен шушы кешенең кое сиртмәсенә бәйләп җиргә бәрдерүләрен дә, итле сөяк өчен тана хәтле этләреннән талатуларын да, яшьлек дуслары Хәсән, Морат белән дошманлаштыруын, нечкә күңелле сабый, табигать баласының садә күңелен үзенең рәхимсезлеге белән таш бәгырьгә әверелдерүен дә онытты. Кулындагы балтасына ялт итеп карап алды да сазлык кырыендагы озын, зифа каен төбенә киерелеп чапты. Икенче чабуында каен чайкалып куйды. Асыл аны этеп Габдрахман байга таба аударды да кәүсәгә баса-үрмәли сазлык эченә ашыкты. Габдрахман байның түгәрәк сакалы сазга тигән иде инде. Башка тотар урыны калмагач, Асыл аның сакалыннан эләктерде. Баш бераз гына кыйшайгандай итте, ләкин гәүдәне саз нык суырган иде, ул кымшанмады да. Асыл каен кәүсәсенә, аның ботакларына сузылып ятты, кулын сазга батырып, картның култык астыннан эләктерде һәм бар куәтенә үзенә таба тартты. Аста нидер гөбердәде, лыпырдады, авыр сулыш алгандай итте. Ниһаять, Габдрахман картның иңбашы, бер кулы өскә чыкты. Ул, өзек-өзек тын алып, кулы белән каен ботагына чытырдап тотынды, бөтен гәүдәсен алга ташлады. Икенче кулын да тартып чыгарды. Ул шул кулын Асылга сузды. Куркудан аларган күзләреннән яшь сыгып:

— Асыл, Асыл... Чыгара күр, монда да бар алтыным,— диде, борыны белән гыж-гыж сызгырып. Асыл аның ләм сыланган кулын эләктереп алды, нык кына итеп тартты.

— Кочакла муеннан, карт тәре! Чукын алтының-иең белән! — дип, артка таба шуышты.

Көчкә сөйрәп чыгарды. Яр кырыена житү белән алар икесе дә торып утырдылар. Габдрахман бай әле үзе яңа чыккан урындагы һава куыкларының лепел-лепел сүнүенә карап тораташ сыман катты. Асыл, еш-еш сулап, тәмәке төрде, бер-ике суырды да Габдрахман картка сузды. Тегесе, пычрак кулларын камышка тиз-тиз сөртеп, шуны эләктерде дә тирән итеп бер-бер артлы суырды. Аннан илереп елап җибәрде һәм Асыл алдына килеп тезләнде.

— Кылган гөнаһларым өчен җир читенә сөрделәр, туган туфрагымнан аердылар. Инде газиз җаным шушы сазда бернинди ясинсыз чыга дигәндә аллаһе тәгалә күңелләреңә миһербан салды... Рәхмәт, Асыл улым! Соңгы алтыныма хәтле синеке, ал! — Габдрахман бай, күз яшь-

ләрен кояшта кипшәкләнә башлаган пычрак кул сырты белән сөртә-сөртә, шулай дип такмаклады.

— Чукын алтының-ниең белән дидемме мин сиңа, карт тәре! — дип кычкырды Асыл аңа һәм аягына басты. Аннары:— Әнә юлың, кайт. Өч көнсез өеңнән чыгасы булма. Минем турыда теш араңнан берәр сүз чыкса, чамала,— дип, урман юлын күрсәтте.

Габдрахман бай сикереп торды. Авыз эченнән ниндидер догалар укып тиз-тиз юлга таба атлады. Сазламык буенда аның каешланып беткән түбәтәе генә аунап калды.

Габдрахман күздән югалу белән Асыл да кузгалды. Кай тарафка юл тотарга инде дип торганда, алда арба сөйрәтеп килүче Габдрахман бай тилесе күренде. Асыл бер каен артына посты, әкрен генә кötә башлады. Арба үз турына житү белән, Габдрахман малаен сугып екты Асыл, кулын арта каерып бәйләде, башындагы картузын бөтереп аның авызына тыкты. Атны тиз генә тугарды, алды арбаны, жирдә ыңгырашып яткан бай малаен куаклык эченә сөйрәп кертеп ташлады. Аннан, атка атланып, урман эченә кереп китте.

Атын дилбегә белән бәйләп жибәреп, көнне кечкенә бер аланда үткәрде. Жир жиләге кызарып пешкән чак иде. Түше белән шуыша-шуыша жиләк ашады. Өйлә авышуга башы авырта башлады, телләре кипте. Аптырагач, урманны чыгып, авылга сыенып аккан бер инешкә барып су эчте, битләрен юды. Ләкин баш авырту, күңел болгануы басылмады. Житмәсә, бөтен тәне кызышырга тотынды. «Әллә Габдрахман каргышы төштеме?» — дип уйлады ул шикләнеп. Кичкә таба хәле тагын да авырайды. Төнгә ниятләгән эше икенче көнгә калды. Төнне көчкә үткәрде. Туңудан гажизләнгәч, печән йолкып өйде, аны тыгызлап, аркасы белән терәлеп ятты. Берәр сәгатьтән печән кыза башлады, тәненә жылы йөгерде. Бик озак шулай тинтерәп ятты. Аннан соң гына йокыга китте. Ул күзен ачканда кояш чыккан, бөтен урман эче жилпенә-жилпенә канат кагып сайраган кошлар тавышы белән тулган иде. Асыл торып басты. Аны күргән Акбүз кешнәп жибәрде. Әчәсе килгәндер инде, дип уйлады Асыл. Атның янына барып, ял асларын каккалап сөйде һәм: «Тагын бер генә төн түзик, аннары кунак сыенда булырсың, миннән аерылганчы»,— диде. Гәүдәсе жиңеләеп киткән иде Асылның, башы да авыртмый, күңел болгануы да беткән иде.

Көнне шушы аланда үткәрде. Ут тергезергә курыкты. Үләнгә сөртә-сөртә, яшь бәрәңгене чи килеш кенә ашады. Кич булып, аланлык өстендә йолдызлар калыккач, Асыл Акбүзен житәкләп урманнан чыкты, беренче төнен үткәргән калкулык артындагы жиләклеккә килде. Атын читтәрәк үсеп утырган зирек агачына бәйләде. Авыл йоклый иде. Кайчак казлар каңгылдашкан тавышлар гына ишетелеп китә. Менә алар да тынды. Авыл, төн пәрдәсен ябынып, тирән йокыга талды. Асыл урыныннан кузгалды һәм сак кына атлап Габдрахман бай өенә таба якынайды. Монда да әйбәт өй житкергән карун. Биек, алты почмаклы, бер дигән нарат бүрәнәләрдән. Асыл ишегалдына керде. Төз лапас башына таратылган коры печәннәрне тартып-тартып төшерде, аларны кочак-кочак тәрәзә каршыларына, ишек төбенә ташыды. Аннары олы бер учма печәнгә ут төртте дә аны һәр өемгә сибеп чыкты. Өй кырыендагы читән аша сикереп, Акбүзгә таба бар көченә чапты. Һәм атка сикереп атланды. Маңгаена бәреп чыккан салкын тирне жиң очы белән сөртеп, стеналарны ялмап югарыга үрләгән ут ялкынына карады. Әнә ул һаман биеккә сузыла, түбә такталарына ук үрмәли. Кинәт чылтырап тәрәзә пыялалары коелды. Өй эченнән ачыргаланып кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелде. Асыл үкчәсе белән ат касыгына тибеп алды да тезгенне тартты. Акбүз урманга ыргылды. Урманга кергәч, Асыл авыл ягына күз атты. Габдрахман бай йорты дөрләп яна иде. Яктысы урман

читенә кадәр төшә. Урамнарда кешеләр йөгерешә башлады. Авылның икенче очында чаң кагарга тотындылар.

Асыл Акбүзне үз иркенә куйды. Ат таныш сукмактан урман эченә кереп китте. Төне буе ат өстендә барып, таң сызылып килгәндә зур аланга килеп чыкты җайдак. Аннары киселә торган делянкалар башланды. Кешеләр белән очрашасы килмәде Асылның. Ә делянкада кеше булмыйча калмый. Ярты чакрымнар китү белән, эт өргән аваз ишетелде. Әнә ул һаман якыная. Асыл тезгенне каты итеп тартты. Акбүз томырылып чаба башлады. Эт тавышы артта калды. Җиде-сигез чакрымнар киткәч, ул бер авылга барып чыкты. Урам коесында атын эчерде дә, ашау-эчү ягын хәстәрләү нияте белән, бер йортның тәрәзәсен какты. Тәрәзәгә зур гәүдәле башкорт килде.

— Нәмә кәрәк? — диде ул, күзләрен уа-уа. Асыл үз гозерен әйтте. Башкорт, аркасын кашый-кашый, нидер уйлап торды да хатынына дәште:

— Бичә торың, анау бер татар әпәй сорай, сатлыкка,— диде. Күп тә үтмәде, ишектә башкорт күренде, аның кулында, кем әйтмешли, тегермән ташы хәтле ике арыш икмәге иде. Биш сум бирде Асыл. Башкорттан юл сорашты да китеп барды. Көн үзәгендә, аланлыкта, тышаулап җибәреп, атын ашатты, хәл җыйдырды. Үзе дә йоклады.

Унөченче көн дигәндә ул туган авылына кайтып житте. Җайдаклы килеш Зәңгәр тау башыннан авылын күзәтте. Тамак төбенә ниндидер төен төйнәлде, йөрәге ашкынып типте, чигә тамырлары сулкылдады. Авыл әллә ни үзгәрмәгән. Ындыр артында гына озын амбарлар калкып чыккан, төньякта, Әхмәт тавы итәкләренә сыенып, таштан берничә йорт калыккан. Анысы нидер. Асыл үзләренең урамын эзләп тапты. Таныш өянкеләр, йортлар буенча күз йөртеп, үз нигезенә килеп житте. Аның өй урыны буш иде. Асылның йөрәге кысылды, чәнчеште, күкрәк куышыннан ниндидер иң газиз нәрсәсе өзелеп төшкәндәй булды. «Минем дә, минем дә нигезләр корыган... Габдрахман байныкы шикелле... Икебез бер төслемени соң без Совет хөкүмәтенә? Соң мин дә бит, Хәсәннәр шикелле, ярлы-ябагай адәм идем... Үз нигезем үземә ярар иде әле, нигә аны җимергәннәр?»

Акбүз, нишләп бу тау башында каккан казыктай каттың әле дигәндәй, алгы аякларын бәргәләп тузан очырып алды, чылтырата-чылтырата тимер авызлыгын чәйни башлады. Асыл аның муенына капланды, аны кочаклап тын калды, бары тик киң җилкәсе генә дерелдәп киткәли иде. «Юк, Габдрахман бай белән мине тиңләргә хакыгыз юк сезнең, юк!..» дип пышылдады аның кайнар иреннәре. Ул иренен ялап алды. Теле ниндидер әчкелт тоз тәме тойды. Асыл башын күтәрде, күзләрен керләнеп беткән җилән җиңе белән сөртте, авызына җыелып барган тоз тәмен җиргә төкерде, күкрәген киереп, иркен сулыш алды.

— Юк, исән булсам, ике аягымның берсе белән дә шуннан читкә атламыйм хәзер! — диде ул һәм атасы, туганнары белән урак урган ике тау арасындагы кара-каршы чишмә буена төшеп китте. Чишмә буенда туктады. Үзенең сабый чакта ялан тәпи эзләре калган урыннарга ятып аунады, нәсел-нәсәбенең, үзенең маңгай тире тамган туган туфрагына киң күкрәге белән сыенды, колачларын җәеп, аны кысып кочакларга итте, сукадай тырнаклары белән җирне тырнады, яшел әрфиядәй үләннәрнең башыннан иркәләп сыйпады.

Инде иянәнеп өлгергән Акбүз елтыр күз кырые белән аңа карап алды да яр буендагы сусыл үләнгә ябырылды. Асыл кара-каршы чишмәнең икесеннән дә ятып су эчте. Нилэр күрмәде, кайсы якларның гына суын эчмәде, ләкин бу чишмәләргә ни җитә! Әнә аның тылсымлы, шифалы көче бөтен тәненә, баш миләренә йөгерде, күкрәге киңәеп киткәндәй, беләгендә көчләр арткандай тоелды.

Кичке шәфәкъ иңгәнче кара-каршы чишмә буенда утырды Асыл. Туган як, яралган як һавасын шашып сулады. Ләкин күңеле белән һаман бер сорауга җавап эзләде. «Ни өчен соң ул менә шушындый сукбай көненә калды, аның бәхет тамырына кем балта чапты? Аны хөкем иткән судья әйткәнчә, әллә үземе? Хак кына үземе? Соң кем үз-үзенә дошман булсын инде? Юк, гражданин судья, ул гына гаепле түгел монда. Ул да бит Хәсәннәр белән бер юлдан атлаган һәм атларлык иде. Берәү дә анадан бозык, җинаятьче булып тумый. Ата-анасы да аны теләми. Ачлык, житмәгән дөнья шул хәлгә калдырды Асылны, гражданин судья! «Син шуны аңламадың бит...» дисеңме? Юк, алай дип тә әйтеп булмый. Коммун төзергә тиешле кешеләрне саклап калу өчен тырыштым бит мин. Барыбер аякка баса алмас кешеләрнең паегын коммун нәселен дәвам итүчеләргә бирдем. Үзем,-грамм да артык алмадым. Актларда да шулай язылган. Безгә беренче ипи уңган елны ук төзергә кирәк иде социализмны. Аңа көчле-куәтлеләр кирәк. Кем чәчә, кем урып-җыя? «Безнең беренче бурыч — көчсезләргә ярдәм кулы сузу»,— дидегез инде сез, гражданин судья. Юк, көчлеләр кирәк, ярлы булсын, ябагай булсын, көчле булсын — Хәсәннәр кебек, Морат ишеләрдәй. Көчле белән төзелә ул коммун... Ә минем әле бирешергә исәп юк, гражданин судья. Әмма ләкин мин бит совет хөкүмәтенең дошманы түгел, ышан, гражданин судья. Шуны аңлыйсызмы сез?.. Йорт-илсез сукбайга әверелсәм дә...»

Зәңгәр күккә уктай атылган тургайлар сайравын тыңлый-тыңлый, Асыл үз-үзе белән шулай бәхәсләште.

Ташлык очыннан кайтып килгән көтү авыл өстенә тузан болыты күтәргәндә, Асыл тагын Акбүзенә менеп атланды. Текәй буйлап авылга якынлашты. Менә Хәсәннәр планы. Кечерәк булса да, яңа өй салып җибәргән Хәсән. Абзар-курасы да ару гына күренә. «Шуңа барам. Аннан башка кемем бар соң минем авылда?» — дип уйлады ул. Капка төбендә атыннан төште. Тезгенне киртәгә бәйләүгә, аны таш койма буенда уйнаучы ыштансыз малайлар сырып алды. Асыл аларга текәлеп-текәлеп карады, ләкин, күпме генә тырышмасын, берсен дә ата-анасына охшатып төсмерли алмады. Аннары ул капка төбендәге сандык чаклы таш өстенә утырды. Капчыгын чишеп, Уфада алган конфетларын балаларга өләште. Алар, конфетларын кайсы авызына кабып, кайсы учына йомарлап, шунда ук өйләренә таралыштылар. Асыл капчыгын тезенә куйды да башын түбән иде. Шул чакны киртә артыннан бер хатын-кыз тавышы килде:

— Әллә Хәсән кирәк идеме?

Асыл сискәнеп китте, башын күтәрде. Аның алдында талдай нечкә билле, күзләре уйнап торган, чегән кебек кара бер хатын басып тора иде. Асыл беравык югалып калды. Яңакларын баскан сакал-мыегын уып, телен тирбәтеп әйтергә сүз таба алмый интекте.

— Ул кирәк иде шул,— диде Асыл, аннары: «Чибәр нәрсә элэктергән үзе, авылдан микән, кем кызы икән?» дип уйлады.

— Хәзер кайтып житәр ул. Даулы болында печән эскертлиләр, ә син кер, ерак юл кешесе булырга охшыйсың, Хәсән кайтканчы чәйләп алырсың...

— Рәхмәт. Монда гына көтим әле мин.

Чуер таш араларыннан чылтырап аккан чишмәдәй саф тавышлы хатын сүзенә каршы ул шулай диде.

Хәсән соң гына кайтты. Башта ул Асылны танымый торды. Танырлык идемени соң! Бөтен йөзен сары сакал-мыек баскан, өстендә житмеш ямаулы җилән, аягында тире оек, чалбар ертыгыннан ике тез башы күренеп тора. Хәсәннең иңендә эскерт куя торган өч җәпле озын саплы агач сәнәк. Аны күрү белән, каяндыр, ишегалдында шым гына уйнап йөргәннәрдер инде, балалары йөгереп чыкты. Балалар Хәсәнгә сарыл-

дылар да капка төбендәге таш өстендә утыручы Асылга карап тын калдылар. Хәсән иңендәге сәнәген капкага сөяде, Асыл янына килде. Асыл да торып басты. Алар күзгә күз карашып тордылар. Хәсәннең кашлары җыерылды.

— Асы-ы-ыл, синме бу? — диде ул пышылдап. Асыл аңа кулын сузды.

— Мин... Алла ташламаса, дуңгыз ашамый дигән кук, менә кайттым,— диде ул, Хәсәннең кулын кысып. Аннары:— Минем сыенып кешем юк инде. Бүгенгә кумасаң...— дип өстәде.

— Иелгән башны кылыч кисми, Асыл. Әйдә кер. Тамак ялгарбыз, кунак булырсың, аннары күз күрер... Ә бу ат кемнеке? — дип сорады Хәсән, киртә кимереп торучы Акбүзгә таба ишарәләп.

— Минеке, шуның белән кайттым... Колхозга бирермен дидем.

Асыл Акбүзнең тезгенен чиште, атны ишегалдына алып керде. Хәсән, аны лапаска кертеп, алдына печән салды. Өйдән үзенең иске, ләкин чиста киемнәрен алып чыкты һәм ишегалды уртасында ни кылырга белми басып торган Асылга дәште.

— Әйдә, буага төшеп меник, өс-башыңны да алыштырырсың, кич белән су да җылы була,— диде.

Алар инешкә таба сөзәкләнеп төшкән тыкрыктан буага таба атладылар. Атлы арба йөрмәгәнгә, тыкрык кучкылланып торган яшел бәбкә үләне белән капланган. Моны Асыл үзенең калын табанлы тире оегы аша да сизде. Тыкрыкка кереп бераз баруга, ул оегын салды, үз авылының үзе аунап үскән су буе үләннәренә ялан аяк басты. Бәрхеттәй бәбкә үләне табан астын әллә ничек, йөрәкләргә тиеп кытыклагандай булды. Бераз бару белән бу халәт бетте, үләннең салкынча табигате үзенә бер рәхәтлек өстәп, бөтен тәненә таралды. Буаның талтирәкләре каплаган, элек, малай чакта, баш түбән сикерә торган яры янында чишенделәр. Асыл ярдан суга сикерде, үз авылының җанга рәхәт суында колач салып йөзде, чумган арада, Хәсән күрмәсен дип, тончыга-тончыга хәтта суны эчте дә. Их, Хәсән, Хәсән, белсәң иде син бу көннәрне күрү өчен ничек тилмергәнен Асылның! Чумганда да, колач салып йөзгәндә дә Асылның уенда шул булды. Ә Хәсән әнә ничек тыныч. Гомергә шушылай булган һәм булырга тиеш, бу суларның, бу әрәмәлекләрнең, бу җирләрнең төп хуҗасы мин дигәндәй ашыкмый гына юына иде. Аннары ул да пошкыра-пошкыра чумып алды, аргы яктан ук уратып йөзеп килде. Әнә ул инде ярда, мускуллары уйнап торган гәүдәсен сөлге белән сөртә. Көч ташып тора Хәсәндә. Ә Асылда элекке куәтләр юк. Аның кулбаш сөякләренә хәтле калкып тора. Хәсән киенеп беткәч кенә, ул сабын белән мунчала алды. Асыл бер кат юынгач, Хәсән кесәсеннән уч төбе чаклы көзге белән пәке чыгарып:

— Мә, егет булып кайт әле өйгә, бабай,— диде. Көзгене үзе тотып торды, Асыл кырынды. Йөзе сакал-мыектан арынгач, үзен икенче кеше итеп тойды Асыл. Сабынланып, тагын бер чумып чыкты да чиста киемнәр киде. Тәне җиңеләеп китте. Ул үзенең ничәмә еллар сөйрәгән сәләмәләренә карады. Алар якын да, кызганыч та булып тоелда аңа. Шуларны җыя башлагач, Хәсән кырт кисте:

— Сиңа нигә ул аламалар, бет оясы! Ташла. Өстеңә кидергәнне салдырып алмам, курыкма. Ә боларны яндырыйк,— диде. Тире оегын гына алып калды Асыл. Калганнарының көлен күккә очырды.

Өйдә көтәләр иде аларны.

— Әллә баттылармы дип хафалана башлаган идем, исән икәнсез, аллага шөкер,— дип каршылады аларны Хәсәннең хатыны Бәрия. Өстәл янына утырышкач, олы агач табак белән тавык салып пешерелгән токмачлы аш китереп куйды. Шунда ук кече якта чыркылдашкан балаларына да кычкырып алды:

— Т-с-с! Тавышыгыз чыкмасын, әнә бу абыегыз капчыгына салып алып китәр үзегезне!

Бу сүздән Асыл кинәт сискәнеп китте, аның иреннәре куырылды, йөзенә кара болыт инде, ул башын түбән иде. «Капчык... капчык...»

— Син нәрсә, Асыл, әллә теленне калдырып кайттыңмы анда? Һаман аяклы мәет кебек... Булган — буявы сеңгән, брат!

Хәсәннең шулай дип эндәшүе генә аның исәрләнеп барган күңелен фани дөньяга кайтарды.

— Болай гына, кайтуыма, менә сезне күрүемә ышанып бетә алмыйм әле,— дип җавап бирде Асыл, башын күтәрә төшеп.

Алъяпкыч астына гына яшереп, Бәрия Хәсәнгә бер шешә китереп тоттырды.

— Бала-чагага сиздермәгез берүк,— диде. Үзе кече якка чыгып китте, балалары белән бергә утырды.

Беренче чәркәне сүзсез генә чәкештереп эчтеләр. Агач табактан олы кашык белән аш ашадылар. Әй, үзеңнекеләр пешергән ашка ни җитә! Әле хәзер дә аның тәме, хуш исләре аңкып тора. Туган җирендә беренче капкан, авызланган бу аш-суны гомеренә оныта алмас Асыл. Тикмәгә генә:

Барып кергәч тәген Гардәле —
Ризык йөртә икән бәндәне,—

— дип җырламаганнар шул борынгылар. Әнә шул эчәр сулары, ашар ризыклары тартып кайтаргандыр инде аны. Ит алдыннан тагын бер чәркә кабылды. Майлы сап-сары тавык итенә сузылганда Асылның куллары калтырады... Унөч еллап бит инде аңа бу нигъмәтне тату түгел, күрергә дә насыйп булмады. Тавык итенең үзенә генә хас ләззәте теленә йөгерү белән аның күңеле тулды, күзенә яшь пәрдәсе сарылды.

— Их!..— диде ул, авыр көрсенеп. Хәсән дәшмәде, тоз сибә-сибә ит ашавында дәвам итте. Шулпадан соң олы җамаяк белән чөгендерле катык ашадылар. Асыл алдына салган тастымал белән авызын сөртеп алды һәм һаман кече якта балалары белән мәш килгән Бәриягә каткат рәхмәт әйтте.

Алар ишегалдына чыктылар. Хәсән лапаска таба атлады. Асыл да аның артыннан иярде. Икесе дә Акбүзнең ике ягына бастылар, ял астыннан аның муенын чәбәкләп алдылар.

— Әйбәт ат,— диде Асыл, Акбүзен иркәләп. Хәсән тәмәке төрә башлады. Асылга да кәгазь сузды. Тәмәке салды. Кабыздылар. Ике-өч суыргач, икесе дә лапас стенасына терәп куелган озын баскычка сөйкәлделәр.

— Я, Асыл, кулың белән эшләгәнне иңең белән күтәрдең, инде ни эшләргә исәп? — Хәсән шулай дип сүз башлады һәм:— Бу нинди ат, башта шуны әйт, дөресен генә,— диде.

Асыл иңнәрен җыерды, тәмәкесен өзеп-өзеп суырды да:

— Атмы?.. Габдрахман бай аты бу,— диде.

— Ничек?.. Әллә кая Себер җибәрелгән Габдрахман бай аты ничек сиңа килеп эләксен? Чынын әйт син, Асыл. Иелгән башны кылыч чапмый.

Асыл үзенең кайда утыруларын, Габдрахман байны ничек эзләп табуын, аны сазга батыруын, Акбүзне кулга эләктерүен — барысын да яшермичә сөйләп бирде. Хәсән аны бүлдермәде, тәмәке пыскыта-пыскыта тыныч кына тыңлады.

— Гөнаһына күрә җәзасын алган кешене тагын нигә җәберләргә? — диде ул аннары.

— Тырнак белән дә чиртмәдем... Ләкин иманын укыттым мин аның. Ә мин сиңа моны әйтми кала алмыйм. Бөтен нәрсәне үз эчендә сак-

лаудан да авыр нәрсә юклыгын белсәң иде син... Менә сөйләгәч, бераз җиңеләеп китәсең. Ә минем синнән башка сөйләр кемем бар?

— Их, кеше булырга кирәк бит инде сиңа да, яшьлеккә таба бармыйбыз ич. Кырыкның өстенә басарга торганда сиңа да болай, адашкан торна кебек, йөрү килешми.

— Башны гел юләргә салсам, монда, авылга кайтмас идем дә мин, Хәсән.

— Анысын да дөрес эшләгәнсең... Тик мир дигәнең гафу итәр микән,ниләр генә кыланмагансың син без юкта? Аларны үз күзләре белән күргән кешеләр ни дияр дә, шулар күзенә син ничек карарсың?

— Соң бит мин дә яшәргә тиеш. Хакым булмаса, һаман утыртырлар, я атарлар иде мине...

— Язылган законнар, язылмаган законнар да була, Асыл. Кайчак аның язылмаганнары катырак.

— Бик беләм. Шуңа да башлап сиңа сугылдым, борын төрттем... Мин дә бит синең кебек күпме нужа суы эчеп үстем, күз алдың. Син аңласаң, башкалар да аңларлар... Читкә тибәрмә мине, Хәсән.

— Мин хәлеңә ничек тә керергә тырышырмын, әлбәттә...— Хәсән тәмәке төпчеген җиргә ташлады, аяк очы белән ышкып сүндерде. Аннары сорады:— Ничек көн итмәкче буласың? Колхозда эшләргәме исәп, әллә берәр учреждение ише җирдәме? Район үзәге бит хәзер бездә, ишеткәнсеңдер?

— Портфельләргә үрелерлек рәт юк, үзең беләсең. Колхозда булмыйча кайда эшлим ди мин. Әнә Акбүзем белән икебезгә берәр җаен чыгарырсыз әле.

— Иртәгә иртәнге нарядка бергә барырбыз. Син белмисеңдер дә әле, Морат бит безнең председатель...

— Китсәнә!..

Асылның йөзе үзгәрде, сөмсерләре коелды. Күз алдына Моратның алыптай гәүдәсе килде. Шул бит аның кулларын каерып бәйләде, шул бит аны Минзәләгә илтте.

Асыл тешләрен шыгырдатып куйды.

Хәсән аңа күтәрелеп карады да:

— Ни бар? — дип сорады.

— Морат мине колхозга аяк бастырмас.

— Морат кына хәл итми аны, идарә членнары да бар.

— Арбаның алгы тәгәрмәче кайдан барса, арты шуннан тәгәри аның.

— Анысын иртәгә күрербез. Ә хәзер, әйдә, чәйләп алыйк та ял итик. Иртәгә таң белән кузгаласы бар. Даулы болынында быел печән каерылып уңды, күрсәң.

Хәсән шулай дип өйгә таба атлый башлаган иде, Асыл аны туктатты, бер серен чишмәгән иде әле ул. Аны әйтергәме, әйтмәскәме дип эченнән үз-үзе белән байтак тарткалашты. Ахырда Хәсәнгә әйтмичә түзә алмады. Хәсән яңадан баскыч янына килеп чүгәләде:

— Нәрсә бар? — дип сорады.

Асыл Габдрахман байның алтыннары турында сөйләде.

Хәсән аны көлемсерәп тыңлады да:

— Шул козгын сүзенә ышандыңмы? Тиле син, йөзгә берәү тулмаган,— дип урыныннан кузгалды. Асыл аның җиңеннән эләктерде.

— Ә ни өчен ул аны бик тә тәпсирләп әйтә: зиратның кыйбла ягында очы корыган нарат булыр. Башта шул наратны эзләп тап, диде. Аннан, кыйблага таба атлап, ике каберне калдыр да өченчесе янында тукта. Баш очында очлы таш булыр. Шул таштан кояш баешына таба җиде адым атла, бер кабернең нәкъ уртасына туры килерсең. Шул кабернең кыйблага караган итәгендә, өч түшәм тирәнлегендә тимер сандык булыр, диде. Менә ачкычын да бирде.

Асыл шулай дип тире оегының кайтарып куелган кунычын язды һәм андагы ямаулыкны ертып алды, җиргә көмеш чылбырлы ачкыч төште. Асыл аны җирдән алып Хәсәнгә сузды.

— Хак булса, бал-майда йөзәрбез. Сиңа да, миңа да җитәр,— дип пышылдады Асыл һәм утлыкка башын төртеп йокымсырап торган Акбүзгә ымлады да:— Син дә берәр ат тапсаң, хәзер үк элдерәбез... Тау арасыннан, турыга. Биш-алты чакрым гына ул турыдан,— дип өстәде.

Хәсәннең дә кашлары жыерылды. Сизде Асыл, аны да ата-бабадан калган милекчелек корты кимерә. Ләкин һаман ышанып бетми булса кирәк.

— Ниятлик, Хәсән, үкенмәссең...

— Син чәйли тор, мин бригадирга барып килим әле, ул атын дворга илтмәгәндер бәлкем.

Хәсән шулай диде дә эре-эре адымнар белән урамга таба атлады. Күп тә үтмәде, ул олы торыклы бер сары алашага атланып кайтып житте. Өйгә кереп, хатынына нидер әйтеп чыкты. Асыл Акбүз өстендә иде инде. Алар, авылны чыгу белән, чишмәле саз асты иңкүлегенә таба юыртып киттеләр. Тау араларына килеп кергәндә, тәмам караңгыланды. Асыл алга чыкты һәм Хәсәнгә карап, көр тавыш белән:

— Күземне бәйләп җибәрсәләр дә, турыга барып чыгам мин ул зиратка, — диде.

Хәсән җавап кайтармады. Алар башта межа буйлап бардылар, каенлыкка җиткәч, уңга борылдылар. Алда Кәүҗияк утлары елтырап күренде. Менә зиратка да килеп җиттеләр. Атларын аның кыйбла ягындагы киртәсенә бәйләп куйдылар да киртә аша зират эченә сикерделәр. Наратны тиз эзләп таптылар. Асыл Габдрахман байның сүзләрен ятлап бетергән. Кыйбла ягындагы өченче каберне дә, аның очлы ташын да шундук тапты һәм кояш баешына таба җиде адым атлады да (кулына кай арада, ничек эләктергәндер ул аны!) көрәге белән төртеп:

— Менә шушында булырга тиеш, Хәсән,— дип пышылдады. Хәсән аның янына килеп тезләнде. Асыл тиз-тиз казый башлады. Күп тә үтмәде, көрәк чыңлап ниндидер тимергә тиде. Асыл тагын да җилкенеп казырга тотынды, үзе гыж-гыж килә. Менә ул көрәген читкә ташлап, чокырга иелде, тимер сандыкны сөйрәп чыгарды. Авырлыгы поттан артык иде. Асыл түзмәде, сандык өстен җиңе белән сыпырыштыргалады да көмеш чылбырлы ачкычын кесәсеннән алып, сандыкны ачты. Анда алтын-көмеш елтырап ята иде. Асыл калтыранган куллары белән аларга орынды, чыңлаган тавышлар чыкты. Хәсән дә аларныroткалап карады. Алтын беләзекләр, алтын калаклар, борынгы алтын акчалар, тагын әллә нинди әйберләр белән тулы иде сандык. Асыл аны бикләде, зираттан үзе күтәреп чыкты. Хәсәнгә атына атланырга кушты һәм сандыкны аңа сузып, зиратка таба йөгерде. Көрәген онытып калдырган икән.

Атларын җай гына атлатып кайтырга чыктылар. Каенлыкта ай калыкты. Җылы. Тын. Ара-тирә басу чикерткәсе генә сайрап ала. Менә баш очыннан, утлы күмер төсле күзләрен ялтыратып, киң канатларын тавышсыз гына җилпеп, мәче башлы ябалак очып үтте. Межа буенча барып, тау арасына кергәч, Асылның күңеленә әллә нинди уйлар килә башлады. «Ялгышмадымы ул Хәсәнне ияртеп? Үзе генә барып ала алмый идемени ул аны? Гомеренә житәрлек байлык бит ул сандыкта. Ә хәзер урталай бүләргә кирәк. Хәсәнгә дә өлеш чыгармый булмый. Ату, барыр да әйтер, кал аннан кулыңны учлап... Бер үзе дә эшли ала иде бит ул аны. Башта ук, авылга, Хәсән күзенә кайтып күренгәнче үк. Ярык тау итәгенә төшеп житәрәк тирән упкын бар. Шуңа якынлашканда Асылның бөтен гәүдәсе калтырый башлады. Ул көрәген кысып тотты, Хәсәнне юри алгарак уздырды. Упкын турына килеп җитү белән көрәген күтәрде һәм Хәсәнгә кизәнде... Ләкин суга алмады, ничектер

кулы бармады... Көрәге лапылдап җиргә барып төште. Асыл сүгенеп җиргә сикерде. Көрәген кармалап тапты да туктап торган Акбүзенә сикереп менеп атланды. Күңелендә кинәт үч корты борынлады. «Шул да бит әле мине ничәмә еллар ристан итеп йөртүчеләрнең берсе... Бәреп үтерергә дә бакыр базына кертеп ташларга... Этем дә таба аласы юк». Кара-каршы чишмәгә җиткәндә ул тагын көрәк сабын сындырырдай итеп кысты. «Чишмәләр өстендә генә бакыр базы. Кое кебек авызлысына ташлыйсың да — вәссәлам. Аннан сандыкны әләктер дә дүрт ягың кыйбла. Хатыны да минем кемлекне белеп бетермәде бит әле. Юк, әйтергә житешүе дә бар...» Кара-каршы чишмә буеннан үткәндә кайнаган канын көчкә тыйды Асыл. Текәйгә җиткәч кенә ул иркен сулыш алып куйды. Иңеннән әллә нинди авыр йөк төшкәндәй булды.

Икенче көнне Асыл өйлә җиткәндә генә уянды. Өйалды ишеген тыштан җиңелчә генә элгәннәр иде, кагылу белән ачылып китте. Хәсән аны уятып тормаган, эшкә китеп барган. Ишегалдына чыгу белән, лапастагы Акбүз кешнәп җибәрде. Асыл, аның янына барып, атның иңбашларын сыпырды. Шул чак, нишләп йөргәндер, бәрәңге бакчасы ягыннан Хәсәннең үзе кебек үк кара чутыр малае — Газиз килеп чыкты һәм:

— Әткәй төш турында кайтам диде, сине көтсен, диде, абый. Мич алдында бәрәңге бар, әнкәй катык та бирерсең диде, — дип такылдап алды малай һәм: — Әйдә, абый, ашарга, — дип, Асылны өйгә керергә кыстый башлады.

Асыл юынып алды да өйгә керде. Өстәлдә бәрәңге белән катык тора иде. Аларны арыш икмәге белән әйбәтләп ашады. Үз тирәсендә бөтерелгән малайны урамга чыгып торырга кушты да, өйалдына чыгып, караватка, баш очына салып йоклаган сандыгын идәнгә алып куйды. Өйалды ишеген бикләде. Ачкычын карый башлады. Ләкин ачкыч юк иде. Чалбар каешына аскан иде,— юк. «Хәсән алган!» Башыннан яшен уты кебек әнә шундый уй үтте. Ул тешләрен шыгырдатты. «Әйтәм, уятмыйча да китеп барган!». Ачудан нишләргә белмичә, кулын артка куеп, сандык тирәли әйләнеп йөрде, аннары аны карават өстенә атып бәрде, өстенә мендәр каплады да тагын лапаска чыкты. Акбүзен чишеп алды. Сандыкны алып качу иде уенда. Шул чак капкада Хәсән күренде.

— Кая җыендың, Асыл? — диде ул, кече капкадан керә-керешкә.

— Менә атны эчертеп меним дигән идем... Нигә иртән уятмадың, үзең нарядка бергә барабыз дигән идең, — дип мыгырданды ул һәм кинәт кабынып китеп: — Ачкычны син алдыңмы? — дип сорады.

— Мин... Сайраплар йоклагач, уятырга кызгандым. Эш бүре түгел, урманга качмас, ял итсен, дидем.

— Китер ачкычны!..

— Нигә ул сиңа?

— Нигә дип, бүләргә кирәк... Аннары һәркем үзенекенә үзе хуҗа...

— Бүлеп тормабыз инде аны, Асыл... Алтын белән нишлибез? Хөкүмәткә тапшырырга кирәк аны.

— Нәрс-ә-ә-ә?

Асылның тавышы гыжлап, пышылдап чыкты. Ләкин Хәсән аңа игътибар итмәде.

— Алтын белән сату-алу итә торган кеше түгел без. Үзеңнең дә, минем дә башны әллә ниләргә бәйләп бетергәнче, котылыйк без ул сандыктан, — диде Хәсән. Асыл коелып төште, кулындагы тезгене ычкынды. Акбүз, ял иткәннән соң шаярасы килеп, Асылның иңбашына борынын төртеп-төртеп алды. Асыл моны сизмәде, авыз эченнән генә болай диде:

— Акылларың булмаса, шулай инде ул... Авызына әләккән мәмәйне йота алмаган бәндә белән эшләрең төшмәсен икән!..

Ул арада Хәсән сандыкны күтәреп чыкты һәм, берни булмагандай, Асылга дәште:

— Әйдә, киттек!

— Кая? — дип тә сорамады Асыл, хуҗасы артыннан ияргән эт сыман, башын түбән иеп, Хәсән артыннан урамга таба атлады. Милиция идарәсенә чыгып җиткәнче әллә ничә кеше очрады. Ләкин Асыл аларның берсен дә танымады.

Милиция начальнигы үзе кабул итте аларны. Хәсән вакыйганы сөйләп бирде.

— Асыл табышы бу. Хөкүмәткә тапшырыйк дип тә башлап әйтте,— диде Хәсән, Асылга карап. Асыл тешләрен кысты, ләкин түзде, бер сүз дә дәшмәде. Сандыкны ачып, аның эчендәге затлы әйберләрне өстәлгә бушаткач, милиция сызгырып җибәрде һәм шунда ук телефонга тотынды. Райком, райфо, банк белән сөйләште. Күп тә үтмәде, өч-дүрт кеше килде. Шулардан комиссия ясап, алтыннарны описька алдылар. Хәсәнгә дә, Асылга да кул куйдырдылар. Шулай итеп колак какты Асыл Габдрахман бай алтыннарыннан. Бәясе күпме иде бит. Сигез йөз егерме мең! Сигез йөз егерме!..

9

...Шаулаша-гөрләшә сыер савучы кызлар килеп керде. Кечке савымга төшкәннәр. Әнә берсе радиоалгычны борып җибәрде. Бөтен бүлмәгә йөрәккә якын «Сарман» көе таралды. Бу көйне ишетү белән, Асылның бөтен гәүдәсе тетрәнеп китә, баш миләренә тылсымлы җылы йөгерә... Әнә тагын берәү керде, ишекне түшәм туфраксаларын коярдай итеп каты япты. Харис бу. Әнә тамагын да кырып алды. Тагын ишек ачылды, ябылуы сизелмәде дә. Бусы — партоешма, Җәүдәт. Асыл башын мендәрдән күтәрә төште, Харис белән Җәүдәт бергә туры килсәләр, бәхәскә керми калмыйлар. Хак та шулай. Менә Харисның тамак төбеннән гөбердәп чыккан тавышы ишетелде:

— Җәүдәт абый, үгезләрне алыгыз... Уйнап-муйнап әйтүем түгел. Миңа урыннары кирәк аларның — икенче группаны симертә башларга...

— Харис туган, мин әйттем бит инде, аларны киләсе елда тапшырабыз дип, начальствоның фәрманы шундый. Агымга каршы йөзеп булмый.

— Кирәк чакта йөз, син бит парторг. Сырты ярылырдай булып симергән үгезләрне тапшырмый тору кем файдасына? Безгәме, хөкүмәткәме?

— Аңлыйм, аңлыйм, Харис туган, соң нишлим?

— Тапшырттыр!..

— Вәкаләтем юк.

— Йөрисең инде йонны уңайга гына сыпырып... Бел, быелгы сайлауда сине, кругом шестнадцать демократны, чөябез... Кыйбатка төшә башлады синең демократияң... Кәрәк тоттырып эшләтәсе бар сине!..

— Кушсалар, анысын да тотарбыз, әллә курка дип беләсеңме, Харис туган? Мин бит синең кебек үк җирдән яралган крестьян.

Алар әнә шулай байтак тел чарладылар. Харис кызды. Җәүдәт җайлап-көйләп кенә сөйләшә, кызмый. Сабырлыкны да биргән ходай үзенә.

«Шул Хариска да сеңдерерлек итеп бер нәрсә әйтми бит. Нигә чәбәләнә, ни җитми торгандыр Хариска. Тапшырылмаса ни, ятсын үгезләре ипине тирескә әйләндереп. Аныкын ашыйлармы әллә? Тапшырсаң, дөрес, акчасы килә инде аның. Әмма быел колхоз да нык утырган ел. Иген рәтләп уңмады. Башаклар эч салганда гына кызу китте, куырды игенне кояш... Шулай, капкан саен калҗа булмый ул... Ә Хәсәннәр шуңа чын күңелдән инанып йөри. Бар дөньяда бәндәләр, үзләре дә рәхәт күрми, кешегә дә тынгылык бирми. Шул Хәсән белән башын бәйләмәсә, бүген менә бу ферма өендә ятар идемени ул?»

Өйдәгеләр чыгып беткәч, Асыл үз-үзе белән әнә шулай бәхәсләшеп алды. Аннары күз алдына милиция идарәсе өстәлендә өелеп яткан алтыннар килде. Әнә алар ничек ялтырый. Күзен йомгач та әллә кайлардан җемелдәшеп күренеп торалар. «Җүләр булды шул, җүләр булды, үзе генә дә барып ала ала иде бит ул аны».

Асыл тирән итеп көрсенде, икенче якка борылып ятты.

## 10

Алтынны тапшырганнан соң, Асыл үзен ниндидер изге әйберсен җуйгандай тойды. Морат аны эшкә кушты. Акбүзе белән печән эскертләүдә йөрде. Аннары көлтә ташыды. Әйбәт эшләде бу елны Асыл. Тигән ипие генә күпме иде. Хәсәнгә кайтарып аударды.

Шул елны өмә ясап, колхоз өч кенә тәрәзәле бер йорт салып бирде. Шул елны ул өйләнде. Күрше авылдан, кем әйтмешли, дөя хәтле сазаган кыз алып кайтты, килгәндә юанлыгы, мин сиңа әйтим, мич чаклы булгандыр. Бер елда рәте китте тегенең, чиргә уралды, хатын-кыз чиренә. Карт кыз булгандыр инде... Ике ел дигәндә кипте, корыды һәм гүр иясе булды. Шуннан соң Асыл бүтән өйләнә алмады, эчүгә сабышты... Хәсән белән Морат юмалап, көйләп карадылар да аннары кул селтәделәр.

Иртәгә сугыш башлана дигән көнне ул тавык кетәге кебек өен сатты. Шимбә көн иде. Көнозын чәйханәдә кемнәр беләндер эчте. Саткан өенә кайтырга гарьләнеп, кич кенә атлар дворына төшеп китте. Ат караучыларның ай-ваена карамыйча эчкә үтте. Акбүзен эзләп тапты, аның муенына асылынып, иреннәреннән үбә-үбә елады. Ахырда рәшәткәле утлыкка авып, шунда йокыга китте. Иртән күзен ачканда дворда бер җан иясе дә юк иде. Чатнап авырткан башын кысып, тагын чәйханәгә таба юнәлде. Кесәсендәге кулъяулыгына төйнәп салган акчасын капшап карады. Бар, исән. Баш төзәтергә дә ерак сәфәргә — кыргыз дуслары янына китәргә иде исәбе. Урамга төшү белән, ул тыз-быз йөгерешкән кешеләрне күреп гаҗәпсенде. Әллә берәр җирдә ут-мазар бармы дип, авыл өстенә күз йөртеп чыкты. Юк, бер җирдән дә төтен-мазар күтәрелми. Эреткән кайнар кургаш тутырылгандай башын түбән иеп, чәйханәгә килеп керде. Монда да бүген нигәдер кеше күп иде. Моңа да гаҗәпсенде Асыл. Ләкин берәүгә дә күтәрелеп карамады, буфет алдына килде дә йөз илле грамм салып бирергә кушты. Баскан килеш кенә каплады стаканны. Иркен сулыш алып, авыз кырыйларын сөртеп куйды да тәрәзә янындагы өстәлдә бер-бер артлы чәкүшкәләр аударып утыручы кордашлары янына килде. Асылны алар каш җыерып каршыладылар. Сизелеп тора: компаниягә аласылары, аның белән сөйләшәселәре килми. Яннарына килеп басу белән, Камали дигәне, аңа төртеп күрсәтеп:

— Гитлер җиңсен генә, мена бу контр тагын баш калкытачак әле... — диде.

Камали кызмача иде. Асылның чигә тамырлары бармак юанлыгы булып бүртте.

— Нәрсә һаман бер балык башы чәйнисең? — дип ысылдады ул, ата каз кебек.

— Чәйнисе юк, контр тек, контр. Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый, диме.— Камали җиде катлы итеп сүгенде: — Тотсын Гитлер учлап!.. Муенын сындырмасак без аның! Иртәгә үк китәм! Мин бит фин сугышында да булган. Өйрәтеп-нитеп торасы юк сезнең кебек!

Асылның күзләре зур булып ачылды:

— Нинди Гитлер?.. Нәрсә бар соң?.. Әллә мин кичәгедән айныйммы, әллә сез юкны сөйлисезме?

— Сугыш!.. Гитлер сугыш башлаган... Безгә каршы. Сөен, контр! —

Камали шулай дип кычкырды да өстәлгә китереп сукты, өстәл өстендәге ике чәкүшкә идәнгә төшеп челпәрәмә килде. Асыл шешәләрне дә күрмәде, сугыш дигән сүз аның башына күсәк белән китереп суккандай итте. Үз атасы, Хәсәннең атасы, тагын әллә никадәр — япон, беренче бөтен дөнья сугышыннан кайтмаган кешеләр күз алдына килде. Беренчесендә ул Габдрахман бай гарипләндереп ташлагач катнаша алмады. Ә Хәсәннәр, Моратлар, менә бу Камалилар ул ут-давыллар аша бер үттеләр бит инде. Юк, хәзер чират Асылда, алар өчен бу юлы инде ул китәчәк. Юк, совет хөкүмәтен Габдрахман бай белән алыштырып булмый. Ни әйтсән дә, үз хөкүмәтең... Асылның йөрәге җилкенде. Ул Камалиның контр дигәненә дә рәнҗемәде, исәрләнеп, өстәл артындагыларны берәм-берәм кочаклап чыкты да:

— Китәм, бүген үк! Сезне сыйлап китәм. Үлсәм, бер искә алырсыз! — дип, кесәсендәге акчасын өстәлгә чәчте һәм официантка кычкырды: — Кил әле, биеп йөр бүген минем алда! Әллә кабат күреп була бу дусларны, авылны... Сыйла безне, ал шул акчаларны!

Камали гына һаман киреләнде:

— Контр акчасына эчмәсәм, минем үземнеке юкмыни,— дип, ул урыныннан ук торып китә башлаган иде, аны иңнәренә басып яңадан утырттылар.

Бераздан бөтенесе бергә, урамнарны иңләп, кочаклашып җырлый-җырлый, хәрби комиссариатка киттеләр. Хәрби комиссариат ишегалды кеше белән тулы иде. Беркемгә дә баш бирмичә, юлда очраганнарны этә-төртә, Камали комиссар янына кереп китте. Бераздан ул чәчләрен бәс сарган олы яшьтәге майор белән килеп чыкты һәм, ишек төбендә чайкалышып торган Асылларга төртеп күрсәтеп:

— Бүген үк китәбез, безгә повестка гына бирегез, атын да, озатучысын да үзебез табабыз, иптәш майор, — диде ярсый-ярсый. Майор аларны көчкә тынычландырды, иртәгә килергә кушты.

Иртән алар барысы да килделәр. Майор аларның үтенечен кире какмады. Шул көнне үк Чаллыга чыгып киттеләр.

Казанда Асыл Камалидан аерылды. Казан янындагы хәрби лагерьда бер айлап өйрәнгәннән соң фронтка китте. Барганда ук, эшелонналарын бомбага тоттылар. Асыл товарный вагон ишеге янында басып тора иде. Әллә кайдан, урман артыннан «юнкерс»лар килеп чыкты да, состав өстеннән улап үтеп, икенче әйләнештә бомба яудырырга тотындылар. Асыл ишектән очып барып төште. Күзен ачканда инде кайдадыр еракта үз составлары дөрләп янганын, аның тирәсендә кемнәрдер йөгерешкәнен күрде. Ул, көч-хәл белән торып, шунда таба китте. Взводыннан ике солдатны очраткач, куанычыннан нишләргә белмәде. Аларга үлгәннәрне күмәргә кушылды. Көнозын кабер казыдылар. Күп иде мәет. Тимер юл буенда яңа бер зират барлыкка килде диярлек... Кичкә хәтле юлларны ремонтлап бетерделәр. Икенче эшелон килде. Шуңа төялеп, юлларын дәвам иттерделәр. Украина җирләренә барып җиттеләр. Нindидер бер хутор янында төшерделәр дә, шушында оборона totasыз дип, траншея казырга куштылар. Казып кына бетергәннәр иде, чигенергә приказ булды. Шулай чигенә-чигенә бик күп траншея казыды алар. Ә үзләренең әле бер генә дә тере немец күргәннәре юк. Немецлар белән беренче тапкыр егерме бишенче көнне очрашты ул. Траншеяда иделәр. Асыл кул пулеметының икенче номеры. Ячейкалары тирән, брустверлары нык. Таң алдыннан — тревога. Ул да булмады, траншея өстендә снарядлар ярыла башлады, җирләр селкенде. Өскә шыбырдап балчык һәм тузан коелды. Асыл үзенең беренче номеры — Себер русы Сидоров белән траншея төбенә сузылып ятты. Менә снарядлар ярылудан туктады. Ул да булмады, берьюлы меңләгән трактор тавышы ишетелде кебек.

— Танклар!..

Траншея буйлап шундый сүз таралды. Асыл, башын да күтәрергә куркып, җиргә сеңде. Бетүләрем шушы икән дип уйлады. Әнә Сидоров сикереп торды, пулеметка ташланды. Ләкин атмый. Менә ул Асылга кычкырды:

— Тор, урыныңа бас!..

Асыл, дер-дер калтырап, аның янына килде. Бруствер өстенә үрелеп, сугыш мәйданына карады. Танклар, пушкаларыннан ут төчкерә-төчкерә, алар өстенә ыргылалар. Алар артыннан җиңнәрен сызганган, күкрәкләренә автомат аскан немецлар йөгерә. Менә танклар якынайды, траншеяга җитәргә йөз-йөз илле метрлар гына калды. Шул чак безнең ПТРлар телгә килде. Әнә бер танкны төтен урады, берсе туктап калган, урынында әйләнә башлады. Өченчесенә ут капты. Алар танклар артыннан килүче немецларга ут ачтылар. Ләкин немецлар көчле иде шул. Арттагырак танклар алга ябырылды. Һәм алар артыннан траншеяларга пехота бәреп керде. Кул сугышы башланды. Сидоров әнә бер немецны пулеметның тимер прикладлы белән бәреп екты. Аңа икенчесе ташланган иде, анысының башына Асыл җитте — мылтыгы белән тэрәп диярлек атты. Шуннан башкасын хәтерләми. Башына нидер бәрелгәне, күзеннән утлар чәчрәгәне генә исендә. Аңына килгәндә, ул траншея төбендә кемнеңдер гәүдәсе астында ята иде. Көч-хәл белән чыкты. Караса, аю кебек бер немец. Төн. Күктә — тулган ай. Аңа карагач, Асылның кычкырып елыйсылары килде. Туган авылы, Хәсәннәр, Моратлар күз алдыннан үтте. Башы шаулый, чатнап-чатнап китә иде. Ул, кармаланып, мылтыгын эзләп тапты һәм үрмәли-мүкәли траншея буйлап китте. Әнә кемдер ыңгыраша. Ул шул якка таба атлады. Бер сержант. Асыл аны иңенә салды. Юк, алып бара алмый. Баш очына утырды, күзләренә яшь килде. Әнә шул хәлендә аны әләктереп алдылар. Сержантны машинага чаклы аягыннан сөйрәп киттеләр. Озак барды машина. Менә ул туктады. Асылны бер чиркәүгә кертеп җибәрделәр. Егермеләп кеше бар иде анда. Кинәт Асылның колагы ишетә башлады, баш авыртуы да басылгандай булды. Ул арлы-бирле йөрергә тотынды. Качарга, ничек тә качарга! Чиркәүнең сәхнә кебек биек урынында дүрт почмаклы капкач сыман нәрсә күрде. Аны күтәрде. Баз сыман җир иде бу. Шунда төшеп китте. Кармалана-кармалана йөри торгач, тимер челтәрле тәрәзәгә туры килде. Әмма тимер челтәрләр нык иде. Ул тагын эзләнергә тотынды. Кулы ишеккә тиде, аны ачып эчкә үтте. Бәләкәй генә подвал иде бу. Анда капшанып йөри торгач, икенче ишеккә юлыкты. Ләкин ул тыштан бикле иде. Аның янындагы почмакта кулына кирәк тиеп китте. Тагын кармаланган иде, авыр гына ломга тап булды. Эчендә җылы керде Асылның. Ул теге тәрәзә янына килде. Лом белән тимер челтәрне каера башлагач: «Т-с-с, спокойно!» дигән тавыш ишетте. Сискәнеп китте Асыл. Шунда ук аның иңенә ике кул басты. «Курыкма, синең кебекләр»,— диде берсе пышылдап һәм, Асыл кулындагы ломны алып, тимер челтәрне үзе каера башлады. Озак маташтылар. Тәрәзәнең ике ягына да өелгән кирпечләрне сүтә-сүтә генә алдылар рәшәткәне. Әнә — куаклык. Бакча булса кирәк. Башлап Асыл үрмәләп чыкты. Тирә-якка колак салып тыңлап торды. Чыннан да, бакча иде бу. Урам якта, ишек төбендә, часовойның арлы-бирле йөргәне ишетелә. Асыл тәрәзәгә иелеп, кул болгады. Аннан ике кеше чыкты. Алар, үрмәләп, куаклар арасына кереп киттеләр. Менә биек утыртма койма. Асыл өскә күтәрелде. Биек яр буендагы чиркәү иде бу. Аста ялтырап кечерәк кенә инеш ага. Аның төбендә, көзгедә чагылгандай, ай ялтырый. Асыл койманың икенче ягына сикерде. Аның артыннан теге ике кеше дә койма аша шулай төштеләр дә шым гына, күләгәләр кебек, текә яр астына шуыштылар. Зур бер авыл читендә булып чыкты бу чиркәү. Елга яры буйлап йөгерделәр. Биш-алты чакрымлап киткәч кенә туктап хәл алдылар. Озын буйлысы Асылның кулын кысты.

— Молодец, тәвәккәл кеше икәнсең! — диде. Таныштылар. Озын буйлысы кече лейтенант иде. Ә бәләкәй гәүдәле, олы башлысы чуваш егете икән... Асыл да үзен атады. «Якташ икәнсез бит!» — диде чуваш егете татарча. Асыл аны кочаклап алды. Бу төндә, бу мәхшәрдә татарча сүз ишетү аның күңелен нечкәртеп җибәрде һәм аңа ниндидер бетмәс-төкәнмәс көч өстәлгәндәй булды.

Таң беленгәндә, алар елга буендагы бер әрәмәлектә иделәр. Көн шунда үтте. Караңгылык иңгәч, тагын кузгалдылар. Атнадан артык шулай иза чиккәннән соң гына, алар үзебезнекеләргә килеп кушылдылар. Өчесен дә кайдадыр формировать ителә торган яңа частька җибәрделәр.

Сугыш беткәнче йөрергә туры килде Асылга ут эчендә. Ләкин ник кенә бер яралансын — аңа дигән кургаш коелмаган, күрәсең. Әмма куркак дип әйтә алмыйсың аны. «Батырлык өчен» медален тикмәгә генә бирмиләр. Ә ул икене тагып кайтты.

Истә калганы тагын шул... Ике ай оборонада бергә булган, бер котелоктан ашаган иптәше белән засадада яталар иде. Немец траншеясы йөз илле адымда гына. Хәтта сөйләшкәннәре ишетелеп тора. Авыз гармуннары уйнаталар. Сүз башламасынмы теге шул чак. «Син теләсәң нишлә, мин ычкынам немецларга, менә парольләре дә бар, — дип, кесәсеннән немец листовкасы чыгарды. — Мин бит дворян малае, болай йөри торган кеше идеммени мин...» — дип тә өстәде. Асыл дәшмәде. Моны ризалык билгесе дип уйлагандыр инде. Хәсрәт, печән эченнән чыкты да, кулын күтәреп, немец траншеясына таба йөгерде. Асылның күз алдына Габдрахман бай килде. Аның күзләрен кан басты һәм ул күп уйлап тормады — автоматының чакмасына басты. Теге, көлтә кебек, җиргә ауды. Ике яктан да атыш китте. Немецлар әллә ничә рәт мәетне алырга маташып карадылар. Ләкин безнең траншеялардан яудырылган ут немецларга баш калкытырга ирек куймады. Аннары ике як та тынды. Төнлә генә кайтты засададан Асыл. Бер медален шуның өчен бирделәр.

Аның өчен сугыш Прагада бетте. Сугыштан соң туры авылга кайтты. Ай, авыр иде заманнар. Сугыш вакытында бушап калган бер йортта яши башлады. Аннары ферма өйләренә күчте. Күбрәк каравыл торды. Хәзер менә бу, элекке байларныкыннан бер ягы белән дә ким булмаган олы, якты, җылы ферма өендә гомер кичерә. Кушсалар, теләсә нинди эшкә дә бара. Бик кушмыйлар да. Карт дия торганнардыр инде. Үзе эш сорап алмый. Хәсәнмени ул үз кадерен үзе белмәскә, йөрсен әнә ул. Шуның өчен коммунист. Ә ул — гади кеше. Ә Хәсән кебек җүләрне шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Ихлас күңелдән йөри бит үзе. Асылның юлы менә ялгыш булып чыкты. Ә Хәсәннеке һаман дәвам итә. Үзе үлгәнче бара инде ул шул юлыннан. Ә Хәсән кебекләр киткәч, Җәүдәтләр шулай бара алырлармы? Андыйлар күпме? Хәсән сыңарлары юк дип әйтеп булмый. Теге гөбердәвек Харис, суйган да каплаган, Хәсән булачак...

## 11

Ишек әкрен генә ачылды. Шапылдатып яптылар. Моны да таныды Асыл: Хәсән керде. Әнә ул бияләйләрен салды, кулына җылы сулыш өреп алды да Асылга дәште:

— Йоклыйсыңмы, болай гына ятасыңмы?

Асыл юри күзен йомды һәм гырылдагандай итте. Ышанамы соң аңа Хәсән, ул тагын тавыш салды.

— Нәрсә карт маймылдай кыланасың?

— Кыланса соң!..

— Чык әле монда.

— Үзең кер.
Хәсән Асыл янына керде, өстәл башына, артсыз урындыкка утырды да:
— Бүген карчык мунча яккан иде, соңрак кагыл. Мунча күрмәгәнеңә дә ни гомер бит инде синең,— диде.
Асыл дәшмәде. Дөрес, дүрт-биш атна бар бугай инде. Хәсәннәрдә кереп кайткан иде соңгы тапкыр. Тәне дә кычыта. Күлмәк-ыштаннары да керләнеп бетте. Барсаң әйбәт булыр иде... Ләкин күңеле алгысый шунда барса. Тагын икенче кат гомер итеп ята бит Хәсән. Тагын балачага үстерә....
— Бармыйсыңмыни?
— Чамалармын әле, синдә генә димәгән мунча...
— Ихтыярың... Аннары, Асыл, син Җәүдәт турында теләсә нинди сүз сөйләп йөрмә. Ул бит колхозда партия башлыгы, ярамый.
Монысына инде Асыл түзмәде, сикереп торып утырды.
— Ә, алаймы? Ошамыймыни? Коммунистлар башлыгы булгач аңа килешә, миңа килешми, сиңа ярыймыни? — диде ул, тез башына сугып.
— Нәрсә килешә? Юньләп әйт әле.
— Үләрсең кылануына! Өченче көн үгез суйганнар иде. Бер-ике кило сорап амбар буена менсәм, бу да тора. Янында әллә ничә кеше, район нәчәлствосы. Фәлән кеше, фәлән кеше исемен яздырып боерык алганнар да ит бүлеп яталар. Ялт итте бер үгез. Миңа тәпиен алырга куша тагын... Тояк кимереп ятар чакмыни минем хәзер, ә?
— Кемнәр икәнен таныдыңмы соң?
— Танымый! Берсе райпо председателе, берсе мәктәп директоры, берсе теге, очлы борынлы, язып-сызып йөрүче, теге кем лә, гәҗит чыгаручы.
— Боерыкка кем кул куйган соң, хәтерләмәдеңме?
— Карамыйча!.. Минем үҗәтлекне беләсең бит син. Җәүдәт үзе кул куйган. Юри карадым, председатель өйдә югын беләм лә мин.
— Да-а!.. Сарыф итәләр колхоз малын. Моның төбенә төшәм әле мин, күрерсең...
— Кырырсың! Кул кулны, ике кул битне юа, диләр. Үзең җүләргә калырсың.
— Булмый торсын әле!.. Күпкә китте бу. Монда кая куярга белмәгән симергән үгезләр күп. Болай егып суя китсәң...
— Суярлар да, ашарлар да, син теш төбеңне суырып калырсың. Үзең ата коммунист, бала коммунистларың синнән акыллырак яши беләләр, рас менә!
— Син минем исемгә кагылма! — дип, Хәсән тавышын күтәрә төште. — Я, киләсеңме мунчага, юкмы?
— Тегене дә кыстырып килимме соң?
— Кил лә! Бер якалашып утырырбыз шунда, күңел булганчы бер сүгәрсең, украң басыла төшәр...
Хәсән шулай дип чыгып китте.

Асыл соң гына килде. Хәсән инде мунчага кереп чыккан, түрдә, каз мамыгыннан гына түшәлгән түшәктә, башына тастымаллар урап, хәл җыеп ята иде. Карчыгы әле кайтмаган иде. Алар кече кызы белән керәләр. Асыл исәнлек-саулык сорап тормады, Хәсәнгә күз төшереп алды да туның түш кесәсеннән бер ярты чыгарып, аны өстәл башындагы олы сандык артына куйды. Аннары өс-башын чишенде. Хуҗаның карчыгы мунчадан кайтканчы берәр чәркә салдылар. Асыл үзе ясап чәй эчте. Чынаягын каплап куйгач, сандык өстенә аякларын бөкләп утырды. Сары тешләрен ыржайтып сүз башлады:
— Хәсән, безнең колхоз кая таба барганын беләсеңме син? — дип

сорады. Хәсән башына ураган тастымалын караваг башына элеп куйды да:

— Ник алай дисең? — диде.

Асыл авызын ерды:

— Нигә коммунизмга барабыз димәдең?

— Дисә соң?

— Барасың.. Безнең счетка арест салганнар әнә.

Хәсән торып утырды.

— Сиңа сөенчеме шул?

— Еламыйм да, мин эшләгән түгел, эшләсем юк.

— Тагын украң котырамы?

— Котырса соң. Синең кебек сукырларны күреп котыра ул. Юрганыңа карап аягыңны суз, диләр иде элек. Алла, мөгез чыгара, имеш, яңа председатель. Авылны, имеш, генеральный план белән яңабаштан салдыра башлый! Башлады! Хәзер бөтен эшләгән шуңа кереп бетте. Быел, житмәсә, ипие дә уңмады. Колхозчың өч ай буе акча алмый утырсын әле... Кая барасыз болай, ата коммун?

— Зарплата була, аңа кагылма, сөенмә, рәтен чыгардылар инде аның...

— Ә кәк имеет права сезнең ул председатель колхозчының зарплатага дигән акчасын башка хаҗәткә тотарга?

— Соң, төзелеш бит, шул суырды инде аны.

— Ә менә миңа синең төзелеш кирәк түгел, ай саен каравыл торган алтмыш сумым килеп торсын, аны хөкүмәт тикмәгә уйлап чыгармаган. Син крестьянны хәзер ите бар, сөте бар дип кенә юата алмыйсың. Сугыштан соң юанган еллар да житәрлек булды. Яшисе килә аның хәзер... Яшәп каласым килә минем. Чыгар да сал миңа алтмыш сумымны! Аны да бирә алмагач, миңа синең әллә нинди, җылытмый торган ерактагы кояш кебек, генеральный планнарыңның поты бер тиен!.. Әллә нинди ыссудалары белән ике йөз меңнән артып киткән ди бит безнең хәзер бурыч. Киләсе ел ипи уңганда да көчкә очны-очка ялгарлык ди.

Юк, Асылның болай адәм рәтле сөйләшкәнен ишеткәне юк иде әле моңа кадәр Хәсәннең. Ул гаҗәпләнүдән авызын ачты, мыек очларын чеметеп алды һәм көлемсерәп:

— Чыннан да украң котырган синең бүген, Асыл. Бар, мунчада чабынып украңны коеп кайт әле,— диде, өйалды ишеге ачылуын ишетеп. Карчыгы белән кызы кайттылар. Асыл мунчага китте. Озак кërә ул мунчаны. Бу юлы да ике-өч сәгатьләп ятты. Хәсән бер кат йоклап та алды. Асыл кайтуга яңартылган самавар, парлар бөркеп, өстәл өстендә җырлап утыра иде. Асыл, олы сандык өстенә тунын җәеп, баш очына ястык салып хәл җыеп ятты. Дәшми-тынмый үзе ясап чәй эчте, аннары маңгаеннан аккан тирләрен муенына салган тастымалы белән сөртә-сөртә, Хәсәнгә дәште:

— Тор әле, тегене җибәреп бетерик.

Хәсән торып утырды, күзләрен угалый-угалый җавап бирде:

— Миңа житте, үзең чамала...

Асыл аңа карап торды да сандык артындагы шешәсен сөйрәп чыгарды, чәй йомрысын мөлдерәмә итеп тутырды һәм ипи кисәге иснәп, буранка авызына каплады. Аның йөзе бурлаттай булды. Беравык тын алмый торды. Аннары уфылдап җибәрде һәм өстәлдәге катык салынган ярты литрлы банкага үрелде. Аны тын да алмый эчеп бетерде.

— Синең бер әйбер укыганың бармы? — диде ул аннары, авыз кырыйларын җиң очы белән сөртә-сөртә. Хәсәннең дәшмичә, сораулы күзләрен үзенә төбәгәнен күргәч, сүзен дәвам итте: — Синең кебек җүләрләр үлеп беткәч, бу дөнья кая таба барыр икән?

— Матур көннәрдән рәхәт көннәргә, тагын да матур булыр дөньяларга.

— Аңламадың син мине. Менә без сугыштан кайттык. Мине исәпкә алма син. Мин — беткән баш. Менә синең кебекләр күп иде бит сугыш беткәндә. Уч төпләре кычытып кайтты алар сугыштан, эшкә кайттылар. Кайту белән, бу көннәрне дә күрәселәребез бар икән дип ашкынып, ярсып тотындылар эшкә. Өч-дүрт ел шулай үтте. Аннан байтагының күңеле сүрелде. Ягъни, мәсәлән, авылдан диюем, шәһәрне белмим мин... Ни өчен?

— Ни өчен соң? Син генә бит бездә белдекле, Асыл. Кеше эшләгәнгә теш кайрап ятучы.

— Белмисең шул. Минем дә кул дигәне бик кычытып тора иде дә бит. Мин дә тотынып карадым. Ә ни алдым? Бер хезмәт көненә йөз илле грамм!.. Әнә Хәсәннәр эшләсен колхозда, дидем. Итек баса башладым... Кемнәр генә ташлап китмәде авылны. Ә син калдың, мин җүләр калдым. Миңа ярый да инде. Итек басып үз көнемне үзем күрәм. Ә син яңа житкәнче үлән суы суырып ни дип йөрдең инде?

— Менә синең кебекләр картаймыш көнендә ачка кәкрәеп катмасын дип.

— Шалишь? Асыл катмас. Син шуны уйлаганың бармы? Менә синең кебек җүләрләр җилкәсендә чыктык бит без бу көннәргә. Әгәр сугыштан соң синең кебекләр булмаса, алар да койрыкларын сыртка салсалар, беткән иде колхозың. Синең кебекләр сугыштан соң икенче Гитлерны — ач-ялангачлыкны җиңделәр. Чигенмәделәр. Көнләшәм, ихлас көнләшәм мин синең кебекләрдән. Сезнең белән очар кеше идем бит мин, канатларым гына иртәрәк каерылды.

— Үзең гаепле.

— Мин генә микән? Шунда Морат белән икәүләп Минзәләгә илтмәсәгез, мин дә бәлкем бу көннәргә калмаган булыр идем. Хәер, ахири, син күргәннәр дә житәрлек булды, дошманыңа да язмасын. Иңендә ничә сугыш, сугыштан соңгы син ул күргәннәр! Чыдаса чыдый икән адәм баласы. Ә ни бирделәр сиңа? Кешедән кай җирең артык? Йорт-җирең, алган акчаң кешедән артыкмы?.. Мин контр булсам да, авылны ташлап китмәдем әле. Ә син, карының белән кар, борының белән боз ярганда, табышлы якларда йөргән кешеләрнең хәзер ничек яшәвен күрәсеңме? Шәп яшиләр.

— Алар бит әзергә кайтты.

— Син ясаган ояга кайтып кунакладылар, рас! Шуларны ике куллап кабул иттегез, әзер ояга күкәй салдырдыгыз. Валлаһи, җүләр сез, акылың юк синең, Хәсән!

— Соң алар да безнең кешеләр, авылдышлар бит. Туган ягына кайтмый кая китсеннәр. Туган туфрак барыбер тарта ул.

— Тарта, кәнишне. Пенсиягә чыккач, ничәмә кеше үләргә дип монда кайтты. Андыйларның үзләренә бер зират ачар идем мин. Элек әчеп үлгән кешеләрне күмә торган тирәдән.

— Йөрәгең карасы һаман юылып бетми синең, Асыл. Нигә син кешеләргә бу кадәр дошман?

— Минме дошман? Дошман булсам, сөлек кебек чагымда кулаягымны бәйләп Минзәлә төрмәсенә илткән син ата коммун янында утырмас идем мин. Аңламыйсың син мине, гомер буе аңламадың... Башымны Габдрахман байлар гына ашады. Шуларның дөнья буенча нәсел-нәсәпләрен бетерергә кирәк иде. Ә аны көчсезләр, чирләшкәләр белән эшләп булмыйдыр иде. Көчлеләр кирәк иде бит аңа... Ә сез шуны аңламадыгыз. Бөтен ачуым килгәне шул минем... Әллә син миңа берүзем каравыл өендә ятуы рәхәттер дип беләсеңме? Житмәсә, нинди генә төшләр керми... Аллага ялвара башладым хәзер... Йокларга ятар

алдыннан тыныч йокылар бир, ходаем, дим. Бирә, бик!.. Гомер ышанмаган алла нигә минем хәлгә керсен ди...

Асыл исергән иде. Хәсән, караваттан төшеп, аның артындагы ястыкны рәтләп куйды да:

— Ят, кайтып йөрмә инде,— диде. Асыл кинәт исенә килде. Ул тизтиз киенә башлады. Өстенә тунын кигәч:

— Җебетте мунчаң, рәхмәт карчыгыңа. Мин китим әле, сарыклар бәрәнлисе бар. Анасы ялаганнан соң яңа туган сарык бәрәнен куенына салып, шуның җылы сулышын исни-исни йоклаганың бармы синең, Хәсән?.. Юк шул. Белмисең әле син аны. Ярый, күп сүз — юк сүз, бигайбә, рәхмәт, мин атлыйм әле,— дип чыгып китте һәм төн караңгылыгына кереп югалды.

12

Хәсән икенче көнне таң белән май заводына китте. Аннан әйләнеп кайткач, иртәнге сәгать җиделәргә ул үзенә тиешле барлык эшләрне эшләп бетергән иде инде. Кайтырга гына дип җыенган иде, Харисның ат белән киртә сөйрәтеп килгәнен күрде. Ул Хәсәнгә ферма буйларын яңгыратып сәлам бирде:

— Исәнме, Хәсән абый!

— Ару, кем, Харис туган, ниләр җимерәсең?

— Теге үгезләргә утар әйләндерәм. Әйләндерәм дә шунда куып чыгарам. Теләсә нишләсеннәр.

— Киңәш-табышсыз ярамас бит. Һич югында, ферма мөдире белән сөйләштеңме?

— Икебез бергә сөрән салабыз бит без.

Хәсән, бүреген күтәрә төшеп, мыегын сыпырды. Аннары:

— Алай икән, алай икән,— диде, башка сүз әйтмәде, борылып люцерна печәне чемченеп торган атына таба атлады.— «Ни житми?» дисең син, Асыл, миңа житкән дә бит, үз көчләрең кергән, тирең түккән малларны күрәләтә җилгә очырып булмый шул. Барың да синең кебек булса, бу дөньяны ничек, кем җилкәсендә алып бармак кирәк?

Туры бия, җай гына юыртып, ферма үреннән авылга таба алдырганда әнә шундый сорауларга җавап эзләде ул. Кайтып өс-башын алыштырды да карчыгының чәй ясап куйган тустаганына да борылып карамады, райкомга — кордашы Морат малае Вәдүт янына китте. Кабул итү бүлмәсендә бер яшь кенә кыз каршылады аны. Яңа кеше булса кирәк, танымады. Күптән сугылганы юк шул райкомга. Вәдүт белән болай очраштыргалап тора. Актив җыелышларында, пленумнарда. Әйтерең юк, үз атасыдай якын күрә Вәдүт аны. Гәүдәсе күренү белән әллә кайлардан кулын сузып килә.

Атасы кебек олы гәүдәле, сабыр холыклы Вәдүт. Җиде кат үлчәмичә кисмәс. Морат кына күрә алмады бу көннәрне, малаеның шундый зур урында утыруын күрсә, ни эшләр иде икән? Колхоздагы бу хәлләрне белсә, үзе килер иде микән, Хәсән микән? Юк, ул килер, инде әллә кайчан килер иде. Үткен иде бит ул, алдан сизәр иде... Сизсә, монда ук чыгып та йөрмәс иде бәлкем. Ул үзе тәвәккәл иде бит. Хәл итәр иде дә куяр иде. Нигә үзең башкарырдай эшкә кемнеңдер фәрманын көтәргә? Җаваплылыкны ул күтәрсенме? Ул чакта рәхәт бит. Синә жил-яңгыр тими, кешеләр белән дә бозылышмыйсың, тәмсез телләнмисең.

Хәсән зур тәрәзә янындагы урындыкка барып утырды. Урамга күз ташлады. Ләкин барлык күренгән нәрсә аңа ниндидер курчаклар,

жансыз әйберләр төсле тоелды. Чөнки күңелендә дә, тел очында да бер уй тибрәнде. «Морат нишләр иде икән бу очракта, юкка кеше бимазалап йөрмимме? Аннан башка да аның эше муеннан бит». Ләкин күңеле, сабыр ит, көт, чит кеше түгел бит ул сиңа, сөйләш, кайбер нәрсәләргә миең дә томаланып бара торгандыр, дияр иде. Уйлар җебе тагын Моратка барып ялганды.

Колхозны бергә оештырдылар алар. Башта сайланган председатель йөкне тарта алмагач, аның урынына Моратны сайлап куйдылар. Морат эшне бригадирлардан башлады. Барсын да алыштырып бетерде. Хәсәнне аръякка бригадир итеп куйды. Тезгенне нык кулына алды Морат. Таш күп бит алар авылында. Җитмәсә, таш базы да бар. Ул председатель булган елны байларның таш амбар, лапасларын сүтеп, ындыр артына җир буе озынлыгында таш пулаттай итеп атлар дворы салдылар, һәр бригададагы атларны бер урынга җыйдылар. Бу бик тә ярап куйды. Теләсә кем теләсә кая чаба алмый башлады. Атлар көрәйде, колхозның көче артты. Бөтен өмет атта иде бит ул чак. Ир канаты гына түгел, колхоз канаты да ат иде. Әнә шул ир һәм ат канаты белән күтәрелде ул елларда колхозчылар. Хәзер генә атның кадере киткәч... Шул атлар белән урман ташыдылар, шулар белән авылдагы саман кирпечтән салынган балчык өйләрне бетерделәр. Ныгыган иде колхозлары, бик ныгыган иде. Әгәр сугыш та чыкмаган булса...

Сугышка алар икесе бергә киттеләр. Вәдүте җиткән егет иде инде. Газиз белән икесе аларны Чаллыга чаклы юлаучы булып озаттылар. Бүгенгедәй күз алдында: аерылганда Морат Вәдүтен кысып кочаклады да: «Бәлки сезгә чират та җитмәс, семьяны ташлама, кешегә миһербанлы бул»,— диде. Вәдүт дәшмәде, аның иреннәре дерелди иде.

Саперный батальонга эләктеләр алар. Олы яшьтә булгангадыр инде. Чигенгәндә күпме күпер, тимер юл дамбалары шартлатмадылар алар. Һәр шартлатудан соң Морат: «Хәсән, беләсеңме, кайчан да булса боларны үзебезгә төзергә туры килә бит»,— дия иде әрнеп. Куәт тә бар иде соң үзендә! Өчәр, дүртәр кеше алып килгән бүрәнәләрне берүзе күтәрә иде ул. Шуңадыр инде, старшина аңа ике солдат паегы бирдерә иде.

Сталинград янында, танкларны чыгару өчен, Иделдә понтон күпер салалар иде. Өстән өзлексез бомбага тоталар. Күпме кеше кырылды анда. Алар батальоныннан егермеләп кеше исән калды микән? Шунда яраланды Морат. Бомбаның кайнар тимере күкрәген актарган иде аның. Госпитальгә кадәр исән килүенә хәрби хирург шаккатты. «Мондый кешене дә үлем алыр икән?» — диде ул гаҗәпләнеп. Хәсәннең үз кулында җан бирде Морат. Соңгы сулышларын алганда аңына килде: «Җайлап кына әйтерсең инде, Хәсән... Минекеләргә күз-колак була күр... Бәхил бул, кордаш... Син исән кайт авылга... Зәңгәр таудан... таудан яулык болга... Минем өчен...»

Соңгы сүзе шул булды. Моратның теләге кабул булдымы, ул исән кайтты. Өч тапкыр госпитальдә ятып ремонтланды ремонтлануын, яңа туар буыннар бәхете, аларны бәхетле итү өчен кайткан булып чыкты бит ул. Моратны Идел яры буендагы туганнар каберенә җирләделәр. Ул кабер туфрагын Хәсән, тәмәке янчыгының бер почмагына төреп, сугыш буе саклап йөртте. Ул туфрак хәзер Вәдүтләрдә саклана. Моратның хатыны сугыш вакытында үлгән.

1942 ел башында Вәдүтне дә, аның Газизен дә сугышка алганнар. Газиз, озак та үтми, бер аягын өздереп кайткан да бит, нишлисең...

— Бабай, сез ни йомыш белән?

Хәсәннең уйларын кабул итү бүлмәсендәге кызның йомшак кына дәшкән сүзе өзде.

— Болай, үзе белән сөйләшәсем бар иде,— дип җавап бирде аңа Хәсән һәм: — Әллә эше тыгызмы? — дип сорады.

— Хәзер юк кебек, доложить итимме соң?
— Юк, кирәк түгел, мин үзем...
Хәсән шулай дип урыныннан кузгалды һәм дермантинлы ишектән кереп китте. Кыз, сәерсенеп, аның артыннан карап калды. Вәдүт нидер язып утыра иде. Ишек ачылганын сизү белән, ул күзлеген маңгаена күтәрде. Хәсәнне күргәч, җәһәт кенә урыныннан кузгалды һәм, ике кулын сузып, аңа таба атлады. Алар күрештеләр. Вәдүт Хәсәнне аркасыннан кочаклап үз өстәле каршындагы урындыкка илтеп утыртты. Үзе аның алдына басып, елмаеп карап торды да:
— Я, Хәсән абый, хәл-шәрифләрең ничек? Әсматтәй сау-сәламәтме, балаларның хәбәр-хәтерләре килеп торамы? — дип сорады.
Хәсән мыек очларын чеметкәләп алды да:
— Чакма ташы кебек әле хәзергә. Тутаң да әйбәт кенә йөри. Балаларның менә каникулга кайтыр көннәре якынлаша,— диде. Вәдүт, урындык тартып китереп, аның каршына утырды. Шул чак телефон шалтырады. Кемдер машина сорый иде. Вәдүт, аның йомышын канәгатьләндергәч, икенче телефонга үрелде һәм телефонисткага:
— Үскәнем, Казаннан шалтыратмасалар, берәүгә дә ялгама, важный эш бар, беткәч үзем хәбәр итәрмен,— диде. Гел шулай, Хәсән кердеме, бөтен эшен ташлый Вәдүт. Бу юлы да шулай эшләде.
— Нинди җилләр ташлады, Хәсән абый? Беләм мин сине, чәйгә чакырырга килмәгәнсеңдер? — диде Вәдүт, аның күзләренә туры карап.
— Сөйләргәме, сөйләмәскәме дип торам әле,— диде Хәсән, башын ия төшеп.
— Я, я, ни бар?
— Бар дип, кем, туган, син миңа менә шуңа җавап бир әле: безнең Җәүдәт кебек кешеләр кайдан барлыкка киләләр?
— Гайфетдиновмы?
— Нәкъ үзе.
Райком секретареның йөзе житдиләнде. Кара кашлары дугадай киерелде. Ул аскы иреннәрен тешләп алды.
— Айт дигәндә тайт диючеләрне әйтәсең инде син, Хәсән абый.
— Аларны да әйтәм. Тагын башкасын да, төптәнрәк уйлап кара әле... Андыйлар ишәеп бармыймы?
— Турысын, боргаламыйча гына әйт әле, Хәсән абый.
— Һәм әйтәм дә, Вәдүт улым. Җәүдәтләр югарыдагы фәрман белән генә яшәргә өйрәнеп киттеләр бит. Югарыдан килгән һәр фәрманга колһуалла укый да шуны үтәргә йөгерә. Тыны-көне бетеп йөгерә, эшләргә тырыша. Шуны эшләсә, җаны тынычлана андыйларның. Ә ул фәрманның дөресме, дөрес түгелмелеге турында күп уйлап тормый.
— Менә аңлашыла башлады хәзер.
— Сизәм, аңлыйсың. Ләкин аларның күбесе андый түгел иде бит. Җәүдәтләр анадан алай булып тумаган. Үзебез махы бирмибезме икән без бу соңгы елларда? Тормышлар түгәрәкләнгәннән-түгәрәкләнә бара. Шуңа куанып, кайберәүләрнең булган житешсез якларын күрмәмешкә салынуларын гаепләмибез түгелме, Вәдүт энем? Чөнки күрмәгәннең күзе, белмәгәннең беләге авыртмый. Аннары һәр начальник өстендә начальник бар. Шулар уйласын дигән чир дә азып бара түгелме? Болар турында уйлаганың бармы синең? Әллә кайларга барасы юк, үзебезнең колхозны гына ал...
— Сезнең колхоз болай арттагылардан саналмый бит, Хәсән абый.
— Колхоз — тирән күл бит ул, син аның төбенә карарга тырыш, Вәдүт улым, төбенә. Анда ниләр күренә? Күрә белгәнгә күренә ул. Ихлас, колхозыбыз арттагылардан түгел. Әмма бит, үзең беләсең, быел ипи белән утырдык. Ике йөз мең ссудага чумдык. Ә ни өчен? Юрганга

карамый аякны суздык. Генеральный план дип артык зурдан куптык. Мондый елны аны соңартыбрак калсак ни була иде? Төзелешләрне, мин әйтәм. Үзәктә бер дигән культура йорты була торып, техника паркына, фермага клублар салып куйдык... Җитмәсә, колхоз председателе хезмәт хакына дигән акчаларны да шул төзелешкә кертеп бетергән. Ни дигән хәл бу, иптәш секретарь?

— Хәсән абый, ай-яй, сорауларны тезәсең, боларга җавап биреп бетерергә башым җитәрме икән? — Вәдүт аны шулай дип бүлдерде.— Монда Мәскәү профессорлары да җавап биреп бетерә алмас.

Хәсән мыек очларын тагын чеметеп алды да сүз башлады:

— Алай димә, Вәдүт туган, син бөтенесенә җавап бирергә тиеш, шуның өчен куелган. Бу йортка мин бөтен җаным-тәнем белән ипанып киләм. Төн йокыларымны качырган сорауларга җавап эзләп киләм. Син — мин түгел, укыган кеше, сиидәйләр алып бара бөтен дөньяны. Сезгә ышанмый кемгә ышаныйк, синең кебекләргә таянмый кемгә таяныйк без? Җәүдәтләргәме? Аларның үзләренә ныклы таяныч кирәк хәзер, бик beләсең килсә. Болар турында уйлыйсыңмы син?

Вәдүт кабинет буйлап арлы-бирле йөрергә тотынды. Чал керә башлаган бөдрә чәчен сыпырып алды. Яңадан Хәсәннең алдына килеп басты.

— Уйлыйм мин, Хәсән абый, бу турыда. Хәзер кайбер колхоз председательләре, сөт кимедеме, рационны баетырга да рөхсәт сорап райкомга шалтырата башлыйлар. Эш башкаручыларны артык опекага алу — иҗади эшнең дошманы. Әнә шул дошман корбаннары ул Җәүдәтләр.

— Менә-менә, мин уйлаган, исем таба алмаган уйларга исем куштың. Ана каз канаты астындагы бәбкәләр кебек кенә яшәргә өйрәнеп бара хәзер кайберәүләр. Ә нишләргә кирәк соң?

— Менә синең кебек коммунистларның бу яман чиргә каршы принципиаль көрәше кирәк. Үзебез тудырган чирне үзебез бетерергә дә тиеш без. Аны әллә кемнәр кайдандыр килеп бетермәс. Җәүдәтләр безнең арада яши, аларның йомшак ягы безгә кемгә караганда да ачыграк, билгеле.

— Анысы шулай, тик монда райкомның да ярдәме кирәк.

— Әлбәттә, Хәсән абый, райком үз штурвалын нык тотарга, дөрес маршрутны компас белән күрсәтергә тиеш.

— Әнә шул компас теле кайчак уйнаклап алмасын иде. Аның печтек кенә калтырап куюы да кайчак бик кыйбатка төшә бит. Без генә түгел, башкалар да сизә моны. Әрнүчеләр белән бергә, сөенүчеләр дә бар монда... Әнә кичә генә авызымны Асыл томалады: «Күкәй тәгәрәтешле уйныйлар»,— ди.

— Ник авыз ера ул тагын?

— Безнең колхоз күрше «Үрнәк» өчен күкәй тапшырган. «Үрнәк»нең планы үтәлми каласы булган. Вәт, без тапшыргач, ул үтәлә, колхоз алдынгылар сафына чыга. Хикмәт менә кайда!

— Оста эшләнгән. Хакмы бу?

— Рас инде. Бухгалтердан белештем. Егерме тугыз мең биш йөз күкәй «Үрнәк»ләр өчен киткән. Акчасы безгә керә дә бит аның. Тик нигә алай күз буышлы уйнарга? Кем тапшырса да, хөкүмәткә китә бит ул. Ә ахыры? Халык арасындагы чыш-пыш сүзләр? Бу алышбиреш артында әнә шулар ятуын да уйларга кирәк.

Вәдүт телефонга тотынды. «Үрнәк»не алып сөйләште. Баш бухгалтер туры килде. Әйе, Хәсән әйткән сүзләр дөрескә чыкты. Секретарь тагын ишекле-түрле йөрергә тотынды. Хәсән аның борчылуын, нинди карарга килергә белми йөдәвен күреп, аңлап утырды. «Бусы баласы

әле, анасын ишеткәч ни диярсең икән, анысын әйтергәме-юкмы?» — дип, икеләнде-икеләнде дә ахырда ниятләде:

— Вәдүт туган, монысы, башта әйткәнчә, әле барыбер хөкүмәткә китә. Аның менә монысын тыңла әле син...

Вәдүт аның каршына килеп утырды. Хәсән Харис вакыйгасын, хәзерләүләр инспекциясенең югары көрлектәге үгезләрне, район ит планын үтәде инде дип, киләсе елда тапшыру өчен резервка калдырырга әмер бирүен сөйләде. Вәдүт аны игътибар белән тыңлады, үз өстәленнән блокнот үрелеп алып, аңаниләрдер язып та барды. Аның өске ирене тартышып-тартышып алды.

— Аңладым, менә нәрсә китергән сине райкомга,— диде Вәдүт, каләмен өстәлгә куеп.— Монысы район өчен дә, колхоз өчен дә «ЧП»!

— Нинди «ЧП» гына ди! Үзең утырган ботакны үзең чабу бу!

Вәдүт маңгаен уа-уа урыныннан торды, кабинет буйлап әйләнде һәм:

— Менә нәрсә, Хәсән абый,— диде,— моны бер звонок белән дә хәл итеп була. Хәзерләүләр инспекциясенә шалтыратсам, шул җитә. Мәсьәлә монда гына түгел. Моның тамырлары тирән. Моны Җәүдәтләр, инспекция начальнигы кебек кешеләр өчен сабак итәргә, Харисларның дөнья кендеге икәнен исбатларга, һәр эштә һәр коммунистның персональ җаваплылыгын канына сеңдерергә, аларның иҗади активлыгын күтәрергә кирәк. Кемнең кем булуына карамастан, синең кебек коммунистларның мәсьәләне кабыргасы белән куюы зарури. Сабак булачак бу. Инициативаны син күрсәт һәм бу эшне уңай хәл итүгә бөтен коммунистларны тупла. Кыскасы, үз көчегез белән бетерергә тырышыгыз бу күз буяучылыкны. Йөзгә якын коммунист бар бит сездә. Кирәк икән, әлбәттә, ярдәм итәрбез.

Хәсәннең башы түбән иелде. Тукта, кеше кулы белән ут тотарга җыенмыймы бу, шуңа өйрәнеп бармый микән, диебрәк тә уйлады ул. Ләкин күңеле ышанмады.

— Ярар, менә шундый-шундый хәлләр, улым,— диде аннары.— Көчем бар әле. Асыл, сиңа ни кирәк, ни җитми, дип игәүләп торса торсын, әмма ниятлим мин бу эшне.— Хәсән карт шулай дип урыныннан кузгалды. Аннары, кинәт башын тотып, кире утырды һәм:— Әй, бу карт хәтерне, оныта язганмын бит,— дип пышылдады аның ирennәре. Башына кигән бүреген яңадан салып тезләренә куйды, райком секретареның күзләренә тутырып карады да:— Баш миемне усак корты кебек кимергән бер нәрсәм калган икән әле, Вәдүт олан,— диде.

Вәдүт аның каршысына килеп басты. Секретарьның болай да кырыс йөзе тагын да җитдиләнде, яңак мускуллары уйнаклап алды. Моны күреп Хәсән, вакытымны болай да күп алдың, тагын нәрсә сайрарга җыенды икән бу, дия торгандыр инде дип тә уйлады. Бабай бүреген кия башлагач, Вәдүт аның иңнәренә кулын салды һәм:

— Я, я, Хәсән абый, әйт, усак кортларыңның да барын да коеп кит,— диде.

Хәсән мыегын сыпырып куйды.

— Син, Вәдүт олан, терлекчелекнең хуҗалык исәбендә яшәвен беләсең,— дип башлады ул сүзен.— Ә менә игенчелек турында уйлаганың бармы?.. Терлекчелеккә караганда барлык эше механикалаштырылган тармак турында. Игенчелектә нинди генә эшне кул белән эшлибез без, ә?..

— Чөгендер, бәрәңгедән башканы?

— Әйе.

— Моңа хәзер җавап бирүе дә авыр.

— Ничәмә еллар шулай бит. Күп уйландым мин бу турыда. Игенчелектә хезмәтне оештыруда нидер җитми кебек тоела миңа...

Әйтәсем килгәне шул: игенчелектә дә, терлекчелектәге кебек, хуҗалык исәбе кертергә вакыт түгел микән?
— Бу турыда укыганым бар минем.
— Укыгач... Әллә күңеленә хуш килмиме?
— Килә дә бит.
— Югарыдан фәрман көтәсеңме?
Хәсән картның күзләре кысылды. Чалу мыегы җиңелчә генә дерелдәп алды.
— Четерекле мәсьәлә бит. Киңәш-табыш итешәсе бар...
— Ә бит моны тормыш үзе тудыра. Туганны гына көтеп ятарга, аны тәрбияләп үстерүгә алдан хәстәрлек булдырмаска безнең хакыбыз юк, Вәдүт олан. Ата-ана кебек... Әллә син дә четерекле нәрсәләрдән шүрли башладыңмы? Ул-бу килеп чыкмагае, «әле болай да эшләр шома бара» арбасына утыра күрмә. Юк, сиңа килешми бу.
Секретарь тагын бераз ишекле-түрле йөренеп алды. Чигәсенә төшкән чәчләрен берничә тапкыр артка сыпырды. Аннары Хәсән картның алдына килеп басты.
— Андый арбага минем мәңге утырасым юк. Четерекле диюем шуннан: мин бу мәсьәләне ничек, нинди масштабта күтәрергә белми гаҗизләнәм. Башта әллә бер колхозда сынап карарргамы, әллә моны район күләмендә күтәрергәме? Менә мәсьәләнең четереклеге кайда.
Беравык икесе дә дәшми торалар. Вәдүт яңадан ишекле-түрле йөренә. Хәсән аның һәр адымын күз карашы белән озата.
— Башта бер генә колхозда сынамак әйбәт булыр,— диде соңында Хәсән.— Безнең колхозда, председатель дә яшь, энергичный, аннары, үзеңнең күз алдың. Һәр көн белешеп тора аласың.
Вәдүтнең йөзенә елмаю чаткылары чыкты.
— Икебез нәкъ бертөсле уйлыйбыз бит без, Хәсән абый,— диде ул һәм өстәле артына барып утырды. Алар игенчелекне хуҗалык исәбенә күчерү, игенчелекнең терлекчелекне азык белән ничек тәэмин итүе, ике арадагы исәп-хисап, техника ремонты, аның чыгымнарын ничек күтәрү, җәен игенчелектә эшләп, кышын терлекчелеккә килгән механизаторлар хезмәтенә ничек түләү турында бәйнә-бәйнә сөйләштеләр, киңәштеләр, бәхәсләштеләр. Уртак фикергә килгәч, икесенең дә иңнәреннән авыр йөк төшкәндәй булды. Алар кул бирештеләр.
— Бер дә килгәнегез юк бу арада, киләсе базар көн икәүләшеп килеп чыгыгыз, Әсматтәй өчпочмак пешереп ашатыр иде бер. Минем Наилә ише генә пешерми бит ул. Телләреңне йотарсың,— диде Вәдүт, Хәсәнне ишеккә чаклы озата килеп. Кабул итү бүлмәсенә чыккач, Хәсән Вәдүтнең кулын тагын кысты.
— Рәхмәт, үзегез чыгыгыз әле, бала-чагалар белән, шуларның чыр-чуын тансыкладым. Аннары, үзең мунча яратасың. Мунча ягып торырбыз. Чабынырсың бер рәхәтләнеп...
Кабул итү бүлмәсендә аларның шулай дустанә сөйләшүләрен елмаеп тыңлап торган кыз, Хәсән карт чыгып киткәч:
— Нинди кеше бу, Вәдүт Моратович? — дип сорады. Вәдүт аңа баш бармагын күрсәтте һәм:
— Во, дөнья бәһасе кеше! — диде дә кабинетына кереп китте.

## 13

Тимерне кызуында сугарга гадәтләнгән Хәсәнгә җае туры килде тагын: райкомнан чыгып, банк турына гына җиткән иде, аларның «Волга»сы тора. Телен йоткан, сөйләшмәс Шәрифҗан рульгә башын салып йокымсырый. Хәсән, ачык тәрәзәдән кулын сузып, аның колагыннан тартты. Шофер сискәнеп башын күтәрде:

— Кем белән син?
— Бөтенесе дә шушында,— диде Шәрифҗан, башы белән банкка таба ымлап.
Кинәт шыбырдап карлы-бозлы яңгыр яварга тотынды. Хәсән, йөзен кулы белән каплап, тагын сорау бирде:
— Тиз чыгарлар микән?
— Кем белә...
Шул чак ишектә бухгалтер, аның артыннан колхоз председателе, партоешма секретаре күренделәр.
— Исәнме, Хәсән абый,— дип, өчесе дә кул биреп күреште. Бухгалтер, кулындагы сумкасын болгап:
— Тагын эләктердек! Бусы хезмәт көненә инде. Мисбах абый әллә ниләргә каерырга тора торуын. Тик тәтемәс, әле дә хезмәт хакына дигәнне әллә ниләргә тотып бетердек,— диде. Председатель җавап бирмәде, Хәсәнгә ымлап:
— Кайта торгансыңдыр бит? — дип сорады.
— Кайтырга исәп.
— Утыр, алайса.
Машина, күлдәге көймә кебек, шуып баргандай гына кузгалды да ялт итеп тыкрыкны борылды һәм Минзәлә елгасы аша салынган тимер күпергә таба элдерде. Күперне чыккач, шофер Хәсәннәр урамына борылмакчы иде, Хәсән аның иңбашына кулын куеп:
— Өйгә түгел, идарәгә чыгам,— диде. Үрне дә очкан коштай гына менде «Волга». Машинадан төшүгә, председатель дә, партоешма секретаре да үз кабинетларына ашыктылар. Бухгалтер кирә-керешкә кассир кызларга кычкырды:
— Ведомостьларны әзерләгез, бай кайта, бай!..
Хәсән башта Җәүдәт янына керде, үзенең беренче секретарь янында булуын, аңа нәрсәләр сөйләвен тәкърарлады. Ахырдан Вәдүт Моратовичның тәкъдимен әйтте. Җәүдәт аны тын да алмый тыңлап торды. Аннары капыл гына сорады:
— Үзегез тудырган чир, үзегез дәвалагыз, дәваланыгыз, диме?
— Шулай диде. Һәм рас та әйтә.
— Сиңа шулай... Аннары кем җавап бирер? Мин дә Мөхәммәт Әминме? Их, Хәсән абый, Хәсән абый, авыртмас башка тимер таяк эзләп йөрисең... Ни дисәң дә диярсең, мин бу эшкә алынмыйм. Бергә эшлисе күпме кеше белән ачуланышырга туры киләчәк...
— Син алынмасаң, мин алынырмын, Җәүдәт туган, житмешне тутырганга биш кенә ел бит әле минем. Синең көчең дә житмәве бар. Начармы-яманмы, мин — партком һәм райком члены. Бу мәсьәләне башта партком утырышында карарга туры килер. Анда да уртак тел тапмасак, колхозчыларның гомуми җыелышына куярбыз.
— Шул гына житмәгән иде... Бәй, тукта, ник соң мин үземә җаваплылык алып утырам әле? Күкәйләр, үгезләр ул бит председатель эше, чакырыйк аны да. Ул да партком члены. Минем төп бурыч кешеләр белән эшләү.
Җәүдәт шулай дип кабинетыннан ашыгып чыгып китте. Бераздан ул колхоз председателе Мисбах Ганиев белән сөйләшә-сөйләшә килеп керде. Җәүдәт сүзнең кай тирәдә куерганын тишеп өлгергән, күрәсең, председательнең йөзендә гаҗәпсенү катыш борчылу сизелеп тора, юка өске иренен тешләштерергә маташа, ләкин эләктерә алмый иде.
— Күкәй акчасы кассага килеп керде инде, Хәсән абый,— диде ул, стена буендагы диванга барып утырып һәм:— Ә тегесе аның район белән килешенгән, монда мөгез чыгарырлык бер әйбер дә тапмыйм мин. Беребез дә колхозның тиененә кагылган кеше түгел,— дип өстәде.

— Колхоз кассасына керергә тиешле акчаны кертми тору да китап мактый торган эш түгел,— дип җавап бирде аңа Хәсән, Мисбахка таба борылыбрак утырып.

— Ул бит барыбер безгә кирәчәк акча...

— Аңлыйм, Мисбах туган, аңлыйм. Хәзер өченче период үгезләрне симертүгә куясы бар. Тегеләрен тапшырмыйча, аларга урын юк. Симертү срогын сузабыз бит малларның. Монысы инде күзгә күренеп торган акчаны күрәләтә җилгә очыру.

— Урын табабыз аларга.

— Кайда, ачык һавада, боз-яңгыр астындамы?

— Менә, Хәсән абый, нәрсә. Әйдә юкка баш ватмыйк. Колхоз өчен мин җавап бирәм. Ул үгезләрне киләсе елда тапшырырга миңа хәзерләүләр инспекциясе үзе әйтте. Башыма да килмәгән иде әле. Быелгы планнарны арттырып үтәдек. Алдагы ел турында да уйларга кирәк. Начальство аның шунысын да исәптә тота. Район даны дигән нәрсә дә бар бит. Кеше арасында, кайсы район дигәндә...

— Мисбах туган, син генә түгел, колхоз өчен барыбыз да җавап бирәбез. Миңа бигрәк тә газиз ул.

— Кайберәүләр кебек, без төзегән колхоз ул дип тә җибәрегез...

— Диярмен дә, чөнки дәхелем бар. Синең күкәй тәгәрәтешле уйнауларың, нинди дер акыллы баш сүзенә мөкиббән китеп, ул үгезләргә тикмәгә ипи черетеп яткыруларың колхозчы җилкәсенә бик кыйбатка төшүе бар, энекәш. Атны абынганчы саклыйлар, шуны онытма...

— Соң, Хәсән абыкайларым, нишләем? Хәзер безгә аларны тапшыру өчен көн бирмәячәкләр.

— Монысы икенче чут.

— Син менә сорап кара көн.

— Сорарга син куелгансың. Сиңа рөхсәт итмәсәләр, аннары без бергәләп уйлап карарбыз.

Председательнең йөзе бурлаттай булды. Ул партком өстәле өстендәге телефонга үрелде, Җәүдәт аңа сораулы күзләре белән төбәлде. Мисбахның кайчак, дәртләп кабынып, нәрсә эшләгәнен үзе дә абайлый алмый калган минутлары була. Инспекциягә генә икән... Телефоннан хәзерләүләр инспекциясе начальнигы Галиевнең хатын-кызларныкы кебек нечкә тавышы ишетелде:

— Ә, сезмени, иптәш Ганиев, тыңлыйм, тыңлыйм...

Мисбах микрофонга өргәләп алды, башта Җәүдәткә карады, аннары Хәсәнгә күзен төбәде дә:

— Иптәш Галиев, теге үгезләрне тапшырмый булмас, җәнҗал чыгарга тора әле алар белән. Иртән фермада булган идем — симертүчеләр якадан алды. Хәзер менә монда Хәсән абзый бер як якадан әләктерде. Колхозның акчасы да юк чак, рөхсәт итегез, тапшырыйк без аларны. Көн бирсәгез икән,— диде. Телефонда тамак кырган тавыш ишетелде. Чәрелдек тавыш яңгырады:

— Сез, иптәш Ганиев, ни сөйләгәнегезне беләсезме?

Председатель сагаеп калды.

— Белмәскә. Менә монда җавап биреп кара хәзер. Вәдүт Моратовичка ук барып җиткән бу.

— Вәдүт Моратович белән үзем сөйләшермен. Тапшырырга рөхсәт булмаячак. Районның киләсе ел планнарын да үтисе бар. Масштаб белән, алга карап уйларга кирәк, иптәш Ганиев.

— Инде нишләргә?

— Ничек әйтелгән — шулай эшләргә. Анда акыл сатарга яратучылар бетмәс.

Инспекция начальнигы шулай дип трубкасын куйды, күрәсең, Мисбах, Җәүдәт белән Хәсәнгә ымлап:

— Ишеттегезме? — дип сорады. Җәүдәт читкә таба карады.

— Галиев сүзе безгә закон түгел әле. Колхозның үз Уставы да бар,— диде Хәсән, Мисбахның төшкән рухын күтәрергә теләп.

— Суга каршы йөзәргәме?..

— Җәүдәт җырын җырлама инде син, энекәш. Кирәк вакыт йөз, йөзә бел. Җәүдәт ялт итеп Хәсәнгә таба борыла:

— Миңа ни булган?

— Булмаган, синең яраткан сүз бит ул, аңа нигә хәтерең кала? Бабайлар сүзе ул...

— Аларның да һәр әйткәненә ярхәмикә алла дип торып булмый.

— Ярар, юкка тәпәләшмәгез әле.

Мисбах шулай дип диванга барып утырды, портсигарын алып папирос кабызды, югарыга төтен алкалары чөеп, Хәсәнгә дәште:

— Я, нәрсә дисең, Хәсән абый? Беләсең, синең сүзеңә колак салам мин. Минем урында булсаң, нишләр идең?

— Бернигә карамый озатыр идем.

— Терлек тапшыруның көн-графигы бар бит. Аны инспекция бирә.

— Без партком утырышы җыйыйк. Анда инспекция начальнигының үзен дә чакырыйк. Шунда хәл итәргә тырышырбыз.

— Ә ул килмәсә?

— Килер. Үзебезнең Вәдүткә шалтыратырсың. Шул көнгә, фәлән сәгатькә инспекция начальнигы безнең партком утырышына чыксын әле дип.

Мисбах дәшмәде, башын түбән иде. Хәсән китәргә кузгалды. «Төшендерсәң уң белән сулны тиз аера, үз сүзем дип киреләнми. Әйбәт председатель чыгар синнән, олан. Таяныр кешеләрең генә нык булсын», дип уйлады ул.

Колхоз председателе урыныннан кузгалды да ишеккә юнәлде. Хәсән карт та аның артыннан иярде. Коридорга чыккач, ул председательнең җиңеннән әкрен генә тотты да:

— Тагын бер әйтәсе сүзем бар әле,— диде. Алар председатель кабинетына керделәр. Хәсән карт Мисбахка игенчелекне хуҗалык исәбенә күчерү турында райкомның беренче секретаре белән булган әңгәмәсен түкми-чәчми сөйләп бирде.

— Безнең колхозда сынамакчы була моны Вәдүт олан,— диде ул, сүзен тәмамлап.

Мисбахның йөзе яктырып китте.

— Кызык, әмма ышанычлы нәрсә бу. Барып чыгачак! Ышанып әйтәм. Быел ук тотынабыз моңа. Иртәгә үк экономистка әмер бирәм: исәп-хисап ясап карасын әле. Аннары конкрет сөйләшербез, нигезләп, аяк терәп! Их, Хәсән абый, Хәсән абый, барлык кеше дә колхоз турында синең кебек кайгыртса, уйласа, ниләр генә эшләмәс идек без! — диде ул.

* *
*

Харис кичә башлаган эшен бүген дәвам итте. Завхоз белән якалаша-якалаша, пилорама янына кайтарылган агачлардан утар әйләндерерлек киртә-кура, баганалык ташыды. Җен ачуы чыгып, задурланып эшләде. Кичкә таба утарны эшләп бетерде. Бөтен җире манма су булды. Ферма өенә кереп, өстендәге сырмасын плитә янына элеп куйды. Асыл карт, аякларын сузып, диванда тәмәке тартып утыра иде. Харис аңа кырыс кына дәште:

— Курилка түгел бу. Чыгып тартсаң ни булырые!

Асылның күзләре кысылып, ул тәмәкесен юри тирән итеп суырды да бүлмәгә төтен таратып:

— Үз өем, үз көем, кысылма, башың яшь! — диде.
Харисның җил-яңгырда йөреп каралган, җәйге кояш нурларын үзенә сеңдергән алсу йөзе агарып китте.
— Бирермен мин сиңа үз өеңне, тышка чыгарып болгасам... Ташла тәмәкеңне!.. Хәзер сыер савучылар килә...
— Өркетмә, синнән курка торган күлмәкләр әллә кайчан, егерме беренче елда ук тузган инде минем.
Харис түзмәде, Асыл картның якасыннан умырып тотты да аны сөйрәп торгызды һәм:
— Ташла тәмәкеңне, контр, ферма комагы! — диде.
— Үтер, үтер, башың кәтер китәсе килсә... Асыл димәсләр, кеше үтергән дигән статья аласың киләмени? — Асыл гыжлап шулай диде һәм Харисны бар көченә этеп җибәрде. Харис аның тәмәке төпчеге тоткан кулына китереп сукты. Төпчек, очкыннар чәчрәтеп, идәнгә очты.
— Ут чыгарасың киләмени, маңка! — диде Асыл үртәлеп, үзе пыскып яткан тәмәке төпчегенә аягы белән басты.— Миннән аласыңмыни үчеңне? Акчаң очамыни? Җәүдәтләрне җиңә алмыйсың шул син. Бер сүз белән каплыйлар шул алар синең авызны! Харап, житмеш җиде яшьлек картка көче җиткән икән. Синең кебек чакта мин үгезне мөгезеннән тотып җиргә ега идем, печмәгәнең, ыжгырып торганын. Ә син печкән, шалтырамасыз үгезләр белән дә менә ничәмә көн чиләнәсең. Җүләр син. Колхозда икәү генә бит сез. Берсе Хәсән — карт җүләр. Икенчесе син — яшь җүләр.
— Тый телеңне, контр! Кисеп эткә ташлыйм бит хәзер!..
— Пробуй! — Асыл ялт итеп өстәлдәге графинны эләктерде дә Хариска кизәнде:— Башыңны ярам бит хәзер, черек кабак кебек,— дип, Харис өстенә килә башлады. Харис ишеккә таба чигенде һәм, ялт итеп, Асылның графин тоткан кулын эләктереп тә алды, шатырдатып артка да каерды. Графин идәнгә төшеп челпәрәмә килде. Харисның ачуы чыкты. Ул Асылның кулын тагын да ныграк каерды. Асыл ыңгырашып, бөгелеп төште. Харис аны шул килеш кече бүлмәгә таба алып китте һәм, ишеген ачып, Асылны шунда төртеп кертеп җибәрде, өстеннән бикләп куйды.
— Чыгасы булма ояңнан, эт,— диде ул, еш-еш сулыш алып. Бүлмә эченнән Асылның буыла-буыла ютәлләп сүгенгән тавышы ишетелде:
— Анаңның кабер тактасын... Тугач, анаң яламаган нәстәкәй!.. Болай калдырыр дисең бугай... Асылны белмисең әле син! Күрсәтермен әле мин сиңа. Ике аягыңның берсе дә җиргә тимәс. Минзәлә төрмәсендәге агач сәкеләрдә аунатмасам, исемем Асыл булмасын!..
Харис аңа дәшмәде. «Чукынсын, өрер-өрер дә, авызы аргач, туктар әле. Адәмнең газизләре егылып үлә. Моңа чире дә тими бит, әллә кайчан таптап кумәсе, хәшәрәт», дип уйлады.
Харис шушы авылда туып үсте. Әтисен ул яхшы хәтерләми. Аны сугышка киткәндә әнисе белән бергә озата барганнар баруын. Авылны чыгып, Саз күперенә кадәр. Өч яшьтә булган Харис. Бердәнберләре булган. Аерылганда әтисе аны кочагына алып үпкән һәм:
— Зур үсеп тор, танк алып кайтырмын үзеңә,— дигән. Тракторчы булган ул. Танкист иткәннәр аны. Днепрны кичкәндә һәлак булган. Харис үзен белә башлаганда ачлык чак була. Эченең өзелеп-өзелеп авыртуын, тәрәзә тупсасына басып, урамга карый-карый, әнисенең эштән кайтканын көтүен, ул ишектә күренү белән идәнгә сикереп төшеп, аның итәгенә ипи сорап сарылганын, үзенең дә, ни өчендер, әнисенең дә елавын яхшы хәтерли әле ул. Олы корсаклы, нечкә аяклы булып үсте Харис. Сугыш беткән елны укырга керде. Бәхетлеләрне солдат гимнастеркасы кигән этиләре китерде мәктәпкә. Хәсән абый да бар иде. Ул күршеләрнең малаен алып килгән иде...

Сугыштан соң да әле байтак еллар ипи пешкән көн алар өчен бәйрәм булды. Башак жыярга, төнлә комбайннар басуга түккән көшелләргә бардылар... Аннары үтте ул көннәр. Жидене бетергәч укымады, ат күтәргә керде. Кыш көне фермада эшләде. Сарыклар бәрәнләгәндә көне-төне фермада булды. Бәләкәй генә каравыл өендә йоклый иде. Бу көннәргә, ай, авыр тернәкләнде бит алар. Нигә шуны оныта икән кайбер кешеләр? Ә Харис менә оныта алмый. Ул күргәннәр онытырлык кына идеме соң? Кирәк түгел, искә алмый, искә төшерергә яратмый аларны Харис. Ә бүгенге тормышлары куаныч өстенә куанычлы, баскан өстенә басып йөрисе, вакытны йокыга да әрәм итмичә, эшләгән өстенә эшлисе генә килеп торырлык бит. Калай түбәле бер дигән өй, мунчасы бар. Абзар тулы мал. Бер заман аны кысканнар иде. Инде яңа Устав бар, асра гына малны хәзер. Колхоз — азыгына чаклы биреп тора. Ә маллы кеше — жанлы кеше, дигән борынгылар. Адашкан, иясез бер сарык бәрәненнән ишегалларына мал тоягы эзе төште аларның. Шуннан әкренләп тернәкләнделәр. Өйләнеп жибәрде. Хатыны укыганрак кеше. Сельпода кассир, ике кыз үстерәләр, икесе дә укый. Анасы картайды инде, өй арасында гына йөри. «Атаң кайтып сине, ожмахтай бу тормышыңны сыңар күзкәйләре белән генә бер күреп китсә икән»,— дип уфылдый ул. Күрсә иде, күрсәләр иде бу көннәр өчен яу кырында башларын салган аталар... Ни диярләр иде икән? Куйган көчебез аларның вакытсыз өзелгән гомерләренә жавап бирерлек, шуңа торырлык, алар канәгать булырлык микән? Без: «Әти! Әтием!» дип бер әйтергә өзгәләнгән, шулай дип әйтүдән мәхрүм ителгән буыннар аларның якты өметләрен аклыйбызмы? Кемнәрнең нинди изге хыяллары, өметләре генә булмагандыр! Гомерләрен сугыш кискән ата уллары, алар уе хәзер — сездә, алар каны — сездә! «Ата-бабаларыбыздан күчеп килгән изге кан кабат коелмасын өчен сез бүген барысын да эшлисезме?» — Бу аларның соңгы сулыш алгандагы васыятьләре. Атам васыяте... Ир бала өчен бу — ил васыяте. Аңар һәрчак тугрымы без?

Харис бераз саргая төшкән сырмасын алып киде. Теге якта Асылның шешә, стакан шалтыратканы ишетелде. «Ачудан эчә, карт жен!» — дип уйлады Харис. Шул чак ишек ачылды һәм колхоз председателе белән Хәсән килеп керделәр. Председатель аңа кулын бирде:

— Саумы, Харис, хәлләр ничек?

— Ярыйсы иде лә, иптәш Ганиев, тик теге үгезләр белән генә тиктомалга жаныма тидегез,— диде. Баш кагып, Хәсән абыйсы белән исәнләште. Хәсәннең күзләре нигәдер елмая иде.

Асыл диванын шыгырдатып ятты. Аңа игътибар итүче булмады.

— Кичкә партком утырышына кил, сәгать жиделәрдә, житешәсенме? — диде председатель.

— Әле кайчан гына булган иде бит, тагын ни бар?

— Нәкъ синең мәсьәлә... Хәсән абый ай-вайга куймый бит, тапшырыйк, ди, синең үгезләрне.

Харисның йөзе яктырып китте.

— Белә шул ул Хәсән абый үрчемне ничек алганны! Үзе эшләмәгән кеше генә белми аны. Шуңа кире өтер чыгарып утыра.

— Син мине дә шулай димә тагын,— диде председатель.

— Димичә, партком члены буларак әйтәм, дөрес түгел бу, дидем. Үзең шул Галиев сүзенә мөкиббән киттең.

— Ул чире китте аның хәзер, Харис энем, жилегенә төшеп аңлатасы калган аңа башта ук. Инде юкәдә икән чикләвек икәнен белде дә бит соң,— дип сүз кыстырды Хәсән.

— Ничек соң?

— Галиев тапшыртмый, Вәдүт белән сөйләшәм, киләсе елга калдырам дип, тапшырырга көн бирми.

— Валлаһи, чыгып, якасыннан алам мин ул бәндәнең! — дип кызып китте Харис.— Вәдүт абыйны әйтер идем. Ник тота икән шул алдар тазны начальник итеп. Май заводыннан куганнар иде бит аны махинацияләре өчен...

Харисның бүселеп киткәнен председатель дә, Хәсән дә елмаеп тыңлады.

— Әйдә, башны бутаган үгезләреңне тагын бер кат үз күзләрем белән карыйм әле,— диде председатель.

Алар өчесе дә чыгып киттеләр. Симертү үгезләре асрала торган фермага керделәр. Цемент улаклар янына чылбырлар белән бәйләп куелган үгезләр барысы да диярлек башларын аларга таба борды. Ятканнары мышный-мышный тора башладылар.

— Минем исне сизделәр,— диде Харис һәм:— Иртәрәк әле, сәгать ярым бар, ашаганыгыз сеңсен,— диде, ягымлы итеп. Үгезләр барысы да чиста, йоннары елкылдап тора. Зур башлылар. Муен белән башлары бер кебек, баш гәүдәгә генә беркетеп куйгандай. Күкрәкләре киң, гәүдәләр зур, аяклар кыска. Председатель аларның һәрберсенең сыртларыннан сыйпап барды. Ферманың аргы башына, Харис группасындагы соңгы үгез янына житкәч туктады да:

— Хәсән абый, кара әле, сыртында күкәй тәгәрәтерлек бусының,— диде Харис, ак кашканың колак артларын кашый-кашый, председатель сүзенә кушып үзенекен әйтте:

— Барысы да шулай алар, иптәш Ганиев.— Үгезе алгы аякларына чүкте.— Менә шулай иязләшеп бетәләр алар миңа. Аерыласы килми үзләреннән. Ә кирәк.

— Һәрберсендә пот ярым май бар боларның,— дип, Хәсән дә сүзгә кушылды.

— Молодец син, Харис! Орден бирер идем мин сиңа! — диде председатель, Харисның кулбашына жиңелчә сугып.

— Анысы да бар аның бездә,— диде Харис, авызын ерып. Хәсән Хариска карады һәм: «Синең кебек жүләрләр үлеп бетсә, нишләр иде бу дөньялар?» — диме Асыл. «Бар аның, дөньяның Харислары, Мисбахлары, Вәдүтләре бар. Алар мин генә түгел. Ат тезгенен кулда нык тота торган затлардан яратылганнар алар», дип уйлады. Аннары Вәдүт сүзләре искә төште:— Кирәксә-кирәкмәсә дә үз канат астыбызга алабыз. Кеше уңны-сулны үзе аерырга өйрәнсен, эше, суларга кирәкле һава кебек, яшәү ихтыяжына әверелсен. Шул вакытта гына яшәве дә, эшләве дә үзе бер ләззәт булачак». Харисны ал син. Узган ел гомуми жыелышта бөтен халык алдында трибунага чыгып сүз бирде бит ул: «Быел берүзем һәрберсен дүртәр центнерга житкереп йөз илле баш үгез симертергә йөкләмә алам. Үзем белән ярышка икенче бригададан Әсәдов Мөдәррисне чакырам»,— диде. Тегесе дә коммунист кеше. Чәчрәп чыкты да: «Мин йөз алтмышка житкерәм»,— диде. Белешкән иде Хәсән. Мөдәррис үз йөкләмәсен үтәгән. Ә Харисның әле һаман унбиш баш тулмаган. Сүзендә тормаса женләнә, кара көя Харис. Ашы аш, йокысы йокы түгел. Жәүдәт: «Планыңны үтәдең, анысына да зур рәхмәт. Дүрт йөз сумнан артык премия тия әле үзеңә. Аннары Мөдәррис белән икегезгә дә Кара диңгез буена санаторийга путевка алдык. Сиңа ни кирәк тагын?» — дигән. «Ни пычагыма синең акчаң һәм путевкаң! Кешеләргә туры карарга путевка бир син миңа. Әйткән сүзеңә хужа була алмаган килеш, кеше күзенә ничек карыйсың? Син генә өйрәнгән бит аңа»,— дигән Харис.

Боларны да тапшырса, ул Мөдәррисенең дә борынына чиртә, жаны да тынычлана. Тешләгән жиреннән барыбер өзми калмый ул. Атасы, мәрхүм, шулай иде. Сугыш чыгар алдыннан бер елны бәхәсләшкән бит трактор бригадиры белән. Өч тәүлек рульдән төшми эшли алам дип. Чиратлап саклаганнар. Өч тәүлек ярым эшләгән. Заправканы да

икенче кешеләр ясаган, шул вакытта гына ашап-эчеп алган. Җене өзелгәнче эшли торган нәсел дип йөртәләр аларны авылда.

Хәсәннең уйларын председательнең куанычлы тавышы бүлде:

— Хәсән абый, тапшырабыз боларны! Галиев аяк терәп каршы торса да! Боларның һәркайсы кимендә сигез-тугыз йөз сумга китә! Сиксән баш бит әле болар. Алтмыш-алтмыш биш мең акчаны фермага бикләп тотып булмый. Беркөн дә көчкә ялынып алдык банктан акча. Ай ярымлык зарплата бит әле ул!

— Алай гына түгел. Безнең план үтәлгән бит,— диде аңа Харис.

— Дөрес, безнең план үтәлгән, югары күрлелек өчен тагын илле процент өстәлә. Яңа закон буенча мең ике йөз-мең өч йөз сум була бит бу! Ант итеп әйтәм, Харис, быел җир тишегеннән булсын, бер «Москвич» табып бирәм. Күптән сорый идең.

— «Москвич» эләккәч, фермадан сызмасам!..

— Бездә «Волга» бар. Куып тотарбыз.

— Кайларга китим ди мин, иптәш Ганиев? Китәсе килгәннәргә юл ачык бит, әнә, китсеннәр КамАЗга, кырыйда гына Чаллы.

— «Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл», дигәнме әле Тукай, Хәсән абзый?

Председательнең бу сүзенә Хәсән елмаеп җавап бирде:

— Сезгә иртә әле, минем дә бик барасым килеп тормый анда. Әби-бабайга утырмага килү түгел лә ул.

— Дөрес, Хәсән абый! Яшик әле, эшлик әле дошманнар күзе көярлек итеп!

— Әнә Асылга күптән вакыт. Ул бара торсын,— диде Харис.

— Аның газраиле әллә тумаган инде? — диде председатель көлеп.

Хәсән аяк очларына карады һәм:

— Алай димәгез, туганнар, бик тә бәхетсез кеше ул. Аның көненә калырга язмасын,— диде.

## 14

Ләкин өчәүләшеп иртә куанган булып чыктылар алар. Партком секретаре Җәүдәт Гайфетдинов көн тәртибен дә, мәсьәләне дә үзенчәрәк аңлатты. Кат-кат: «Партиянең, иптәшләр, аның демократик централизмы да бар, аны да онытмаска кирәк. Югары органнар директивасы съездлар арасында һәр партия члены өчен закон»,— диде. Гадәтенчә, Харис сабырлыгын тиз җуйды:

— Иптәш Гайфетдинов, әйләнгәләп-тирбәнгәләмичә генә аңлат әле, үз принцибыгыз ничек? — диде. Җәүдәт күзлеген салды.

— Минем принцип — партия принцибы,— диде ул, Галиевкә карап. Галиев башын югары күтәрде, һаваланып, һәр партком членына күз йөртеп чыкты.

Башлап Мисбах Ганиев сүз алды:

— Бирергә, иптәшләр, сүз куертып утырасы юк. Харис үгезләрен тапшырырга кирәк, и вәссәлам! Кичә кич яңадан фермада булдым, аларны тапшырмау — җинаять. Дөрес, элек мин дә икенчерәк төрле уйлаган идем. Хаталык миндә. Яхшы, Хәсән абый якадан алды, йөри идем әле һаман шул килеш,— диде ул. Председательнең мондый тактикасы Галиевкә ошамады, күрәсең, ул нечкә бармакларын өстәл өстендә биетә башлады, председательнең сүзен башын кыңгыр салып тыңлады. Мисбах Ганиев урынына утыру белән, инспекция начальнигы сүз сорады.

— Бик тә примитив, элекке крестьянча, алга карамыйча уйлыйсыз сез, иптәшләр.— Галиев галстугын төзәтеп куйды.— Эш бит быел

белән генә бетми. Киләсе, аннан алдагы, тулаем бишьеллык планнар турында уйларга кирәк. Хуш, сез быел ул сиксән баш үгезне озаттыгыз, ди. Ярар, аннан акча керде, ди, планнан тыш тапшырган өчен илле процентын да иярттеп. Шуннан ни була? Күз ачып йомганчы тотып бетерәсез сез аны. Гаеплэп әйтүем түгел. Акчаның күзе юктан гына әйтүем. Ә киләсе ел планын кем үтәр? Сездән үк сораячакбыз бит без аны. Сездән үк! Ә аны үтәрлек рәтегез бармы? Ягез, карыйк әле,— ул шулай дип егерме дүртенче форманы кулына алды.— Айлык нәтиҗәләр менә болай. Савым сыерларыгыз дүрт йөз дә ике баш, киләсе ел аларның җиде проценты браковать ителәме? Ул буламы егерме сигез баш. Алар урынына быел ук буаз таналар куярга кирәк. Алар пока егерме ике генә баш. Мөгезле эре терлек планыгыз быелга барысы — мең дә бер йөз баш. Хәзер бар мең дә илле. Үтәлеп җитми илле, аның өстенә җитмәгән алты тананы да өстә. Барысы буламы илле алты. Тагын теге сиксән башны тапшырсак, ул була йөз утыз алты баш! Быелгы баш санын үтәү өчен генә кирәк бит ул. Аны каян алмак һәм планны ничек үтәмәк буласыз? Без бит, иптәш Ганиев, ул үгезләрне тапшыруны тоткарлаганда әнә шуларны да, аның өстенә район хәлен дә искә алдык. Район даны өчен һәркем янарга тиештер, минемчә...

Әнә кай як белән суктырды начальник. Хәсән бусын уйламаган иде. Вәдүт тә әйтмәде бу турыда, исеннән чыкты, үзләре уйласыннар, җаен тапсыннар диде микән. Ә Галиев һаман сөйли, исәплэп күрсәтә. Үзенең саннары белән Хәсәннең аңын томалап бетерә язды. Менә председатель реплика ташлады:

— Иптәш Галиев, сезнең дәлилләрегез дә дөрес, баш санын үтәргә кирәк, сүз дә юк. Без аның өчен җыелмадык. Сез конкрет кына әйтегез, рөхсәт итәсезме безгә үгезләрне тапшырырга, юкмы?

— Юк, район интересын искә алып, юк. Безгә киләсе елның январь аенда ук беренче квартал планын үтәргә кирәк. Беренче январьсыз рөхсәт юк.

Председатель нидер әйтергә дип авызын ачкан иде, өлгермәде, Харис чәчрәп сикереп торды һәм, көрәктәй кулларын алга сузып:

— Менә шушы куллар белән көне-төне эшләгәнемне җилгә җибәримме? Гади колхозчы, партком члены буларак әйтәм: бирми кара рөхсәт, бугазлап алырмын! — диде. Җәүдәт, графинга карандашы белән бәргәләп:

— Харис, этика кирәк, сабыр,— диде. Бу сүзгә Харис тагын да кыза төште:

— Сезгә генә берни түгелдер ул, ә минем бергә эшләгән, бергә аунап үскән кешеләргә күренәсем бар. Валлаһи, хатын, балалар күзенә күренергә оят бу көннәрдә...

Галиев аңламыйча сорау бирде:

— Нигә оят?

— Иөкләмәсен үтисе бар аның. Ярышучысы узып китте дә, шуңа көнчелегеннән нишләргә белми,— диде аңа Җәүдәт.

— Ярышта кем дә булса җиңелергә дә тиеш бит инде, аңа нигә кызарга? — диде Галиев. Харис аңа таба иелә төште һәм әкрен генә пышылдап:

— Ә минем җиңеләсем килми, абзыкаем! — диде.

Озак бәхәсләштеләр. Ләкин һаман бер фикергә килә алмадылар. Хәсән мыегын бөтерә-бөтерә сорау бирде:

— Бу турыда сезгә иптәш Моратов берәр сүз әйтмәдеме?

— Әйтте, урында, менә сезнең белән киңәшеп хәл итәргә кушты.

Галиевнең бу сүзеннән соң Харис тагын аягүрә басты. Аның йөзенә кызыллык йөгергән, иреннәре агарган иде.

— Соң, тагын ни кирәк? — диде ул тотлыга-тотлыга.— Сез генә каршы бит моңа: кул күтәрергә дә, эш бетте. Башкалар минем яктан сөйли бит.

— Бу купчелек белән хәл ителә торган мәсьәлә түгел. Эш монда принципта, район данында.

— Шилә кырыккан кеше икәнсез...

Харисның бу сүзенә Җәүдәт тагын графин шалтыратып алды. Хәсән беравык уйга калды, аннары иплән кенә урыныннан кузгалды да, барлык партком членнарына күз йөртеп чыкканнан соң, Галиевнең күзенә туры карап:

— Безнең мөлкәт белән идарә итәргә кем хокук бирде сезгә, иптәш Галиев? — диде.— Колхозчы үз тирен түгеп тапкан мал бит ул. Аңа ул үзе хуҗа. Бусысы булса бер, икенчесе шул: үзебезгә зыян ясый-ясый күз буяучылыкка барыйкмы? Ит белән әллә мактанырлыкмы хәлләр? Ул магазиннарда һәр вакыт булырга тиеш, туган. Китә торырга, алай гына түгел, срогында китәргә тиеш безнең ит рабочий класска. Менә шулай аңлыйм мин моны. Ул председательгә таба борылды.— Иптәш Ганиев, минемчә, иртәгә үк гомуми җыелыш җыярга, мәсьәләне шунда куярга кирәк. Колхозчылар безне аңлар. Гомуми җыелыш карарына кем каршы килә ала? Безнең өчен иптәш Галиевнең рөхсәт язуы кирәк тә булмаячак ул чакны. Берегез, үзең бару файдалы булыр, Бөгелмәгә барып кабул итү пункты җитәкчеләренә җыелыш карарын тоттырырсыз. Анда да җүләрләр утырмый, аңларлар...

Хәсән шулай дип урынына утырды. Галиев аңа чәнчеп-чәнчеп карап алды. Ләкин дәшмәде. Вәдүт Моратовичның Хәсән картны хөрмәт итүен белә иде ул. Бу тешле картка бик әче итеп, батырып әйтәсе килә дә бит...

Колхоз председателе Хәсәннең тәкъдимен хуплады. Иртәгә кичкә гомуми җыелыш җыярга булдылар. Галиевнең дә килүен үтенделәр.

— Миннән башка хәл итәсе булгач, минем ни кирәгем булыр инде? — диде ул, дулкынлануын яшерергә теләп.

Әмма килде ул җыелышка. Президиумда утырды. Тик авыз күтәреп бер сүз дә әйтмәде, чыгыш та ясамады. Җыелыш Харис терлекләрен иртәгә үк озату турында карар чыгарды. Җыелыш беткәч, Галиев колхоз председателе янына килде, дустанә генә кул биргән булды һәм, аскы иренен тешли-тешли:

— Хәзер бар инде Бөгелмәгә, Хәсән абый әйтмешли, анда да җүләрләр утырмый... Минем рөхсәттән башка алар бер баш та кабул итмиләр... Кул кирәк, имза кирәк,— диде. Председатель аңа сабыр гына җавап кайтарды.

— Тапшырырбыз, иптәш Галиев. Дөреслек безнең якта.

Галиев җавап бирмәде, кырт кына борылды да клубтан чыгып китте.

Дөреслекне чыннан да нык эзләргә туры килде председательгә.

Бөгелмәдә аның белән сөйләшеп тә тормадылар диярлек. «Рөхсәт язуы юкмы, юк. Әллә нинди язулар күрсәтсәгез дә булмый. Министр приказы шундый», гына диделәр. Шоферны кайтарып җибәрде дә Бөгелмәдән Казанга очты. Министрның үзенә барып житте. Әмма икенче көнне кулына язу алып кайтты. Шул ук көнне озаттылар үгезләрне. Колхозның барлык машиналарына төяделәр. Вәдүт Моратович аша СМУдан, «Сельхозтехника»ның район берләшмәсеннән машиналар алдылар. Председатель үзе, зоотехник, Харис үгезләр төялгән автоколоннаны озата киттеләр.

Хәсән карт соңгы олауны озатканчы фермадан китмәде. Менә ахыргысы, Харис утырганы да кузгалды. Хәсән аларга хәерле юл теләп калды. Ферма өенең дә ишеге ачылды. Иңенә тунын салган Асыл

чыкты. Ул, кулын каш өстенә куеп, саз ерып үкереп барган машиналарга озак кына карап торды. Янына килеп җиткән Хәсәнне абайлагач:

— Үҗәтләндеме тәки? — диде.

Хәсән, бияләйләре белән өс-башын каккалый-каккалый:

— Үҗәтләнде! Молодец кеше! — диде. Аның иңеннән авыр йөк төшкәндәй булды, тәннәре җиңеләеп китте.

— Атасы сыңары... Тешләк... Яратам шул тешләгән җиреннән өзгән кешеләрне. Сиңа карый да үҗәт ул Харис. Тик кызурак,— диде Асыл һәм ишеккә таба борылды. Хәсән аның җиң очлары, итәкләре өтәләнгән сары туныңа, бөкресенә карап торды да, көне буе йөгереп, кибеп беткән авызында бер тамчы да төкерек булмаса да, «тфү!» дип җиргә төкерде, юешләнеп беткән бияләен бил бавына кыстыра-кыстыра, авылга таба атлады.

## 15

Көн кичкә авышса да, үзенә күрә матурланып китте. Ноябрь азаклары булуга карамастан, җылытып та җибәрде. Ике ай буе күк йөзен каплап торган болытлар, тишек юрган кебек, ертылып-ертылып китте. Алар арасыннан салават күперәдәй кояш нурлары балкыды. Баеп барса да, яңа чыккандагы кебек тоелды Хәсәнгә бүгенге кояш нурлары. Ике ай буе күренми торганга күңел алгысап киткәндер инде. Хәсәннең күңеле күтәрелде. «Үҗәтләндеме тәки?.. Бусы сиңа карый да үҗәт»,— ди бит. Сиңа карый да җүләр дими, үҗәт ди. Шулай, безнең орлык корырдай түгел, Асыл, корымас. Харислар миндәй генә түгел... Тагы бер-ике елдан алар ниләр майтарганын күрсәң, күзләрең шар булыр әле. Аларны күрергә насыйп булса... сиңа да, миңа да. Ә күрәсе килә, бик тә килә. Шул көннәр хакына дип яшәде, үтте бит аның гомере.

Хәсәннең кинәт кашлары җыерылды, маңгае өстендә тирән буразналар сызылды. Алар әнә ничек берсе өстенә берсе өелгән. Кайсына нинди юл, тормыш сукасы эз салган? Йөрәгенә, бер учлык тормыш йомгагына гына төйнәлгән алар. Аларның очын табуы да авыр хәзер. Ә кайберләре, менә шулай ялгыз калганда, көннән-көн матурланган туган авылы урамнарыннан куанып узганда, көзен тын калган басуларны иңләгәндә борынын төртә һәм, шул җеп очына ияреп, тормыш йомгагы иплә кенә сүтелә башлый.

Маңгайга буразналар сызган иң авыр көннәрне сугыштан соң кичерде ул. Әле дә хәтерендә... Бөгелмәдә ишетте ул җан өшеткеч хәбәрне. Сугыш беткәч тә бер айдан соң демобилизацияләнгән иде. Канатлары булса, очар кошлар кебек бер тал-тирәккә дә кунмыйча кайтыр, бала-чаганың ялан тәпи эзләре калган изге сукмакларны сулышлары белән тартып китерер иде. Шулай ашкынып кайтты. Менә тетрәнерлек хәбәр.

— Синекеләрдән берәү дә калмады, Хәсән...

Бөгелмә вокзалы янындагы бәләкәй генә чәйханәдә авылдашы... очратты. Шул әйтте. Әйтмәгән булсачы... Һич югында, авылга чаклы ашкынып, дәртләнеп кайтыр иде. Биш ел буе сыгылу белмәгән иңнәре төште, дөнья мәгънәсез булып, арлы-бирле чабышкан, ашыккан кешеләр җанлы бер күләгә генә булып тоелды.

Кайтты... Минзәлә елгасы шулай, элеккечә, ярларына сыена-сыена ага. Ярлар шәрәләнгән. Тал-тирәкләрнең эзләре дә калмаган. Буа киткән. Текә ярлар, кыялар артында элекке Астафийның ике катлы таш тегермәне моңаеп утыра. Урамнарның рәте юк: капка-койма сирәк кешедә калган. Саламнары череп, каралып беткән өй түбәләрендә адәм буе алабуталар үсеп утыра. Ара-тирә тәрәзәләренә аркылы такта

кадакланган, сукмакларын үлән баскан өйләр очрый. Аның нигезе авылның Тышлык очы дип йөртелгән ягында иде. Солдат капчыгын иңенә аскан килеш, кирза итекләрдән, тузанлы юлдан ул барыбер шул якка, үз нигезенә ашыкты. Әнә өйләре. Морҗалары — сораеп тора, түбәләре, дөя үркәчедәй, урталай сыгылып төшкән. Юлда яшь-кыркыннар очрады. Ләкин аларның берсе дә аны танымады. Үзе төсмерләргә тырышты, әмма берәүгә дә ошатмады. Очраган бере ябык, өс-башларының адәм тәганәсе калмаган. Мыеклы солдатны сөзепсөзеп карыйлар. Аталарын көтүче балалардыр инде...

Хәсән үз урамнарына керде. Урам якта таш койма иде аларның. Үзе ташын ташып, үзе өйгән иде аны Хәсән. Урам яктан аны кычыткannар басып китә язган. Бәләкәй капка юк, баганаларын кемдер казып алган. Тамак төбенә төйнәлгән төердән Хәсәннең тыны кысылды, тез буыннары йомшарды, өйалды ишегенә, тәрәзәләргә кадакланган аркылы тактага текәлгән ачык күзләреннән өзелеп сагынуларны, юксынуларны, ил кайгысын үзенә сеңдереп тышка бәреп чыккан чишмәдәй яшь коелды. Беркавым шулай тораташтай басып торды. Аннары, иңеннән капчыгын алып, өйалды бусагасына утырды, башын тезләренә салды. Күпме сугышларда йөреп, күзеннән яшь чыкканы булмады. Ә бу минутта ул тыела алмады. Бөтен йөрәге, күңеле белән иңрәп, әллә ничә үлем алдында югалып, тетрәнеп калмаган мәгърур ир башын иеп, яшь койды, таң нурларын үзенә җыйган иртәнге чык төсле күз яшьләре мыек очларына җыелып тора-тора да, лепелдәп төшеп, баскыч тактасына сеңә... Кинәт ул баш очында кемнәндер ярдәм сорагандай еламсырап мияулаган мәче тавышы ишетте. Хәсән башын күтәрде... Ул!.. Аларның елкылдап торган кара йонлы мәчеләре! Әнә ул мияулыймияулый өйалды ишек өсте турына килде, уттай янып торган күзләре белән Хәсәнгә карап торды да ыңгырашкан төсле әллә нинди авазлар чыгарып, өй почмагына сикерде һәм, стенага үткен тырнаклары белән ябыша-ябыша, җиргә төште. Төште дә мырлый-мырлый Хәсәннең аягына килеп сарылды. Хәсән үксеп җибәрде. Мәчене кулына алды, аны дөньяда иң кадерле әйберсе кебек итеп сак кына күкрәгенә кысты, мырлап торган юеш, салкынчарак борынын яңакларына тидерде, башыннан, сыртыннан иркәләп сыйпады...

Кара мәче... һәм ишек-тәрәзәләре кадакланган нигез.

Сугыштан соң авыл әнә шулай каршылады аны... Ләкин яшәргә кирәк иде. Тормыш инстинкты аны үзенә ияртте. Ул, юл капчыгын чишеп, солдат паегы белән кара мәчесен сыйлап утырганда алардан ике генә йорт аша торучы Әсма килеп керде, эштән кайтышы иде. Ул сөйләде... Кар астында калып кышлаган башак агуланган икән ул елны. Халык шуңа ябырылган. Шуның белән агуланып, авылда җиде йорт эче үлеп беткән. Яраланып кайткан Газизе дә шуның белән китеп барган. Әсманың да ике кызы үлгән, ире — Хәсәннең кордашы — Сталинград янында ятып калган. Берүзе яши икән Әсма. Ул боларны, авыл хәлләрен елый-елый сөйләгәндә, башка күрше-күлән, бала-чага да җыелды. Хәсән, мәчесен кочаклаган килеш, Әсманың сөйләгәнен тын гына тыңлады. Җыелган бала-чагага капчык төбеннән алып шикәр өләште.

— Ике кызыңны бергә куйдык. Башта үлгәнен — Гамбәрияне аеры куйдылар, Газизне дә... Каберләрен беләм... Сулулар алгач күрсәтермен. Хатының Бәрия тилмерепләр үлде инде, Хәсәнемне көтә алмадым, балаларны булса да саклый алмадым, бәхилләр булсын инде, диде. Җан биргәндә янында булдым, аңа кәфенлеккә соңгы ашъяулыгым белән киндер капчыгымны бирдем,— диде Әсма, күзләрен әллә ничә җирдән ямалып беткән яулык чите белән сөртә-сөртә.

Шикәр әләктергән бала-чага да, күрше-күләннәр дә тарала башлады. Әсма гына калды.

— Инде нишләрсең икән, Хәсән? — диде ул еламсырап. Хәсән урыныннан торды. Мәчене җиргә куйды.

— Нишлисең?.. Яшәргә кирәк. Бу көннәрне күрермен дип кем уйлаган! — диде дә ишеккә аркылы кадакланган тактаны кубарды. Өйалды ишеген ачып керде. Шыр ялангач. Өй ишеген ачты, атлап керде дә туктап калды. Агач өстәл шул, карават та исән. Анда хатынының иске бишмәте дә бер колак мендәре тора. Кучкарда шешәгә мамык тыгылган лампа кебек нәрсә. Әсма да ишек янагына сөялгән килеш аңа карап тора. Бөтен җирне тузан баскан, теләсә кайда кәгазь ертыклары. Хәсән ни кыларга аптырап торганда, Әсма дәште:

— Хәсән, чиләкләрне ал да Минзәләдән су апкайт. Өеңне сөрткәләп чыгарыйм,— диде ул, җиңнәрен сызгана-сызгана. Хәсән бер сүз әйтмәде, өйалдында торган чиләкләрне алып суга китте. Ике рәт барып кайтты. Әсма бөтен җирне ялт итеп юып чыгаргач, өйгә бераз нур кунгандай булды.

Сугыштан соң үз нигезенә кайткан көнне төнен ул кара мәчесен кочаклап йоклады. Дөресрәге, күзен йомган килеш ятты. Күз алдында айдай балкып әле Бәриясе, әле кызларының чыр-чулашып кайтып кергәннәре пәйда булды. Солдат шинеле кигән Газизе, менә син дә кайттың, әткәй, дип елмаеп басып торды.

Авыр еллар иде. Икенче көнне үк колхоз идарәсенә барды. Арыктурык ат бирделәр. Шуның белән эшли башлады. Әкренләп җимерелгән-кыйшайган йорт-курасын торгызды. Шулай берүзе, ялгызак көе алты еллап яшәде ул. 1951 елны үзе кебек үк ялгызак Әсманы димләделәр. Икесе дә риза булдылар. Сабыр холыклы, аз сүзле Әсма белән яши башлау йөрәк яраларына әкренләп шифалы дару булды. Авыл, аның кешеләре белән бергә ул да үзгәрде, якты таңнарга таба кыюрак, җиргә ышаныч белән басып, аннан көч алып атлый, эшли башлады. Әсмасы аннан биш-алты яшькә кече иде. Ул бер-бер артлы ике кыз тапты. Өйгә генә түгел, күңелләргә ямь өстәлде. Үлгән кызларының яшьлеге кире кайткандай тоелды Хәсәнгә. Ул аларны шул кызларына охшатып сөйде. Болары да, алар кебек, Хәсәннең үзенә охшаган иделәр. Туп кебекләр, түгәрәк йөзле, кысыграк күзлеләр, бит очлары борчак сыярлык уймакланып тора. Икенче оя икенче нигез дә сорады. Әйбәтләп алты почмаклы өй салып җибәрде. Колхоз транспорт белән булышты, анысы бик ярады.

Хәзер кызларының берсе кияүдә, берсе укуда, врачлыкка укый. Хәсән кызы да врач булсын әле!

«Юк, корырлык та, югалырлык та түгел безнең нәсел, тамырлары нык аның!» — Хәсәннең иреннәре шулай дип пышылдады. Ул адымнарын кызулатты. Шул чак арттан шатор-шотыр килеп «Беларусь» тракторы куып җитте. Җитте дә шып туктады. Кабина ишеген ачып, фермага чөгендер, бәрәңге ташучы егет Хәсәнгә кул болгады.

— Хәсән абый, Хәсән абый!.. Асыл бабай үлеп ята! — дип кычкырды. Хәсәнгә әллә нинди бозлы су койгандай булды. Ул куырылды. Асылга да үлем тиюе аңа аяз көнне яшен суккандай булды. Аңа да вакыт җитәр икән. Ләкин күңеле ышанып җитмәде, эчкәндер әле, дип уйлады. Шулай да кире борылды. Ул килеп кергәндә өйдә авылның «Мең тәңкә» дип йөртелә торган бер үсмер җүләре генә бар иде. Ул Асылның авызына чүмеч белән су салып тора иде. Хәсән аны читкәрәк этеп җибәрде. Асыл янына килде. Ул олы якта диванда ята иде. Күзләре йомык. Өзек-өзек сулыш ала.

— Асыл, Асыл, ни булды? — дип дәште аңа Хәсән. Асыл җавап бирмәде. Хәсән аның янында, инде нишләргә дип, озак кына басып торды. Менә Асылның күзләре ачылды. Ул Хәсәнгә тутырып карады. Иреннәре кыймылдап куйды, ләкин сүзе чыкмады. Хәсән аның өстенә иелде һәм:

— Нәрсә дисең, Асыл? — дип сорады. Асыл бөтен көчен җыйды, аның яңаклары тартышты. Әмма сүзен ачык әйтте:

— Син җырлә инде...— диде. Минут та үтмәде, ул җан бирде.

Асылны икенче көнне җирләделәр. Юарга, кабер казырга болай кеше күп килде. Хәсән үзе кабер казышты. Менә зиратта тагын бер кабер артты. Тик баш очына таш утыртучы булмады. Барысы да таралды. Ялгыз кабер янында Хәсән генә басып калды. Әнә сугыш вакытында афәттән үлгәннәрнең каберләре кайсы буяулы койма, кайсы тимер челтәрдән, сабыйларныкы да. Баш очларында исемле ташлары. Һәр кабер өстендә сиреньнәр, яшел бәрхет бөркәнгән наратлар. Ә бу каберне кем әйләндерер дә, аның өстенә кемнәр генә агач утыртыр? Үзен белгәннәр үлеп беткәнче, бу кабер җир белән тигезләнер, аны килеп төзәткәләүче дә булмас. Хәсәннең дә моңа кулы күтәрелми. Озак карап торды ул зиратның бер читендәге ялгыз кабергә. Аннары, башын иеп, нидер уйлап, капкага таба түгел, зиратның таш коймасына таба атлады. Өелгән таш өстеннән өчпочмаклы зур гына ташны кубарып алды да аны Асыл кабереңнең баш очына утыртып куйды.

Әллә ничек күңелсез булып китте Хәсәнгә. Асылларсыз тормыш мәзәгрәк кебек тоелды. Аларсыз ничек яшәрсең? Әле шуңа ачу итеп, аның белән талаша-талаша, аны үрти-үрти, җенләнеп эшли иде. Бу да көч бирә иде аңа. Ә хәзер? Хәсән, нәрсәсендер җуйган, юксыну белән тулы күңеленнән шул сорауга җавап эзләде. Үзе дә сизмәстән, күз алдына партком утырышы, Галиев гәүдәсе килеп басты. Әнә ул ничек тәкәббер карый. «Сезнең монда сөйләнүләрегез нәрсә? Мин — баш, мин — түш», дигән салкын нурлар уалып коела аның күз карашыннан. Юк, Асыллар барысы да гүр иясе булып бетмәгән әле. Асыл, ичмаса, күңеле нәрсә уйлаганны шәрран яра да әйтеп сала иде. Аны авызлыклавы җиңел иде. Галиев кебекләрнең нәрсә уйлаганын белеп кара син. Йомшак җәеп катыга утырта, күз алдында күз буа беләләр. Харис үгезләре белән нинди канительләр тудырмады... Юк, тормышның яме китмәде Асыл үлү белән. Галиев кебекләр белән якалашып яшисе бар әле. Ә яшәү — көрәш, шунда җиңү — бәхет. Бәхетле ул Хәсән! Асыл, мәрхүм, сиңа ни житми дип, теңкәсенә тия торган иде. Җавабын тапты, тел очына үзе килде: «Бәхет бәйгесе өчен көрәштә алышыр кеше житми аңа, алышыр кеше житми! Ул һаман сабан туй батыры булып кала!»

Хәсән башын югары күтәрде, тормыш кайнап, яшәү шатлыгы бөркеп торган туган авылына, җылы, якты өенә, елмаеп торган Әсмасы янына ашыкты.

## Равил Фәйзуллин

# ТӨРЛЕ ДӘФТӘРЛӘРДӘН

### Ике күпер

Яңа күпер.
Тимер-бетон.
Җимерелмәс
күк күкрәткән
аллаң төшеп
биесә дә.

Яңа күпер.
Ыгы-зыгы.
Машиналар.
Юлаучылар.
Очрашалар.
Күрешәләр.

Ә читтәрәк —
иске күпер.
Мәет илткән
кабыкмыни...
Хәзер аннан
беркем йөрми.

Юк! Ялгышам:
төнлә монда
бер чал чәчле
ана йөри.
Күзенә аның
йокы керми.

«Белми бит ул
яңа күпер
салынганын!
Киткәне күк —
моннан кайтыр
минем балам...»

Ничәнче ел
ялгыз ана,
сугыш кырын
кабер иткән
улын гүя
каршы ала...

1962

*
* *

Анкетада, паспортта без,
белешмә кәгазендә,
бераүләргә — фотоларда,
табельдәге исемдә,
дипломнарда, суммаларда,
повестка, медальләрдә,
гайбәтләрдә, шигырьләрдә,
җисем-тәндә — бераүгә...

Кеше кадәр кеше бит без!
Язуга сыя бик аз...
Багам ташка, үләннәргә —
белергә телим бераз
үзем хакында.

Дөньяда чынлап яшимме?
Миндә ни чагылышы бар
авазларның, төсләрнең?
Миңа ни мөнәсәбәте
мәңгелек җисемнәрнең?
Ил-халыклар хәрәкәте,
социаль вакыйгалар —
минем уйда, телдә, көйдә
ни яңгыраш табалар?
Хаҗәтем дәрәҗәсе ни
шушы Җир улы булып?
Әйтче дөресен, Табигать,
хаким булып, олы булып!
Исәп, исәп, исәп, исәп...
Уйлар күче — яшь башта.
Ә күзләрем һаман бага
үләннәргә дә ташка...
Бу үләннәр, бу ташлар шул
элек киткәннәр төсе...

Ятар туфрагы өстендә
яши, көрәшә Кеше.
Мизгел яшәп, мәңгегә дип,
корган уенда көче!

1971

## Берлек

Без — үрмә гөл түгел.
Яшәп булмый гел үрелеп бергә.
Һәр кешенең үз сукмагы үзгә.
Ялгыз башка күмәк сынауларын
тормыш безнең алга күп тезгән.
Ә шулай да, бәхет бу дөньяда
бик күп, бик күп бирелгән безгә!

Теләк булса, һәр хәлиткеч чакта
килә алабыз уртак бер сүзгә;
уртак сөенү, уртак хәсрәтләр
чагыла ала миллион йөздә.

Ялгыз дисәк тә, япа-ялгыз түгел.
Күк астында, шушы тормышта
күпме кеше бергә атлый ала,
сулаган күк бер үк сулыштан!
Бергә барып була, бергә җырлап,
уртаклашып сынык икмәкне...
Була... кайчак пуля тишеп үтә
бер сафтагы ике күкрәкне.
Була бергә янып мәхәббәттә,
хозурлыгын тоеп таңнарның.
Күпкә түгел, азга булса да,
бергә тибүләре җаннарның
бәхет түгелмени?

...Була үкенү, алданулар кайчак,
гайрәт чигү дуслар, ярлардан.
Әмма —
иң олы хис — Берлек хисе
торамыни үпкә-зарлардан?

Тормышта күп чатлар-аермалар...
Кем сукмагы кемне кая илтә!
...Кайчак язмышларны озын юллар,
еллар түгел, мизгел хәл итә!
Шул мизгелдә бергә булалганнар
мең рәхмәткә лаек, мең данга.
Китта түгел, шул Берлектә тора
Дөнья да,
Җир дә,
Ватан да!

1974

## Урта Идел халкы бәрәңге ала

Кайлардадыр хөрмә җыялардыр,
йөзем изәләрдер айкалып...
Безнең якта авыллары белән
бәрәңгегә чыккан бар халык.

Авыл өчен тансык сентябрьнең
аяз көне гомер гомергә.
Бурaзнада халык: казый, чүпли...
сөлек кебек ябышкан җиргә.

Шушы бураздалар крестьянның
язмышына кергән, канына.
Салган көче, килер өмете аның
гектарларда, сотыйларында.

Казыганы алтын булмаса да,
ким дә түгел бу як байлыгы.
Шушы туфракта, чәчкән-җыйганда —
кешеләрнең бәхете, саулыгы.

Шушы җирдә... Бар да ялтырамый —
төрле төре була байлыкның.
Эчтәрәге була, өстә ятмаганы —
күңелендәгесе күк халыкның.

Чумизалар, кукурузлар булды.
Үтте. Ә бәрәңге калды ул һаман.
Алданудан курка җир кешесе,
ә бәрәңге алдаламаган.

Авыл өйләренең төп терәге
бәрәңгедә, сөттә, арышта.
...Нидә үстең диеп сорамыйлар
сынауларда, яуда, алышта.

Һәм еш кына, буразнада аунап,
бәрәңгедә үскән малайлар,
җир үрләре белән чикләнмичә,
йолдызларга менеп алалар.

...Урта Идел халкы бәрәңге ала.
Бәрәңгедә гаме халыкның.
Кырда һөҗүм бара.
Җиңел түгел
алу җирнең карышын, адымын.

Тәгәрәшеп чыккач төпләреннән
буразналар китә яктырып.
Ул яктылык күчә күңелләргә,
җегәр кертеп, дәртне арттырып.

Уңган быел саратские дә,
ак сорты да, әмерханы да.
Муллык йөзе җирдә чалкан яткан
һәр күзәнәк саен чагыла.

...Кайлардадыр хөрмә җыялардыр,
йөзем изәләрдер айкалып.
Безнең якта авыллары белән
бәрәңгегә купкан бар халык.

Бер булса да үзе, төрле җиргә
төрлечәрәк карый кояшы.
Бүген авыл янып бәрәңге ала,
күтәрергә вакыты юк башын.

1974

## Безнең байлык

Алтыннар, көмешләр, гәүһәрләр...
Күзләрен яндырган кемнәрнең!
Мин исә хәтергә энҗе итеп
тезәмен бәхетле көннәрне.

Бар алар, бар алар
бернигә алышмас
бәхетле ак көннәр!
...Картлыкта дисбе итеп хәтердән
аларны тартсам да үкенмәм.

1974

Тала кул,
кибә ми...
Хезмәтеңнән —
Җиргә ни,
Илгә ни!

Миллионнар —
чәчәләр, уралар,
тегәләр, коралар...
Кешеләр
тир түгеп,
бил бөгеп
эшлиләр.

Аз — хезмәт кешесен сөям дип
күкрәк сугып ант эчүләр!

Миллион гадиләр
бер җайга эшлиләр.
Көрәшче кешеләр —
көчлеләр нишлиләр?

Икеләтә эшлиләр!
Өчләтә эшлиләр!

Карашлары —
үзләре тудырган
торба-машлар,
ракеталар,
чыбыклар аша —
киләчәктә.
Һәр эшче кул нинди хәрәкәттә?
Юл ачамы һәлакәткә,
әллә — тыныч яшәүгә,
иминлеккә,
рәхәткә?

. . . . . . . . . . .

Җирдә күп кешеләр.
Җирдә күп эшләләр.
Кемнәр соң
көрәшче-көчлеләр?
Максатларын белүчеләр,
эшләренең мәгънәсен, төп асылын күрүчеләр,
җирдә бәхет арттыручы хезмәт өчен
гомерләрен бирүчеләр —
шулар —
көчлеләр!

Аз — хезмәт кешесен сөям дип,
күкрәк сугып ант эчүләр.

1974

### Язгы кичтә көзге бер уй

Сагышлы үткәннәр,
билгесез киләчәк —
барсы да күзеңдә.

Минем өчен ят сызыклар —
җыерчыклар юк —
йөзеңдә.
(Дөресрәге,
минем өчен алар юк дип,
ышанып киләм үз-үземә.)

Ә шулай да
хәзер ешрак,
көн күзендә түгел,
эңгер-меңгер вакытта,
я тонык утта
багасың көзгегә...

Мин ул чак
(сискәндерермен күк)
төбәлмәскә тырышам йөзеңә.
Карап торам берәр әйбергә,
я тәрәздәге гөлгә,
я булмаса, матур тезеңә.

Язгы шәфәкъ,
моңсу йөз — көзгедә.

Көз өйдә.

1974

## Кыска шигырьләрдән

### Туган ягын оныткангa...

Өздереп сайрый сыерчык!
Аһәңе — колагымда!
Кайтып җиту шатлыгыннан
гыйбадәт кыла бугай.
... Туган ягын оныткангa
кош җанын бирсен ходай!

### Кыска шигырь

Сүз-пуля — аз.
Санаулы.
Киенмәгән ул
броняга, маск-халатка.
Кыска шигырь — охшаш шыр яланда
утка кергән ялгыз солдатка.

## Эзләр

Дулкыннарның эзе бармы?
Дулкыннар эзе — комда.
Еллар эзе кайда димсез,—
алары — маңгаемда...

* *
*

Бер чәчәктән ике балкыш:
берсе — көн, берсе — төн...

Кавышусыз мәхәббәттән
берсе җыр калдырмакчы.
Берсе — Кояшка үч итеп,
дөньяны яндырмакчы...

* *
*

Белсәм дә...

Син биргән бөек мизгелләр!

Кабатлыйм исемеңне —
мизгел өчен җаным белән
белсәм дә түлисемне...

* *
*

Бәхетле булсаң...

Кошлар китә. Саулык, байлык китә.
Карлар китә. Ярлар... Бар да китә.
Бәхетле булсаң —
язганы җитә.

* *
*

Сыңар шәкерте булмаган
бер «классик» агайга

Алдыңда кышың булса да,
җимешле чак — көзең юк.
Иҗатыңда йөзең юк.
Исемең бар, үзең юк.

## Соңарган диалог

— Бар!
Яшел үләннәргә яңагың куй!

Чатлама кыш иде тышта.

— Мә акча!
Әниеңә бүләкләр ал!

Ул күптән кабердә инде.

## Михайловскоеда

Йолдыз, кояшларны күрми торып,
ничек тоймак кирәк ак айны!
Мин Пушкинның торган җирен күреп,
бөеклеген белдем Тукайның.

1974

**Шамил Рәкыйпов**

ОЧЕРК

# «МӘҢГЕ САКЛАРГА!»



Мин кәгазьләр актарып утырам. Алдымда утызлап хат, архивта саклана торган мәгълүматларның униарча бит күчермәләре, Берлин операциясе һәм аңа кагылышлы сугышлар турындагы китаплардан язып алынган дистәләрчә битләр, фоторәсемнәр, газета мәкаләләре...

Болар — рейхстаг өстенә байрак кадаган татар егете Гази Заһитовның батырлыгы сурәтләнәчәк очерк өчен тупланган материаллар.

Менә Башкортстаннан җибәрелгән бер хат. Аны Газиның авылдашы язган. Ул, Гази Заһитовның «беркайчан да Герой булмавын» хәбәр итеп, чак кына ризасызлыгын да белдерә сыман.

Мин аны аңлыйм. Газета-журналларны караштырып бара, киноны, телевизион тапшыруларны кызыксынып тамаша кыла торган замана агаедыр ул. Юкны маташтырмагыз, дус кеше, рейхстагны алучы каһарманнар арасында Заһитов фамилиясе беркайда телгә алынмый, дип әйтүе дә мөмкин аның. Алар Гази белән бергә үскәннәр. Ул, мөгаен, болай фикерлидер: геройлар баскан урынында тора алмаган аргамактай ярсу, тау бөркетедәй кыю, арысландай гайрәтле булалар. Ә Гази, аучыларга хас булганча, атнага ике сүз әйтә торган йомыкый, юаш, түземле, сабыр холыклы булган. Кая инде андыйга кешене шаккаттыра торган батырлык?!

Гази, башка күп иптәшләре кебек үк, әрәмәдә ат көткән, печән чапкан, тайгага ауга йөргән; әтисеннән күреп сихәтле дару үләннәре җыйган һәм үсә төшкәч укырга киткән. Врач булырга хыялланган ул. Билгеле инде, алга куйган максатына ирешәчәгенә нык ышанган. Шөбһәләнергә нигез юк — тормышның корылышы шундый. Һәркемгә юл ачык, иренмә, ялкауланма гына. Һәм тырыш, сабыр Гази техникумга керә. Ләкин көтмәгәндә — матур хыялларны чәлпәрәмә китергән сугыш. Фашистлар җирдә кешелек күрмәгән явызлыклар кыла башлый. Егет йөрәге моңа ничек түзсен?! Аңарда мәкерле дошманга аяусыз үч, нәфрәт кабына — чикерткәне рәнҗетергә дә батырчылык итмәгән яшүсмер үч алучы булып сугыша.

Моннан утыз ел элек аны Советлар Союзы Герое исеме бирүгә тәкъдим итеп акка кара белән язганнар: «30 апрельдә рейхстагны штурмлаганда Заһитов рейхстагка беренче булып бәреп керде... Яралы килеш,

рейхстаг түбәсенә беренче Җиңү байрагын кадады. Рейхстагны штурмлаганда күрсәткән батырлыгы, гайрәте һәм каһарманлыгы өчен иптәш Заһитов Советлар Союзы Герое исеме бирүгә лаек».

Мин ышанам: тамчы да хилафлык юк монда. һәммәсе булган боларның, хәтта артыгы беләндер бәлки. Тик аның фамилиясе хәзергә геройлар исемлегендә юк. Юк... ә күрсәткән каһарманлыгы моңа лаек табылган. Шулай дип тарихка кертелгән һәм бу батырлык язылган документлар кенәгәсенең тышына «Мәңге сакларга!» дип мөһер басканнар. Димәк, бәясе чиксез кыйммәт бу кәгазьләрне киләчәктә бер кеше генә кулына алмас әле...

Мин кабат Бүләкләү кәгазенә текәләм. Кабат укыйм: «Өлкән сержант Гази Заһитов, яралы килеш, рейхстаг түбәсенә беренче Җиңү байрагын кадады».

Бу кысынкы, саран җөмләләрдә ничаклы тирән мәгънә, серле язмышлар?! Халкыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыкларын ишәйткән тагын бер якты сәхифә дип бәяләргә кирәк моны. Сөйләтәсе иде һәммәсен Газиның үзеннән иркенләп, тәртибе белән, тәфсилләп, тик соң шул инде: ул тау өстендәге каберендә йоклый. 1945 елның 1 мае көнне төшкән рәсеме исә дәшми...

Шунысы куанычлы, тарихи фоторәсем, көннәр үтү белән, барыбер телгә килде бит, килде!

Мин Газиның элеккеге полкташы, сугышчан дусты Михаил Петрович Минин хатларын кулыма алам.

Миңа хәзер шул билгеле: Хәрби академияне тәмамлаганнан соң, Воронеж шәһәрендә хезмәтен дәвам иттергән инженер-майор М. П. Минин — 1945 елның 30 апрель төнендә рейхстагка Җиңү байрагын кадаучыларның берсе. Ул «Без беренче!» дип күкрәк кагып йөрмәгән, дан артыннан кумаган. Ә СССР Оборона Министрлыгы архивында саклана торган тарихи мәгълүматларны дикъкать белән укып чагыштырсаң, уйлансаң, Минин һәм аның иптәшләре күрсәткән батырлыкка таң каласың, бу батырлыкның әлегә чаклы тиешенчә яктыртылмавы гаҗәпләндерә.

Минин соңгы хатында архивта саклана торган бер мөһим документның күчермәсен җибәргән.

Укыйм: «1945 елның 30 апреленнән 1 майга каршы төндә бригаданың разведчиклар төркеме, рейхстагка бәреп кереп, Берлин өстенә беренче булып Кызыл Байрак кадады. Рейхстагны алуга катнашучыларга — Германия башкаласы өстенә Кызыл Байрак кадаучыларга, шул исәптән яралы өлкән сержант Заһитовка, Советлар Союзы Герое исеме бирү һәм хөкүмәт бүләкләре өчен мәгълүматлар хәзерләп җибәрелде. СССР Оборона Министрлыгы архивы, фонд 136, 212465 тасвирлама, 23 бит...»

Бу документның күчермәсе миндә дә бар. Ул — 136 нчы Армия пушка-артиллерия бригадасының сугыш хәрәкәтләре дәфтәреннән. Көнендә язылган, димәк,— тарих үзе. Тик нишләп соң бу төркем күрсәткән батырлык әлегә чаклы матбугатта яктыртылмаган?

136 нчы Армия пушка-артиллерия бригадасы Берлинны алу өчен сугышларда 79 нчы укчы корпуска булышлык күрсәтә. Көтмәгәндә хәбәр тарала: корпус командованиесе рейхстаг өстенә Кызыл Байрак кадарга теләүче коммунистлардан һәм комсомоллардан штурмлаучы төркем оештырачак икән. Бригададан унбер кеше үзе теләп бу эшкә алына. Алар арасында беренче дивизионнан А. П. Бобров, Г. К. Заһитов, А. Ф. Лисименко һәм М. П. Минин да була... Ә бүтән частьлардагы разведчиклардан татар егетләре Вәлиев, Габидуллин, башкорт Рәхимҗан Кошкарбаев һ. б. лар теләк белдерә.

Заһитовлар төркеме 27 апрельдә кич 79 нчы корпус штабына килә. Биредә танкистлар, элемтәчеләр һәм артиллеристлардан 25 кешелек

штурм группасы оештырыла. Аның командиры итеп Мәскәү егете капитан Владимир Николаевич Маков билгеләнә.

Корпус политбүлеге начальнигы И. С. Крылов штурмчы бу группага, һөҗүм итүче башка частьлар белән бергә сугышып, рейхстагка бәреп керергә һәм аның түбәсенә Кызыл Байрак кадау бурычы куелуын белдерә. Моның нинди зур әһәмияткә ия булуын барысы яхшы аңлый: дошман паникага биреләчәк, корал ташлаячак. Димәк, һәр ике яктан ничаклы кеше гомерен саклап калырга мөмкинлек туа.

Политбүлек начальнигы ымлауга, бүлмәгә Байракны кертәләр. Капитан Маков, полковник кулыннан байракны тантаналы төстә алып, партия оешмасы секретаре буларак М. П. Минингa тапшыра.

Бу минутларда аның ничаклы дулкынлануын әйтеп торыргамы? Дөньяда шушы Кызыл Байрактан да изгерәк, кадерлерәк нәрсә булмагандыр секретарь өчен. Хәер, секретарь өчен генәме?

Смирно басып, керфек тә тетрәндермичә торган горур кыяфәтле иптәшләренә карый ул. Әнә нинди тәвәккәл һәм батыр алар! Лисименко, Бобров... Ә Заһитов һәммәсеннән калку, киң күкрәкле, калын муенлы, таза, чибәр егет. Шундый көчле кешене үз янында тою һәрчак ышанычны арттыра, гайрәт өсти. Заһитов төркеменең төнге «аудан» беркайчан да буш кул белән кайтканы юк. Ул тегенди-мондый яралануга да игътибар итми. Дәвалау ысулларын яхшы белгәнгә, бик тиз беренче ярдәмне күрсәтә. Үзе ул санчастька барып та тормый һәм башкаларга караганда тиз терелә. Кыскасы, бу төркемдәге сугышчылар менә дигәннәр. Шуңа күрә Минин нык ышанып:

— Байракны рейхстаг түбәсенә кадарбыз! — ди.

— Кадарбыз! — диләр иптәшләре, секретарьны куәтләп.

Автомат, гранаталар, пистолет һәм хәнҗәр белән коралланганч, китәргә боерык бирелә.

Мин үз-үземә сорау бирәм:

— «1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы» дигән китапта бу группа турында бертөрле дә хәбәр юк. С. А. Неустроев һәм К. Я. Самсонов батальоннары исә телгә алына. Ни өчен шулай?

Актарына торгач, җавап табыла: кыю егетләр капитан Неустроев батальоны составында булганнар икән.

Ничә армия, ничаклы техника рейхстагка ыргыла. Яралы сугышчылар санчастька барудан баш тарта. Гитлерны әсир итәргә теләүче кайнар канлылар ишәя. Тик бу кыю теләкләрне гамәлгә ашыруы гына җиңелдән түгел: рейхстагка килү юлларын фанатик фашистлар саклый, алар үз канына исергән ерткыч күк ярсып сугышалар. Һәр йортның подвалыннан, тәрәзәләреннән ут ява. Урам-тыкрыкларда, бакча, паркларда адым саен диярлек миномет, пушка установкалары, җиргә күмеп бәләкәй крепостька әверелдерелгән танклар. Дары төтене, хәрабәләргә әверелгән йортлардан чыккан тузаннан — тирә-як кояш тотылгандагыдан да караңгырак. Җәһәннәм дигән нәрсә булса, ул шуннан артык түгелдер.

Мининның бер кулында автомат, икенчесендә чехолга салынган байрак. Заһитов — алда. Разведка ясый да кул изи, разведка ясый да кул изи. Утлы кургаш бөркеп яткан җимерек йортлар арасыннан мең бәла белән алга үрмәлиләр. Хәзер инде алар төп частьларны шактый узып киткәннәр. Инде үз көчләренә генә таянырга туры килә. Каршылык артканнан-арта. Капитан Маков, әледән-әле рациясен көйләп, артиллеристларны ярдәмгә чакыра.

Шулай өченчеме, дүртенчеме тапкыр артиллерист дуслар ярдәменә сыенганда, болар өстенә таш стена ишелә. Унсигезәү генә калган булалар, бу юлы тагын ике сугышчы сафтан чыга, ә Ленинград егете өлкән сержант Алексей Петрович Бобров контузия ала.

Фашистлар, безнең разведчикларның кайдан хәбәр биреп ятуларын сизеп, алар урнашкан йортка снарядлар яудыра башлый. Гөрселдәп

түбә ишелә, стеналар ава. Бобров, командирын гәүдәсе белән каплап, аны үлемнән саклап калырга өлгерә. Аңа Советлар Союзы Герое исеме бирү өчен язылган Бүләкләү кәгазендә шундый юллар бар:

...«Бобров һәм аның иптәшләре, немец позицияләренә үтеп, рейхстагка төбәп атучы безнең артиллерия утын корректирладылар. Алар урнашкан йортны фашистлар камап алды, ләкин разведчиклар бирелмәде. Бу сугышта Бобров, автоматтан атып һәм граната ыргытып, 11 немецны юк итте. Разведчиклар дошманның һөҗүмен кире кактылар һәм йортны безнең пехотачылар килгәнче үз кулларында тоттылар...»

Маков егылган җиреннән сикереп тора да: «Хәзер алга, егетләр, фәкать алга!» — дип боера.

Тоташ янгыннар эченнән төне буе баралар да баралар. Төтенгә түзеп булмый — тончыга башлагач, җиргә ятып хәл алалар, һуштан язучыларга су бөркиләр.

Капитан Маков корпус штабы һәм батальон командиры Неустроев белән даими элемтәдә тора, дошманның бу тирәгә тупланган көчләре турында мәгълүматлар тапшыра.

Икенче көнне ниндидер бер зур йорт ишеге янында немец часовоен юк итәләр. Бераздан подвалда, күзләрне чагылдырып, гранаталар гөрселди. Исән калган 30 фашист кулларын күтәрә... Разведчиклар аларны тылга озаталар. Бу эпизод М. П. Минин һәм Г. К. Заһитовка Советлар Союзы Герое исеме бирү өчен язылган Бүләкләү кәгазендә телгә алына. Шушы документларның архивтан җибәрелгән фотокүчермәләрен үзара чагыштырып карасаң, һәммәсе туры килә. Һәммәсе дөрес.

Дәһшәтле 30 апрель кичен хыялымда күзалларга тырышам. Караган кинофильмнар искә төшә. Менә фашистик Германиянең Эчке эшләр министрлыгы бинасы. Менә җир астында тирәндә Гитлерның бункеры булган империя канцеляриясе... Берлин операциясен күрсәткән картадан шушы объектларны табып алам. Аларга хәтле безнең гаскәрләр зур бер оборона сызыгын үткән булганнар. Ул — ярлары бетон белән ныгытылган Шпрее елгасы. Аның аркылы салынган чуен күпер — Мольтке күпере. Фашистлар аңа ике урынга баррикада өеп куйганнар. Якын килерлек түгел — кыямәт уты яудыралар. Барыбер безнең саперлар күпергә үтеп миналарны зарарсызландыралар һәм өелгән ыбыр-чыбырны сүтеп юл ясыйлар. Бу яктагы үз йөрешле установкалар, танклар, артиллерия, минометларыбыз туктаусыз ата. Ләкин дошман подвалларга, кирпеч стеналар артына поскан — һаман бирешми. Безнең гаскәрләр күпердән теге якка чыгарга берничә кат күтәрелсәләр дә, бу хәзергә барып чыкмый. Караңгы төшкәч кенә елганың теге ягындагы йортлар өчен сугышырга тотындылар. Ниһаять, «Гиммлер йорты» — ягъни Эчке эшләр министрлыгы бинасы дошманнан тулысынча чистартыла. Моннан рейхстагка 500 метрлап кына инде. Һәммәсе — уң якка урнашкан 674 нче укчы полкның майор В. И. Давыдов батальоны һәм сул яктагы 756 нчы укчы полкның капитан С. А. Неустроев батальоны соңгы штурмга әзерләнә. Алар ике тапкыр күтәрелеп карыйлар, ләкин оборонадагы гитлерчылар яудырган ут ифрат көчле була. Исән калганнар снаряд чокырларына, траншеяларга ятарга мәҗбүр.

Көндез, капитан Маков боерыгы буенча, Гази Заһитов белән М. П. Минин «Гиммлер йорты»ның дүртенче катына менеп, рейхстагка үтү юлларын күзәтә башлыйлар. Алда Тиргартен паркы. Аны снаряд, миналар актарып бетергән. Танк үтмәсен өчен казылган киң чокырга туп-тулы итеп су җибәрелгән. Үткен күзле Гази, бер урында чокырга аркылы сузып салынган металл балкаларны күреп: «Шулар өстеннән йөгереп чыгабыз. Бу юнәлештә куркыныч азрак,— ди. Командир риза була. Караңгы төшә башлаганны көтәләр. Бу карарны корпус штабындагылар да хуп күрә. Аннан: «Озакламый гаскәрләр һөҗүмгә күтәреләчәк»,— дип белдерәләр.

Сәгать уннар тирәсендә безнең артиллерия рейхстагка һәм аның тирәсендәге дошман гаскәрләренә кабат бик көчле ут ача. Бераздан, күктә яшел ракета кабынуга, разведчиклар «ур-ра!» кычкырып алга ташлана. Су җибәрелгән чокыр аркылы салынган балкалар өстеннән йөгереп үтәләр. Пуля тиеп авып калучылар да шактый. Бина тәрәзәләрен томалаудан калган төзелеш әйберләренә ышыклана-ышыклана, рейхстагның төп керү ишекләренә омтылалар. Менә ул киң мәрмәр баскычлар. Сугышчылар өстенә яңгыр урынына пуля ява. Үлүчеләр, яраланучылар күп. Алар кулындагы флагларны исәннәр алып йөгерә. Колонналар ышыгына кергәч, пулялар куркынычы кими. Беренче эш итеп, колонналардан зәһәр свастикалы фашист байракларын йолкып алалар. Алар урынына разведчик Булатов белән башкорт егете Рәхимҗан Кошкарбаев үз флагларын бәйли. Бикле зур ишекләр янына дистәләрчә сугышчы җыела...

Язучы В. Субботинның 1974 елның 30 апрелендә «Правда» газетасында басылып чыккан фронт язмалары искә төшә.

150 нче укчы дивизиянең шул чактагы хәбәрчесе В. Субботинга взвод командиры лейтенант Рәхимҗан Кошкарбаев әңгәмә вакытында болай дигән:

«— Комбат мине «Гиммлер йорты»нда тәрәзә янына алып килде. «Рейхстагны күрәсеңме? — диде ул.— Кирәкле кешеләр сайла, флаг кадарсың». Һәм миңа төргәк тоттырды.

Бер төркем разведчиклар тәрәзәдән чыгып киттек. Тиздән җиргә ятарга туры килде. Фашистлар бик көчле ут ачтылар. Янымда нибары бер сугышчым калды... Ул әледән-әле: «Нәрсә эшлибез инде, иптәш лейтенант?» — дип сорый. Су белән тулы тирән чокыр янында ятабыз. «Әйдә флагка үз имзаларыбызны язабыз» — дим мин янымдагы иптәшемә һәм без шәмәхә карандаш белән шундук: «Л-т Кошкарбаев, кр-ц Булатов. 674-полк, 1-б-н»,— дип язып куйдык.

Сулы чокыр янында караңгы төшкәнче яттык. Аннары артиллерия ата башлады һәм без, беренче атышлар яңгырауга, рейхстагка йөгердек. Килеп җиткәч тә, Булатовның аягыннан тотып, өскә күтәрдем һәм ул икенче кат биеклегенә флагны кадады...»

Разведка взводы командиры лейтенант Сорокин өстәп: «Тәрәзә янындагы флаг кичке 8 ләр тирәсендә кадалды, ә 11 сәгать 30 минутта атлар өстенә, түбәдә. Бу төркемдә разведчиклардан Орешко, Провоторов, Пачковский, Лысенко, Габидуллин һәм Бреховецкий бар иде», — дигән.

Мин, 150 нче укчы дивизия командиры генерал-майор Шатилов һәм шул ук дивизиянең штаб начальнигы полковник Дьячковның 1945 ел, 30 апрельдә 18 сәгатьтә 79 нчы укчы корпус штабына җибәргән докладнойларын (Оборона министрлыгы Архивы, фонд ЗУА, 4306 тасвирлама, 528 эш, 45 бит) хәрби тарихчылар өйрәнүенә калдырып, Беренче Белоруссия фронты командованиесе рейхстагка кадар өчен ничә Байрак билгеләве турында уйланам.

Е. Долматовскийның «Җиңү автографлары» исемле китабында алар тугыз диелә. Шулар өстенә сугышчылар үзләре әмәлләгән флаглар да шактый булган икән әле... Ә капитан Маков җитәкчелегендәге Заһитовлар төркеменә 79 нчы укчы корпус политбүлегендә хәзерләнгән Кызыл Байракны рейхстаг түбәсенә кадау бурычы йөкләтелә.

...Менә бу төркем рейхстагның нык имән ишекләре янында. Капитан Маков боерыгы буенча Заһитов, Бобров һәм Лисименко баскычта яткан бүрәнәне күтәреп киләләр. Аны дистәләрчә куллар эләктереп ала һәм ишеккә томырырга тотына. Ишекне ватып, автоматлардан ата-ата, караңгыга ташланалар. Артиллеристларга рәхмәт: гитлерчыларның шактый өлеше, рейхстагка яуган көчле утка түзә алмыйча, подвалларга поскан. Бүлмә арты бүлмәгә бәреп кереп, автоматлардан ут чәчәләр.

Караңгы. Өлкән сержант Гази Заһитов кесә фонаре белән әледән-әле коридорны яктыртып ала. Бер өер фашист почмакка ышыкланып безнекеләргә ут ача. Заһитов кулындагы фонарь — мишень бит инде ул. Минин граната ыргытып өлгерә.

— Алга, егетләр, алга! — ди төркем командиры, автоматтан өзлексез ата-ата.

Вестибюльгә чыгалар. Монда да фашистлар. Бу юлы Лисименко бер-бер артлы ике граната ташлый. Һава дулкыны томырылып өстән узуга сикерешеп торып, иелә-иелә йөгерәләр. Төтен күзләрне әчеттерә. Ниһаять, алда — икенче катка алып менә торган баскыч. Култыксаларын граната умырган, тимерләре аждаһа тешләре сыман ыржаеп-тырпаеп калган... Шунда капитан Маков:

— Минин, байрак белән өскә! — дип кычкыра. Баскычка йөгерәләр. Заһитов фонарен яктыртып-яктыртып ала. Тагын гранаталар ыргыталар, җимерек баскычтан ата-ата меналәр. Аста безнең гаскәрләр сугыша. Алар хәзер фашистларны тоткарлап торалар. Менә икенче кат... Чарлак. Разведчиклар чарлакта түбәгә чыгарга җай эзли. Биредә бернинди баскыч юк. Шунда өлкән сержант Заһитов багана юанлыгы чылбырлары өстән төшеп торган йөк лебедкасын күреп:

— Чылбырга тотынып өскә! — ди. Бер-бер артлы өскә күтәреләләр. Кечкенә тәрәзә табып түбәгә чыгалар. Караңгы төшкән инде. Аста шәһәр тетенләп ята. Менә ул Берлин!.. Яктырткыч пулялар выжлап уза, миналар гөрселди, снарядлар ухылдап ярыла. Берсе шартлаганда янәшәдә көндез үзләре «Җиңү алласы» дип атаган скульптуралар төркемен шәйләп алалар. Һәм башня өстенә менеп баскан Заһитовка Кызыл Байракны сузалар. Аннары Заһитов, кулъяулыгын тешләре белән ертып, Байракны металл сапка бәйли. Мининны үз җилкәсенә бастырып, бронза ат өстенә мендереп җибәрә. Минин, еш-еш сулап, мең бәла белән скульптура таҗына якынлаша да Байракны кадый. 30 апрельдә рейхстаг түбәсендә җилфердәгән беренче Байрак була ул.

Икенче катка төшкәч, капитан Маков сугышчыларны тәбрикләп күкрәгенә кыса һәм, рацияне көйләп, корпус командиры генерал-майор С. Н. Переверткинга заданиенең үтәлүен белдерә. Корпус командиры үз чиратында һәммәсен кат-кат котлый да, дошманны өскә җибәрмәс өчен, баскычны сакларга боера.

Астагы бүлмәләрдә, коридорларда сугыш тагын да кыза төшкән. Рейхстаг түбәсенә алып чыга торган баскычка гитлерчылар ике-өч тапкыр ярсып һөҗүм итсәләр дә, Газилар чигенми. Шундый бәрелешләрнең берсендә Заһитов каты яралана. Аңа А. Ф. Лисименко беренче ярдәмне күрсәтә. Гази һуштан яза. Аңга килгәч, үзен санчастька озатырга кыстауларына риза булмый.

— Безгә... моннан китәргә һич ярамый! — ди ул.

Күпмегәдер тынлык урнаша. Аркасын соры таш стенага терәп баскычта кырын яткан яралы егеткә кайнар чәй эчергәч, ул күзләрен ача. Егет нык алҗыган, иреннәре күм-күк, күз төпләре кара көйгән, андасанда эре шадралы яңаклары эчкә баткан. Өч көн, өч төн буе керфеккә-керфек тидермичә һаман ут, төтен эчендә, әҗәл якасында йөре әле! Менә егерме биш кешедән алтау калдылар. Әле шул алтының берсе — Василий Фамильский бу группага юлда гына кушылган. Димәк, егерме биштән бишәү генә исән дигән сүз...

— Безнекеләр рейхстаг гарнизонына ультиматум игълан итәргә китте,— ди врач эзләп кайткан Лисименко һәм биш бармак чаклы гына шәм төпчегенә ут элдерә.

— Чынлапмы, Лисименко?

— Ихластыр әгәр. Үз күзләрем белән күрдем.

— Әйтәм, фашистлар тынып калды!..

— Бу бит, беләсезме, ни дигән сүз, егетләр?! — ди Гази. Аның чырае яктырып китә, күзләрендә нур балкый.
— Бу бит...— Ул, өч көн кырынмаган ияген капшап, сөенеченнән сүз таба алмыйча Бобровка карый.
— Бу — сугыш капут дигән сүз! — ди салкын канлы Бобров.
— Әйе, рейхстаг бирелсә, фашистларның күбесе корал ташлаячак, — ди капитан Маков та. — Шулай итеп, исән калдык микәнни без, ә?! Рейхстагка ультиматум, ә?! — Тарихи минутлар бу! Кызганыч, фотограф юк... Гомерлек истәлек булыр иде.
Шул чак кайсыдыр көтмәгәндә:
— Рәсемгә иртәгә төшәрбез. Ә хәзер секретарь взнос алсын да партбилетларга имзасын салсын! — ди.— Рейхстагта салынган имза — тоже тарихи имза!
— Дөрес!
— Шәп фикер! — диләр егетләр һәм, кабаланып, күкрәк кесәләренә тыгылалар.
Минин Заһитовка карый. Рейхстагка бәреп керүдә, аның түбәсенә менүдә зур батырлык күрсәткән бу яшь коммунистның партбилетына беренче булып үз имзасын саласы килә аның. Ләкин Заһитов та, Лисименко да бүтән батарея партоешмасында исәптә торалар. Бәлки... Юк, уставны бозарга ярамый! Егетләр, күрәсең, бу эшнең никадәр җитдилеген уйламыйлар әле. Заһитов кына билетын бирергә ашыкмый, кулын йөрәк өстендә тоткан килеш тора бирә. Тонык янган шәм яктысында иреннәренең тетрәнүе күзгә чалына. Парторг егетнең кулына игътибар итә һәм бармакларының калтыравын күрә. «Ни дә булса бар монда...— дип шөбһәгә төшә ул.— Әллә партбилетын җуйдымы икән?»
Заһитов һаман хәрәкәтсез тора, күзләре ярым йомылган, чырае ап-ак.
— Гази, көттермә...
— Шәм сүнә аннары!
— Давай тизрәк...— диләр башкалар.
Ниһаять, Заһитов күзләрен ача да еш-еш кайнар сулап: «Минем билетка... имза салып булмас, ахры...» — ди.
— Ник булмас?.. Ут-суларны кичеп, Берлинга җиткәч кенә билетыңны саклый алмадыңмы әллә? — ди кайсыдыр.
— Саклый алмадым шул... Бигрәк үкенечле булды... Яңасын кайчан бирерләр инде хәзер...
— Бирсәләр әле...
Һәммәсе тынып кала. Шәм сүнә. Нигәдер моңсу, авыр булып китә. Барысына билгеле: партия билетыңны җуйгансың икән, сиңа бернинди ташлама ясамаячаклар...
Аскы каттан төтен күтәрелә башлый.
Лисименко, борчылып, баскычтан аска карый.
— Ни булыр бу?..
— Мин хәзер белеп менәм! — дип, Бобров капитанга текәлә һәм, ул ризалык белдерүгә, автоматын әзер тотып, аска йөгерә.
Баскыч янындагылар сугышка әзерләнәләр. Гранаталарны барлыйлар, автоматларны коралар. Астан Бобров тавышы ишетелә.
— Фашистлар безне төтен белән тончыктырмакчылар,— ди ул.— Рейхстагның аскы катындагы бүлмәләргә ут төрткәннәр. Гарнизон ультиматумны кире каккан.
— Да-а... Эшләр болай булгач, хөртирәк әле...
— Үлсәк үләбез. Байракны алдыртмыйбыз!
— Фашистка бирер өчен менгереп кадамадык без аны рейхстаг түбәсенә! — диләр сугышчылар.
Аста кабат автоматлар тырылдый. Караңгылыкны телеп, утлы ноктталар сибелә. Стенадагы таш сыннардан кыйпылчыклар коела... Юк, дүрт

елга якын адым саен сагалаган әҗәл дигән бәдбәхет яннан китмәгән икән әле. Шунысы билгеле: бу аның соңгы селтәнүе, биредә алар ул аждаһаның авызын томалаячаклар. Менә-менә соңгы сәгате сугачак аның. Димәк, хәзер сугышчан дусларның гомерен күрәләтә куркыныч астына куймаска кирәк.

Тәтен... Тын алуы кыенлаша бара, төтен күзләрне әчеттерә, ә фашистлар астан да менә, коридорлардан да килә...

Минин Заһитов белән баскычны сакларга ята.

Заһитов гранатасын аска томыра.

Дошман чигенә. Тагын килә, тагын чигенә. Ниһаять, рейхстагның пыяласы ватылып беткән ялангач рәшәткәле гөмбәзе аркылы таң яктысы сирпелә. Бераздан көчле «ур-ра!» тавышлары белән бу шыксыз салкын бинаны селкетеп, рейхстаг бинасына өстәмә көчләр бәреп керә.

Заһитов, салынкы гына атлап, элеккеге урынына килә, кабат стенага аркасын сөяп утыра һәм, кабат уң кулын изүенә тыгып, күзләрен йома.

— Менә бит, агай, рейхстагны алып шатлыктан үрле-кырлы сикерәсе чакта, ут йотып утыр,— ди кайсыдыр.

— Гази, ничек булды соң бу? — ди Минин.

— Сизмичә калганмын, иптәш парторг...

— Ничек инде алай? Билетыңны сул түш кесәңдә йөртә идең бит,— ди Минин, Заһитовны аңламыйча.

Ул тагын да сәеррәк итеп җавап кайтара: «Билет хәзер дә шунда...»

— Соң, нигә, алайса, «саклый алмадым», дип аһ орасың?

— Чыннан да саклый алмадым шул, иптәш парторг...

— Үзе кесәдә, үзе «саклый алмадым» — нигә шулай боргаланырга, Заһитов?

Башка сугышчылар да болар янына килә. Һәммәсе аптыраашта: ничек була инде бу? Партбилетын сорагач, бая Заһитов, аңа имза салып булмас шул инде, диде, саклый алмадым, диде. Ә хәзер — кесәдә! Кесәдә булгач, нигә дип тукталып калырга иде?!

Заһитовтан җавап көтәләр. Менә ул, кырыс карашлардан уңайсызлангандай, башын аска ия һәм хәлсез тавыш белән: «Мин боргаланмыйм... Дөресен әйтәм»,— ди. Аннары күкрәк кесәсеннән партбилетын алып Мининга суза.

— Менә... имза салырлык түгел бит...

Партбилетны пуля үтәдән-үтә тишеп узган һәм ул бөтенләй диярлек канга манчылган икән.

Һәммәсе телсез кала.

Егетләр Заһитовның гимнастеркасын салдыралар. Бая Лисименко караңгыда җәрәхәтне бәйләгәндә күрмәгән: дошман пулясы Гази күкрәгенең сул ягыннан кереп, култык астыннан чыккан була...

Бу хәлгә ышанырга да, ышанмаска да белмиләр. Бүтәннәрдән ишетсәләр, бәлки юкны сөйләмәгез диярләр иде. Ә монда ул егет үзе күз алдында утыра. Аңа, Җиңү Байрагын кадаучыга, йөрәгенә төбәп аткаңнар. Һәм тидергәннәр. Ә ул барыбер үлмәгән, барыбер Җиңү Байрагын саклаучылар сафында калган. Могҗиза булмый ни булсын бу?!

Санитарны табып китерәләр. Ул да телен шартлатып куя. Җәрәхәтне бәйли һәм тизлек белән санчастька барырга куша. Ләкин Заһитов үз постыннан барыбер китми әле. Заданиене үтәгән төркемне корпус штабына чакыргач кына, башкаларга ияреп дигәндәй, рейхстаг түбәсенә меңәләр, байрак астындагы яссы ташка шәмәхә карандаш белән үз имзаларын салалар да аста фоторәсемгә төшәләр.

Рейхстаг эчтән пыскый. Рейхстагка яңадан-яңа сугышчылар килә. Алар, ни туры килсә шуның белән тырмаштырып, стеналарга, колонналарга үз имзаларын салалар да, чын җиңүчеләрчә изүне чишеп, бөергә таянып һавага ата-ата, җиңү салюты бирәләр. Гаҗәеп күренеш бу!



*Менә алар — рейхстаг өстенә Байрак кадаучылар: (сулдан) А. Ф. Лисименко, А. П. Бобров, Г. К. Заһитов, М. П. Минин.*

Һава болытлы, һәр җир пыскый-төтенли, ә безнең сугышчыларның йөзе көләч, шатлыкның иге-чиге юк.

Санитарлар, шәфкать туташлары рейхстагтан яралыларны ташыйлар. Эчтә корал ташлаган немец гаскәрләренә дә медицина ярдәме күрсәтелә. Аларны рейхстаг идәненә тезеп салганнар. Алар ыңгырашырга да читенсенеп, тыныч кына яталар. Подваллардан, бункерлардан йончыган, кара киемнәре ертылып беткән солдатлар һәм офицерлар чыга. Арада генераллар да күренгәли. Куллар югары күтәрелгән, күзләрдә курку, буйсыну...

Безнең сугышчылар һәр төркемнән диярлек: «Гитлер кайда?» — дип сорыйлар.

Әсирләр тиз-тиз: «Гитлер капут!» — дип җавап бирә.

Әсир төшү, җиңүче ихтыярына буйсыну паролена әверелгән мәзәк тә, чирканыч та булган бу сүзне безнең сугышчылар Сталинградта ук ишетергә күнеккән иделәр инде. Монысында ул чын мәгънәсендә дөреслеккә туры килгән: Гитлер кичә, 30 апрельдә, көндезге 15 сәгать 50 минутта, ягъни Газилар «Гиммлер йорты»ннан рейхстагны күзәткәндә, бункерында агу эчеп үзен-үзе үтергән булган инде. Аның үләксәсен нацистлар, империя канцеляриясе ишегалдындагы снаряд чокырына ташлап, өстенә бензин сибеп яндырганнар...

Бу хакта егетләргә, 8 нче Гвардия армиясенең яңа гына чыккан газетасын селки-селки, шатлыктан авызы колагына җиткән Вася Фамильский әйтә. Барысы аңа ябырыла. Буяу исе аңкып торган газетада Гитлерның үлемен хәбәр иткән хәбәр басылган була.

— Раз Гитлер капут, сугыш та капут, алайса — дип, Заһитов, үз эшен тәгәлләгәнгә санап, тынычлап санчастька юнәлә.

Докторлар аны рентгеннан карагач, шаккатканнар: пуля йөрәк яныннан бер сантиметр гына читтәрәк узган...

Иптәшләре Заһитовның тизрәк терелүен теләп, кул болгап кала.

Рейхстаг түбәсендәге скульптурада алар кадаган Кызыл Байрак һаман мәһабәт төстә җилферди...

Гази госпитальдә дәвалана, терелгәч күп тә үтми, демобилизациялэнә. Туган якларына — Башкортстан АССР, Мишкә районы, Янагуш авылына кайта. Якташлары аны авыл Советы председателе итеп сайлыйлар. Олылар хөрмәт итеп әйткәнчә, Газитдин сугыш китергән авырлыкларны тизрәк бетерү өчен җиң сызганып эшли. 1950 елда ул, партия Үзәк Комитеты чакыруына җавап төсендә, Бөре авыл хуҗалыгы белгечләре әзерләү училищесына укырга китә. Һәм аннан киң профильле механизатор таныклыгы алып кайта. Үзләренең Фрунзе исемендәге колхозда иң алдынгы тракторчы, комбайнчы була. Гази Заһитов 1953 елның 23 августында, авыл хуҗалыгы машиналары өчен запас частьлар алырга барганда, төнлә автомобиль һәлакәтенә очрап, фаҗигале төстә вафат була.

Рейхстагка Байрак кадаганы өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелүгә тәкъдим ителүен белгәндерме ул, юкмы — әйтүе кыен. Бәлки белмәгәндер дә. Бик тыйнак кеше була ул. Ә аның Герой исеме бирүгә тәкъдим ителүе хак. Һәм менә күргәнебезчә, бу документка дүрт генерал: 79 нчы укчы корпус командиры Переверткин, 3 нче Удар Армиянең командующие Морозов һәм 3 нче Удар Армия гаскәрләре командующие Кузнецов һәм шул ук Удар Армиянең Хәрби Совет члены генерал-майор Литвинов «лаек» дип кул куйган. Бу кәгазь 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре штабына җибәрелә...

М. Егоров һәм М. Кантария Беренче Белоруссия фронты Байрагын рейхстаг өстенә кадыйлар. 5 нче номерлы бу байрак Җиңү Байрагы дип кабул ителә.

Ә 79 нчы укчы корпус Байрагын фашистлар оясы рейхстаг өстенә кадаган Г. Заһитов һәм аның кыю иптәшләре Беренче Белоруссия фронты гаскәрләре командующиеның 576 нчы номерлы приказы нигезендә Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.



*1945 ел, 1 Май. Рейхстаг*

— Явыз дошманны җиңеп илгә кайтырга боерык алдык — шул иде безгә иң зур бүләк. Башкалар шикелле үк, Гази Заһитов та шулай уйлагандыр, мөгаен,— дип яза М. П. Минин.

Табигый матурлык беркайчан да бәясен җуймаган кебек, тыйнак батырлык та адәм балаларын үзеннән читкә этәрми. Халкы мактанычы булган чын батырның каһарманлыгы үз иленә кайчан әйләнеп кайтса да, соңламый, диләр. Хак сүзләр болар.

Әле шул араларда гына Михаил Петрович Минин истәлеккә дип миңа бер фоторәсем җибәрде. 1945 елның 1 Май иртәсендә төшерелгән рейхстаг рәсеме иде ул.

Эш кәгазьләрем арасында бүгенге рейхстагның да фоторәсеме бар. Бу — ФРГ эшлеклеләре тәкъдиме белән торгызылган рейхстаг. Ике рәсемне — ике рейхстагны — элеккегесен һәм хәзергесен чагыштырып карыйм. Алар бер-берсенә һич охшамаган. Түбәсендә Җиңү Байрагы җилфердәгән рейхстагны ни өчендер элеккеге стильдә реставрацияләргә теләмәгәннәр. Мин үз-үземнән сорыйм: ни өчен? Фашистик Германиянең хурлыклы җиңелүе, ваттырылган колонналар, статуялар, һәйкәлләр тузаны, көле белән кушылып, чүп-чар базларында тизрәк онытылсын дипме?! Мөгаен, шулайдыр... Алайса, ярый әле, антифашистлар рейхстаг стеналарындагы йөзләрчә имзаларны — җиңү автографлары салынган кайбер мәрмәр плитәләрне тарих өчен, хәтерне яңартыр өчен саклап калганнар дип куанам. Бу гаҗәеп коллекция хәзер музей түрендә. Рәхим ит, бар да кара... Кызганыч, рейхстагның стена плитәләре генә исән-сау калган. Гөмбәзне, гөмбәз янындагы статуяны, Газилар салган Җиңү имзалары белән бергә, көлгә әверелдерелеп һавага очырганнар...

Ярый әле, хакыйкатьне теркәүчеләр бар, архив бар. Сугыш сөреме сеңгән андагы кәгазьләрнең күбесенә, шул исәптән рейхстаг түбәсенә Байрак кадаган Гази Заһитов һәм аның батыр иптәшләре каһарманлыгы язылган кадерле битләргә дә «Мәңге сакларга!» дип мөһер басканнар!

Мин ышанам: чын тарихның үзе булган чиксез кыйммәтле бу кәгазьләрне бер генә кеше кулына алмас әле...

Госман Бакиров

# УЛ ЕЛЛАРДА

*Истәлек*

## I



елның җәе.

Матбугат йортының урамга караган тәрәзәләрен җәйге кояш нурлары кыздыра. Без, тәрәзәләрне газеталар белән каплап, эшләп утырабыз. Бүлмәбез шактый зур, дүрт почмакта дүрт язу өстәле. Ул өстәлләр янында язучылардан Афзал Шамов, Ибрай Гази, Хәсән Хәйри һәм мин. Эш сәгатендә сөйләшеп утыру юк. Шунысы кызык: беребез дә тәмәке тартмый. Эшләп аргач, болай гына коридорга чыгып сөйләшеп торабыз. Сүз иҗат эшләребез турында бара. Киләчәккә өметебез зур. Ләкин менә сугыш башланып китте бит, каһәр. Яшьрәкләр фронтка озатылды. Күп тә үтми, каләмдәш дустыбыз Муса Җәлилне дә озаттык. Озату алдыннан Матбугат йортының Тукай клубына җыелдык. Мусаның туганнары, дуслары, партия һәм совет җәмәгатьчелеге вәкилләре. Татар язучылары, композиторлар, Муса сүзләренә язылган җырларны башкаручы артистлар, Казанда торучы антифашист чит ил язучылары, рус совет шагыйре Алексей Сурков, Мусаның дусты һәм тәрҗемәче Семен Липкин һ. б.лар чын күңелдән шагыйрьгә җиңү юлы теләп калдылар.

Шуннан соң бераз вакыт үткәч, бер көнне безнең янга өстенә яшел гимнастерка, башына пилотка кигән Абдулла Алиш килеп керде. Ул кергәч, Ибрай Гази каләмен өстәлгә ташлады да, урыныннан кубып:

— Әһе, әле син дә хәрби киемгә төренергә өлгердеңмени?— дип, стена буендагы диваннан урын күрсәтте.

Алиш ботинкалы аякларын чалыштырып утырды да, гадәттәгечә елмаеп:

— Әйе, китәм, дуслар, менә киендерделәр. Күрешеп чыгыйм дип кердем,— диде.

Кайсыбыз диванга, кайсыбыз урындык алып каршысына утырдык. Байтак сөйләшкәч, ул, урыныннан кузгалып, барыбыз белән кул кысышып күрешеп чыкты. Мин аны коридор буенча баскычка кадәр озата бардым. Абдулла минем иң якын дустым иде. Күп еллар



*Беренче Украина фронтында миномет батареясе командиры, хәрби частьның партия оешмасы җитәкчесе, «Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасы хезмәткәре. Хәрби чины — старшина.*

Матбугат йортында бергә эшләдек, педагогия институтында бергә укыдык. Ул гына да түгел, квартираларыбыз да бер ишегалдында. Институттан кайтышлый Черек күл буйлап ай яктысында әдәбият турында сөйләшеп йөрибез. Шулай йөреп, соң гына квартираларыбызга кереп китәбез. Төн уртасына кадәр аның тәрәзәсендә ут балкый. Ул язып утыра торган иде. Шундый якын дустымның кулын кысканда миңа бик авыр булды. Исәнлектә күрешик, дип калдым. Ул, баскычның бер бүлеген төшкәч, борылып карап, кулын селекте:

— Хуш, дустым!

Бу соңгы күрешүебез булды...

Фронттан борчулы хәбәрләр килә, Кызыл Армиянең каты каршылык күрсәтүенә дә карамастан, дошман өере, Украина туфрагын таптап, һаман алга үрмәли, башкалабыз Мәскәүне кулга төшерергә ниятли.

Илебез гаять кыен көннәр кичерә. Фронтларда дошманга каршы көрәш алып бару белән бер үк вакытта кырлардагы игеннәрне түкми-чәчми җыеп суктырырга кирәк. «Бөтенесе фронт өчен!» Көн тәртибендәге төп мәсьәлә менә шул. Кырлардагы игенне үз вакытында җыеп алу өчен, шәһәр халкын колхозларга ярдәмгә җибәрә башладылар. Без дә, язу өстәлләрен каплап, пароход белән хәзерге Куйбышев районына киттек. А. Шамов, Х. Хәйри һәм мин салам түбәле бер йортның яшел чирәм каплаган ишегалдында палатка корып урнаштык. Безнең белән бергә корректор кызлар һәм машинисткалар килгән иде. Аларны өйләргә урнаштырдык. Көне буе борчак, карабодай җыеп кайтудан арылса да, алар кичләрен капка төбендәге эскәмияләргә чыгып җырлап утыралар. Без палатка эчендә уйланып ятабыз: сугыш кайчан бетәр, болай чүпләнеп йөрү белән генә фронтка зур булышлык күрсәтеп булырмы? Каләм урынына корал тотып фронтка китү хәерлерәк булмасмы?

Игеннәрне җыеп алгач, Казанга кайттык. Без тагын язу өстәле янында. Ләкин күңел тыныч түгел. Фронт ягыннан, Украинадан Казанга күчеп килгән хатын-кызлар, бала-чагалар көн дә артып тора. Менә бер төркем рус язучылары да килеп төште.

Эвакуациягә килгән шул язучылар белән Тукай клубында очрашу булды. Анда Д. Бедный, В. Бахметьев, С. Алымов, Доронин, Лев Ошанин, Кипринский, Москвин, Италия язучысы Дж. Джерманетта һәм башкалар катнашты. Алар үз чыгышларында бу сугышның җиңү белән тәмамланачагына һич шик тотмаулары турында сөйләделәр. А. Толстой да Казанга килгән иде. Язучылар белән очрашу вакытында ул шундый сүзләр әйтте: «Килер бер вакыт, мин бу сугышта татар халкының да зур геройлыклар күрсәтүе турында роман язармын». Кызганычка каршы, яза алмый калды, ул 1945 елда вафат булды. Шулай да ул безнең Казаныбыз турында бик матур истәлекле сүзләр

әйтте. Казан минем өчен,— диде ул,— туган йортым диярлек. Мин Казанда укыдым, анда беренче әсәремне яздым, хәтта беренче мәхәббәтем дә шунда бөреләнде». Чыннан да аның әсәрләрендә Казан исе аңкый. «Гадюка» («Кара елан») исемле повестенда ул Казан купецының кызын төп героиня итеп ала, «Хождение по мукам» («Хәсрәт чигеп йөрү») дигән әсәрендәге Телегинның тормышы шулай ук Казан белән бәйле...

Кыш җитте. Фронттан гел күңелсез хәбәрләр килеп тора. Дошман Ленинградны камап алган. Халкы ачыга, ягулык җитми. Фашистлар өере Мәскәү капкасы төбенә дә якынлашкан.

Шундый көннәрнең берсендә, Матбугат йортына култык таягына таянып Фатих Кәрим килеп керде. Кочаклап күрешкәч, диванга утырдык. Ул госпитальдә ятып чыккан икән.

— Семьям белән күрешеп чыгарга килдем. Сезне дә күреп чыгарга булдым,— диде ул.

— Тагын китәсеңмени? — дидем мин гаҗәпләнеп.

— Тагын,— диде ул, култык таягына үрелеп.— Берәр ай ял итәм дә тагын китәм. Дошман аяусыз. Идел кичәргә, Уралга омтыла. Тагын китәм...

Бу күрешү дә соңгысы булды. Ул сугыш кырында ятып калды.

Салкын кыш үтте. Җәй башланды. Сугыш дәвам итә. Немец илбасарлары Сталинград тирәсендә каты сугыш алып бара. Эшкә яраклы ир-ат фронтка китеп бетте, ирләр генә түгел, шәфкать туташы булып эшләрлек кызлар да китте. Ә менә без — ирләр, матбугат эше белән утырабыз. Кулда бронь булса да, әллә фронтка китик микән, дибез: «Яшең иллегә җитеп бара, син ул турыда борчылма»,— ди иптәшләр.

Булса ни. Мин мылтык тота беләм инде. Беренче империалистик сугышта катнашкан кеше бит мин. Дөрес, хәзерге кебек сугыш «төмен» белеп сугышкан егет түгел. «Ат», дисәләр, атам, «ят!» дисәләр, ята идем. Ә хәзер мин дошманга каршы көрәшнең мәгънәсен аңлыйм...

Семьям белән дә киңәштем. Китәргә булдым. Бергә эшләүче иптәшләрем белән хушлашып чыктым. Якын дустым Шәриф абзый Камал өенә дә сугылдым. Ул өйдә, Островский урамындагы квартирасында тәрәзә алдындагы язу өстәлендә эшләп утыра иде. Бик якын итеп безнең белән йөрешә торган җәмәгате Хәят җиңги, мине ачык чырай белән каршылап, чәй хәзерләде. Тыныч чакларда үткән көннәрне искә төшереп, сөйләшеп утырдык.

Шәриф абзый мине култыклап, парадный ишегенә кадәр озата килде, кулларымны кысып, фронттан исән-сау җиңеп кайтуымны теләп калды.

## II

18 нче ноябрь, 1942 ел. Минем фронтка китеп барыш. Казан вокзалында ыгы-зыгы. Фронт полосаларыннан күчерелгән хатын-кыз, бала-чага, карт-коры, зур-зур төеннәр, сандык һәм чемоданнар күтәреп, платформа буйлап ашык-пошык үтәләр. Аналарының итәкләренә тагылган яшь балалар, калышмаска тырышып, вак адымнарын кызулаталар. Берничә көннәр буена су тимәгән битләрендә юл-юл булып, яшь эзләре сызылган. Алар кысан вагоннарда килеп йончыганнар, әниләрен борчып, шыңшыйлар.

Якын дустым Афзал Шамов та озата килгән. Ул, минем кулларым кысып:

— Тиздән мин дә китәм. Канечкеч дошман һаман түргә үрмәләгәндә монда ничек түзеп ятарга? Китәм мин дә, сау бул, дускай, исәнлектә күрешик! — дип калды.

Әле генә бушаган вагоннарны сөберөп чыгарга да өлгермиләр, аркаларына сохари капчыклары аскан чуар киемле халык кереп тула да бара.

Туганнарын, улларын һәм ирләрен озатырга килүчеләр кочаклашып үбешәләр.

— Исән кайт, бәгырем!

— Немецларны җиңеп кайтыгыз, дуслар!!

— Сынатмагыз, туганнар!!!

Озатучыларның күз яшьләренә манылган бу сүзләре халкыбызның изге наказы булып яңгырый.

— Сынатмабыз, дуслар! — дибез аларга.

Паровозның көчле тавышы иртәнге тын һаваны ярып, таш шәһәр өстенә җәелә дә, биек йортлар арасына кереп югала. Вагон көпчәкләре салмак кына алга таба тәгәри башлый.

Безне Ижевск шәһәренә алып килделәр, сугыш эшенә өйрәтергә тиешләр икән. Частьларга бүлделәр. Кемнәр саперлар, кемнәр минометчылар бүлегенә алынды. Мине минометчылар частена билгеләделәр.

Көне буе урманда өйрәнүдә булабыз. Баракка кайткач, минометларны сүтеп җыябыз, шулай итеп аның бөтен «серләрен» өйрәнәбез. Мине политрук ярдәмчесе итеп куйдылар. Кичке занятиеләрне мин үткәрәм, стена газеталары чыгарам. Эш җитәрлек.

Фронттан килгән ямьсез хәбәрләр өстенә өйдән килгән хатта да бик кайгылы бер хәбәр килеп төште: күптән түгел генә хәерле теләк белән мине фронтка озатып калган Шәриф абзый Камал кинәт үлеп киткән икән. Бу хәбәрне алгач, мин кайгымны иптәшләр белән уртаклаштым да барак алдындагы эскәмиягә утырып уйга чумдым. Үткән көннәр, бергә очрашкан минутлар күз алдыннан кичтеләр. Тыныч елларда ул җәйне Түбән Осланда үткәрә иде. Бервакыт мин иптәшем һәм кызым белән анда кунакта булдым. Без килеп төшкәндә, ул ике бүлмәле агач өйнең бакчага караган тәрәзәсе алдындагы өстәлдә эшләп утыра иде. Әдәбият бакчабызда иң матур урын алган «Матур туганда» романын язуы икән. Без, эштән бүлдердек, дип уңайсызландык. Ул бер дә борчылу сиздермәде:

— Әзрәк ял да кирәк бит! — дип куйды.

Хәят җиңги ишегалды түрендәге агач бакчада, яшел үлән өстендә аш-су хәзерләп, кунак итте. Аннан соң Шәриф абзый белән Иделгә төшеп су кердек. Мин аның су өстендә батмыйча чалкан ята алуын күреп шаккаттым. Ул шулай яткан килеш газета да укый ала икән!..

Мин шундый күңелле сәгатьләрне күз алдына китереп озак утырдым. Минә хәзер минем шул якын дустым да юк инде...

Сталинград тирәсендә дошманга каршы каты һөҗүмнәр башланган. Эшләр ашыгыч. Безгә дә чират килеп җитте. Эшелонга төялеп юлга чыктык. Поезд Казан ягына бара. Минә туган авылым Курса да күренеп калды. Сабый чакта чана шуып уйнаган тау өсләре кар белән капланган. Хуш, туган авылым!

Кичкә таба Казан тирәсеннән үтеп киттек.

Вагон тәрәзәләреннән, яртылаш ачык ишекләрдән сузылып, озак карап бардык. Безне үстергән, безне иркәләгән ямьле Казан, безнең бөтен яшьлек истәлекләребезне саклаган, тыныч, шат тормышыбыз бишеге булган Казан минут саен ераклаша бара.

Вагондагылар тимер мич тирәсенә җыелып утыралар. Арада госпитальләрдән дәваланып чыккан кызылармеецлар да бар. Алар —

сугышны күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган егетләр. Алар безнең шикелле вагон тәрәзәләренә дә тыгылмыйлар, ишек янында да әйләнмиләр, бернәрсәгә дә исләре китмәгәндәй, тимер мич тирәсендә тәмәке суырып утыралар.

Күп тә үтми, тимер мич вагон эчен җылыта башлый, мич тирәсенә бүтәннәр дә җыелалар. Шинельле егетләрнең берсе, әледән-әле мич капкачын ачып, утлы күмерләрне актара, утын өсти, авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс кенә итеп нәрсәдер көйли. Икенчесе, аңа кушылып, көйне көчәйтеп җибәрә. Мич тирәсендә түгәрәкләнеп утыручылар, вагон тәгәрмәчләренең тыкырдауларына кушылып, җырлый башлыйлар: торган саен көчәя барган җыр тавышы бөтен вагонны шаулата. Ул диңгез дулкыннары арасында тирбәткән кебек, җанга рәхәтлек бирә, йөрәкне дулкынландыра. Авыр уйлар акрынлап тарала, йөрәктәге авыр төеннәр ниндидер бер тылсымлы көч белән чишелә бара. Ватаныбызга, халкыбызга карата тирән ышаныч тагын да көчәеп кабына, горурлану туа, дошманны җиңәрбез дигән ышаныч ныгый бара.

Менә Рузаевка станциясендә икенче көн туктап «хәл» җыябыз. Кайчан китәчәгебез һаман билгесез.

Туктале, дустым Шәриф Камал туып үскән, мәктәп ачып балалар укыткан Пешлә авылы шушы станция янында булырга тиеш ич. Шунда барып, аның сабый чакта уйнап йөргән урамнарын гына булса да карап килсәм! Аннары тагы минем тормыш иптәшем дә шушы авылда туган бит. Бәлки аның да туганнарын очратырмын. Безне фронтка озатучы капитан белән сөйләшеп алдым. «Бүген китмибез әле», диде ул. Шуннан соң мин, шинелемне җилкәмә салдым да, тәвәккәлләп, Пешләгә киттем. Ерак түгел икән шул! Ләкин урамнары тын, беркем дә юк. Тәбәнәк йортларны кар баскан. Мин урам уртасындагы карлы сукмак буйлап акрын гына атлыйм. Шул вакыт, көянтә-чиләк асып, чишмә буеннан күтәрелеп килүче бер хатын очрый.

— Кемне эзлисез, абый? — диде ул.

— Мин беркемне дә эзләмим, тик менә язучы Шәриф абзый Байгильдиев торган йорт күренмәсме, дип йөрим. Мин фронтка китеп барам.

— Һай, абый, ул торган йорт юк шул инде, ә-энә, анда агач мәчет янындарак булган ул.

— Минем тормыш иптәшем дә шушы авылда туган, ләкин алар бөтенләй Әстерханга күчеп киткәннәр. Монда туган-тумачасы калгандырмы, белмим.

— Исеме, фамилиясе ничек соң иптәшегезнең?

— Сайганова!

Бу сүзне ишетү белән хатын, чиләкләрен кар өстенә куеп:

— Минем дә фамилиям Сайганова, исемем Мәйсәрә. Әнә безнең өебез, ерак түгел, әйдәгез, чәй эчеп чыгыгыз! — диде ул.

Түр тәрәзәләре урамга караган, бакчалы бер йортка алып кереп китте бу. Өйдә ире чәй эчеп утыра иде. Ул тимер юлда эшли икән. Мин килеп кергәч, ул, урыныннан кузгалып, якты чырай белән каршылады. Самавар яңартылды, чәй эчәргә утырдык. Стенага эленгән балдызларым рәсеменә күзем төште. Аларны исемнәре белән әйтеп телгә алгач, минем Пешлә кияве икәнлегемә шик-шөбһә калмады.

Чәй эчкәч, рәхмәт әйтеп, урынымнан кузгалдым. Шәриф абзый йөргән урамнарны да күрәсем килгән иде, дигәч, Гали мине озата чыкты. Юлда Шәриф абзый турында сүз кузгаттым.

Моннан берничә генә ел элек, мин иптәшем ягыннан кардәш тиешле Хәнәфи абзыйны очраткан идем (80 яшьлек бу карт әле дә исән, Мәскәүдә яши). Ул Шәриф абзыйның беренче шәкерте булып, аның

мәктәбендә укыган икән. Менә шул абзыйның сөйләгәне искә төште. Ул болай дип сөйләгән иде:

— Авылыбызда мәчет янында бер агач мәктәп бар иде,— ди ул.— Бина икегә бүленгән иде, беренче яртысында — кыз балалар, икенче яртысында малайлар укыды. Шәриф абзый яңача укыта, җәгърафия, хисап, тарих кебек фәннәр дә бар иде. Укытучыбыз мәктәпнең бер почмагында, кечкенә генә бер бүлмәдә тора иде. Шушы авылныкы булса да, нигәдер ул үз йортында түгел, шул мәктәп почмагында куныл-төнеп ята иде. Ул көндезен ир һәм кыз балаларны укыта, ә кичен, без мәктәптә кунарга калгач, безгә русча укыта иде. Мәктәптә парта дигән нәрсә юк, астыбызга бишмәтләребезне җәеп, көрсиләр алдында тезләнеп утыра идек. Шәриф абзыйны бик ярата идек. Ул безгә дөнья хәлләре турында күп нәрсәләр сөйли иде. Русча да укыта башлагач, без бик куандык, әмма ләкин аңа русча укытырга рөхсәт бирмәделәр. Авылыбызда алты мәчет, 6—7 мулла бар иде. Менә шул бәндәләр жалоба язганнар, укытучы балаларны котырта, русча укытам дигән булып, патшага каршы сөйли, дигәннәр. Бер көн урядник кереп, Шәриф абзыйны үз бүлмәсенә чакырып алды. Ни турындадыр озак сөйләшеп утырдылар. Урядник киткәч, Шәриф абзый безнең янга чыкты. Аның төсе киткән, нигәдер бик дулкынланган иде ул. Бик күңелсезләнеп безгә карап торды да:

— Менә, балалар, моннан соң сез русча укый алмассыз инде, рөхсәт итмиләр, праваң юк, диләр. Жалоба биргәннәр! — диде.

Без бик күңелсезләндек. Русча бик укыйсыбыз килә, әти-әниләр дә каршы килмиләр иде.

Берничә көннән Шәриф абзый, иске чемоданын күтәреп, бүлмәсеннән чыкты да безнең каршыга килеп басты.

— Гаеп итеп калмагыз инде, балалар, хәзер мин мәктәптән китәргә булдым. Минем урынга икенче мөгаллим киләчәк! — дип безнең белән саубуллаша башлады. Без елап җибәрдек. Моны күреп, ул тагы: — Борчылмагыз, балалар, тырышып укыгыз, белем алсагыз, дөньяда ким-хур булмассыз, сау булыгыз! — дип чыгып китте.

Без аптырашып калдык, еладык, жалоба бирүчеләрне каргадык, нигә безгә русча укырга ярамый икән, правасы юк, имеш. Китүенең сәбәбе шул гына микән? — диештек без үзара.

Шәриф абзый шул китүдән югалды. Соңыннан гына белдек. Ул Оренбург якларына китеп, эшкә урнашкан икән. Ара-тирә авылга кайткалады. Без аны бик сагынып көтеп ала идек.

Хәнәфи абзыйның шул истәлеге турында сөйләп бара торгач, станциягә килеп җитүебезне сизми дә калдык. Шуннан соң Гали:

— Ул мәктәп юк инде, янган ул. Мин аны күрә алмадым,— диде.

Мин Шәриф абзыйның күптән түгел генә Казанда үлүе турында әйттем. Бу хәбәрне Гали ишетмәгән икән әле. Ул аптырап китте.

— Авыр туфрагы җиңел булсын инде. Бик әйбәт язучы иде бит ул. Без аның китапларын бик яратып укый идек, моннан соң да без аны онытмабыз,— диде ул.

Мин Гали кода белән күрешеп станциягә кереп киттем. Вагоннар кузгалмаган иде әле, һәммәсе дә үз урынында. Без икенче көнне иртән генә кузгалып киттек.

Кысып куелган вагон ишегеннән ап-ак кар белән капланган киң кырлар, болыннар, кар астында посып кына утырган авыллар күренеп калалар.

Станцияләрдә зур җанлылык хөкем сөрә. Танклар, машиналар, туплар төялгән эшелоннар фронтка таба туктаусыз агылалар.

Сталинградка якынлашып киләбез. Ләкин безнең поезд, кыр уртасында еш-еш кына туктап, сугыш вакытында җимерелгән юлларны рәтләгәнне көтеп тора. Юл буйларында тимер өемнәренә әйләнгән

машиналар, танклар аунап ята. Бу сугыш хәрабәләре — безнең өчен әле беренче күренешләр. Шуңа күрә бик кызыксынып, алар тирәсендә әйләнгәлибез. Менә, янган, җимерелгән немец танклары, аларның кайсылары йөзтүбән килгән, кайсылары борыны белән җиргә кадалып кергән.

Әнә, чокырларда дошман солдатларының үле гәүдәләре аунап ята. Җирле халыкның сөйләвенә караганда, алар — Сталинградта чолганышта калган немец солдатларының мәетләре. Алар пленга бирелергә теләмичә, ачы бураннарда, кар диңгезендә каңгырап йөреп, салкыннан, ачлыктан үлгәннәр.

Поезд күптән түгел генә давыллы сугышлар булып узган кырларны үтеп алга бара. Кулларында төрле флагчыклар тоткан, майланган киемле станция эшчеләренең, хатын-кызларның йөзләрендә шатлык нурлары балкый. Аларның елмаюлы йөзләреннән: менә поезд да йөри башлады бит, үзебезнең паровозлар кычкырып үтәләр, димәк, без азат ителдек, дигән фикерләрне укыйм мин.

Безнең юл Сталинград аркылы үтмәде. Сталинградта чолганышта калган немец гаскәрләре тар-мар ителгән иде инде.

Тимер-бетон баганалары гына тырпаеп калган күпергә җиткәч, поезд туктый. Без вагоннардан төшәбез һәм яңа гына чыккан юеш җир өстендә тезелеп басабыз. Шуннан безне миномет дивизионына алып баралар. Анда безне дивизионның үткән сугыш юллары белән таныштыралар. Полк минометларын күрсәтәләр. Күп сугышларда булган взвод командиры:

— Бу дәһшәтле корал белән без, калмык далаларын үтеп, Сталинград өчен барган сугышларда дошман өстенә коточкыч ут яудырдык. Фрицларның бик күп җанлы көчләрен, техникасын юк иттек! — ди.

Менә 120 миллиметрлы минометлар. Аларның һәрбер минасы бер пот чамасы, өч километр ераклыкка оча, дошман өстенә төшеп, берьюлы дистәләрчә фашист солдатын кырып ташлый.

Шул минометларның берсенә мине командир итеп билгелиләр. Мин риза. Көчемне кызганмам. Минем батарея составында канлы сугыш уты кичкән өч солдат та бар. Берсе кыргыз егете икән. Гаптерахман исемле. Минометларны төяп йөрүче пар атлы 6 арба бар. Шуларны төяп алга кузгалабыз. Без хәзер — Беренче Украина фронты сугышчылары. Алда зур көрәш юлы. Баш очында дошман самолетлары оча. Алар күренү белән без юл читендәге куаклар эченә чумабыз. Бомба ярылган урыннарда чокырлар казыла. Бу минем — дошман белән беренче очрашуым. Утлы яңгыр сибәләп торуга да карамастан, без, минометларны әледән-әле алга күчереп, дошман өстенә «күчтәнәч»ләрне җибәреп торабыз. Күзәтү пунктларыннан килгән хәбәрләргә таянып, прицелны күчерә торабыз.

Бер-бер артлы күп кенә авыллар азат ителә. Шулай атналар буе каты сугыш юллары үткәч, Ворошиловградтан 20 километр уңда тар гына бер үзәнлектә тукталып, оборонага күчәбез.

Анда миңа партия яңа бурыч тапшыра: батареяда партия җитәкчесе булып эшли башлыйм. Бу җаваплы һәм җитди эшне батареяда ничек җәеп җибәрү турында сөйләшү өчен коммунистлар белән беренче җыелыш уздырабыз.

Дошман самолетлары, өзлексез очып, безнең тылыбызны, оборона полосаларыбызны күзәтеп тора. Дошманның еракка ата торган туплары безнең өстебезгә снарядлар яудыра. Шуңа да карамастан, хәрби тормыш үз җае белән кайный бирә. Минометчылар үзләренең сугыш осталыкларын камилләштерү өстендә эшли. Мин землянкаларда беседалар үткәрәм, сугышчылар буш вакытларында, Ленин бүлмәсенә җыелып, газета-журналлар укыйлар. Туганнарына, якыннарына хат язалар.

Мин дә өйдән, каләмдәш дусларымнан хатлар алып торам. А. Шамов та миннән соң күп тормаган, үзе теләп фронтка китеп барган икән. «Фронт газетасында эшлим, алдынгы сызыкка кадәр барып, батыр сугышчылар белән бик еш очрашам», дип яза ул. Икенче дустым Ибрай Гази да онытмый, ул да фронттан язып тора. Ул «Сталин байрагы» исемле фронт газетасында эшли икән. «Бәкер дускай (ул мине шулай атый иде), без фашист юлбасарларны куабыз, безнең солдатлар тулы җиңүгә ирешәчәкләренә нык ышанып сугышалар. Исәнлектә күрешик», дип яза ул.

23 нче май. Җәйге кояш күк читендә очлаеп күренгән террикон өемнәре артына күмелергә дә өлгерми, тын үзән эчендә батарея командирының тавышы яңгырый:

— Һөҗүмгә әзерләнергә!

Кичке салкынлык кочагына чумган үзән эчендә кызу хәрәкәт башлана. Кояш баю белән тау итәгендәге яшел үләннәрне кимерергә өйрәнгән атлар бер минут эчендә миномет арбаларына җигеләләр. Авыр минометлар сүтелеп, арбаларга төяләләр. Минометчылар, чокырларыннан, землянкаларыннан бөтен әйберләрен чыгарып, мина ящиклары өстенә урнаштыралар. Караңгы төшкәндә колонна көнбатышка таба кузгала.

Озак та үтми, күк читендә йортлар, агачлар шәүләсе күренә. Бу — авыл. Юл читендә утыртылган баганага «Красная Поляна» дигән язулы такта кадакланган.

Кайчандыр тормыш кайнап торган бу авылның урамында гына түгел, йортларында да җан әсәре күренми. Урамнар, сукмаклар чүп үләннәре белән капланган. Җәй башыннан бирле ачылмаган капка төпләрендә, кеше аягы таптамаган ишегалларында, чишмә юлларында билдән үлән үскән. Алма, чия бакчалары, хуҗалары юклыктан ташландык хәлгә төшеп, моңаеп утыралар. Авылның бу күренеше йөрәкләрдә ачы сызлану тойгылары уята.

Биредә һәр йорт янында тирән итеп казылган, таш белән кысалаңган, түбәләре кирпеч яки таш белән көймәләп капланган подваллар бар. Шуларның берсенә телефон куеп, күзәтү пункты белән тоташтырабыз.

Икенче көнне мин, дулкынланып торган арыш басуы эченнән, яшеренә-яшеренә, кечерәк кенә бер калкулыкта, куаклык арасында урнашкан күзәтү пунктына барам. Бу урыннан стереотруба аркылы немецларның алдынгы позицияләре бик ачык күренеп тора. Алар анда тар гына бер инеш буенда урнашып, тирән окоплар ясаганнар. Аратирә аларның, инешкә чыгып, су алулары да күренә. Дошман окоплары бездән ике километр чамасы ераклыкта гына. Күзәтү пункты биргән мәгълүматлар буенча, без дошман позициясенә минометларыбыздан ата башлыйбыз. Дошман да ут нокталарыбызның кайда урнашканын сизеп, безгә туптан атарга керешә. Сызгырып килгән авыр снарядлар безнең окоплар өстендә җир селкетеп ярыла. Әле генә исән утырган йортлар, кирпеч, бүрәнә кисәкләренә әйләнеп, һавага оча. Шул вакыт кемдер:

— Лейтенант Перчинский һәлак булды! — дип кычкыра.

Командирларыбызның һәлак булу хәбәре бездә дошманга каршы ачу-нәфрәт ялкынын тагын да көчәйтә. Атыш беркадәр басылуга командирыбызны исән калган йортларның берсенә алып керәбез. Ул да булмый, 3 нче взвод сугышчылары орудие командиры старшина Ходжаевны күтәреп китерәләр. Ул снаряд ярчыгы тиеп авыр яраланган икән. Аңа ашыгыч ярдәм күрсәтәбез, яраларын бәйлибез. Ул авыр сулый. Тиз генә ат китертеп, санитария частена озатабыз.

Немецлар контратакага ташлана. Без Красная Полянадан алар өстенә көчле ут ачабыз. Ике яктан да башланган артиллерия атышы

сәгатьләр буена сузыла. Авыл янында уннарча «Катюша» телгә килә. Һәр ике яктан атыш нәтиҗәсендә авыл өсте кара төтен эчендә кала.

Подвалга урнашкан телефон аша взвод командиры лейтенант Германов безгә команда биреп тора. Без шуның буенча минометны әле уңга, әле сулга борып, дошман өстенә берәр потлы миналарны яудырабыз, ләкин, шуңа да карамастан, прицел киметелә бара, өстәмә зарядлар да биштән өчкә кала. Бу хәл дошманның һаман якынлаша баруын күрсәтә.

Димәк, хәл җитди. Ничек тә дошманның атакасын кире кайтарырга кирәк. Без тагын да ашыгыбрак ата башлыйбыз. Баш очында ярылган дошман шрапнельләре дә, җир селкетеп ярылган авыр снарядлар да безне туктатмый. Ящик артыннан ящик миналар килеп тора. 15—20 метр ара калдырып тезелгән минометлардан, ут көлтәләре чәчеп, миналар оча.

Шул вакыт телефон янында утырган комсомолка Лиданың тавышы яңгырый. Ул украинча:

— Нема лейтенант Германов, погиб командир! — дип кычкыра.

Әле генә снаряд төшеп ярылган подвал ишеге төбенә йөгереп киләм. Таш, кирпеч ватыклары өеме астында лейтенантның аяклары гына күренеп ята. Бер сугышчы белән мин аны актарып чыгарам. Исән, ләкин каты яраланган. Ат китертеп, аны санчастька озатабыз. Ләкин ул юлда вафат була.

Элемтәче Огнетов, бернәрсәгә дә исе китмәгәндәй, өзелгән телефон чыбыкларын ялгап йөри, күзәтү пункты белән ике арада элемтәне рәтли. Яратам да соң мин аз сүзле шул егетне! Бер караганда юаш кына булып күренгән бу егет ут эченә керер, ә өстенә йөкләнгән бурычны үтәми чыкмас!

Зарядны өстәргә команда бирелә. Бу безне рухландырып җибәрә. Димәк, дошман чигенә! Без һаман атабыз, ә дошман тына. Башларын, кулларын ак бинтлар белән ураган яралы пехотачылар урамнан үтеп бара. Кулын бинт белән бәйләп муенына аскан бер лейтенант, безнең янда туктап, су эчә.

— Я, сөйлә, иптәш лейтенант, алгы сызыкта безнең эшләр ничек? — дибез аңа. Ул әле суынып өлгермәгән минометларыбызга карап ала да:

— Молодцы, егетләр! — ди,— сезнең коралларыгыз бик туры суктылар. Дошман кыр тутырып үле гәүдәләрен калдырды, ул чигенә, хәзер безнең пехота аларның калдыкларын куа китте.

Атакасының уңышсыз чыгуыннан ярсыган дошман, яңа көчләр китереп, төштән соң тагын ут ача. Минем миномет сафтан чыга. Наводчик — кыргыз егете комсомолец Габдерәимов — һәм берничә иптәшебез яралана. Мин аның ярасын бәйләп, санитария частена җибәрәм. Ләкин тиешле ярдәм күрсәтелү белән үк ул тагы борылып кайта.

— Зарар юк, болай да үтәр әле,— ди батыр егет. Ул тимер кисәкләренә әйләнгән минометына карап тора да: — Сталинградтан ук килгән миномет! Моның белән без күп кенә немецларны кырган идек! — ди...

1943 елның 5 нче сентябре.

Безнең гаскәрләр авылдан-авылга немецларны куып, Донбасс үзәге Сталинога бара. Бик күп шахталар очрый. Ләкин аларның барысы да шартлатылган, яндырылган.

Таң алдыннан Макеевкада туктап, минометны әле яныгп, пыскып утырган бер йорт янында урнаштырабыз. Тирә-юнебез немецлардан тазартылмаган әле. Чигенергә өлгермәгән дошман солдатларын

берәм-берәм тотып алабыз. Аннары минометны Макеевканың икенче урамына күчерәбез.

Шул вакыт тимер рәшәткәле капка төбенә баласын җитәкләп бер хатын килеп чыга. Йөзе шат.

— Арагызда татарлар юкмы, иптәшләр? — ди ул татарчалатып.

Мин аның каршысына килеп:

— Исәнмесез? Менә мин — татар,— дим.— Баласының башын сыйпыйм.

— Сезнең татарча газетагыз яки китабыгыз юкмы? Үз телебездә басылган китапларны бик сагындым,— ди ул.

Фронтка киткәндә генә басарга биреп калдырган «Яшь патриотлар» исемле җыентыгымның бер санын кичә генә почта аркылы алган идем. Әле укып бетермәсәм дә, сумкамнан чыгарып, аңа бирдем. Ул бик куанып:

— Рәхмәт сезгә! Җиңеп кайтыгыз! — дип, кулымны кысып калды.

1943 елның 23 нче декабре. Без хәзер Беренче Украина фронты составында. Землянкада җыелып, шәм яктысында командованиенең иртәгә һөҗүм башлау турындагы приказын укыйбыз. Һәрберебезгә конкрет бурычлар йөкләнә. Аннары:

— Урыннарга! — дигән тавыш урман эчен яңгыратып җибәрә. Йөгерешеп минометлар янына чыгып басабыз. Һәркайда кызу хәрәкәт башлана, наводчиклар алдан хәзерләп куйган установкаларны тикшерәләр. Расчетның башка номерлары мина ящикларын ачып, миналарны хәзерли башлый.

— Менә хәзер «концерт» башлана! — диләр минометчылар.

Кайдадыр, нарат урманы кырыенда урнашкан «Катюша»лар «концертның» беренче номерын башлап җибәрә. Аның артыннан йөзләгән орудиеләр эшкә керешә. Без дә бөтен минометлардан берьюлы ут ачабыз. Күкләр гөрелди, җирләр селкенә башлый. Миномет көпшәләрен әле уңгарак, әле сулгарак боргалап, наводчиклар ату юнәлешен үзгәртеп тора. Зарядлар өстәлә бара. Прицел күтәрелә. Ут валы һаман алга таба күчерелә тора.

Бераздан минометларны төяп, алга күчәбез.

Менә дошманның беренче окоплары. Кая карама — үлекләр; землянкалар җимерелгән; траншеялар җир белән тигезләнгән. Тирәюньдә немец автоматлары аунап ята, патроннар, пулемет тасмалары белән җир өсте тулган.

Ашыга-ашыга атларны куабыз. Арба көпчәкләре, сукаланган пычрак җир өстен ярып, бик авырлык белән генә алга тәгәри.

Әнә снаряд ярчыклары бер атыбызның борынын яралады. Ярасыннан кып-кызыл кан шаулап ага, ләкин ул, шуңа да карамастан, авыр арбаны сөйрәп, һаман алга атлый.

Җимерек окоплардан, кулларын күтәреп, бер төркем немец солдатлары чыга. Алар нәрсәдер мыгырдыйлар, имештер, биредә алар үзләре теләп калганнар. «Безгә тимәгез», диләр.

30 нчы декабрь. Житомирга 10 километр гына калды. Яңа елны шунда каршыласак, шәп булыр иде!

Кичкә таба Богородск дигән зур гына бер авылга туктыйбыз. Нindидер бер могҗиза белән бу авыл исән калган. Авыл халкы да урыннан кузгалмаган. Без килеп керүгә, алар безгә бөтен ярдәмне күрсәтә башлыйлар. Гаскәр үтә торган тайгак юлларны төзәтәләр. Хатын-кызлар, бала-чагалар, чиләкләр белән көл алып чыгып, таулы юлларга сибәләр, атларга печән, солы китереп салалар...

Төн. Житомирны ике яклап камап алабыз. Дошман туктаусыз артиллерия уты яудыра. Без, тимер юл өеменә ышыкланып, шәһәргә якынлашабыз. Таң ату белән пехота шәһәр читендәге урамнарга бәреп керә.

Шәһәр өчен каты сугыш башлана. Артиллерия канонадасы урамнарны селкетә, бер яктан безнең танк частьларыбыз шәһәргә якынлаша. Артиллерия һәм танклар булышлыгында пехота дошманны кысрыклый башлый. Чардакларга, подвалларга урнашкан дошман пулеметларын безнең орудиеләр тынып калырга мәҗбүр итә. Разведчикларыбыз дошман яшеренгән урыннарны табып, безгә хәбәр бирә. Без шунда ук минометлардан ут ачып, дошман урнашкан җирләргә миналар яудырабыз. Аннары пехота артыннан шәһәргә бәреп керәбез. Дошман, безнең гаскәрләрнең кысуына каршы тора алмыйча, урамнарда үлекләрен, җимертелгән техникасын калдырып, шәһәрне ташлап чыга. Тимер юллар челтәре һәм дошманның мөһим терәк пункты булган Житомир тулысынча азат ителә.

1944 елның 20 нче марты. Дошманнан чистартылган Тарнопольгә барабыз. Фронт хәзер Тарнопольне үтеп, алга китте.

Шәһәр бездән дүрт кенә километр булса да, ул биредән бөтенләй күренми. Төн. Ялангач кырда кар бураны уйный.

Шайтан туе ясап үкергән кар бураны хыялларны кузгата, уйлар еракка-еракка, туган-үскән илгә, туган Казанга барып тоташа. Үткән гомерләр, тормыш бер-бер артлы күз алдыннан кичәләр...

Менә 1915 елның көзге айлары. Без — солдатларны төягән вагоннар Тарнополь янындагы җимерек таш күпер алдында туктый. Вагоннардан чыгып, кар өстенә тезеләбез...

Кыш буе окопта ятабыз. Берничә мәртәбә һөҗүмгә күчеп, немецлар белән йөзгә-йөз килеп сугышабыз. Аннары яз килә. Брусилов һөҗүме башлана. Шактый көчле артиллерия хәзерлегеннән соң, атакага күчәбез. Немецларның озакка чыдамлы ныгытмаларын ватып, алга үтәбез... Бер-бер артлы авыллар азат ителә... Ниһаять, каты сугыштан соң Тарнополь дә дошманнан арчыла...

Бу — Тарнопольне азат итүдә беренче тапкыр катнашуым иде. Мин ул вакытта яшь, тәҗрибәсез идем әле. Дошманга каршы көрәшнең дә ни икәнен аңлап бетерми идем. 1917 елгы революция дулкыннары мине алга алып китте. Торган саен тормыш миңа киңрәк булып ачыла барды. Мин кешелек дөньясы бәхете өчен көрәшүчеләр барлыгын күрдем. Бөек Ленин образы минем киләчәгем өчен якты маяк булды. Ул минем бөтен тормышымны яктыртты, миңа көрәш дәрте бирде. Мин бөек Ленин партиясе члены булу бәхетенә ирештем...

28 елдан соң немецлар белән мин тагын очраштым. 28 елдан соң мин тагын да Тарнопольне дошманнан азат итәргә килдем. Бу юлы мин коралымның үткенрәген сайлап, чукмарымның зуррагын күтәреп килдем.

15 апрельдә Тарнополь дошманнан тулысынча тазартылды. Шулай итеп, миңа үз гомеремдә бу шәһәрне дошманнан азат итүдә ике тапкыр катнашырга туры килде.

## Марат Кәримов

### Бездән алда яшәдегез

Бездән алда яшәдегез,
Бигрәк тә аз яшәдегез.
Ут уйнаган яу кырында
Яшен булып яшьнәдегез.

Сез калдырган шул нур белән
Яктыртылган заманыбыз.
Колакларда яңрап тора
«Алга!» дигән авазыгыз.

Күз алдыннан китәсе юк
Җирне кочып ауганыгыз.
Без бит сезнең дөньялыкта
Исән калган дәвамыгыз.

Безгә тияр пуляларны
Каплап калды күкрәгегез.
...Яшен булып яшьнәдегез,
Ә без — сезнең күкрәвегез.

### Ленинград егете сержант

Поликарпов истәлегенә

...О җирне тетрәткән ул һөҗүм!
Солдатлар барсына түзәләр.
Теш кысып түзәләр, үләләр...
Терeләр дусларын күмәләр.
Снаряд каплаган сержантның
Гәүдәсе кайда соң? Медален
Таптылар бары тик — ил данын
Арттырган Батырлык медален.
Кадерләп кабергә салдылар:
— Туган җир, бу — синең улың бер,
Гәүдәсе юк, калды тик төсе,
Үзеңнең куеныңнан урын бир!

Сугыштан соң кайтып, без аңа
Һәйкәлен куярбыз алтыннан.
Яңгырады соңгы залп. Солдатлар
Киттеләр зур җиңү артыннан.
...Ничә ел җир саклый медальне,
Җуела сугышның эзләре,
Кем белә, әлеге солдатлар
Күптәннән һәйкәлдер үзләре.
Яу үткән яланда — ызаннар,
Ызанда металлы тузаннар.
Туган җир, куеныңда күпмедер
Һәйкәлгә әйләнер медальләр...

•

— Талларга тотынып, бөгелгән талларга,
Кайларга агасың, Иделем, кайларга?

— Барасы урыным — астагы үзәндә.
Түбәнгә ашыгам, урыным түбәндә.

— Кайларга чабасың, гомерем, кайларга?
— Тауларга, офыкта күренгән тауларга.

Түбәндә яшәүнең мәгънәсе нилектә? —
Биектә кешенең урыны, биектә...

Уфа.

**Павел Лукницкий,**
Ленинград язучысы

# НЕВА «УЧ ТӨБЕ»



Сугыш вакытында Ленинградны саклаучы сугышчылар һәм командирлар арасында илебезнең барлык милләт вәкилләре бар иде. Ул көннәрдә мин Таҗикстанның партия җитәкчеләреннән таҗикларның Ленинград өчен ничек сугышуларын белүемне һәм шуларның берәрсе турында газетага язып чыгуымны үтенгән телеграмма алдым.

Таҗикларның берсен мин Нева ярында сугышучы подразделениедә очраттым. Ферганәдәге Сох кышлагында туып үскән чибәр, яшь Тәшабай Адилов иде ул. Армия сафына 1939 елда алынган, Көнбатыш Белоруссияне азат итүдә катнашканнан соң үзенең часте белән Выборг янында Бөек Ватан сугышын каршылаган егет.

Сугыша-сугыша Выборгтан чигенгәч, Адилов Неваның уң як ярында, Нева Дубровкасындагы десант группасына эләгә. Ул вакытны сул як ярда кечкенә генә бер җирне немецлардан сугышып алырга кирәк иде. Бу җир блокаданы өзү максаты белән хәзерләнгән һөҗүм өчен плацдарм булырга тиеш. Отрадное—Островки участогында һәм Неваның Кара Елга дип аталган кушылдыгында шундый плацдармнар булдырырга тырышып каралды. Ләкин бу участокларда уңышка ирешеп булмады.

Сентябрьнең унтугызыннан алып егерме бишенә кадәр барган сугышларда безнең гаскәрләргә Неваның сул як ярында — Мәскәү Дубровкасы дигән җирдә, ниһаять, форпост төзү мөмкин булды. Сугышчылар бу форпостны «Нева уч төбе» дип атадылар.

«Нева уч төбе» өчен барган сугышларда Тәшабай Адилов та катнашты.

Аның бу сугышта ничек катнашуы турында мин шул штурмда булган берничә сугышчының сүзләре буенча һәм Адиловның үзенең сөйләвенә таянып язам. Төннәрнең берендә, «Уч төбе»н яулап алып, аны дошманга кире бирмәс өчен соңгы сулышларына хәтле сугышкан командирлар һәм солдатлар һәлак булып беткәч тә, шул җирне тотып калучы кешеләрнең кызылармеец Тәшабай Адилов һәм аның бер коралдашы (кызганычка каршы, аның исеме тарих өчен сакланмаган) икәнлегенә иптәшләренең берсе дә шикләнми иде.

Ниһаять, Нева. Кызыл балчыклы биек ярлар. Уң як ярда — Нева Дубровкасы, урман эчендә утырган кәгазь комбинаты поселогы; чәчелеп утырган кирпеч һәм агач йортларны немец бомбалары һәм миналары җимергән, алар яналар. Сул як ярда да нәкъ шундый ук посе-

лок — Мәскәү Дубровкасы. Андагы йортлар инде янып беткән, яр буйлап Ленинградтан Шлиссельбургка бара торган таш юл үтә. Яр чите белән юл арасында немецлар траншеялар казыганнар. Дзотларның амбразураларына куелган пулеметлар Неваның салкын суы өстенә төбәлгән... Поселок янындагы урман эченә артиллерия яшеренгән. Минометлар да беренче сигнал булуга ут ачарга торалар. Урман, поселок һәм траншеялар Неваны кичеп чыгарга ниятләнеп тә, шуны булдыра алмаган авиадесант дивизиясенең гитлерчы башкисәрләре белән шыгрым тулы.

Ә уң якта — сиздермичә генә каты һөҗүмгә әзерләнүче безнең гаскәрләр.

Понтончылар Невадагы балыкчы көймәләрен җыйдылар, төннәрен, дошманга сиздермичә, аларны урман юллары буйлап алып килделәр дә дача өйләренә, үзәннәргә, уйсулыкларга һәм яр буйлата казылган чокырларга яшереп куйдылар. Урманда бүрәнәдән понтоннар һәм ярым понтоннар ясадылар.

Һәм менә бары да әзер булды. Караңгы төн уртасында, артиллерия хәзерлегеннән башка гына, елганы кичү башланды. Уннарча көймәләрне күтәреп китерделәр дә суга төшерделәр. Үзләренең командирлары белән берничә йөз сугышчы көймәләргә тавышсыз гына кереп утырды да агымны кисеп йөзә башлады. Алар сул якка җитеп килгәндә немец ракеталары кабынып, су өстен яктырттылар.

Тревога сигналы күз ачып йомганчы десант өстенә артиллерия, миномет утларын җибәрде, пулеметлар туктаусыз ата башлады... Ләкин өч-дүрт минуттан соң көймәләр яр буена килеп туктадылар, беренче штурм уңышлы булды... Яр кырында һәм немец траншеяларының беренче линиясендә кул сугышы башланды. Немецлар чигенделәр, кечкенә плацдарм сугышып алынды. Ләкин уң як ярдан өстәмә көчләр көтәргә туры килмәде: Нева берөзлексез яктыртылып тора һәм снарядлар, миналар шартлавыннан кайный иде.

Безнең десантны тар-мар итәргә омтылып, немецлар каршы һөҗүмнәрен туктатмадылар. Әгәр дә понтончы-сугышчы Щеголевның кыюлыгы булмаса, десантчылар бөтен группалары белән тар-мар ителгән булырлар иде. Патроннар бетте, сугышчылар инде гранаталар белән каршы тора башладылар — шул вакыт, таң яктысында, батыр понтончы, немецларның котырып ут ачуына да карамастан, яр буена килеп, көймәгә сугыш кирәк-яраклары төяде, утырып ишкәкләргә тотынды һәм Нева аша йөзә башлады. Батырларның юлдашы бәхет була. Немецның барлык артиллеристлары һәм пулеметлары өчен мишень булган бу куркусыз понтончының елга аша чыгуын йөзләрчә кешеләр борчылып күзәттеләр. Щеголев ярга исән-сау килеп җитеп коралларын бушатты, берничә яралыны көймәгә алып, яңадан хәвефхәтерсез уң як ярга чыгып җитте [1].

«Уч төбә»ндә сугыш яңа көч белән кабынып китә. Ләкин көндез әкренләп тына. Бу җирдәге кешеләрнең исәнме икәнлекләрен дә белергә мөмкинлек булмый. Ярдан ярга барган артиллерия, миномет дуэле «уч төбә»н безнекеләр өчен дә, немецлар өчен дә аяк басарга мөмкин булмаган җиргә әйләндерә.

Икенче төн җитә. Таң алдыннан Кызыл Армиянең тагын өч йөзләп сугышчысы көймәләргә утырып Неваны кичәргә омтылалар. Ләкин аларны немецлар көтеп тора. Бик күп көймәләр батырыла. Десантчыларның бер өлеше Невада һәлак була. Калганнары кире борылырга мәҗбүр ителә.

---

[1] 1942 елның башында политрук И. Курчавов мине үзенең «Понтончылар батырлыгы» дигән кулъязмасы белән таныштырды. (Воениздат, 1943 ел) Понтон-күперчеләр батальонының югарыда сөйләнгән сугышы бу кулъязмада тулы итеп язылa.

Кара төндә кырык разведчик сул як ярга чыга. Елга ар ягында иртә беләнгә кадәр сугыш шау-шуы ишетелеп тора. Ләкин бу кырыкның берсе дә әйләнеп кайтмый. «Уч төбе» яңадан немецлар кулында кала.

Таң алдыннан тагын дүрт йөз сугышчы «Уч төбе»н штурмлауга ташлана.

Көймәләрнең берсендә, башка кызылармеецлар белән, ике таҗик — Тәшабай Адилов һәм аның аерылгысыз дусты Абдувәли дә була. Сугыш юлларын алар икесе бергә үтәләр.

Фашистлар, атмыйча, десантны яр буена якын ук китерәләр дә, йөз метр калгач, көчле ут ачалар.

Көймәләр шатырдап таралалар. Пулемет утыннан кырылган сугышчылар һәм командирлар суга авалар. Калганнары «ура» кычкырып ярга ташлана. Штурмчылар әзәйгәннән-әзәя бара...

Тәшабай болай уйлый: көймәләрне агым уңга кага, фашистлар утларын да шунда сибәләр. Агымны кыеклатып, уңга ишү өчен осталык һәм көч кирәк була. Ә Тәшабай белән Абдувәли Сох дигән тау елгасында теләсә нинди көчле агымны җиңәргә өйрәнгәннәр. Алар сулга, утның көчсезрәк җиренә таба ишәләр... Пулемет уты тигән көймә бер якка кыңгырая. Дуслар суга ташланалар һәм, коралларын югары күтәреп, сул як ярга килеп туктаган җимерек салга йөзеп чыгалар.

Авыр сулап, сугышчылар як-якларына караналар. Агымның түбәнрәк ягында исән калган көймәләр ярга якынлаша баралар. Солдатлар җимерек көймәләрдән суга сикерәләр һәм, йөзеп, ярга киләләр. Әле тегендә, әле монда йөзеп килүчеләрнең башлары мәңгегә су астына күмелә. Снаряд ялкынында һәм пулялар сызгыруында, төтен һәм шартлау тавышлары астында минометлар, пулеметлар, сугыш кирәк-яраклары бушатыла.

Тәшабай белән Абдувәли янына берничә кеше йөзеп килә. Шулай итеп, барысы унбишләп кеше җыела. Ниндидер командир сугышчыларны яр буйлап штурмга күтәрә, ләкин шунда ук пуля тиеп егыла. Монда башка командирлар булмый. Тәшабай: «Минә бу арыктан... шуышыйк!» — дип кычкыра да яр битен кисеп үткән канауга ташлана. Аның артыннан башкалар шуышырга тотына.

Алар, гитлерчыларга сиздерми генә, беренче траншеяларның борылып киткән җиренә, фашистларның түбән таба, ярны штурмлаган кызылармеецларга атып яткан урыннарына килеп чыгалар. Кыю егетләр арттан фашистларга ташланалар һәм траншеяларны кулга төшерәләр, ләкин көтмәгәндә траншеяларның икенче линиясеннән каршы һөҗүмгә килгән башка гитлерчылар белән очрашалар. Каршы һөҗүм кире кагыла. Унбиш сугышчы бер-береннән дүрт йөз метр ара калдырып, бөтен траншея буена сибеләләр. Ярты километрлап фронтка унбиш сугышчы!.. Дошман яңадан атакага ташлана. Шул арада Нева аша тагын бер рота чыгып өлгерә. Өч дистәләп кызылармеец, берничә командир һәм политрук ярдан сикереп тора да унбиш сугышчыга ярдәмгә ташлана. Траншея экренләп безнекеләр белән тула, алар җиргә ятып, дошманга ут яудыралар. Яр башына ротага якын сугышчы җыела. Дошманның каршы һөҗүме тагын кире кайтарыла.

Исән калган гитлерчылар траншеяларның икенче линиясенә чигенәләр. Арырак тигез бушлык, аннан урман башланып китә. Дошман батареялары әлегә атмыйлар, аларга снарядлар ташыйлар. Минометлар һәм пулеметлар да яңадан сугышка әзерләнеп, тын торалар...

Командирның тавышы тәшвишле тынлыкны ярып үтә:

— Ленинград өчен! Ура!..

Һәм шунда ук атака, икенче оборона линиясен штурмлау... Яңадан сугыш шау-шуы, тагын ялкын, төтен, тузан.

Абдувэли Тэшабайдан уңдарак алга йөгереп уза. Тэшабай шунда ахирэт дусының кычкырып егылганын күрэ: «А-а-а! Ярдэм ит!» «Йөрэгемне кинэт ут алгандай булды»,— дип сөйлэде Тэшабай соңыннан шушы минут турында. Тэшабай, бернигэ дэ карамыйча, дусты янына йөгереп килэ дэ җиргэ тезлэнэ, э Абдувэли инде дэшми, ул инде үлгэн... Тэшабай ярсулы ачудан бүтэн берни дэ сизми, снарядлар шартлавын да, пулялар сызгыруын да, үзенең тормышын да, үлемен дэ, барлык дөньясын оныта: «Абдувэли! Абдувэлием минем!». Телендэ сүз, башында уй, күңелендэ бер телэк калмый. Тэшабайның бөтен барлыгын ачу гына билэп ала... Тэшабай Абдувэлинең кесэсеннэн документларын, фоторэсемнэрен ала, дустының саргаеп калган канлы йөзенэ карый. Аңын томан каплагандай була. Берни дэ күрмичэ, ишетмичэ, Тэшабай тавышсыз гына елый. Аны хэлсезлек чолгап ала, ул йокыга тала.

Уянып китсэ, тирэ-як тып-тын. Тэшабай үлеп яткан дустын күрэ. Һэм кинэт, гомерендэ булмаган бер нэфрэт белэн кычкырып җибэрэ: «Алга! Хэзер бары тик алга гына!» Ул як-ягына карый. Алда бер кешенең дэ юклыгын күрэ. Уң якта да, сул якта да, артта да бер кеше юк. Таныш булмаган бердэнбер кызылармеец кына үзенэ оя казып маташа. Бер гитлерчы аңа пулеметтан аткалап тора. Сугышчы җиргэ иелэ һэм пулемет туктаган арада тагын казый башлый.

Тэшабай сул якта түмгэклэр барлыгын күрэ. Шуларга яшеренеп дошман пулеметчысының артына төшэргэ мөмкин икэн. Ул артына эйлэнеп карый — дүртэү шуышып килэ: ике солдат, кызылфлотчы һэм эшче киеменнэн бер карт. Партизаннар, дип уйлый Тэшабай алар турында. Тэшабай аларны янына чакырып ала да дошман пулеметының кайда торганын һэм аңа ничек якынлашып булуын аңлата. Бу дүрт кеше Тэшабайдан син кем дип сорамый, нэрсэ эшлэргэ кирэк дип кенэ сорыйлар.

Тэшабай партизанны бер якка, дошман пулеметчысының игътибарын үзенэ юнэлтү өчен сулга табарак җибэрэ. Карт: «Була ул»,— ди дэ шуышып китеп бара. Тэшабай үзе, калган өч сугышчы белэн бергэлэп, дошманның артына төшэргэ китэ. Аларның атарга әзерлэп куйган гранаталары, ике винтовкалары, ике автоматлары була. Сиздермичэ генэ пулеметчыга якынлашалар. Ике гитлерчы — беренче һэм икенче номер пулеметчылар — картны шэйлэп алалар. Пулеметларын борып, җентеклэп төзилэр дэ атып җибэрэлэр. Карт яшеренеп өлгерми... лэкин ике гитлерчының үзлэренең дэ шунда гранаталар белэн тетмэлэре тетелэ, пулеметның җимерелгэн сошкасы бер кырыйга очып китэ...

Тэшабай пулеметның стволына ташлана. Ул — ватылмаган икэн. Аяксыз пулеметны Тэшабай траншея буйлап төзи дэ якындагы землянкага атып җибэрэ. Аннан дүрт фашист йөгереп чыга. Алар хэбэрлэшү юлына куян кук сикереп төшэлэр, танкка каршы казылган чокырга чумалар һэм урманга качалар. Тэшабай һэм аның иптэшлэре калган дошманнарны эзлилэр, эмма якында бер генэ тере гитлерчы да булмый.

Дүртэүлэп кичкэ хэтле буш землянкаларны саклыйлар. Ашарга берни дэ юк, карын ач. Кич җиткэч, яр буена кайтып үзебезнекелэрне табу нияте белэн траншеядан чыгалар. Яр буендагы юлга килеп җитэлэр, лэкин урманнан атылган пуляларга юлыгалар. Кызылфлотчы белэн бер сугышчы җиңел яралана, Тэшабайның өченче юлдашы авыр җэрэхэт ала. Тэшабай аны җилкэсенэ салып, трофей пулеметның стволын да калдырмыйча, экрен генэ ярга шуыша башлый.

Тирэ-як шомлы тынлыкка чума. Эңгер-меңгердэ үлгэннэрнең гэүдэлэре генэ шэйлэнэ. Тэшабай озак шуыша. Ул күтэреп барган сугышчы да үлэ. Дөм караңгыда Тэшабай иртэ белэн үзлэре сугышып

алган беренче траншеяга килеп җитә. Монда беркем дә юк. Ярның кыелып төшкән җирендә, нәкъ су кырында ул бер төркем яралы сугышчыларны очрата. Алар бирегә таң алдыннан килүе мөмкин булган ярдәмне көтеп җыелганнар.

Ни булды соң әле?.. Ярга төшерелгән рота каты сугышлар алып барды. Каршы һөҗүмгә төшкән гитлерчыларны тар-мар итте, начальникларын урманга куып кертте. «Уч төбе»н нинди көчләр саклап торганын белмәгән фашист командованиесе тылдан китерелгән өстәмә көчләрен сугышка керту-кертмәү мәсьәләсен көне буена хәл итә алмады. Ә «уч төбе»н тотып торган көчләр бик аз иде: үзеннән күп мәртәбәләр өстен булган дошман көчен тар-мар итеп, подразделение үзе дә шул һөҗүмдә һәлак булды. Барлык командирлар үлеп бетте. Яраланган сугышчылар кичкә хәтле позицияләрне үз кулларында тоттылар, ә караңгы төшкәч хәлсезләнеп, бирегә, су янына җыелдылар. Хәл артык куркыныч. Обстановканы белеп алса, дошманның минут эчендә һөҗүмгә күтәрелүе бар. Ә «уч төбе»н сакларлык кеше юк.

Шушы ике дистәгә якын яралы сугышчыдан башка яр буенда берәү дә юкмыни соң инде?

— Я ярдәм итегез, я атып китегез! дип, яралылар елыйлар. Карыйм, барыр җир юк. Мин үземне дә һәлак булганга санадым,— дип сөйләде миңа Тәшабай,— арттан, елга аръягыннан беркемнең дә, бернинди ярдәмнең дә килүе мөмкин түгел. Яр буйлап киттем. Күрәм — пулеметлар: берәү, икәү, станоклы өч пулемет, кул пулеметлары; автоматлар, гранаталар, патроннар чәчелеп ята... Корал күп, сәламәт кеше генә юк. Ләкин күреп торам — берәү автоматын немецлар ягына төбәгән килеш утыра. «Тагы берәрсе бармы?» — дип сорыйм аннан. «Белмим, берәүне дә күрмим!» — ди бу. «Ә син яралы түгелме?» «Колагым томаланды. Зыяны юк!» Мин болай дип уйладым: «Үзем соңгы сулышка хәтле атармын. (Адилов нәкъ шулай дип әйтте: «Соңгы сулышка хәтле»). Миңа чигенер урын юк!» Шулай дип уйладым да теге солдаттан: «Син станоклы пулеметны күтәрә аласыңмы?» — дип сорадым. «Алам»,— диде бу. «Ә минометтан ата беләсеңме?» «Беләм!..» «Алайса, менә нәрсә...» Тәшабай, рус телен вата-сындыра, үзләренең нәрсә эшләргә тиешлеген сугышчыга аңлата. Үзе яралылар янына әйләнеп килә дә аларга Ленинград турында сөйли башлый, чигенергә ярамаганны, чигенер җир юклыгын әйтә. Кемнең җиңел яраланганын, кемнең йөри алуын, ә кемнең бары тик куллары гына хәрәкәтләнүен белешә. Шуннан соң: «Син унлап гранатаны күтәрә аласыңмы?.. Яхшы! Гранаталар ташларсың!.. Ә син станоклы пулемет тасмасына патроннар тезәрсең... Ә син...» дип, эш бүлеп чыга.

Һәр сугышчы Адиловтан приказ ала. Яралылар эшкә тотына. Ә Тәшабай белән аның яңа танышы караңгыда бөтен яр буен йөреп корал җыялар, аларны сугышка яраклык хәлгә китерәләр. Яр буена унбиш, егерме метр ара калдырып, биш рота, ике батальон минометы дошман позицияләренә каратып куела. Югарыда, дошманнан алынган траншеяларга өч станоклы, ике кул пулеметы урнаштырыла, пулеметлар арасына корылган автоматлар салына. Бу сугыш кораллары рының һәрберсе янына Тәшабай, яралы сугышчылар ярдәме белән, патрон һәм мина ящиклары ташый.

Менә шушы куәтле кораллар төн караңгылыгында, сугышка әзер булып, тын гына торалар. О! Әгәр алар янында кешеләр дә булса! Ләкин алар юк. Сау-сәламәт кешеләрдән бары тик алар икәү генә. Тәшабай сул флангтан станоклы пулемет янына урнаша, ә аның иптәше уң флангтагы икенче пулемет янына ята.

Шул минуттан башлап Тәшабай фамилиясен сорарга да оныткан иптәшен «уңъяк» дип атый башлый. Тегесе дә Тәшабайдан исемен

ничек дип сорап тормый, дәшәргә кирәк булганда: «Әй, сулъяк!» дип кычкыра.

Авыр эш эшләп хәлдән тайган сугышчыларга Тәшабай, яңадан патроннар, миналар кирәк булганга кадәр, су буенда ял итәргә куша.

Шуннан соң борчулы көтү сәгатьләре башлана. Тәшабайны сусау йөдәтә, ләкин ул бер генә минутка да күзәтүне туктатырга батырчылык итми, караңгыга төбәлеп карап ята. Үзе пулемет янында, ә үзе уң ягындагы башка пулеметларның кайсы җирдә һәм түбәндәге минометларның кай урында торуларын күңеленнән кичерә. Үзе уйлый: шушы төнне үләргә туры килсә дә, актык көченә хәтле сугышачак ул. Аннары ничә еллар элек Фергана тауларында, Сохның ташлы үзәнендә Абдувәли белән сугышлы уйнауларын, шул чагында бөтен малайларга үзенең командир булуын уйлый. Канга баткан Абдувәлинең хәзер кайдадыр алдарак, төн карасында күмелмичә үлеп ятканы күңеленә килә, әгәр исән калсам, аны ничек тә күмәргә кирәк дигән уй йөгерен үтә.

Көтмәгәндә алдарак ниндидер тавыш ишетелеп китә. Тәшабай бераз тыңлап торгач, аның әкрен генә әйтелгән команда тавышлары икәнен аңлый. Ул пулеметына ныграк сыена. Кинәт тау егетенең үткен карашы траншеяларга якынлашкан бик күп караңгы тапларны шәйләп ала. Гитлерчылар зур ярым түгәрәк ясап шуышып киләләр икән...

Бу урында Тәшабайның үзенә сүз бирик:

«Мин шунда ук пулеметтан ата башладым — уңга, сулга, теттерәм генә. Бөтен лентаны атып бетердем. Күрәм, күләгәләр бик якын. Ящикта гранаталар бар иде. Нәкъ урталарына тондырдым. Икенче пулемет янына йөгереп килдем. Уңга, сулга — тагын бөтен лентаны. Яралы немецларның тавышы ишетелә: елыйлар, кычкыралар! «Мин аларның бик күбесен үтердем, яраладым. Хәзер үземә үләргә туры килсә дә герой булып үләчәкмен» — дигән уй башка килде. Тагы да уңгарак йөгереп килдем дә пулемет янындагы егеткә кычкырдым: «Ут ач!» Ул шунда ук ата башлады. Берничә тапкыр атты да янына йөгереп килде. «Ник атарга куштың?» «Алдыңда ни торганын күрмисеңме әллә?» — дидем тегеңәр. Ә ул: «Алда тып-тыныч. Берни дә ишетелми»,— диде. «Тыңла, яхшылап кара, бер адым алга атласалар да, станоклы пулеметтан, кул пулеметыннан, винтовкалардан ат, граната ыргыт. Бик көчле ут ач. Ә мин минометка йөгерәм»,— дип әйттем.

Ул станоклы пулемет янында калды, ә мин түбәнгә, миномет янына төштем. Яралы солдатлар барын да эшләп торалар, пулемет тасмаларына пуля тезәләр...

Рота һәм батальон минометларыннан өч йөз, дүрт йөз метр арага ун ящиклап мина атып бетердем... Шуннан соң бар да тынып калды.

Немец артиллериясе һәм минометлары кинәт кенә яр буен котырынып утка тота башлады. Мин шунда ук өскә сикереп мендем дә станоклы пулеметка ташландым. Үтерсәләр — бер ни эшләп булмый, исән калсам шәфкать көтмәсеннәр!

Яралылар элек казылып куелган чокырларда. Өстә — мин. Уң якта калган егетем — ул туктаусыз атып ята! Бөтен җирне төтен каплады, берни күренми. Белмим, берәрсе исән калдымы икән... көтеп ятам. Кинәт — исерек немецлар йөгереп килә. Акыралар-бакыралар. Мин пулеметтан ут ачтым — немецлар җиргә ятты. Уң яктагылары гына йөгерүләрендә булдылар. Атар идем — лентам бетте. Мин егерме-утыз метрдан икенче пулеметка йөгереп килдем, тагы ата башладым (пулемет белән пулемет арасында корып куелган винтовка һәм автоматлар да бар бит әле).

Үземә-үзем: «Ут! — дип кычкырам. Урыннан-урынга чабып йөрим, барлык автомат коралларадан атам. Немецлар тыналар. Артиллерия генә сирәк-сирәк атып куя...»

Укучы бәлки миннән сорарга телидер: ә немецлар күпме иде? Бер ротамы, икеме? Һәр вакыт тәгәллекне яратучы немецлар ничә төнге атакага барганнар? Һөҗүм итеп килгәндә нинди ут ачканнар? Адилов гранаталар ташлаганда алар да граната кулланганмы? Укучының бик күп сораулар бирүе мөмкин. Мин аларның барсына да: «Белмим»,— дип кенә җавап кайтара алам. Моны хәзер әйтеп тә булмый. Ләкин бер нәрсәне яхшы беләм: әле генә сугышып алынган плацдармны саклау кирәк булганда дошманны хәйләләү, аны аптыраштa калдыру, кыска гына вакытка булса да аның үз-үзенә булган ышанычын югалту — бу зур хәрби батырлык, кайчакта бөтен бер батальонга, полкка, дивизиягә дан китерерлек зур уңыш... Ә бу очракта, мин ачыклап бетермәгән фактлар калса да, шунысы хак — бу төндә ике сугышчы плацдармны саклап калдылар!..

...Фашистлар кире чигенде. Тагын тып-тын булып калды. Шул кадәр тын иде, хәтта үлеп җитмәгән фашистларның ыңгырашулары да, кара җирнең иң тирән катлавыннан килгән кебек, тынлыкны бозмый иде. Төтен һәм тузан белән кап-кара булган, чәчләре тузгыган, тирләп беткән Тәшабай, көчкә генә тын алып, пулеметларны корырга тотынды. Аңа булышырга теләп, яшеренгән җирләреннән яралылар чыкты. Беришеләре Тәшабай кебек үк батыр сугышкан икенче егет янына шуышып китте.

...Ул арада төн карасы бераз гына сыеклана башлады. Таңның беренче билгеләре икенче ярдагы безнең артиллеристларга «уч төбе» алдындагы фашистларның хәрәкәтен шәйләргә мөмкинлек бирде. Дошманнар тагын атакага хәзерләнәләр. Үзебезнекеләрнең һәм дошманның кайда икәнен ачыклап, артиллеристлар фашистларга залп бирә башладылар. Кинәт Тәшабай үз гомерендә беренче тапкыр баш очында сәер тавышлар ишетте: шу, шу, шу — әйтерсең лә ефәк тукыма кыштырдый. Бу — безнең эрэслар тавышы иде. Әлегә кадәр яшеренгән җирләреннән ата башладылар. Әле генә фашист торган җир буп-буш һәм тып-тын булып калды.

Урман артыннан инде бер генә ату тавышы да ишетелми иде. Тәшабайның баш өстеннән снаряд сызгырулар да туктады...

Неваның уң ягыннан сул як ярга таба бик күп көймәләр йөзә башлады. Алдан моторлы көймәләр килә, алар артыннан ишкәкләрен селтәп баркаслар йөзә, алар артыннан понтоннар, балыкчы көймәләре тезелгән... Аларга беркем дә атмый, алар парадтагы кебек тыныч кына киләләр...

Тәшабай саклап калган «уч төбе»нә диңгез пехотасы килеп урнаша.

Озын буйлы полковник үзенә очраган яралы сугышчылардан:

— Кем, кайсы часть оборона тотты? — дип сорады.

— Командир берүзе,— диделәр сугышчылар,— яралымы ул, үлгәнме — белмибез. Карагыз әле, югарыда ул...

Полковник аңламады. «Уч төбе»н шулай батырларча саклаган частьның командирын эзләргә җибәрде.

Кызылфлотчылар уң яктагы егетне таптылар. Егет аларны Тәшабай янына китерде һәм алар бергәләп полковник янына төштеләр.

— Кайсыгыз командир? — дип сорады полковник каралып, пычранып беткән, җенгә охшап калган Тәшабайдан.

Ләкин төнге атышлардан колагы тонган Тәшабай аны ишетмәде.

Полковник диңгезчеләрчә каты итеп сүгенеп җибәрде:

— Син нәрсә, сугышчы, сораганны ишетмисеңме әллә? Сугыш белән кайсыгыз җитәкчелек итте?

Тәшабай, ниһаять, аңлап алды, ак тешләрен җемелдәтеп, кулын пилоткасына күтәрде:

— Командир — сугышчы Тәшабай Адилов!..

Уңнан да, сулдан да бер-берен бүлә-бүлә, яралы сугышчылар Адиловның сөйләгәннәрен дөресләп тордылар. Полковник барын да аңлады һәм кулларын җәеп, Тәшабайны кочагына кысты да бик каты итеп өч тапкыр үбеп алды. Шулай ук итеп «уч төбе»нең икенче сакчысын да үпте.

— Я, геройлар! Хәзер ял итегез, соңыннан сөйләшербез! — диде ул.

Кызылфлотчылар икесен дә землянкага алып кереп утырттылар. Ашарга бирделәр. Ләкин Тәшабай ашый алмады, ашыйсы килми иде... Балтик диңгезчеләре үзара карашып алдылар: «Егетләр хәлдән тайган... Ял итсеннәр!» Өстәл өстенә ашамлыклар куеп, нарларга бушлатларын, шинельләрен ташладылар да берсе артыннан берсе әкрен генә чыгып киттеләр. Комендант взводының сугышчылары КП төзи башлаганнар иде. Шуларның балта тавышы астында, шинель һәм бушлат өемнәренә сөялгән Тәшабай белән аның иптәше бер сәгать, сәгать ярымлап йокымсырап алдылар.

Кичә генә Абдувәли үтерелгән җир хәзер нейтраль зона — снаряд чокырлары ыржаеп торган, җимерек кораллар һәм мәетләр аунаган ялангач буш урын.

Анда Абдувәли ятып калды. Аны җирли алмаган Тәшабай көне буе тынычлык тапмады. Траншея кырыннан баш күтәрүгә немецлар пулеметтан атарга тотыналар, Тәшабай өч тапкыр күтәрелеп карады, өч тапкырында да аңа таба миналар ташкыны яварга тотынды. Һәм батальон командиры катгый рәвештә Тәшабайга траншеядан чыгуны тыйды. Ләкин төн җитүгә Тәшабай рөхсәт алды.

— Бар! — диде капитан.— Күрәм, җаның өзгәләнә!.. Тик кара аны, аңлыйсыңмы?

Тәшабай шуышып китте.

Бу төнне фашистлар караңгылыкны әледән-әле ракеталар белән яктырталар һәм аткалап торалар иде. Тик торганда минометлары ата башлый, миналар шул кадәр күп ярыла, алардан чокырларга төшеп кенә качарга мөмкинлек була. Тәшабай чокырдан-чокырга шуышып бара торгач, ниһаять, дустының мәете янына килеп җитә. Аркасына салып, траншеяга алып кайта. Ул тагын ике тапкыр шуып чыга, ташлап калдырылган шинельләрне җыеп кайта.

Шуннан соң траншея артында коры, әйбәт урын табып, озаклап кабер казый. Кабер төбенә дүрт шинельне җәеп, әкрен генә Абдувәлинең мәетен куя. Дустының тыныч йөзенә соңгы тапкыр карап калу өчен ракета яктыртканын көтә, аннары аның кулларына үзенең кулын куя да әкрен, ләкин ачык итеп:

— Мин синең өчен янам, Абдувәли... Йөзенче фашистны үтерми торып тынычланмамын,— ди.

Үзе тынып кала. (Бу минутлары турында Тәшабай болай дип әйткән иде: «Антым күңелемә сеңеп калсын дип уйладым».)

Бераздан ул Абдувәли өстенә калган дүрт шинельне яба да туган ил туфрагы белән каберне күмә. Траншеяга ул сүзсез генә кайтып керә һәм сугышчылар арасына барып утыра [1].

*«Безнең батарея сугышчылары»*
*китабыннан.*

[1] «На страже Родины» газетасының 1942 ел, 9 июнь санында Ленинград фронты гаскәрләренә приказ басыла. Батырлык күрсәткән сугышчыларны бүләкләү турындагы бу приказда Ленин ордены белән бүләкләнгән өлкән сержант Тәшабай Адиловның фамилиясе иң башта тора. Соңыннан Тәшабай Адилов үзенең антын да җиренә җиткерә: снайпер була да 1942 елны 114 фашистны юк итә.

# ТАТАРСТАННАН АЛГАН ТӘЭСИРЛӘР

Польша патриотлары — антифашистлар сугыш елларында Мәскәүдә «Нове виднокреги» («Яңа горизонтлар») дигән журнал чыгардылар. Бу журнал 1945 елга кадәр — Польшаның немец-фашист илбасарларыннан азат ителгән көненә кадәр — чыгып килде һәм Советлар Союзында сыену урыны тапты. Меңнәрчә поляклар арасында зур популярлык казанды.

Башта Кызыл Армия сафларында, соңыннан Польша гаскәрләрендә көрәшкән поляк сугышчылары да бу журналны яратып укыды. Журналга Польшаның һәм Советлар Союзының күренекле әдипләре Ванда Василевская, Ежи Путрамент, Леон Пастернак, Илья Эренбург, Ярослав Галан һ. б. язышып торды.

«Нове виднокреги» журналының берничә экземплярлары Мәскәүдә һәм Казанда — В. И. Ленин-Ульянов исемендәге Казан университетының фәнни китапханәсендә саклана. Бу юлларны язучыга, диплом эшен әзерләгәндә, журналның китапханә фондларында сакланган барлык экземплярларын карап чыгарга туры килде. Шул вакыт аның игътибарын поляк язучысы Мария Мильштейн очеркы җәлеп итте. Эвакуация елларында ерак татар авылларының берсендә укытучы булып эшләгән Мария Мильштейнның «Образки з Татарии» («Татарстаннан алган тәэсирләр») дигән очеркы журналда 1944 елның 3 санында басылган.

Үзеннән-үзе билгеле, поляк язучысының җылы хисләр белән язылган бу очеркын тәрҗемә итмичә калып булмады.

Журнал укучыларына Мария Мильштейнның шул очеркын тәкъдим итәбез.

И. СИБГАТУЛЛИН.

## Мария Мильштейн

## ФӘРИТ

Сабанчы белән Калейкино[1] арасы ерак, юл начар. Чокырлы-чакырлы, кешеләр аякларын сындырсыннар өчен юри шулай эшләгәннәр дип әйтерсең. Ә кышын? Кышын анда бернинди юл юк. Кар белән капланган чиксез киң дала гына бар. Ап-ак дала. Бөтен чокыр-чакырларны, инеш-чишмәләрне ак кар каплаган була. Бу тоташ аклык, тоташ бертөрлелек һәм коточкыч тынлыкта беренче калган кеше үзен бик җайсыз сизәр иде. Ләкин һәр иртәне, таң яктысы кургашындай күк йөзенә таралып та өлгермәстән, дала җанлана башлый. Берсе артыннан берсе атлап килгән кечкенә кара шәүләләр күренә. Алар — Сабанчы балалары. Мәктәпкә киләләр. Чиксез ак фонда алар кырмыскаларга охшыйлар. Кырмыскалар кебек үк тырышып, үзләренә юл салалар. Юл салуы кыен монда, Татарстан кышы карлы була. Кечкенә гәүдәләр җилгә сыгыла. Очлы эшләре

[1] Әлмәт районы авыллары.

белән битне кар кисә. Юлны буран күмә. Ә алар киләләр. Көрткә керәп батмас өчен, таяк белән юлны капшый-капшый баралар. Кайберләре үзе үргән чабатадан юлга чыккан, кайберләре итектән. Көрткә керсәң — бәла. Итек эченә кар тула.

Дәшми генә баралар. Вакыт-вакыт кемдер авыр сулап куя, кайсыдыр «уф, алла!» дип көрсенә. Көн саен шулай — мәктәпкә хәтле сигез чакрым, мәктәптән соң да сигез. Барлыгы уналты. Ә язын, җир җебеткәч, язгы кар сулары күперләрне, басмаларны алып киткәч, балалар су ерып килерләр. Мәктәп бусагасын атлап кергәч кенә алар, үткән юл турында уйлап та карамыйча, юеш аякчуларын алыштырырлар.

Бүген беренче булып Фәрит җавап бирә. Тактага җөмләләрдән буразналар суза, аркылы да торкылыга хәрефләр чәчә. Дулкынланудан һәм артык тырышудан телен чыгарган. Күренеп тора — дәресен әзерләгән. Ул кичә мәктәптә булмады. Ни өчен? дип сорадым. Тотлыгып җавап бирде:

— Урманга бардым. Утын алып кайтырга.

— Кичәме?

— Әйе.

Кичә шундый көчле буран иде, көн яктысын күрерлек булмады. Җил котырды. Салкыннан тын куырыла иде. Өйләре биек кешеләрнең генә тәрәзәләре күренеп калды. Калганнарын барын да кар күмде. Чанага җигелгән укучымның шушы дәһшәт белән көрәшеп баруы күз алдыма килде. Ялгызлык исемнәре кагыйдәләрен сорарга кыенсынып куйдым. Алдымда басып торган шушы кечкенә генә балага — Татарстан улына карап берничә минут уйга калдым. Аның мәктәпкә килә торган юлын һәм урманга утынга баруын тагын бер кат күңелемнән кичердем. Шунда ук аларның окоплардагы аталары исемә төште. Бу бит Сталинград янындагы, я Курск тирәсендәге сугышлардан күп вакыт элек булган хәлләр иде. Ул вакытта дошман әле Мәскәү янында иде. Ленинград блокадада. Әмма Фәриткә карыйсың да, җиңүгә ышаныч арта. Гитлерның ике йөзләп дивизиясе генә түгел, бөтендөнья гаскәрләре ташкын булып килсә дә — бу кешеләр аны да җиңәр иде. Балалары яктылыкка омтылып, белем өчен мәктәпкә килгән юлларында карны таптап үткән шикелле, аталары да дошман яуларын таптап, изеп узалар иде.

## «ҖЕН КАРЧЫГЫ»



Башта мин Мәрзияда тордым. Беренче көннән үк мин аның «җен карчыгы» икәнен аңладым. Күзләрем начар күргәнлектән, бер көнне ялгыш кына бер стакан сөт түккән идем. Ул шундый тавыш күтәрде, әйтерсең лә мин аның барлык кәҗәләрен, кәҗә бәтиләре белән бергә, суеп ташлаганмын.

Ә берничә көннән соң каты грипп мине түшәккә еккач, уйлап та тормады:

— Иркәләнеп ятуыңны ташла, әнә безгә ындыр сугарга булыш! — диде.

Шул вакытны мин үзалдыма: «Җен карчыгы! Җитмәсә, баш булырга ярата»,— дип куйдым.

Ул иртән иртә үк, әле өй эче караңгы вакытта, дөбердәргә тотынды. Мин чиләк шалтыравын, сыер сауганда кычкырып сукрануны, балта чапкан тавышларны ишетеп яттым. Сүрән генә таң атуга сәке өстендә әле генә юылган кер өелеп тора, ялт итеп идән юып чыгарыл-

ган, парын бөркеп өстәл өстендә кайнар аш утыра иде инде. Җылы шәлен бәйләп алган Мәрзия үзе малаена ниндидер эш өйрәтеп тора иде. Миңа булышырга кушуы, ахры. Аннары куенына икмәк кыерчыгы кыстырды да иркәләп улының аркасыннан сөйде. Ишеккә җиткәч, миңа да сүз катты:

— Ындырга киттем. Мичне караштыр инде син.

Белеп торам, төш җиткәнче ул ашлык сугачак.

Төштән соң Мәрзия шаулап кайтып керде дә мичтән чүлмәк белән аш алды. Иртәнге шикелле үк аны зур табакка бушатты. Ашап туйгач, учы белән авызын сөртеп куйды. Аннары ашыгып юеш керенә тотынды. Инешкә кер чайкарга бармакчы.

Мин кыймыйча гына аңа:

— Кырык градуслы суыкта инешкә кер чайкарга йөрү сәламәтлек өчен зарарлы бит, якында гына ике кое бар,— дип әйттем.

Ул миңа үтергеч караш ташлады.

— Борын төбендә генә инеш булганда кое янында пычранып яталармыни?

Аның «борын төбендә» дигәненә километр ярым барырга һәм тайгак тау астына төшәргә кирәк.

Керен чайкап кайтып әлгәч һәм өйне җыештыргач, Мәрзия ишегалдына кар көрәргә чыкты. Ләкин шунда ук карга батып кире керде.

— Буран котыра, көрәп булмый. Әйдә, улым, утынга барып кайтыйк,— диде ул малаена.

Биш минут та үтмәде, алар чана тартып урманга киттеләр. Әйләнеп кайтып, утыннарын лапаска өеп бетергәндә инде караңгы төшкән иде.

Бөтен эш беткәч, Мәрзия ярты өйне алып торган туку станогына утырып, киндер тукырга тотынды. Өйдә тонык кына булып ут яна.

— Күзеңне бетерәсең бит, йокларга ят инде,— дип әйтергә батырчылык иттем мин аңа.

— Тиле син. Колхозга капчыклар кирәк. Яңа ашлык өлгергәч кенә каян алырбыз? — диде ул. Ә бер минуттан ачу белән өстәп куйды.— Иремнең фронтта икәнен әллә син чынлап та белмисең инде? Миңа ике кеше өчен эшләргә кирәк. Йоклап торырга вакыт юк.

Аның күпме утырганын әйтә алмыйм, станокның бер көйгә тукылдавына йоклап киткәнмен. Тормышка сәләтсез булуым өчен мине нинди сүзләр белән тиргәвен дә ишетмәдем. Кышын елгада кер чайкый алмавым, гомумән, аның өчен бик гади һәм җиңел тоелган күп эшләрне эшли белмәвем Мәрзиянын җен ачуын чыгара иде.

Менә шулай Мәрзияда мин бер ел яшәдем. Ләкин мин аның берәр төрле эштән куркуын, яки аны эшли алмавын хәтерләмим. Үземә карата әйтелгән төрле сүзләрне дә күп ишеттем: «пешмәгән», «аңгыра», кайберләрен хәтта кабатлап әйтүе дә уңайсыз. Ләкин инде беркайчан да аның хакында «җен карчыгы» дип уйламадым. Җен карчыгы түгел иде ул, ару-талуны белми торган хезмәт кешесе иде.

## Клара Булатова

### Борынгыдан урман, суларга бай

*Төмән дәфтәреннән*

Борынгыдан урман, суларга бай,
Күлләргә бай Себер җирләре,
Өч йөз мең дә, биш йөз мең дә, диләр,
Төмән өлкәсенең күлләре.
Урманнары төрле җәнлеккә бай,
Балыкка бай күлләр, елгалар.
Куеныдагы гаҗәп байлыклары
Бик күпләрне кызыктырганнар.
Булган, булган, мәрхәмәтсез килеп
Талаучылар булган Себерне,
Хәзинәсен яулый-даулый белсәң,
Саклый-яклый да бел син җирне!
Безнекеләр килгән... Безнекеләр
Баткаклыкны, юлсыз сазлыкны
Яшьлекләрен өстәп гөл иттеләр —
Бу калалар шулай калыкты.
Бу калалар үсә күккә үрелеп,
Ак калалар Себер түрендә.
Ак калалар ак кораблар кебек,
Ак кораблар яшел диңгездә.
Җир бирә дә, сорый үзеңнән дә,
Шуны белә безнең кешеләр.
Алар монда «үзем» өчен түгел,
«Илем өчен!» диеп эшлиләр.
Ил яшьлеге ак калалар сала,
Төзи бара яңа Себерне.
Байлыгын да файдалана белә,
Ярата да белә бу җирне.

### Көн каршында раслап галим сүзен

Фән хәтерли Ломоносов сүзен:
«Рус куәтен Себер күтәрер».
Көн каршында раслап галим сүзен,
Нефть бирә сазлык җир хәзер.

Ватанымның мәйдан үзәгендә,
Элек үле булган сазлыкта —
Самотлорда туган магистраль
Дөньякүләм мәйдан-дан тота.

Җәйләре дә быел йомшак килгән,
Якның кырыслыгы үзгәргән.
Юл читләре билдән яшел үлән,
Кояш исе килә үләннән.

Туган җирнең яме-бизәгенә
Кеше эше монда тоташкан,
Үләннәрдән кояш исе килә,
Бәхет исе килә кояштан.

## Обь буенда

Кызымы син елга патшасының,
Сеңелесеме алтын балыкның?
Су кызыдай килеп чыктың да син
Өнен алдың бөтен халыкның.

Синдәгедәй сафлык, сылулыкны
Бу каеннар кайчан күргәннәр?
Обь буенда коенып йөрер икән
Ык буенда үскән гүзәлләр...

Чәчләреңдә энҗе бөртекләре,
Күз тимәсен, бигрәк чибәрсең.
Күп бит монда Себер егетләре,
Гашыйк итеп куйма бирәрсен.

Ни дисәң дә яшь чак — юләр чак бит,
Бер караштан очкын кабына.
Берүк инде кайгы сала күрмик
Ык буенда калган ярыңа.

Ул бит анда сине көтә булыр:
«Яз кайтмаса,— диеп,— көз кайтыр»...
Бөтенләйгә монда торып калсаң,
Кемнәр аны ничек юатыр?..

Ул болай да әле ут йотадыр
Син киткәнгә, үзе калганга.
Себерләргә кызлар түгел, алар
Китә иде элек заманда.

Үзгәрә шул тормыш, яңара шул.
Син килгәнсең менә Себергә.
Күңел ачып йөрү өчен түгел,
Обь буенда шәһәр төзергә.

Төзелештә кран баскычыннан
Карлыгачтай менеп китәсең,
Коенганда дулкын арасында,
Акчарлактай уйнак икәнсең.

Пляжларга бик еш йөрмә инде,
Зифа буең ятлар күрмәсен.
Күп бит монда Себер егетләре,
Гашыйк итә күрмә бирәрсен...

1974

## Венера Туктарова

●

Ни диеп шаулыйсыз, талларым,
Узучы җилләргә буйсынып?
Сез шуны белегез: буйсынган
Кала ул бөгелеп я сынып.

●

Ян тагын бик аз гына дип,
Ялварудан ни файда?
Юлыңда кояш булмаса,
Яктыртмас иде ай да.

### Бал корты

Илем юк: таралган.
Ә илсез бал кортын
Кайчан, кем санлаган?

●

Янган чакта ул учактан
Ут алмады кемнәр генә?
Узгынчылар күрми хәзер...
Сүнгән учак... Көлләр генә.

●

Син яныймнан үткән чакта
Бер үлеп, бер терелэм.
Газапларым онытылгачтын
Очравыңа сөенәм.

●

Сөю
беркемнән дә сорап килми.
Килә икән, ул бит — диңгез:
үз ярларын үзе күрми.

Әлмәт, 1974.

## Энҗе Гыйрфанова

### Кояшлы яңгыр кебек

Салават күперен сузып,
Кояшлы яңгыр ява.
Яңгыр тамчылары аша
Карап торам дөньяга.

Күңелем дә шулай минем,
Кояшлы яңгыр кебек.
Ишелеп кайгы килсә дә,
Шатлыгым тора көлеп.

Гомерем дә шушы көндәй
Кояшлы да яңгырлы.
Күзләремә яшьләр килсә,
Сөртеп ала таң нуры...

●

Төннәр буе сиңа хат язарга
Әзер дә бит, әзер кулларым.
Ялгыз үттем менә бу язда да
Бормаланган тормыш юлларын.

Ялгызлыкның чиге булсын өчен,
Дәшми калам тагын хатыңа.
Бәхетемә тагын аяк чалам
Башкаларның бәхете хакына.

●

Алтынланып, ялкынланып,
Киң Уралга көз килә.
Тирә-ягым алтын диңгез,
Юк янымда сез генә...

Җил очырта, җил биетә
Коелган яфракларны.
Хәтерләтеп үткәннәрне,
Туган-үскән якларны.

Тауларга ут капкан димә,
Ут капкан йөрәгемә.
Илтсә дә илтер ялкынын
Сезгә тик җилләр генә.

Чиләбе өлкәсе.

## Халисә Мөдәрисова

●

Тәрәзәмне каерып давыл керде
Дер селкетеп тынган күңелне.
Йокы баскан күзне чагылдырып,
Яшен үтте телеп күгемне.
Тәрәзәмне каерып давыл керде,
Давыл эзли үзенә тиңнәрен,
Син куркынып күзләремә бактың,
Тик аларда курку күрмәдең.
Син алардан юаш курку көтмә,
Ул күзләрдә ялкын, күз-күмер,
Тын күлеңнең төнбоегы түгел,
Диңгез акчарлагы бу күңел.
Тәрәзәмне каерып давыл керде,
Давыл аңлый минем җанымны,
Тәрәзәмне барып ябып куйдың,
Тик туктатып кара давылны...

●

Башкаларга булыйм, әйдә,
Бер гайбәт сүзе генә.
Үзең генә бел син мине
Һәм аңла үзең генә.
Үзең генә таны мине,
Аер төн карасыннан,
Карашымны эзләп тап син
Мең күзләр арасыннан.
Серле дөнья бул син миңа,
Мәңге ачылмас тылсым,
Юллар читкә каерса да,
Ерак-якыным бул син.
Күңелемә канат куяр
Сорнаем моңнары бул,
Болытлы да, кояшлы да
Иң матур җырларым бул.
Бер кеше дә белми торган
Күңелем өмете бул,
Минем өчен гади түгел,
Әкият егете бул.
Тик миндә генә ялгышма,
Мин түгел иң зур йолдыз,

Юк, серләр эзләмә миннән,
Мин гади генә бер кыз!
Йолдыз димә, кояш димә,
Алтын да көмеш димә,
Ничек бармын, шулай ярат,
Бары шул килеш кенә.

●

Бөтенләйгә түгел, бер сәгатькә
Мин дусларсыз калдым,
Бөтенләйгә түгел, бер сәгатькә
Мин дошмансыз калдым.
Бүлмә тып-тын, ә тәрәздә тик төн,
Сәгать вакыт саный,
Ялгыз калдың, ялгыз калдың, диеп,
Әйтерсең лә яный.
Мин бу төннең йолдызларын күрмим,
Аен күрмим аның,
Болытларын һәм утларын күрмим,
Таңын күрмим аның.
Иң яман һәм иң куркыныч
Бер бушлыкта йөзәм.
Яхшылык һәм явызлыкны сизмим,
Мин ялгызлык сизәм.
Кайгыру юк, шатлану юк,
Күз яше дә коймыйм,
Мин үземне бу дөньяга
Кирәк итеп тоймыйм.
Бер сәгатьнең минутларын санап,
Дошманымны көтәм,
Һәр минутның секундларын санап,
Дусларымны көтәм.

Уфа, 1974.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**МАРТ, 1974 ел**

Бөек Ватан сугышы һәм хезмәт ветераннары хаты бездә күп кенә фикерләр, зур хисләр уятты, ул тагы да яхшырак эшләү, бишьеллыкның билгеләүче елында планнарны ничек итеп тизрәк үтәү турында уйланырга мәҗбүр итә.

Без, КамАЗ төзүчеләр, өлкән иптәшләребезнең яхшылык теләп әйткән сүзләрен, эшчеләрчә каты итеп кулларыбызны кысуларының бәясен яхшы беләбез. Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше яшьләренә беренче бишьеллык геройлары да хат белән мөрәҗәгать иткәннәр иде. Ул вакытта, буыннар эстафетасын кабул итеп, төзелешнең барлык комсомол-яшьләр коллективлары күтәренке социалистик йөкләмәләр алдылар. Социалистик ярышны без: «Бүген кичәгедән, иртәгә бүгенгедән яхшырак эшләргә!» — дигән девиз белән оештырдык. Йөкләмә буенча сентябрьдә үтәлергә тиешле еллык планны августта тутырдык.

Шушы ачык комсомол җыелышында без, сугыш һәм хезмәт ветераннарының хатын тикшереп, мондый җавап бирәбез: Сезнең данлы фидакарьлегегезгә лаек булырбыз. Безнең коллективның һәр яшь эшчесе җиңү байрагы янында рәсемгә төшү хокукын яулап алу өчен бөтен көчен куяр.

Бишьеллыкның билгеләүче елында өстәмә планга без түбәндәге сүзләрне яздык: «Эш нормасын норма ярым итеп үтәргә, ике мең сумлык материалларны һәм энергияне янга калдырырга, иҗади удар хезмәт исәбенә 1974 ел заданиесен комсомолга В. И. Ленин исеме бирелгән көнгә үтәп чыгарга сүз бирәбез».

Зәй «Гидромонтаж» идарәсенең
комсомол-яшьләр идарәсе коллективы.
«Комсомольская правда», Мәскәү.

СМУ-76 ның Михаил Викторов җитәкчелегендәге төзүчеләр бригадасы исемлегендә Сальвадор Альенде исеме дә бар.

Чили халкының милли герое исеме батырлык, какшамас ныклык һәм революция эшенә тугрылык символы булып әверелде. Ул совет яшьләре белән бергә КамАЗ төзи. 76 нчы номерлы төзү-монтаж идарәсенең өченче участогында үткәрелгән гомуми җыелышы беркетмәсендә түбәндәге сүзләр бар: «Иптәш Сальвадор Альендены бетончыларның почетлы члены дип санарга. Аңа тиешле хезмәт хакын тынычлык фондына җибәрергә».

Михаил Викторов җитәкчелегендәге балта осталары, бетончылар бригадасында кырык ике кеше. Аларның берсе эшкә символик рәвештә чыга. Әмма ул һәр кешенең йөрәгендә, Чили патриотлары язмышын якын итеп кабул иткән һәр совет кешесенең йөрәгендә.

Сальвадор Альенде безнең белән, ул КамАЗ төзи!

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

...1970—1974 елларда экономик хезмәттәшлек турында Совет-Франция килешүендә каралган товар әйләнешенең ике мәртәбә артуына бишьеллык ахырына кадәр ук ирешеләчәк.

Унъеллык программада каралган төп юнәлешләрнең берсе — СССР һәм Франция территорияләрендә промышленность комплексларын кору буенча үзара хезмәттәшлек. Бу өлкәдәге эшләр, кагыйдә буларак, озак сроклы кредитлар бирү шартларында алып барылачак. «Рено» предприятиеләренең Кама буенда автогигант төзүгә катнашулары һәм СССРның Фос-Сюр-Мер металлургия комбинатында домна мичләре коруда, шулай ук Жиронда тамагындагы Амбес районында нефть эшкәртү предприятиеләрен камилләштерү һәм киңәйтүдә катнашуы мондый хезмәттәшлекнең мисалы булып тора ала.

АПН хәбәрчесенең Франция Милли җыелышы председателе урынбасары һәм Франция-Совет сәүдә палатасы Ролан белән интервьюсыннан, Париж.

Кама автогигантын төзүчеләрнең эш алымы илебездә киң билгеле: тизләтелгән темплар, иң яңа техника куллану, хезмәтнең алдынгы методларын файдалану. Быел күп меңле коллектив алдында зур, катлаулы мәсьәләләрне хәл итү бурычы тора. Һәм аларны гамәлгә ашыру эшен КамАЗ төзүчеләр коллективы иҗади хезмәт һәм зур энтузиазм белән башкара. Төзелешнең күп кенә подразделениеләрендә өстәмә, каршылау планнары кабул ителде. Бу эшне Мәскәү вәкилләре башлап җибәрде. Алар 1 ноябрьга 105 мең квадрат метр торак мәйданы җитештерергә сүз бирделәр.

Күптән түгел мәскәүлеләр тагын бер карар кабул иттеләр: 20 апрельдә — ленинчыл коммунистик өмә көнендә — җитештерү буенча өстәмә, каршылау планын үтәүнең иң югары ноктасына ирешергә!

«Советская Татария», Казан.

КамАЗда Ереван рәссамы Петрос Оганесович Малаян булып китте. Ул удар төзелеш кешеләренең образларын эшләде. Рәссам иҗат эшләренең бер сериясен «КамАЗ хатын-кызлары» дип исемләгән. Аның рәсемнәрендә төрле һөнәр кешеләре: бетончы, маляр, плитә ябыштыручы, техник, инженер булып эшләүче хатын-кызлар сурәтләнә.

«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».

Нью-Йоркта КамАЗга багышланган китап басыла. Аны «Чейз Уорлд информейшин корпорейшин» (ЧУИК) авторлары коллективы әзерләде...

Китапны ЧУИК ни өчен КамАЗга багышлаган соң?

Монографиядән күренгәнчә, КамАЗ үзенең җитештерүчәнлеге белән авыр йөк машиналары эшләп чыгара торган барлык Америка заводларын (барысын бергә исәпләгәндә) узып китәчәк.

КамАЗ, диелә китапта, бишьеллыкның мөһим төзелеше булу белән бергә, «салкын сугыш чорыннан соң» чит ил фирмалары катнашында салына торган беренче зур төзелеш.

Шулай ук аңда, КПССның XXIV съезды директиваларына ятышлы рәвештә, техниканың авангард казанышлары, дөньядагы барлык яңалыклар файдаланылуы да әйтелә. КамАЗ өчен зур суммаларга машиналар һәм җиһазлар сатып алына. АКШ тан 260 миллион долларга җиһазлар сатып алырга контрактлар төзелде.

Авторлар Совет-Америка хезмәттәшлегенең һәр ике як өчен дә файдалы булуын басым ясап әйтәләр. «КамАЗ,— диләр алар,— Америка Кушма Штатларының экономик тормышына сизелерлек йогынты ясый башлады». Автопромышленность эшчеләренең берләштерелгән профсоюзы председателе Леонард Вуд болай ди: «Гомумән, сүз 160 мең эшчегә эш бирү турында бара, бу контрактны төзү безнең милли интересларга бик ятышлы».

КамАЗ турында АКШта китап чыгу Американың эшлекле даирәләрендә безнең ил белән хезмәттәшлеккә керүгә җитди кызыксыну туганын ачык күрсәтә.

АПН, Нью-Йорк.

«КамАЗ төзелеше ударнигы» — бу сүзләр бик матур итеп эшләп значокка алтын хәрефләр белән язылган. Бу мактаулы бүләк тугызынчы бишьеллыкның удар төзелеше алдынгыларына фидакарь хезмәт, зур җитештерүчәнлекле, яхшы сыйфатлы эш нәтиҗәләре күрсәткән өчен бирелә.

Халыкара хатын-кызлар көне — 8 март алдыннан «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең СМУ-62 йорт салу комбинатының баш инженеры Марина Ивановна Майна бу мактаулы бүләккә лаек дип табылды. Чаллыда үсеп чыккан йортларга, автоградтагы күп төрле объектларга аның эзләнүләре, тырышлыгы, йөрәк җылылыгы күп кергән.

«Советская Татария», Казан.

Чаллыга СССР Министрлар Советы Председателе урынбасары В. Н. Новиков, СССР Монтаж һәм махсус төзү эшләре министрлыгының һәм СССР Госснабының җаваплы хезмәткәрләре килде.

Аэропортта В. Н. Новиковны һәм аның юлдашларын КПСС Үзәк Комитеты члены, КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеев, өлкә комитет секретаре М. Т. Троицкий, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәренең партия, совет, хуҗалык оешмалары җитәкчеләре каршылады.

Чаллыга килгәч, беренче көнне В. Н. Новиков һәм аның юлдашлары кою, тимерчелек, җыю, двигатель заводларында төзелеш эшләре белән таныштылар, РИЗ цехларында булдылар, төзүчеләрнең һәм завод эшчеләренең көнкүреше һәм эшләре белән кызыксындылар.

Кичен В. Н. Новиков төзелешнең җитәкчеләр активы белән киңәшмә үткәрде. Киңәшмәдә Кама автомобиль комплексын кору буенча җитди мәсьәләләр каралды.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

СССР Монтаж һәм махсус төзелеш министрлыгының Кама автозаводын төзү Баш идарәсе каршындагы «Нежность» вокаль-инструменталь ансамбле Чаллыда зур популярлык казанды. Бу ансамбль шәһәрдә әле беренче «Кызлар ансамбле». «Нежность» узган елның октябренда гына оешкан иде. Аның һәр концертын тамашачылар яратып карыйлар.

«Советская Татария», Казан.

Двигательләр заводының генераль проектировщик һәм җиһазлар белән тәэмин итү функциясен башкаручы «Рено» фирмасы соңгы айларда, совет белгечләре әйтүенчә, проектлау эшләрен уңышлы алып бара. Бу айда двигательләр эшләп чыгару буенча барлык төп участокларда төзү чертежларын эшкәртү өчен заданиеләр өлгерер дип көтелә...

Хәзер Парижда «Автопромимпорт»ның белгечләреннән һәм КамАЗдан киткән техник делегация членнарыннан торган зур группа эш алып бара. Сатып алу комиссиясе дә уңышлы эшли. Төзелгән контракт нигезендә җиһазлар якын арада Франциядән Камадагы төзелешкә җибәрелә. Март-июнь айларында дизель двигательләренең детальләрен механик эшкәртү өчен автомат линияләр һ. б. җиһазлар килеп җитәчәк...

СССР һәм Франция хезмәттәшлеге инде уннарча еллар дәвамында һәръяклап нәтиҗәле бара. Кама автомобиль комплексы төзелешендә бу эшлекле бәйләнешнең тагы да ныгуы чагыла.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

## Заһид Шәфигуллин

# БӨРЕЛӘР АЧЫЛГАНДА

## Агыла хатлар Кощакка



Хатлар... хатлар... Кайлардан килмиләр дә, кайларга китмиләр алар. Казан аша үтә торганнары гына да тәүлеккә 280 меңгә җитә диләр элемтәчеләр. Алар менә шул хатлар арасында «Питрәч районы, «Кощак» совхозы, Н. Б. Вәлиевкә» дип адресланганнарын еш күрәләр. Кайлардан килә ул хатлар һәм кемнәр яза икән аларны?

Күңелдә туган сорау юлга чакырды. Казан автовокзалыннан кузгалган җайлы һәм мәһабәт автобус, асфальт юлдан кызу чабып, ярты сәгать дигәндә Кощакка илтеп төшерде.

Совхоз дигәч, гади бер авыл күрермен дип уйлаган идем. Ә биредә — киң урам буйлап тезелеп киткән икешәр катлы йортлары булган шәһәр сыман поселок икән. Куксел төстәге тимер-бетоннан салынган биналар да байтак. Һәркайда эреле-ваклы декоратив агачлар һәм җиләк-җимеш агачлары. Үзәктә — парк, культура йорты, сәүдә биналары, совхоз конторасы...

Почтальон ханым конторадан сумкасын шактый бушатып чыкты. Ерак Көнчыгыштан, Урта Азиядән, Украинадан, Мәскәү, Ярославль һ. б. өлкәләрдән әлеге хатлар шушы йортка килә икән. Эш кешеләренең эшлекле сораулары тулы бу хатлар өемен совхоз директоры Нәгыйм Вәлиев өстәлендә күрү ничектер күңелле булды. Урта буйлы, ягымлы, хәрәкәтчән, җор сүзле директор кешеләр белән елмаеп сөйләшә. Бу юлы ул хатларны җәһәт кенә минем алга күчереп куйды да «укыгыз, карагыз!» дигән сыман елмайды.

Бер хатка «Украина ССРның ит һәм сөт промышленносте министрлыгы, капиталь төзелеш буенча баш идарә, Киев проект-тикшеренү бюросы» дигән штамп сугылган.

«Борчуыбыз өчен гафу итегез,— дип башлап китә хатны бюроның баш технологы А. Моташко,— безгә Сезнең ярдәмегез кирәк. Куян асрау фермагыз турында «Сельская жизнь» газетасыннан укыган идек. Аннары сездә безнең вәкилләр дә булып кайтты.

Безнең оешма 6 мең ана куянга промышленность комплексы проектлаштыра. Хәзер анда хезмәтне оештыру мәсьәләсен хәл итәбез. Механизация нәкъ сездәге кебек диярлек. Менә шушы бер ярусллы механиклаштырылган корпуста хезмәткә түләү нормасы ничек, ана һәм бала куяннар карауда нагрузка нинди, кызыксындыру һәм материаль стимуллаштыру чаралары системасы нидән гыйбарәт — менә шулар

белән таныштырсагыз иде. Югыйсә, бездә бу мәсьәләләр ахырынача хәл ителмәгән әле».

Украин дусларның хатлары аеруча күп. Мин аларның тагын берсе белән танышыйк. Анысын Сумы өлкәсенең С.-Будский район советы башкарма комитеты җибәргән. «Безнең район авыл хуҗалыгы идарәсе белгечләре,— дип язылган бу хатта,— тәҗрибәгезне урында өйрәнергә сезнең совхозга барырга җыена, чөнки үзебезнең «Заря коммунизма» колхозында куян үрчетү комплексы төзергә планлаштырдык. Безнең вәкилләргә куян фермасы төзү өчен проект-смета документациясе һәм нәсел куяннары сатып алырга булышсагыз иде».

Хабаровск умартачылык совхозлары тресты директоры урынбасары В. Калинин да үзенең хатында «куян фермасы төзү өчен проект-смета документациясе җибәрүне үтенеп» сорый.

Одесса портыннан пенсионер ветврач Г. И. Поддубный механикалаштырылган куян фермасының рәсемен күрергә теләвен әйтә.

Куян үрчетүче һәвәскәрләрнең хатлары бигрәк кызыклы. «Кадерле Нәгыйм Бариевич! — дип яза Ярославль өлкәсенең Первомайский районыннан укучы Кузнецов. — Сезнең хатыгызны алдым, вакыт табып җавап язуыгыз өчен рәхмәт. Минем «Белый великаным» 9 бала китерде. Икесе — ак, җидесе — соры. Алар күзләрен ачтылар һәм йөреп тә киттеләр инде. Бик тә күркәмнәр үзләре. Мин, үскәч, һичшиксез, куян карауючы булачакмын, тик бездә әлегә зур куян фермасы гына юк.

Нәгыйм Бариевич! Минем «Совет шеншилласы»ның алгы тәпие кәкре. Шуның сәбәбен әйтә алмассызмы? Аны нәселгә файдаланырга ярармы икән?»

Эше никадәр тыгыз булуга карамастан, Нәгыйм Вәлиев ихлас күңелдән, балаларча беркатлылык белән язылган мондый хатларны да, олырак яшьтәге һәвәскәрләрнең сорауларын да җавапсыз калдырмый. Кешеләр ышанычын аяк астына салырга мөмкинме соң! Әнә Ферганә өлкәсенең Коканд шәһәреннән Г. А. Зырянов, гүя күптән таныш кешесенә мөрәҗәгать иткәндәй, җавап аласына ышанып язган. «Хөрмәтле Нәгыйм Бариевич! — дип башлаган ул хатын. — Кыргызстанның Ош шәһәрендә сезнең «Куян асрауда яңалык» дигән брошюрагызны кулга төшердем. Ул зур хуҗалыклар өчен генә түгел, безнеңише һәвәскәрләр өчен дә бик шәп, кирәкле китап. Куян үрчетү белән мин күптән түгел, өч елдан бирле генә шөгыльләнәм әле. Ләкин нәселле куяннар безнең тирәдә юк, бу мәсьәлә белән беркем шөгыльләнми дә. Нәсел өчен сездән куяннар сатып алып булырмы? Хәбәр итсәгез иде».

Әлбәттә, аңа җавап күптән барып җиткәндер, бәлки инде «Кощак» совхозыннан кайтарылган «шеншилла» һәм «великан»нар, Урта Азия киңлекләрендә яңа тормыш башлап, үзләренең нәселен таратырга өлгергәндер. Украинада да, Хабаровск краенда да яңа куян фермалары үсеп чыккандыр...

Нәгыйм Бариевич моңа шат. Ул үзләре үстергән куяннарның яңадан-яңа урыннарда тәмле диетик ит булып үрчүләренә чын күңелдән куана. Куян үрчетүгә яңадан-яңа кешеләрнең килүе, Кузнецов кебекләрнең куян үрчетүче булырга вәгъдә бирүе шатландыра аны. Бу — табигый. Мәгълүм ки, һәрбер останың өйрәнчекләре була, ул аларның үз һөнәре серләренә төшенүенә, киләчәктә аның эшен дәвам итәчәгенә куана. Мин Нәгыйм Вәлиевне дә шул осталарга тиң күрдем.

## Дан флагы һәм китап

Совхозга мин көз көне килдем. Җәй буе авылны ямьләндереп торган топольләр, яфракларын коеп, шәрә калган. Кояш та, болытлар арасыннан сирәк-мирәк кенә чыгып, бик сүрән елмая. Мондый чакта сов-

хоз конторасы каршындагы стенд кына барыннан да ачыграк һәм яктырак күзгә ташлана. Иң өстә — Ленин силуэты. Аның мөлаем карашы, стендтагы «Коммунистик хезмәтнең җиңүенә ирешербез» дигән сүзләре бөтен совхоз коллективының эшчәнлеген, юнәлешен һәм максатын билгели сыман. Почет тактасындагы көләч йөзләр дә «Бөек Ильич сызган юлдан тайпылмабыз» диләр сыман. Сулдагы озын колгада кызыл флаг — Дан флагы җилферди. Кем хөрмәтенә күтәргәннәр аны? Түбәндәрәк: «Бишьеллык планны 2 ел да 10 айда үтәгән куян үрчетү фермасы коллективы хөрмәтенә», диелгән.

Шундый кыска срокта шундый уңышка ничек ирешteләр икән? Сере нәрсәдә моның?

Коллектив членнарының күп төрле сорауларына тиз-тиз җавап бирергә, мәсьәләне шунда ук хәл итәргә күнеккән директор минем сорауга да җавап бирер, җәелеп сөйләп китәр дип уйлаган идем. Әмма ул хәйләкәр генә елмайды да, сул ягындагы шкафтан кечерәк кенә брошюра алып, минем алга куйды.

— Биредә бөтенесе әйтелгән,— диде.

Йорт куяннары рәсеме төшерелгән аксыл-сары тышлы бу брошюраның авторы — Н. Б. Вәлиев. Димәк, директор үзе. Исеме — «Куян үрчетүдә яңалыклар». 1973 елда Мәскәүдә Россия авыл хуҗалыгы нәшриятендә басылган. Бу бит совхозның бөтен ил алдында сөйләрлек тәҗрибәсе бар дигән сүз. Совхозга күп хатлар килү дә шуңа бәйле икән.

Уйлый калсаң, гаҗәеп күренеш ич бу. Чылтырап аккан кечкенә генә чишмәнең диңгезгә барып тоташуы кебек. Казан янында бер авылда туган тәҗрибә, үзенә акрын-акрын юл ярып, Татарстан чикләреннән шактый еракка — бөтен Союзга таралган.

Тагын шунысы матур яңалык: үз совхозының тәҗрибәсен директор үзе бөтен ил күләмендә пропагандалый — яңа комплекслар, үзенә яңа көндәшләр тууга юл ача. Капиталист яки фермер алай эшләр идеме соң?! Үз эшенең серен бик югары бәягә сатар иде ул.

Ә безнең новаторларның максаты башка. Үз алымын мөмкин кадәр күбрәк коллективларның үзләштерүен һәм шул нигездә Ватанга мөмкин кадәр күбрәк продукция бирү турында кайгырта ул.

## Диссертация

Көннәрдән бер көнне, тагын барып күрешер өчен, директорның кайчан өйдә булачагын белешергә дип телефон шалтыратсам, совхоз секретаре:

— Нәгыйм Бариевичны сорыйсызмы? Ул Казанда, авыл хуҗалыгы институтында диссертация яклый,— дип җавап бирде.

...Мин килеп кергәндә, «Почет билгесе» орденлы Казан авыл хуҗалыгы институтының Актлар залында диссертация яклау башлана иде инде. Залда галимнәр, вуз укытучылары, совхозның баш белгечләре. Мин дә алар янына елыштым. Урыным совхозның партком секретаре Сергей Федорович Горшунов янына туры килде. Партия җитәкчесе үз коммунистына уңыш теләп дулкынлана.

Гыйльми совет председателе Николай Семенович Катков:

— Хәзер укытуда техник чаралар күп кулланыла. Диссертация яклауда да бу методика зыян итмәс. Диссертантка сүз биргәнче, кыска гына бер фильм карап алыйк,— диде.

Ут сүнде. Экранда «Кощак» совхозында эксперимент» дигән язу күренде. Залдагылар гүя яңа тип куян фермасында булдылар...

Менә инде шушы ферманың серле якларын аңлату өчен Нәгыйм Вәлиев трибунага чыкты. Бу минутта ул аудиториядәге күп санлы сту-

дентларга лекция укучы галимгә охшый иде. Стенада унбишләп таблица. Ул үз фикерләрен раслау өчен әледән-әле шуларга мөрәҗәгать итә.

Диссертациянең темасы: «Йорт куяннары үрчетүне промышленность нигезендә оештыру һәм аның нәтиҗәлелеге».

— Бер чагыштыру урынлы булыр,— ди диссертант. — 1973 елда куян караучылар Нина Сотникова һәм Мария Григошина 5 әр мең чамасы үрчем алып үстерделәр. Ә менә Михайлова, Денисова, Лифанова, Чигвинцева 2 450—2 700 әр генә куян баласы алып тәрбияләде. Сорау туа: ни өчен шул кадәр зур аерма? Әллә соңгылары артта калучылармы? Юк, һич тә алай түгел. Алар да алдынгы — элекке елгыдан 400 әр үрчем артык алдылар.

Ә хикмәт нәрсәдә соң?

— Җитештерү ысулында.

Диссертациянең үзәгендә әнә шушы ысул ята да инде: ул әле моннан берничә ел элек кенә Вәлиев идеясе белән, аның җитәкчелегендә «Коҗак» совхозында эшләнеп, тормышка ашырыла башлаган иде. Менә инде ул үзенең өстенлекләрен дә күрсәтергә өлгергән.

Куян үрчетүне промышленность нигезенә күчерү хәзерге фән-техника революциясе чоры таләбенә бик тә туры килә. Бу ысулның һәркайда хуплап кабул ителүенең сере нәкъ шунда. Бу бишьеллыкта шушы ысул белән Татарстанда 45 хуҗалык, шул исәптән 19 совхоз, куян ите җитештерүгә специальләшәчәк. 1975 елда куян ите җитештерү 3 000 тоннага җиткерелә. Бу саннар КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советы карарында билгеләнгән. Һәм аны тормышка ашыру йөзеннән республикада 36 механикалаштырылган куян фермасы сафка кертелде инде. РСФСР Авыл хуҗалыгы министрлыгы Коллегиясе карарында да бишьеллык азагына чаклы 600, 1 000, 2 000 баш ана куянга исәпләнгән 640 куянчылык комплексы төзү мәсьәләсе куелган иде. Болары да «Коҗак»тагы комплекс үрнәгендә гамәлгә аша.

Яңа ысулның төп асылы нидән гыйбарәт?

Диссертант сүзләре белән әйткәндә, ул җәнлекләрне бер урынга күбрәк туплауны, аңа рацион һәм азык әзерләүнең яңа ысулын, продукция җитештерүне оештыруның яңа технологиясен, барыннан да бигрәк, хезмәтне югары дәрәҗәдә механикалаштыруны үз эченә ала.

Диссертантка сораулар ява:

— Биредә кулланыла торган техниканың ышанычлылык коэффициенты нинди?

— Чит илдәге шундый техника һәм технологиядән калышмыймы?

Сорауларга җаваплар тулы һәм ышандырырлык булды.

Бер җаваптан менә шундый нәрсә күз алдына килде: моннан икеөч ел элек «Бөреле» совхозы Италиядән куян асрау комплексы өчен технология проекты һәм техника сатып алган. Аны биредә италияле белгечләр үзләре монтажлаган. Ләкин совхоз кешеләрен аларның техникасы канәгатьләндереп бетермәгән, чөнки анда тирес чистарту һәм башка кайбер процесслар механикалаштырылмаган булган. «Бөреле» совхозы җитәкчеләре, бу мәсьәләнең очына чыгуны таләп итеп, чит ил белгечен «Коҗак» совхозына алып киләләр һәм андагы техниканы күрсәтәләр. Ул хезмәтне механикалаштыру һәм автоматлаштыруда коҗаклылар тәҗрибәсен өйрәнгән һәм аны «Бөреле»дә файдаланган.

Диссертациягә экономик фәннәр докторлары, профессорлар М. И. Куркин (Казан), В. И. Ильдеменов (Чабаксар) һәм башка иптәшләр яхшы бәя бирде.

«Бу хезмәттә фәннең производство, теориянең практика белән тыгыз бәйләнеше ачык гәүдәләнә». — Монысы Казан ветеринария институты доценты, кафедра мөдире М. П. Рабинович ясаган нәтиҗә.

Шул чыгышларны тыңлап утырганда җир катламы астында ничә-мә-ничә гасырлар буена яткан таш күз алдына килде. Ничә мең еллар дәвамында аңа беркем кагылмаган. Ә көннәрнең берендә күзәтүчән берәү килеп чыккан да аны файдалану идеясен әйткән. Әлеге таш, әйтик, Чупай ташы, Әлмәт кебек шәһәр, поселоклар төзүдә төп материал ителгән. Ул кешегә хезмәткә куелган.

Нәкъ шушы таш кебек, үзләрен кузгатуны көтеп яткан мәсьәләләр тормышта азмыни? Ә бит аларны кузгатырга, эшкә файдалану мөмкинлеген фәнни яктан нигезләргә кирәк. Нәгыйм Вәлиев өнә шундый хәзинәне нәкъ шулай эшкә җигү белән яңалык ача, батырлык эшли.

## Куян... Зыян?.. Файда?

Нәгыйм Бариевич — Буа ягыныкы. Ул якларда игенче хезмәтенә мәхәббәт ничектер аеруча зур, ә куян асрау һөнәрен, бигрәк тә аның яшь чагында әллә ни санга сукмыйлар иде дисәк, ялгышмабыз кебек. «Бер тиенлек куян өч тиенлек зыян» дигән әйтем дә бәлки тикмәгә тумагандыр.

Әйе, йорт куянына караш һәр җирдә диярлек күп еллар шул мәкальдәгечә булып килде. Шуңадырмы, куянчылык тармагын Нәгыйм Вәлиев укыган ветеринария техникумында да, институтта да игътибар бирмичә генә узып киткәннәр иде.

Ләкин тормышның үз агымы, үз законнары бар бит. Шушы агым дулкыннары куянчылыкны әле ярга кагып, әле үзәнгә этәреп килде. 1957—1961 елларда куянчылыкның алгы планга чыккан вакыты иде. Татарстанда нәсел өчен ана куяннар саны 106 меңнән артты, 1713 тонна куян ите җитештерелде. Моңарчы тарихта булмаганча, 1961 елда 1 миллион куян тиресе сатылган иде. Бу чорда «куян... зыян» дигән сүзләр сирәгрәк ишетелде. Бер хуҗалыкка зыян, икенчесенә файда китерә иде инде ул вакытта. Хәер, Нәгыйм Бариевичка ул чакта куяннар белән шөгыльләнергә туры килмәде. Шулай да «Энергетик» совхозында — управляющий, «Актай» совхозында директор булып эшләгәндә күршедәге «Яшь көч» колхозының куянчылык фермасына күз салгалый иде. Бу ферма бөтен Әлки районында иң алдынгы булганга аның игътибарын тартты. Мөдир Харис Сафин куян фермасын Татарстан күләмендә, ә куяннар Харисны ил күләмендә таныттылар. Куянчылыктагы хезмәтләре аны партиябезнең XXII съезды делегаты булып барырга лаек итте.

«Менә сиңа бер тиенлек куян!..»

Нәгыйм Вәлиев шулай дип сокланган иде ул вакытта. Тик, гаҗәп, бераздан бу фермалар акрынлап таркала барды. Сәбәбе? Хәзерге чор эшнең киң колачлы булуын, хезмәтнең техника ярдәмендә башкарылуын таләп итә. Ә куянчылыкта фермалар кечкенә, хезмәт машинага көйләнмәгән, кустарьчылык хөкем сөрә иде. Димәк, куян асрау эше терлекчелекнең башка тармаклары белән ярышта яки төшеп калырга, яки алар дәрәҗәсенә күтәрелергә, промышленность нигезенә күчерелергә тиеш.

Чистайда авыл хуҗалыгы идарәсенең баш зоотехнигы булып эшләгәндә туган уйларын практикада сынап карыйсы килә иде Нәгыйм Вәлиевнең. Көчле суыкларда туңмый калган алмагач бөреләре язгы кояш нурларында бүртәеп ачыла башлаган кебек, белгеч күңелендәге фикерләр дә үсә, җитлегә барды һәм үзенә җәнлек «җене» кагылган Нәгыймне Чистай җәнлек совхозына (хәзер ул «Луч» совхозы) китерде. Ул инде — әлеге совхозның директоры. Мавыгып башкарылган эштә дүрт ел чамасы вакыт сизелми дә узып китте. Бу чорда беркадәр уңыш та яуланды. 1000 баш ана куяннан

1966 елда 8 мең баш үрчем алынган булса, 1970 елда ул 16.740 башка җиткерелде. Куян үрчетүне промышленность нигезендә оештыру мәсьәләсе көн тәртибенә килеп баскан иде басуын, әмма бернинди проект, бернинди тәҗрибә булмау кулны тотты.

Ә хәлләр, вакыйгалар ел фасыллары кебек туктаусыз үзгәрә тора. Яңа урын, яңа эш тәкъдим итеп, Нәгыйм Вәлиевне «Коцщак» совхозына күчерделәр. Җәнлек совхозлары трестында шулай кирәк таптылар. Карышырга ярамый иде.

Яңа хуҗалыкка күчү кызыклы һәм дулкынландыргыч чорга — тугызынчы бишьеллыкка партиянең XXIV съезды Директивалары проектын бөтен халык тикшерүе барган чакка туры килде. Ул көннәрдә һәркемгә эзләнү, Директивалар проектында күздә тотылганнарны тормышка ашыру өчен үзендәге мөмкинлекләрне барлау, яңа фикер, яңа тәкъдим әйтү өчен зиһенне киеренкерәк эшләтү хас иде.

Кешеләр берәм-берәм дә, коллектив белән дә уйландылар, фикерләрен җыелышларда тикшереп ачыкладылар. Ит җитештерүне арттыруга совхоз нинди өлеш кертер, дигән сорауга җавап биргәндә, бөтен өмет куянчылыкка төбәлде. Совхозда сыерлар да җәнлекләр генә асрала. Ит җитештерүне сыерлар исәбенә генә текә күтәрү кыен эш иде. Димәк, өмет — куяннарда. Биредә аның базасы да бар. Тик күпмегә арттырып булыр икән соң бу җәнлекләрне? Уйлаша, киңәшә торгач, яңа директор, партком секретаре һәм баш белгечләр һәр анадан үрчем алуны арттыру исәбенә 1970 елгы дәрәҗәне бер ярымга арттырырга мөмкин дигән нәтиҗәгә килделәр. 1970 елдагы 21 мең чамасы үрчем урынына, 1975 елда — 31 мең!

Ләкин директорның күңеле моның белән бик үк канәгать түгел әле. Ул зуррак үсешкә омтыла — ике тапкырга арттырасы иде үрчемне. Ә моның өчен азык каян алырга да, арттырылган ана һәм бала куяннарны кая куярга? Өстәмә читлекләр куярга урын юк — ферманы ике яктан чокырлар киртәли, ике ягы исә совхоз поселогына терәлеп тора. Киңәйтим дисәң, аны бөтенләй яңа урынга күчерергә кирәк. Бу исә күпме вакыт, күпме өстәмә чыгымнар таләп итәчәк.

— Бәлки,— диде Нәгыйм Вәлиев, — промышленность нигезендә куянчылык комплексы төзү ярдәм итәр. Аз гына мәйдан биләгән шундый комплексларда 20 шәр мең тавык асрыйлар бит. Нигә куянчылыкта да бу ысулны кулланмаска?!

Идея бар, идея туган, тик аны тормышка ашыру өчен институтлар тарафыннан эшләнгән махсус проект кына юк. Әллә, тәвәккәлләп, аның беренче үрнәген ясап карарга мы?

«100 баш сыерга исәпләнгән абзар проектын нигез итеп, шуңа эчке җиһазларны үзебезчә көйләсәк ничек булыр?» — Бу сорау совхозның барлык белгечләре алдына куелды.

Моның барып чыгасына берәүләр ышанды, икенчеләре шөбһәләнде. Иң мөһиме: ният барып чыкканда, зур перспектива ачылачагын күреп, бу кыю тәкъдимне трестта якладылар. Кышын-җәен үрчем алу, яшь куяннарны бөтен ел буе симертеп иткә тапшыру мөмкинлеге туа бит.

Бишьеллыкның беренче елы язында һәм җәендә төзелеш кайнап торды. Цехта яктылыкны арттыру, температура үзгәрүен киметү, чисталык тәэмин итү өчен стенаны шәмәхә төстәге пыяла блоклардан эшләргә булдылар. Директор, «газигын» әле үзе йөртеп, әле шофер Михаил Андреевич белән көн саен диярлек юлда булды. Күршедәге Питрәч кошчылык фабрикасына бик еш бардылар. Читлек ясау, автомат ашаткычларны, тирес чистарткычларны көйләү ысулын өйрәнделәр.

Куяннарга читлекләрне ни зурлыкта ясарга соң? Иңе, буе, биеклеге күпме булырга тиеш?

Боларга җавап табу өчен директор белән баш инженер Федор Ва-

сильевич Зыков күп киңәштеләр, кайчакларда бәхәсләр дә булгалады. Фикерләрнең дөреслеген сынап карау өчен, төрле зурлыктагы, төрле биеклектәге 11 читлек эшләнде. Аларга куяннар кертелде. Сынаулар нигезендә буе — 92, иңе — 60, биеклеге 45 сантиметрлы үрнәккә туктaлдылар. Ул ана куян өчен иркен, анда яшь үрчемгә оя итү өчен кечерәк кенә тартма да куеп була.

Шундый читлекләрне тезеп чыккач, бинаның бөтен буена бер-берсенә тоташтырылган тимер челтәр сузылган кебек булды. Өч линия. Аларны операторлар карый. Яңа эшкә зур тәҗрибәле Нина Николаевна Сотникова, Тамара Ивановна Абрамова, Мария Никитична Григошинаны кулай гаптылар. Ә Анфиса Николаевна Тунгускова бригадир булды. Барысы дүрт кеше — ике оператор, слесарь һәм бригадир — 600 ана куянны карарга, вакытында үрчем алырга өлгерәләр, чөнки коры азык автомат ярдәмендә бункердан килә, су — автоэчергечләрдә, тиресне транспортер чыгара — кнопкага гына басасы. Торакның икенче өлешендә — ягъни икенче секциясендә, кечерәк читлекләр тора. Аларда — алты меңләп куян баласы. Бу нәниләр бирегә беренче секциядән күчерелгән. Монда аларны шул ук операторлар карап үстерә һәм симертә.

Торак төзелгәннән соң мәсьәлә азыкка барып терәлгән. Автоматлар коры комбиазыкка көйләнгән. Икенче төрле әйткәндә, бу азыкның составы күп төрле азыктан торырга тиеш. Ә аны промышленность әле әзерләми иде.

Баш зоотехник Евгений Ильич Пискунов белән баш ветврач Павел Семенович Корчагин алдына бурыч куела: шушы фермада асралачак куяннар өчен комбиазык рецептын эшләргә.

Шул арада совхозның үз төзүчеләре коры азык әзерләү цехы салалар. Аңа күп төрле техника куела. Башта печән бераз салам кушылып ваклана, аннары аны «АВМ-0,4» агрегаты печән оны итә. Шуннан соң комбиазык составына керергә тиешле башка компонентлар тиешле үлчәүдә «ОГМ-0,8» агрегаты бункерына салына. Болгатыла, җентекләп аралаштырыла һәм болганган масса грануляторга җибәрелә, кайнар су сиптерелә, дозаторга килә, аннан пресс-матрицага китә. Әзер гранулллар, суытылып, капчыкларга тутырыла. Менә дигән туклыклы азык!

Хәзер аның ничек эшләнүен карап торуы күңелле. Ә бит моннан берничә ел элек Нәгыйм Вәлиев шуны булдыру өчен күпме алдынгы хуҗалыкларда булды, үзенең белгечләрен тәҗрибә өйрәнергә кайларга гына җибәрмәде. Хәзер гранулллар күпләп җитештерелә. Ул куяннарга да, хәтта сыерларга да бирелә. Гранулллар җәйдән һәм көздән үк әзерләнә, аларда туклыклы матдәләр яхшырак саклана.

Азык әзерләү агрегаты туктаусыз эшләсен өчен яшел азыкның күп булуы мөһим. Тик аның чыганагы чикле. Җирләр ярлы — көлсу туфрак. Яңгырлар аз булса, уңыш бөтенләй түбән. Һәр куяннан үрчем алуны 30—40 башка җиткерим дисәң, башта аңа азык әзерлә — хуҗалык итү законы шундый. Культуралы көтүлек — бу мәсьәләне хәл итүдә төп юл. Лениногорскилыларның бу өлкәдәге беренче тәҗрибәсе уңышлы чыгуын ишетү белән Нәгыйм бу яңалыкны үз хуҗалыгына кертергә ашыкты. Үлән чәчелде. «Волжанка» агрегаты сатып алынды. Торбалар уздырылды. 100 гектар мәйданда сугару көйләнде. Гектардан 300 центнер яшел азык! Бу үләнгә булган ихтыяҗны бик яхшы каплады.

Кыенлыклар инде артта. Хәзер механикалаштырылган торак бар, азык бар, эш сөюче кешеләр бар — уңыш яулау өчен тагын ни кирәк?!

Хезмәтнең һәм тырышлыкның нәтиҗәләре күркәм. Куян үрчетүдә үсеш сокландыргыч. 1970 елда куяннардан 21. 838 үрчем алынган булса, 1973 елда ул 46. 874 башка җитте! Бу — 918 центнер куян ите

дигән сүз, бу — кимендә 250—300 баш сыер ите хәтле. Хуҗалык 1974 елда куяннардан үрчем алуны 50 меңгә җиткерергә йөкләмә алып эшләде. Йөкләмәсе уңышлы үтәлде.

...Цехның беренче бинасы янында тагын бер шундый бина үсеп килә. Тагын бер куян комплексы төзелә. Юк, монысы инде сынау тәртибендә түгел. Аның өстенлегеген күреп, белеп эшләнә ул. Комплекста куян үстерүнең табышы 22 процентка артык. Яңа ысулның да, шулай ук әле күптән түгел якланган диссертациянең дә мәгънәсе — вакыт отуда. Вакыт аз китсә, табыш зур була. Бу тармак соңгы елларда 150 шәр мең сум чамасы табыш биргән, яңа бина аны тагын да арттырырга ярдәм итәр.

## Совхоз өлеше

Нәгыйм Вәлиевнең сейфта гына саклана торган бер папкасы бар. Анда нинди документлар? диярсез. Ниндидер саннар караштыру өчен, директор ул папканы минем алга ачып салды. Кәгазьләр, кәгазьләр... Кайсы журналдан, кайсы газетадан пөхтә итеп кисеп алынган. Арада ротаторда басылган карарлар да күзгә чалына. Барысы да җәнлек асрау, куян асрау турында. Димәк, аларда әйтелгән һәр фикер кадерле, һәр фикер кыйммәтле. Ул аларны бөртекләп җыя. Ә бөртекләрдән көшел өелә.

Директор әлеге «алтын бөртек»ләр белән таныштыра. Менә «Правда» газетасының 27 декабрь (1973) санынннан материал. «Хәзер, — диелгән анда, — мехларның 10 проценты гына сунарчылыктан алына, 90 процентын җәнлек фермалары бирә! Илдә чәшке, төлке, ак төлке, су күселәре үрчетә торган уннарча зур хуҗалыклар бар. Нәтиҗәдә безнең ил бу өлкәдә зур уңышка ирешә. Әгәр 1968 елда АКШ — 8,5 миллион, СССР 2,5 миллион җәнлек тиресе җитештергән булса, хәзер урыннар киресенчә алышынды диярга мөмкин... Җир шарында елга 21 миллион җәнлек тиресе җитештерелә. Шуның өчтән бер өлеше Советлар Союзына туры килә.

Бу мәгълүматлардан соң: «Сезнең совхоз шушы гомуми уңышка нинди өлеш кертә?» дигән сорауның тууы табигый.

Директор, ел саен бик күп туристларны, экскурсантларны кабул итә торгач, бу сорауга җавапны бик оста аңлатып бирә. Илебез хезмәт ияләренең тормышын бизәүгә, аларга затлы якалар җитештерүдә «Коцак» совхозының да өлеше шактый икән. Бередә йорт куяннары белән берррәттән чәшке һәм ак төлке дигән кыйммәтле җәнлекләр дә үрчегелә. Мәсәлән, 1973 елда бер чәшкедән — уртача 4,2, бер төлкедән 7,2 үрчем алып үстерергә планлаштырылган булган. Ә җәнлек караучылар планны арттырып үтәгәннәр. Мәсәлән, төлкеләрдән 8,3 әр үрчем алып үстерелгән. Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы җәнлек караучы Нина Спиридоновна Попкова, Анна Григорьевна Андреева, Мәгъсүмә Паничева, Мария Матвеевна Горшенина кебекләрнең уңышлары тагын да күркәмрәк. Аларның дусты һәм киңәшчесе — зоотехник Елизавета Андреевна Варнек. Моннан егерме бер ел элек бу хуҗалыкка беренче җәнлекләрне алып килүче, җәнлек карау серләренә уннарча кешеләрне өйрәтүче һәм тәрбияләүче ул. Аларның тырышлыгы белән совхоз 1973 елда дәүләткә 63 276 данә чәшке тиресе, 9302 данә төлке тиресе саткан. Җәнлек асрау хуҗалыкка 1 миллион 169 мең сум табыш китергән. Менә шушы була инде совхозның өлеше. Зур өлеш бу! Бөтен коллективның — эшчеләр, белгечләр һәм җитәкчеләрнең уртак тырышлыгы, бергәләп эзләнүе нәтиҗәсендә үстерелгән җимеш.

## Кояш Тимбикова

# ӘМИНӘ КЕЛӘМНӘРЕ

Әминә диңгез яры буйлап салмак кына алга атлый. Күзләре табигать күренешләреннән төсләр эзли.

Балтик суы Рига култыгына бераз ял итәргә кереп яткан диярсең: тын, сабыр. Дулкыннар әйтерсең кечкенә акчарлакларны тибрәтер өчен генә.

Каршыда — җемелдек тәңкәләрдән җәелгән көмеш дәрья сыман биниһая киң мәйдан. Кояшны болыт капласа, су өсте куе яшел төскә керә. Коеп яңгыр ява башласа, офык сызыгы юкка чыга, тирәюнь тоташ су дөньясына әйләнә. Кайда күк, кайда диңгез — һич аерырлык түгел.

Аяз кичтә исә диңгез шәфәкъ аллыгына чума, әллә кайларга сузылган алтынсу паласны хәтерләтә. Су яссылыгыннан кире кайтарылган нурлар яр буендагы һәр нәрсәне тонык ахак кызыллыгына төрә.

Андый чакта Әминә адымын акрынайта төшә. Зур кара күзләре кысылып кала. Ул монда күргәннәрен ятлап өлгерергә, зиһененә сеңдерергә тырыша. Күпме төс! Хыялда гына йөргән, әле берәү дә тукымаган гаҗәеп келәмгә төшерерлек никадәр матурлык! Шул хозурлыкны, сихри гүзәллекне, дулкыннардагы бөдрәлекне түкми-чәчми җепләргә күчерсәң иде! Җепләрдән чәчәкләр ясап, келәмнәр тукырга иде! Келәмнәр өйләрнең стеналарын, ятакларны бизи. Әминә хыялында бөреләнгән матурлык башкаларны да шатландыра, йөзләгән күңелләрне хушландыра.

Хәер, карап сокланучылар, мөгаен, ул келәмнәрнең иң элек Әминә тарафыннан табылган күркәмлектән барлыкка килүен белми дә торганнардыр. Америкада да, җиде җир читендәге Австралиядә дә, Франциядә дә, Скандинавия илләрендә дә, ГДР да да ул келәмнәр барыннан да бигрәк СССР турындагы кадерле истәлек булып саклана. Келәм тукучы рәссам Әминә Хусанованың исеме күргәзмәләр вакытында гына телгә алына, каталогларга теркәлә.

Һәр күргәзмә — рәссам өчен зур сынау. Сүрия. Дәмәшкъта оештырылган халыкара күргәзмә. Монда Әминәнең тахта өстенә ябу өчен тукылган затлы келәме куела. Көнчыгыш илләрдә сынлы сәнгатьнең бай традициясе тупланган. Андагы рәссамнар белән көч сынашу өчен зур осталык кирәк. Диңгездән алган серлелек тә, латыш этнографиясендәге байлык та, кечкенәдән күңелгә сеңгән, әнисе Бәдерниса апа өшәнчекләрендәге бизәкләр дә — бары да күз алдында тотыла. Күркәм дип табылган төсләрне Әминә төрлечә аралаштырып карый. Эскиз ясый. Аннары рәссам станогы янына утыра, тукый башлый, меңнәрчә төеннәр



бәйли, төеннәр тезмәсеннән сурәтләр чыгара.

Келәмче кулыннан үткән җепләрнең барын бергә чорнасаң, зур шар хасил булыр иде. Йомгактагы җепнең һәр тотамы, һәр карышы башларны әйләндерерлек эзләнүләргә, катлаулы вакыйгаларга бәйле. Кызны шуларның кайсы рәссамнар арасына кертеп җибәрерлек этәргеч булган? Гаиләме? Уку еллармы? Юлларымы?

Әминә ханым:

— Мин Хусанова түгел идем,— дип сөйли.— Хөсәенова мин. Әтием — Хөсәенов Мирзагаян-Болгари. Ул һәр вакыт исеме янына «Болгари» сүзен өстәп яза иде. Ригага килгәч, латышлар минем исем-фамилиямне үз телләренә җайлаштырып, үзгәртеп җибәрделәр, «Хусанова» дип йөртәләр, «Амина Мирдзовна» дип эндәшәләр. Чынында, Мирзагаян-Болгари кызы мин...

Дин гыйлемен Бохараның үзендә үзләштергән Мирзагаян хәзрәт төпчек кызының дөнья күләм күргәзмәләрдә дан казанырлык рәссам булачагын белсә, акылыннан язган булыр иде.

Көннәрдән бер көнне Мирзагаян-Болгари, гадәтенчә, авыз эченнән бисмилласын кабатлый-кабатлый, укырга дип, кулына корьән ала. Китапны ачып җибәрсә, күзләренә ышанмый тора: Әминә иң урта битләргә чибәр кыз сурәте ясап куйган! Нечкә билле, зифа буйлы. Кулларында — чәчәк бәйләме...

Өйдәгеләр, бу хәлне күреп, инде дөньяның асты өскә килер дип көтәләр. Тик әти кешегә әллә нәрсә була. Ул кулына карандаш ала да рәсем янына: «Әминәм ясады»,— дип язып куя.

Үзсүзле кызының беренче рәсеме төшерелгән бу китапны Мирзагаян агай гомеренең соңгы көненә кадәр саклый. Соңыннан туганнары аны Әминәгә бүләк итәләр.

Очраган һәр кәгазь кисәгенә рәсем ясаучы кызга бервакыт Ригадан хәбәр килеп төшә. Күрше Степан Коловның олы кызы Лиза Әминәгә: «Монда яңа училище ачылды. Синең кебек рәсемгә оста укучыларны җыялар. Бөтен рәсемнәреңне сал әле, бәлки кабул итәрләр», дигән хат яза.

1946 ел. Сугыш калдырган эзләрнең әле өр-яңа вакыты. Себердәге Татарск шәһәре белән Рига арасын Әминә атна буе үтә. Латвиягә якынайган саен кыз фашистлар яндырып үткән авылларны, җимерек өйләрне, ватык паровозларны ешрак күрә бара.

Тормышның бик авыр чагы. Торак йортлар җитешми, туйганчы ашарлык ризык юк. Латвиядә шул шартларда да халык иҗатында булган сынлы сәнгать үрнәкләрен өйрәнү, аны үстерү, заманга яраклаштыру чараларын күрә башлыйлар. Керамикадагы, туку һөнәрендәге сәнгатьчә элементларны бөртекләп җыялар, җентекләп өйрәнәләр. Латыш карчыклары тукыган тастымалларны күргәндә, Әминәнең күңеле ирексездән татар өенә барып тоташа. Әбисеннән калган кызыл башлы сөлгеләрне, чигүле намазлыкларны, чәмчәле читекләрне, энҗеле калфакларны күз алдына китерә. Бала чактан күзен иркәләгән матурлык чыганакларын училищеда, Балтик буе музейларында күргәннәре белән чагыштыра, уртаклык табарга тырыша. Балтик буенда җыела торган гәрәбәдә җемелдәүче мең төрле сарылык... «Мин ихтыярсыздан әнә шул төсләргә тартылам, — дип сөйли Әминә ханым. — Әнинең өшәнчекләре барысы да

яшелле-кызыллы иде. Бәхетемә, ул төсләр латыш этнографиясендә дә еш очрый. Келәмнәр тукыганда, «перлите» ысулыннан файдаланырга яратам. Бу сүз «энҗе» дигән төшенчәне аңлата. Келәмгә төшерелергә тиешле сурәт җепне күпертеп калдыру юлы белән ясала. Күз алдыма әтиемнең туганы Мөсәвәрә апаларда күргән бик борынгы күкрәкчә килеп баса. Шундый матур иде ул: ука белән күпертеп чигелгән, сирәк кенә кызыл рубин төймәләре җемелди...»

Мәскәүгә җибәрелгән келәм дә «перлите» ысулы белән башкарылган. Аны күргәзмәнең дирекциясендә үк сатып алып калалар. Гомумән, Әминә иҗат иткән бер генә әсәрнең дә салон киштәләрендә яки күргәзмә залларында озак тоткарланганы юк икән. Автор үзе генә үзеннән риза түгел. Ул сынлы сәнгать белгечләре тарафыннан югары бәя алган келәмнәреннән дә мең төрле гаеп таба. Рәссам фикеренчә, иң матур келәмнең рәсемнәре әле ясалмаган, төсләре билгесез.

Кайбер очракларда Әминә ханым башка рәссамнар белән бергә иҗат итә. Акварелистлар яки эстамп осталары аңа эскиз китерәләр. Туку технологиясе таләп иткән чараларны Әминә башкара. Соңгы сүз аның станогына бирелә. Рәсемчеләр еш кына, үз әсәрләрен Әминә келәмендә күреп, үзләре үк сокланалар:

— Нинди матур, мин болай килеп чыгасын башыма да китермәгән идем! — диләр.

Әминә дә соклана белә. Һөнәр училищесында тыңлаган беренче дәресләргә әле дә соклана ул. Сәнгать тарихы буенча лекцияләр укучы Герман Осипович Минц дәресләрен Әминә аеруча яхшы хәтерли. «Мин, укытучымның берәр ишарәсен күрми калудан куркып, лекцияне дә язмый идем,— ди.— Аның һәр сүзе, ул сүзне әйткәндәге мимикасы, адымы, кул хәрәкәтләре — барысы да үзе сәнгать, үзе матурлык иде».

Герман Осипович белән Әминә хәзер дә дуслар. Һөнәр училищесыннан соң күп еллар үткән, сынлы сәнгать училищесы укытучыларын, Ленинград сәнгать академиясе профессорларын тыңлаган Әминә. Әмма матурлык серен аңлатырдай беренче адымны атлаганда кул сузучы укытучы иң кадерлесе булып кала бирә. Шәкерте янына бер килүендә, Минц Әминәнең әнисе Бәдерниса апаны очрата. Кызының остазы белән әңгәмә башлагач, әни кеше:

— Ун-унбиш ел укыды кызым,— ди,— баксаң, киндер сугарга гына өйрәткәннәр икән үзен. Без аны укымыйча, әбиләребез сукканны карап торып та эшлидер иек.

Бәхәс китә. Бәдерниса карчыкны Әминәнең станогы каршына утырталар. Кулына кызының әле яңа гына иҗат иткән, «Максла» сәнгать советы тарафыннан эталонга кабул ителгән рәсемен тоттыралар.

— Әйдә, кирәкле җепләреңне сайлап ал,— диләр.— Десинатура ясa, тукып җибәр!

Бәдерниса апа аптырап кала. Аяк астында — егермедән артык тәбәлдерек, мең төрле шүре, әллә ничә төсле җеп...

— Ә-ә,— дип сузып җибәрә ул.— Без болай нечкәртеп тормыйдыр иек шул.

Ул үзенең чупләмле сөлге, сәке паласы тукулары хакында сөйли. Соңыннан укытучысы Әминәгә:

— Нинди бай син, Әминә,— ди.— Әниеңнең белгәннәрен барын да өйрәнергә кирәк!

Бәлки әнә шундый тынгысыз укытучылары, эзләнүчән остазлары тәрбиясе нәтиҗәседер: Әминәгә өзлексез өйрәнү, яңалыкка омтылу «җене» кагылган.

Сынлы сәнгать, сәнгать тарихы, теориядәге яңа агымнар турында кайда, кемнең сүзләрен ишетергә мөмкин — Хусанова шул лекциягә ашыга. Мәскәүдә, Ленинградта аның бик күп таныш белгечләре бар. Аларның фикерләрен белеп торырга омтыла ул.

Эрмитаж фәнни хезмәткәре, сәнгать белгече Николай Николаевич Никулин җитәкчелегендә Әминә Латвия рәссамы «Ян Паулюк портретлары һәм автопортретлары» дигән темага диплом эше язган. Дипломны кабул итәргә Мәскәү галимнәре дә килгән. Язма тирән эчтәлекле, кыйммәтле фикерләргә бай дип табыла.

Әминә гаҗәеп принципиаль, гадел кеше. Идеаль гаделлеккә омтылу төпчек кыз гадәтенә әтисе холкыннан күчкән. Бу җәһәттән Әминә бала чагындагы бер вакыйганы хәтерли.

...Кичен, шәһәр читенә, көтү каршыларга барган җирендә, кыз бер төргәк таба. Чаба-чаба өйгә кайта, керә-керешенә:

— Әти, акча таптым! — дип кычкыра.

Мирзагаян ага төргәкне ала, акчаларны саный, һәр кәгазьне, һәр таңкәне җентекләп карый. Соңыннан:

— Табышыңны түкми-чәчми өйгә алып кайтуың яхшы булган, кызым,— ди.— Хәзер инде төргәкнең иясен дә табарга кирәк. Акчаларына караганда, ул бик ярлы татар булырга охшый...

Икенче көнне Татарск базарында кәләпүшенә гарәп хәрефләре белән эре итеп: «Мин акча таптым», дип язган хәбәр тагып йөрүче картны күреп гаҗәпкә калалар. Кайберәүләр: «И-и, бичара, — дип, картны кызганалар.— Ачлык нишләтми кешене?!. Акылдан язу өчен күп кирәкми шул. Акча табу турында хыяллана, күрәсең...»

Базарның бер почмагына акча югалткан хатын да килеп чыга. Ул очраган һәр кешегә мөрәҗәгать итеп елый: «Оек балтырыма гына тыккан идем, харап иттеләр, бер тиенсез калдырдылар»,— ди. Төшереп югалткан акчасын кемдер алган дип белә. Аның такмаклавына читтән үтеп баручы бер кеше игътибар итә:

— Ник алай сабырсызланасың? — ди ул.— Алла ризалыгы өчен булсын! Дога кыл! — Аннары, мыскыл иткәндәй, естәп куя:— Нишләтми бу дөнья кешеләрне?! Тегендә бер җүләре: «Акча таптым!» дип игълан тагып чыккан, бусы гомерендә күрмәгән акчасын, югалттым дип, үзен кешедән кызгандырып утыра. Бар, әнә теге карттан сора, бәлки синекен дә тапкандыр...

Бичара хатынны сөендерә алуы шатлыгыннан Мирзагаян агай ул көнне өендә бәйрәм оештыра. Кызларга конфетлар өләшә, үзе кат-кат:

— Себердәге туганын эзләргә килер өчен, егерме ел җыйган акчасы булган бит ул хатынның,— ди.— Ярый әле, Әминә кызым, синең кулыңа кергән. Берәр комсыз тапса, үз кирәгенә тоткан булыр иде. Сугыш чоры бит, җитешмәүчәнлек күп. Шулай да гаделсезлеккә юл куярга ярамый!

Шушы кечкенә генә вакыйга кыз күңелендә хәзергәчә бары тик тугры юл белән генә яшәргә кирәклекне кисәтүче иң якты хатирә булып саклана. Авырлыкларны сер бирми үткәрүчән, башка төшкән хәсрәтләрен иң якын дустыннан да яшереп, бары тик ялгыз гына кичерүчән латыш кызлары да Әминә табигатендәге ныклыкка, гаделлеккә, алга омтылышка сокланып карыйлар. Аның күңелендә сагыш тоеп алсалар, юатырга ашыгалар, шатлыгын күреп, котлыйлар, бәйрәмнәрдә сөенечен уртаклашалар, бүләкләр китерәләр. Бүләкләренең күбесе — китаплар. Беләләр алар: яхшы китап — Әминә өчен иң зур куаныч. Тәҗрибәле педагоглар белән очрашырга, аларның алтын бәясе торыр сүзләрен ишетергә туры килмәгәндә, Әминә китаплар дөньясына чума. Аның китапханәсендә дөньякүләм танылган рәссамнарның әсәрләрен туплаган альбомнар, теория буенча бәхәс алып бара торган монографияләр, сәнгать тарихына караган кыйммәтле китаплар саклана. «Венеция тарихы», «Тува халыклары сәнгате тарихы», «Пикассо графикасы», «Литва сәнгате», «Модернизм турында мәкаләләр», «Көньяк-көнчыгыш Азия сәнгате тарихы», «Төркия сәнгатьле керамикасы», «XVII гасыр Франция портреты», «Чуваш рәсем сәнгате тарихы», «СССР художниклары»... санап бетерерлек түгел.

Укыган саен сәнгатьнең бөеклегенә соклана бара Әминә. Аның өчен яңадан-яңа серләр чишелә. «Бабур-намә» альбомындагы рәсемнәргә карап, ул:

— Менә игътибар гына итегез әле! — ди.— Бер-берсе белән янәшәдә үк нинди җете төсләр кулланылган. Алардан шул кадәр килештерерлек итеп файдалану өчен рәссамның зур талантлы булуы шарт. Мондый төсләрне бер-берсе белән яраклаштыру, «сугыштырмыйча», тамашачы күзен иркәләтерлек дәрәҗәгә китерү өчен гаҗәеп осталык кирәк!

Мисырдан китерелгән Тутанхамон фиргавен табутын күрү өчен, Әминә ял арасында Ленинградка барып кайткан. Тутанхамонның битлегенә ул аеруча нык игътибар итә. «Гади алебастр ярдәмендә кеше елмаюының нинди тирән мәгънәсе сурәтләнгән!»

— Миңа оят булып китте,— дип искә ала Әминә.— Без эзләнәбез, бәхәсләшкән булабыз. Ә Мисыр рәссамнары моннан меңнәрчә еллар элек әнә нинди осталыкка ия булганнар. Кызарып чыктым, фиргавен битлегендәге сизелер-сизелмәс елмаю гел миңа юнәлтелгән кебек иде. Фиргавен минем көчсезлегемнән көләдер төсле тоелды.

Әминә Хусанова үзе тукый торган келәмнәргә ни бар осталыгын, фән йортларыннан, китаплардан, сәнгать күргәзмәләреннән алган белемен салырга омтыла. Кайчак әзер җепләр рәссам теләген канәгатьләндерерлек булмый. Ул очракта Әминә үзе буяулар сайлый башлый, эремәләр әзерли, җепләр мана.

Өендәге станок бавында төрле төстәге бер бәйләм җеп саклана аның. Келәм остасы шул чукка ишарәләп:

— «Лалә» җепләре болар,— ди.— Үзем мандым, үзем сайладым.

Чаллыдагы «Энергетик» культура сараеның иң кадерле кунаклар өчен бүленгән бер залында Әминәнең «Лалә» дип исемләнгән келәме эленгән.

— «Лалә»нең төеннәре сигез төсле җептән тора.— Әминә бу келәме турында рәхәтләнеп сөйли.— Шактый кызыклы гамма килеп чыкты...

Шулай да рәссам хәтта «Лалә» дән дә тулысынча канәгать түгел. Соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре арасында иң яраткан бу келәмнең дә Әминә кайбер өлешләрен генә яратып, «нәкъ мин теләгәнчә килеп чыкты», дип сөйли. Монысын, мөгаен, үз хезмәтен яраткан кешенең бәхете, аның карамагында әле тагын бик мул иҗат байлыгы булу белән аңлатырга кирәктер.

Чаллы өчен әзерләнгән хезмәтен иң кадерле әсәрләре рәтеннән санавы да табигый. Дистәләгән еллар буе аерылып торган туган җире өчен, аның да дөнья шаулаткан КамАЗы өчен нидер башкару рәссамга яңа иҗат дәрте өстәгән.

КамАЗ төзелешеннән үтенеч килгәч, Латвия сәнгать фондында гомуми кызыксыну туа. Культура сараена витражлар ясауны рәссам латыш Авотишька тапшыралар. Затлы келәм турында сүз кузгалгач, бөтен рәссамнар бер булып, Әминә Хусанованы тәкъдим итәләр.

— Ниһаять, мөмкинлек туды! — дип шатланалар. — Күрсәт әле, Әминә, үз осталыгыңны, Татарстаныңны куандыр!

Рига газеталарында бу турыда мәкалә дә басылып чыга.

«Лалә»нең ни дәрәҗәдә тырышып иҗат ителүе турында сөйләп тору да урынсыз. Келәмнең бик матур булуын да, тизрәк тукылып бетүен дә, бөтен кешегә караганда, Әминә үзе ныграк тели. Тиздән Татарстанны, Казанны, КамАЗны күрү мөмкинлеге аны канатландырып җибәрә. Читтән торып укулар, эштәге өсте-өстенә килеп торган ашыгыч заказлар, гаилә мәшәкатьләре Әминәгә бер генә мәртәбә дә Татарстанга кайтырга мөмкинлек бирмәгән икән. Әнисе янына кайтып-китеп йөргәндә, Казан тимер юл станциясен генә күреп уза ул. Ерактан күреп, борынгы Кремль, Сөембикә манарасына соклана.

Чаллыга келәмен илтә барганда, Әминә командировкасын ике көнгә арттырып бируләрен сорый. «Кайтышлый Казанга керермен, Татарстан рәссамнары белән танышырмын» дип өметләнә.

Декабрь. Самолет Мәскәүдән туры Чаллыга оча. Рәссам да, Татарстанга багышланган беренче хезмәтен кочаклап, КамАЗга юл ала. Уйлары туган җиргә үзеннән алдарак барып җитә. Күңелне төрле шикләр куркыта. Нәкъ шундый ук культура сарае күп шәһәрләрдә салына бит. Әминәгә аларның кайберләрен бизәргә дә туры килгәләгән. Мцинск шәһәрендә күргәннәре әле дә хәтердә. Ул анда утыргычларга япма, сәхнә пәрдәсе ясаган булган. Мцинскига баргач, сарайны беренче тапкыр карап чыгарга уйлаган. Гомуми күренеш әйбәт кенә тәэсир калдырган. Ә бер бүлмәдә, «Макслa» рәссамнары ясаган затлы шкаф өстендә иске зур кәстрүлгә утыртылган фикус гөле күргәч, тетрәнеп киткән Әминә. Гөлгә чүмечләп су сибәләр, шкаф стенасы буйлап агып төшкән су идәнгә җыела, күл хасил итә икән.

— Бу бит бер дә килешми,— ди Әминә.— Матур да түгел, рәссамнарның хезмәтен дә юкка чыгаргансыз!..

Культура үзәкләренә якын урнашкан, үзенең традициясе булган Мцинскида да сәнгать әсәренә шундый мөнәсәбәт күргән Әминәнең Чаллыга якыная барган саен борчылуы арта бара. Хыялында йөрткән Татарстан белән беренче очрашуны, Чаллы халкы белән беренче танышлыгын рәссам хәзер шатланып искә ала.

— Гаҗәпләнеп карап тордым: культура сараена изге йортка кергән кебек аякларын юып яки бөтенләй икенче кием киеп керәләр. Идәнендә — мәрмәр. Ак мәрмәр, кара мәрмәр, соры мәрмәр... Латвиядә, Мәскәүдә, Ленинградта әллә нинди затлы сарайлар күреп сокланганым бар. Әмма җирнең асты-өскә килгән Чаллыда шул кадәр зиннәтле, шулай кадерләп саклanучы йорт күрермен дип башыма да китермәгән идем. Шикләнүләрем урынсыз булуын сизеп, җиңел сулап куйдым...

КамАЗ төзүчеләренең нинди темплар белән яшәвен Әминә Бигеш аэропортында ук сиземләп ала. Үзе дә шуларга охшарга тырыша, ашыгып эшли. Тик алдан корган планы барыбер барып чыкмый. Буран котыра. Казанны күрү өчен калдырылган ике көн вакыт, һава яхшырганны көтеп, аэропортта үтә.

Командировкадан кайткан Әминәне:

— А-а! Син бөтенләй үзгәреп, матурланып, яшәреп кайткансың, сәфәрләр котлы булсын! — дип каршылыйлар.

Рәссам да шаярта:

— Казанга кергән булсам, әле бөтенләй дә танымаган булыр идегез,— ди.— Буран гына комачаулады.

Дуслары Әминәнең Татарстан җиренә тирән мәхәббәт саклавын тоеп торалар. Бергә-бергә ял иткәндә, бәйрәм кичәләрендә, аңа аерым игътибар биреп:

— Яле, Әминә Мирдзовна, гел безнеңчә генә булмасын, татарлар турында сөйләшик әле! — диләр.— Берәр җырыгызны җырлап күрсәтегез әле, без дә кушылырбыз!

Кызганычка каршы, латыш җырларының башында, биюләренең үзәгендә торучы Әминә мондый чакта аптырабрак кала. Әнисенең кинәттән сагышланып китеп, сузып-сузып җырлый торган бер җырыннан башканы белми икән бит ул.

...Аккош атасым килә,
Аткач, аласым килә...

Бик яшьли карт кешегә кияүгә чыгып, Теләчесеннән аерылып, салкын Себер якларына килгәч, сагыну сагышына түзә алмыйча, Бәдерниса апа гел шул җырны суза торган булган. Кадерле дусларың алдында, матурлыгы белән дан тоткан Латвия җире, киң Балтик суы буенда мондый җырны Әминә ничек кабатлый алсын соң?

Тик дуслары аңа дәшми калырга ирек бирмиләр.

— Яхшылап әйткәнне тыңламасаң, мәҗбүр итәбез без сине!— ди берәү.— Син партоешма бюросында эшлисеңме, эшлисең! Безгә тирән эчтәлекле ял оештырырга тиешме син, тиеш! Сөйлә безгә татар халкы турында! Җырла безгә аның җырларын!

Бу шукның сүзен икенчеләре күтәреп ала.

— Дөрес әйтәсең: аны мәҗбүр итәргә кирәк! — диешәләр.

Әминәгә ризалашудан башка чара калмый.

— Ярый, ярый,— ди ул.— Мин сезгә татарларның бер мәзәген сөйлим, алайса. Тыңлагыз!

Бер карчык үзенең картына инәлә икән: «Карале, сиңайтәм, бар, чык әле, казлар кайтып килә, капканы ач, ашарларына бир!» Карты иренеп, кузгалырга да теләмичә, ята бирә икән. Шуннан соң карчык хәйләгә керешә. «Сиңайтәм, казлар артыннан ниндидер кызлар килеп бара, каршыла!» — ди. «Кызлар» сүзен ишеткән карт «кыһ-һым!» — дип тамагын кыра да, мич башыннан төшеп, ишегалдына чыгып китә, ди.

Тыңлап утыручылар көләргә тотына.

— Тагын берне сөйлә әле, Әминә,— диешәләр.— Бигрәк тапкыр икән сезнең якның карчыклары!

— Һай, уйнак икән картларыгыз!

Бер Әминә генә көлми. Мондый чакларда ул үзен гаепле кеше кебек хис итә. Күпме нәрсәгә өйрәнелгән! Җиде классны бетерер-бетермәс кызыннан эшкә урнашуны таләп итүче, гыйлем алуны кызларга кирәк һөнәр түгел дип танучы, динче ата йортыннан китеп, замана сынлы сәнгатенең остасы булып өлгергән ул. Әминә чаршауларын Украина шәһәрләренең культура сарайларына эләләр. Латвия балыкчылары ул тукыган келәмнәргә карап: «Гәрәбә ялтыраулары чагыла сыман!» — дип, ул тапкан төсләрне, ул сайлаган җепләрне мактыйлар.

Саулкрасте шәһәрендәге «Су анасы» ресторанына эленгән келәмне Әминә хәтта үзе дә яраткан. Бу әсәрне алар рәссам Фридрихсон белән икәү башкарганнар.

— Фридрихсон акварелист ул. Өч су анасы сурәте ясап китерде. Рәсем бик шартлы, абстракт төстә башкарылган иде. Эшләве гаҗәп кыен, әмма мавыктыргыч булды.— Әминә бу турыда бик рәхәтләнеп сөйли.— Диңгез ярында күзәтеп йөргәндә тапкан төсмерләрне эшкә җиктем. Келәм дә акварель белән ясалган кебек килеп чыкты. Туку өчен «төньяк» ысулын сайладым. Чаллыдагы «Лалә»не тукыган ысул...

«Чаллы», «Чаллыдагы» кебек сүзләрне Әминә үз хезмәтенең зурлыгын билгеләүче үлчәү берәмлеге итеп алган. Ул тырышып-тырышып Казан татарлары сәнгате тарихына караган китапларны укый. Татарстан рәссамнарының иҗатын өйрәнергә тырыша.

Үзе зарлана:

— Бу темага китаплар бик аз,— ди.— Әллә кайлардан эзләттем, юк, таба алмыйлар.

Теләкләренең иң тирәндә ятканын әйтми Әминә. Анысын кояшлы диңгез ярында йөргәндә, Балтик дулкыннарына озаклап карап торганда, йөзенә чыккан сагыштан гына абайларга була. Сүз арасында биргән сораулары да рәссамның күңел түрендәге теләген аңлата. Ул:

— Казанда яңа театр салына икән, пәрдәләрен кем тукыр? — дип сорап куя.— Урындыкларын кем тышлый?

Күргәзмәләр турында сүз кузгалса да, ул Татарстанны телгә ала.

— Казанда хатын-кыз рәссамнары өчен махсус күргәзмәләр оештырыла, диләр, дөресме шул? — ди. Безнең традицион Сигезенче март күргәзмәләребез турында сораша.

Артыгын әйтми. Тел очында: «Минем дә шул күргәзмәләргә катнашасым килә! Чакырыгыз әле! Җигегез әле иҗатымны эшкә!» — диган сүз торса да, эндәшми кала.

# ЯЗУЧЫ АБДУЛЛА ӘХМӘТКӘ 70 ЯШЬ



*Шушы елның мартында язучы Абдулла Әхмәткә 70 яшь тулды. Халык белән бергә, каләмдәшләренең бердәм сафында атлап, ул зур вакыйгалар аша үткән, күпне кичергән әдип. Коммунист язучының олы һәм бәхетле язмышы бу.*

*Абдулла Әхмәтнең әдәби иҗаты аның тормыш юлыннан аерылгысыз, хезмәт биографиясе исә — әсәрләренең нигезен тәшкил итә.*

*Туган ягы — Урал арты даласында аңа бала чактан ярлы крестьян тормыш-көнкүрешенең авырлыгын татырга туры килгән. Совет дәүләтенең яшь гражданины буларак беренче хезмәт адымнарын ул балалар йортында тәрбияче булып башлаган. Шуңа да әдип иҗатының да күпчелек һәм иң күркәм өлеше балалар әдәбияты белән бәйле.*

*Абдулла Әхмәт 20 нче елларда «Сабан һәм чүкеч» исемле җирле газетада каләм тибрәтә башлый. Аның яшьлек еллары Урал белән һәм андагы бишьеллык төзелешләре белән дә нык бәйләнә. Утызынчы еллар башында Свердловск шәһәрендә аның «Магнитка ударниклары» дигән беренче китабы дөнья күрә. Яшь әдипнең әдәби авазы шул чакта ук Мәскәүдән чыккан беренче хикәяләр җыентыгы аша да ишетелә.*

*Ә аннары, Казан педагогия институтын тәмамлап һәм әдәбият фронтының әзерлекле солдаты сыйфатында ныклап иҗат эшенә керешкәч, ул бер-бер артлы шул чорның кискен мәсьәләләрен күтәргән, беренче бишьеллык алдынгыларының хезмәт батырлыкларын зур рухлану белән җырлаган хикәя һәм очеркларын иҗат итте, театрлар өчен пьесалар язды. Әдипнең каләме елдан-ел үткенләнә барды, иҗади куәте үсте. 1939 елда Абдулла Әхмәт СССР Язучылар союзы члены итеп алынды.*

*Бөек Ватан сугышының башыннан ук — әдип фронтта. Авыр яраланып, госпитальдән чыкканнан соң да ул фронт газетасы корреспонденты булып, озын сугышчан юл үтә, хәрби хезмәтләре өчен хөкүмәтебезнең ордены һәм медальләре белән бүләкләнә. 1944 елда, фронтта чагында, Абдулла Әхмәт партиябез сафына керә.*

*Сугыштан соңгы чорда язучының иҗат активлыгы сизелерлек артты, халкыбызның хәрби батырлыгын, тыныч хезмәттәге каһарманлыгын сурәтләгән хикәя һәм очерк китаплары матбугатка чыкты, яңа пьесалары театрларыбыз сәхнәләрендә куелды. Татарстан нефте темасын, нефтьчеләребез образларын башлап әдәбиятка алып керүче язучыларның берсе Абдулла Әхмәт булды: Казан, Свердловск, Уфа театрлары сәхнәләрендә барган «Серләр» пьесасы драматургиябездә бу теманы күтәргән беренче әсәрләрдән иде.*

*Иҗатының буеннан-буена Абдулла Әхмәт балаларның ышанычлы дусты һәм киңәшчесе булып кала. Нәни гражданнарның психологиясен, хыял-омтылышларын нечкә сиземләп язылган күп санлы хикәяләре, балалар әдәбиятына багышланган мәкаләләре — язучының яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүгә багышланган мактаулы хезмәте.*

## Абдулла Әхмәт

# ЗӘҢГӘР КОНВЕРТ

ХИКӘЯ



Кинәт ишек ачылды. Землянкага сугышчыларга таныш, аларның һәр көн саен кетеп ала торган һәм һәркайсына бик якын булган кеше килеп керде. Бу — зифа буйлы, җитез хәрәкәтле, йөзеннән, сүзләреннән һәм үзен тотышыннан яшьлек аңкып торган көләч йөзле Таня дигән кыз иде. Таняның сөйләшкәндә ап-ак булып тигез тешләре күренә һәм ул елмая төшеп сөйләшә. Бу сөйкемле кыз белән аз гына булса да сөйләшеп калу солдатларга үзенә бер рәхәтлек бирә иде. Айлар буе юеш окопларда ятучы сугышчылар, Таняны күргәч, ничектер, үзгәреп китәләр. Яше булсын, карты булсын, кызга ничек тә ыспайрак күренергә тырыша, ул килеп керде исә, тиз генә төзәтенә, сыпырына башлый. Ротага бик аз гына вакытка килеп китә торган бу кызны һәркем күреп, ягымлы тавыш ишетеп калырга тели. Яшь сугышчылар исә, кыз белән сөйләшкәндә, ничектер көлкерәк, үткенрәк сүзләр әйтергә тырыша.

Бу кызны сугышчылар, якын һәм үз итеп, «безнең Танюша» дип йөртәләр. Танюша, гадәттәгечә, бүген дә пилоткасын кыңгыр салган, дулкынланып торган кыска, җитен кебек аксыл-сары чәчләрен иңбашына тигез генә салындырган. Ул кергәч тә честь биреп исәнләште һәм ягымлы, яңгыравык тавыш белән:

— Биергә, егетләр, биергә! — дип кычкырды.

Хат ташучы бу кызны урап алалар. Землянкадагы кешеләрнең барысы да еракгагы якын кешеләреннән хат көтә. Танюшаны куругә:

— Танюша, тизрәк бир миңа хатны!

— Зинһар, мин биергә әзер! — дигән тавышлар төрле яктан ишетелә башлады.

Ләкин Таня ашыкмады. Еракган, һәркайсыбыз сагынган һәм һәркайсыбызның да йөрәгенә бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт салган туган илдән, якын күргән кешеләрдән килгән хатларның кыйммәтен яхшы белә шул ул. Шуңа күрә дә кыз бу кадерле хатларны тантанасыз, «бушка» бирергә теләми иде.

Землянкада старшина Мәҗитов кына хат көтми иде. Ул кече яшьтән үк ятим калган. Уралдагы шәһәрләрнең берсендәге балалар йортында тәрбияләнеп үскән егет ул. Дүрт ел сугышта йөреп, старшина, ичмасам, дүрт кенә хат та ала алмады. Бервакыт аңа тылдагы кызлар белән хат алышырга була дигәннәр иде дә, ул анык адрес ала алмый калды. Баштарак аңа хатсыз бик авыр, бик күңелсез булды. Иптәшләренә килгән хатларны укып кына бераз юанды ул. Ләкин аның үзенең дә шундый җылы хисләр белән тулып килгән хат-

лар аласы килә иде. Иптәшләре куаныша-куаныша, белсә-белмәсә тыпырдап биеп хат алган бу минутта Мәҗитовка ничектер аеруча күңелсез булып китте. Әнә, нечкә, озын буйлы гармунчы, туктаусыз елмаеп, гармунын тарта, хат алучылар бииләр... Балалар кебек шатланып, бер читкәрәк китәләр дә ашыкмый гына укый башлыйлар. Ә Мәҗитов берүзе бер читтә утыра бирә.

— Укысыннар, соңыннан миңа да укытырлар әле,— дип юана ул.

Таня, Мәҗитовның кичерешләрен аңлаган кебек, аңа карап алды, кыз бу егетнең беркемә дә юклыгын яхшы белә. Атаклы разведчикның күңелен күтәрерлек, дәртен үстерерлек хат язучысы булмавын уйлап, ул аны күңеленнән кызганып та куйды. Яшь, сукса тимер өзәрлек таза, төскә-биткә дә теләсә нинди кызның күзе төшәрлек бу егетнең сабыр холыклы икәнлеген дә белә иде кыз.

Таня сумкасыннан бик матур зәңгәр конверт чыгарды.

— Бу — кызлар хаты! — диде ул, аерым бер тантана белән. Үзе дә сизмәстән, Мәҗитовка күз ташлады. Мәҗитов та аңа карап тора иде.

— Кемгә? — дип әйткәнен дә сизми калды Мәҗитов. Ни өчендер, бу хат аңадыр кебек иде.

— Кемгә ул хат? — дип кабатладылар күпләр.

— Кемгә булсын, мактаулы разведчикка! — диде Таня, конвертны баш очына күтәреп.

Разведчик егетләр зәңгәр конвертка текәлделәр. Таня конвертка язылган язуны кычкырып укыды. Анда болай диелгән иде: «Иң алдынгы разведчикка. Казан мех фабрикасының алдынгы эшчесе Наилә Ихсановадан».

Әле землянкада ике-өч кенә төн кунган разведчик Бикбулатов, «Наилә» дигән исемне ишеткәч, урыныннан ук сикереп торды. Ләкин һичберәүгә бер сүз әйтмәде.

Землянкага разведрота командиры капитан Кравченко килеп керде. Разведчиклар аны аягүрә басып каршы алдылар. Почта йөртүче кыз зәңгәр конвертны командирга сузды һәм үзе җитез адымнар белән чыгып та китте.

Капитан, конвертка язылган сүзләрне укыгач, бик азга гына уйга калды.

Кемгә бирергә соң бу хатны?

Командир разведчикларына күз төшереп алды. «Старшина Мәҗитов — кыю, үткен, тәҗрибәле разведчик. Өлкән сержант Малахов? Башкалар? Алар бит берсе дә тел-теш тидерерлек егетләр түгел».

Әнә шундый уйлар белән капитан конвертны кемгә бирергә белмичә кулында тотты. Конвертта ниндидер бер рәсем дә барлыгын сизде. Димәк, кыз анысын да җибәргән булса кирәк. Офицер, кулындагы зәңгәр конвертны селкә-селкә, разведчиклар янына килеп утырды.

— Бу хатны мин Мәҗитовка, я Малаховка, яисә башка берәр разведчикка гына биреп куяр идем дә, ләкин безнең арада яңа сугышчы да бар. Бәлки ул безнең барыбызга караганда да...

Командир сүзен әйтеп бетермәде. Разведчиклар яңа гына госпитальдән килгән сержант Бикбулатовка карап алдылар. Ләкин бу яңа разведчикның тышкы кыяфәте аларның күбесенә ошамады, һәм аның зәңгәр конвертны алырга кандидат буласын алар башларына да китермиләр иде. Бикбулатов — тәбәнәк, юка гәүдәле, аз сүзле булуы белән ул землянкадагы таза буйлы, үткен, шау-шулы егетләр янында ничектер югалып кала шикелле иде.

— Мәҗитовка булсын инде бу хат! — диделәр кайберәүләр.

Мәҗитов зәңгәр конвертны алырга үзе дә каршы булмаячак иде.

Капитан Кравченко исә башкачарак уйлады. Ул үзләренә командование тарафыннан мөһим, җаваплы бурыч куелуы турында сөйлә-

де. Алар шушы көннәрдә башланачак һөҗүм алдыннан дошманның «телен» тотып китерергә һәм аннан кирәкле мәгълүматлар алырга тиеш иделәр.

— Бу «тел» күпне белә торган «тел» булырга тиеш,— диде командир.

Зәңгәр конверт мәсьәләсе болай хәл кылынды: иртәгә булачак операциядә иң зур егетлек күрсәткән разведчикка бирергә булдылар аны.

Рота командиры бу җаваплы операциягә катнашу өчен кыюларның да кыюын, җитезләрнең дә җитезен генә сайлап исемлек төзеде дә землянкадан чыга башлады. Ләкин ул ишектән чыгарга өлгермәде:

— Иптәш капитан, рөхсәт итегез сезгә мөрәҗәгать итәргә,— дигән кыюсыз гына бер тавыш ишетелде.

— Я!

— Операциягә минем дә катнашасым килә! — диде Бикбулатов.

Капитан, кулын ишек тоткасыннан ычкындырмыйча гына, Бикбулатовка карап торды. Бу яңа егетне үзенең әле яхшылап белмәвен, аның белән әле төпле сөйләшә алмавын, аның йөреш-торышындагы сүлпәнлек, кыюсызлыкларын уйлап, командир ни әйтергә дә белмичә аптырабрак тора иде.

— Госпитальгә кадәр нинди частьта идегез әле сез?

— Разведкада, иптәш капитан.

— Операцияләрдә катнашканыгыз бармы?

— Күп мәртәбәләр, иптәш капитан.

«Ни эшләп соң бу егет бер тапкыр да бүләкләнмәгән икән?» дигән сорау килде капитанның башына. Ул Бикбулатовның үзенә киңрәк булып торган гимнастеркасына карады. Аның күкрәгендә «гвардия» значогыннан башка берни дә күренми иде. Командир үзенең каршысында төз басып торган кечкенә гәүдәле Бикбулатовны күңеленнән үзенең таза егетләре белән чагыштырып алды. Разведчик әнә, Мәҗитов кебек таза, үткен, кыю булырга тиеш. Ләкин шуның белән бергә, командир разведчикка болар гына җитмәвен дә яхшы аңлый. Шуның өчен дә ул Бикбулатовка тагын да текәлебрәк карады. Бу сугышчыдан ул әнә шул сыйфатларның берсен генә булса да табарга тырышты. Киң маңгай астындагы кечкенә, ләкин үткен кара күзләр, керфек тә какмыйча, ышанычлы караш белән капитанга текәлгәннәр. «Бу юлы сезгә землянкада калып торырга туры килер!» — дия генә күрмәсен дип пошынып торды Бикбулатов.

— Ярый, хәзерлән! — диде Кравченко аңа.

Землянка ишеге ябылуга, Бикбулатов үзенең юл капчыгын алырга ашыкты.

Фашист дигәннәрен бер сугуда аяктан егып аңын югалта ала торган авыр йодрыклы Мәҗитов Бикбулатовның барлык хәрәкәтләрен күзәтеп тора иде. Разведчик булгач, ул үзе кебек, яисә үзенең дусты Малахов кебек булсын иде, ә мондый чиртсәң егылырга торган кешедән нинди юньле разведчик чыксын соң, дип уйлады сыман ул.

Разведчиклар, гадәттәгечә, операциягә барыр алдыннан була торган хәзерлекне күрә башладылар: кайберәүләр сакал-мыекларын кыра, күпләр уйлана-уйлана хат язалар. Разведчикларның эше аеруча куркынычлы, катлаулы эш бит ул. Кем белә алда нәрсә көткәнен!.. Гармунчы, гадәттәгечә, аккордеонын чыгарды, ләкин аның башына:

— Кем белә, бәлки бу минем актык уйнавымдыр! — дигән уй килмәде. Алай да, һәр вакыттагы кебек, бу юлы да операциягә китәр алдыннан аеруча бирелеп, аерым бер моң белән уйнады ул. Бикбулатов каләмен язылып бетмәгән хаты өстенә куйды һәм гармунчы татарча уйный башлау белән, кычкырып, ләкин моңлы тавыш белән аңа ку-

шылды. Дөньяны әле күп күрмәгән, әле юньләп кайгы-хәсрәт, сагышны татымаган бу яшь егеткә кайдан килгән бу кадәр моң? Егет саф авылча сузып, гаҗәп бер тирән моң белән җырлый иде. Мәҗитов, кырынып бетмәс борын ук, кулындагы пәкесен куйды һәм Бикбулатовның җырын тыңлап тынды.

Туган илдән чыккан чакта
Күтәрелде томаннар.
Дөнья хәлен белеп булмый,
Сау булыгыз, туганнар!

Туган илебездән еракта-еракта, немец җирендә, татарча яңгыраган җырда бер моң гына түгел, аның өстенә монда ниндидер бер горурлык та бар иде...

*
* *

Төн. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Ләкин разведка кешеләренең моңа исләре китми. Бу караңгылык разведчикларга булышчы гына ул. Автоматларын аскан разведчиклар, барысы да бер эзгә генә басып, яфрак кыштырдавын да колактан ычкындырмаска тырышып, дошман ягына «ауга» баралар. Сапер егетләр алар килүгә дошманның миналанган һәм тимер чыбык киртәләре корылган оборона капкасын ачып куйганнар иде инде. Егетләрнең төрлесе төрле уй белән атлый. Мәҗитов күбрәк «тел» тоту турында уйлап барды. Зәңгәр конвертка ия булу уйлары да байтак вакытлар аның башында чуалды. Ә Бикбулатов исә, яңа частьта да сынатмаска кирәк, дип уйлады һәм зәңгәр конверт хуҗасы Наилә Ихсанованы исенә төшерде: «Исеме дә, фамилиясе дә туры килә. Минем беренче мәхәббәтем, онытылмас мәхәббәтем түгелме икән ул кыз?»

Старшина Мәҗитов төркеменә «тел»не кулга төшерү йөкләтелеп, башка группалар аларга ярдәм итәргә тиешләр иде.

Менә караңгы калкулык өстендә әрле-бирле йөреп торучы дошман часовоеның тоныкшәүләсе күренде. Мәҗитов төркемендәгеләр барысы да тиз генә җиргә ябышып яттылар. Фриц еш кына туктый һәм, нәрсәдер ишеткәндәй, тыңлана иде. Мондый вакытта Мәҗитов разведчиклары шуышмыйлар, сыланып яткан килеш күзәтүләрен генә беләләр. Мәҗитов үзе еш кына Бикбулатов ягына күз төшергәләп ала.

«Яңа кеше ул бездә»,— дип уйлый ул.

Кинәт немец часовое йөрүеннән туктады да безнең разведчиклар яткан якка карап кычкырды:

— Һальт!

Шул ук вакыт часовой автоматтан бер атып та алды. Аның пулялары разведчикларның баш өстеннән бер-бер артлы сызгырып үттеләр.

— Ничек күрде соң ул безне?! — дип уйлап куйды разведчиклар.

Мәҗитов үз янында сузылып яткан Бикбулатовның колагына пышылдады:

— Күрде, кабахәт! Нишләргә?

Ләкин Бикбулатов аңа җавап бирмәде. Ул өзлексез күзәтүен дәвам иттерә иде.

Бераздан соң часовой разведчиклар турысына килгәч, тагын берничә очередь бирде һәм немец телендә нидер мыгырданды.

— Сизде, ләгыйнь! — диде Мәҗитов, тагын Бикбулатовның колагына пышылдап.

Часовой читкәрәк киткән арада, Бикбулатов Мәҗитовка:

— Пычагым да сизмәде! — диде.

Бераздан соң инде Мәҗитов та часовойның хәйләсенә төшенде. Ул, бернәрсә сизмәсә дә, безнең разведчикларны күргән кебек, караңгыга ата һәм үзенә-үзе мыгырдана икән. Янәсе, безнең разведчиклар була калса, сизде дип белсеннәр дә кире китсеннәр! Бикбулатовның мондый хәйләне моңа кадәр абайлаганы бар.

Немец часовое читкә киткән саен, разведчиклар аңа таба якынрак елыштылар. Төркем башлыгы Мәҗитов, кинәт җир астыннан калкып чыккан төсле, урыныннан купты да бик тиз генә атылып немец часовоен аяктан екты. Разведчиклар аның кулларын бәйләп капчыкка салды һәм куаклыкка кереп югалдылар.

Ләкин бу «тел» кыйммәтле «тел» түгел икән. Бу — тоталь мобилизация буенча алынган карт бер бәндә булып чыкты.

— Инде ни кылабыз? — диде бер разведчик.

Мәҗитов аңа җавап биреп тормады. Аның башында башка уйлар йөри иде. Ул, үләксәгә карагач кичерелә торган бер җирәнү белән, карт фашистка карап уйга калды.

— Чишендерик әле шул мәлгуньне, — диде кинәт кенә, үзе шунда ук фрицның шинелен салдыра башлады. Разведчиклар башта старшинаның планын аңламасалар да, кушканны үтәп, немецның итеген, пилоткасын, башына ураган чүпрәкләрен салдыра башладылар.

— Кем немец часовое булырга тели? — диде Мәҗитов.

Мәҗитовның планын аңлаган Бикбулатов:

— Мин телим! — диде һәм старшинаның алдына килеп басты.

— Син? — диде аптырабрак старшина.

— Әйе. Бераз немецча да сукалый белəм. Рөхсәт итегез!

Нәкъ баягы җирдә, немец дзоты алдында, нәкъ баягы кебек үк әрле-бирле атлаган яңа «часовой» йөренә башлады. Аңа якында гына Мәҗитов разведчиклары яталар. «Часовой», йөрүеннән туктап, шулар ягына карап нәрсәдер мыгырдана һәм әледән-әле кыска-кыска очередьлар биргәләп куя.

— Я, егет тә икән бу Бикбулатов! Нинди кешене белмәгәнмен мин, — дип уйлап алды Мәҗитов.

— Һальт! — дигән тавыш ишетелде. Часовой үзенә таба килә башлаган кешегә автоматын төзәде. Теге кеше немецча нәрсәдер әйткәч, часовой үрә катты. Постлар тикшереп йөрүче немец офицеры, часовой янына килеп туктарга да өлгермәде, җиргә ауды. Башка разведчиклар килеп җиткәндә, Бикбулатов аның кулларын бәйли иде инде. Шуннан соң ул үзенең бер бияләен офицерның авызына тыгып куйды:

— Мә, суыр, тик тыныңны гына чыгарма!..

Разведчиклар, «тел»не яшен тизлеге белән күтәреп алып, куе караңгылык эченә кереп югалдылар.

*

* *

Землянкага капитан Кравченко килеп керде дә, түргә уза-уза, кесәсенә тыгылды һәм Казаннан килгән теге зәңгәр конвертны тартып чыгарды.

— Иң алдынгы разведчикка! — диде ул, разведчикларга күз төшереп. — Казаннан, мехкомбинат эшчесе Наилә Ихсановадан, бик матур кыздан, — дип өстәп куйды.

Бикбулатов үзе дә сизмәстән: «Наиләдән!» — дип кычкырып куйды. Аның күз алдына сугыш башланыр алдыннан матур инеш буенда йөргән Наилә килеп басты. «Чыннан да, шул Наилә микән? Алай дисәң, Наилә авылда иде»,— дип уйлап алды. Ә һәркемнең башында: «Кемгә була инде бу хат?» дигән сорау йөри...

Кравченко кичәге уңышлы операциягә катнашкан разведчикларның барысының да бүләккә куелуларын белдерде.

— Старшина Мәҗитовның күкрәгендә өченче орден балкыячак, Бикбулатовның да беренче ордены була,— диде ул.

Бер сугышчы:

— Иптәш капитан, Бикбулатовның да өченче ордены була торгандыр, аның ике ордены бар бит инде, — диде.

Разведчиклар Бикбулатовка таба борылдылар. Алар аның моңа кадәр үзенең ике орден белән бүләкләнүе турында берсүз дә әйтмәвенә, хәтта аларны тагып та йөрмәвенә аптырадылар. Командирның:

— Сержант Бикбулатов, нишләп соң сез хөкүмәт бүләкләрен тагып йөрмисез? — дигән соравына Бикбулатов беркадәр тартыныбрак һәм гафу үтенгән тавыш белән җавап бирде:

— Әллә тагын, мин бит әле сезнең подразделениедә дүртенче көн генә, уңайсызландым...

Разведка командиры, бу егет белән аерым сөйләшәсе бар икән, дип уйлап алды да сүзен дәвам иттерде:

— Үзегез беләсез, кичәге операциягә старшина Мәҗитов оста җитәкчелек итте. Иң кирәкле бер вакытта әһәмиятле «тел» әләктерүне тәэмин итте. Ә өлкән сержант Малахов исә, безнең разведчикларны куа килгән дошманны туктатып торып, «тел»не үзебезнең якка алып кайтуга зур ярдәм итте. Ә Бикбулатов, — диде командир, Бикбулатов сүзенә басым ясап, — ул гаҗәеп егет булып чыкты. Аның кыюлыгы, хәйләсе нигездә бөтен уңышны хәл итте. Менә асыл егетләрнең дә асылы өч егет. Шуларның кайсына бирәбез бу зәңгәр конвертны?

Землянка эче тынды. Разведчиклар, үзләренә сиздермәскә тырышып, әле Мәҗитовка, әле Малаховка, әле Бикбулатовка карап алдылар.

— Мәҗитовка булсынмы әллә бу хат? — диде командир, кулындагы зәңгәр конвертны әйләндергәләп.

Мәҗитов конверттан күзен ала алмады. «Эх, әгәр дә миңа бирелсә ул, мин ачсам иде аны, хатның җылы сүзләрен мин укысам, кызның рәсемен иң элек мин карасам, нинди бәхетле булыр идем! Мин дә хат язу һәм хат алу бәхетенә ирешер идем», — дип уйлады ул. Ләкин теләндә икенче сүзләр яңгырады:

— Зәңгәр конвертның миңа булуына мин каршы, чөнки кичәге операциядә миннән уздырган осталар булды,— диде Мәҗитов кинәт кенә, — хат Бикбулатовка бирелергә тиеш!

Мәҗитов Бикбулатовның операция вакытындагы кыюлыгы, хәйләсе турында капитанга тагын да тулырак итеп сөйләп бирде һәм зәңгәр конверт... әлбәттә, Бикбулатовка бирелде. Егетләр конвертны әйләндереп кай җиреннән ачарга аптырап торучы Бикбулатовны сырып алдылар. Бикбулатов, нечкә бармакларына кыстырып, конверт эченнән кыска гына язылган хатны тартып чыгарды. Ләкин ул аны укып тормады, ашыга-ашыга кулына рәсемне алды һәм үз-үзен белешмичә:

— Наилә, минем Наиләм ич бу! — дип кычкырып җибәрде. Аптыраган разведчиклар рәсемне кулдан-кулга йөртеп карый башладылар. Озын чәч толымнарын икегә үреп күкрәкләренә төшергән кыз разведчикларга елмаеп карады.

Бикбулатов тирән итеп бер сулап куйды һәм шатлыкны да, үпкәләүне дә аңлаткан тавыш белән:

— Әй, егетләр, җитте, җитте инде, үзем карыйм, китерегез Наиләмне минем! — дип, тиз генә рәсемне алып күкрәгенә кысты...

АЙАСТАННАН — ӘРМӘН ИЛЕННӘН

## Рафаэль Патканян

1830—1892

### Тургай

«Ник син, тургай, күккә менеп аласың да,
Көмеш тавыш чыңлый болыт арасында?

Ник син җирдә гөлле урын сайламыйсың?
Балаларың белән бергә сайрамыйсың?»

«Әх, муеннан чумдым шул мин кайгы-моңга...
Дустым китте, мин аерылып калдым монда.

Ул сабанчы иде, тырыш кеше иде,
Иген игү аның сөйгән эше иде.

Килде дошман, басып алды бу җирләрне,
Куды аңа буйсынмаган күп ирләрне.

Белмим, дустым хәзер кайда каңгырадыр,
Баскыннарга кайдан каргыш яудырадыр?

Әрмән җире кинәт бушап, тынып калды,
Шуны күреп хәтта күзләр тоныкланды.

Юкка түгел болытларга омтылуым —
Бу бит минем зур бәладән котылуым.

Еракларга качып яшим күпләрдән мин,
Көне-төне сорыйм биек күкләрдән мин:

Дустымны, дим, туган кырда күрсәм иде,
Матур сайрап тизрәк сәлам бирсәм иде!

Таламасын, дим, кешеләр берсе-берсен...
Тавышымның моңсулыгын шуннан бел син».

## Сурен Вагуни

### Солдат итеге турында җыр

Таушалган итекле бер солдат фронттан
Кайтты да кич кунды бер җылы куенда.
Таптаган ул итек чик буе юлларын,
Пычрагы юылган киң Идел суында.

Аяусыз һөҗүмгә кергәндә шул солдат
Аякта шул булган — шул итек, күн итек.
Тик шуны киеп ул атлаган, шуышкан
Көннәрне төн санап, төннәрне көн итеп.

Шул итек топ-тобын бик күп як ишетте —
һәм Ржев, һәм Мәскәү... Сталинград тыңлады.
Ул анда әйтерсең илбасар өере
Дөмеккән минутта чаң булып чыңлады.

Бакчалар һәр язда шау чәчәк атсынга,
Басулар уңышны бирсенгә мул итеп, —
Сугышта ватылган-җимерелгән шәһәрләр
Тузанын һәм көлен таптады шул итек...

## Ашот Граши

1911—1973

### Төнге баллада

Мин төш күрдем: төнлә ишегемне
Яуда үлгән дуслар кактылар.
Менә алар минем тын бүлмәдә.
Сагынып эзләгәннәр. Таптылар.

Блиндажмыни — бар да иелеп керде,
Мылтыкларын кысып күкрәккә.
«Менә, — диләр, — хәзер безнең җиңү
Дөнья күген ничек күкрәтә!»

Сүз арты сүз: бергә кичкән утлар,
Без гөрләткән туплар турында.
«Шигырь!» диләр. Укыйм: «...үлде алар...»
Бүлдерәләр нәкъ шул урында.

«Юк, җырлама үлем хакында, дус!
Кара гүрдә күптән черсәк тә, —
Безнең учтан үсеп чыга үлән
Язгы-җәйге матур бер чакта.

Син яшәүне макта! Ул бит — имән,
Яфрак ярып тиеш шауларга.
Яфрак идек без дә, ләкин көйдек
Яшел язны яклап яуларда».

Шулай диде дуслар-походташлар —
Дөресен әйтеп, турыдан ярдылар.
Катырак кысып телсез мылтыкларын,
Таң атканда китеп бардылар...

## Геворг Эмин

### Алар күпләр

Елмаепмы, җитди аңларсызмы?!.
Телим күптән, телим бүген дә:
Судка биреп хөкем итәргә мин
Гестаполар ишеге төбендә
Үскән гөлне — чөнки ләззәтләнеп
Палач күзе аңа караган.
Телим тагын судка бирергә мин
Дошман йөргән ярны ялаган
Һәр дулкынны — чөнки ул елгага
Партизанны дошман батырган.
Һәм аннары судка бирәсе бар
Дошман йөргән төндә яктырган
Тулган айны — чөнки шул яктыда
Илбасарлар корбан сайлаган.
Һич калмаска тиеш судтан читтә
Освенцимда өзелеп сайраган
Сандугач та — чөнки шул минутта
Күпме кеше утта янган бит.
Ә аннары кәгазь. «Миңа моны
Ник басасыз? Бу сүз ялган!» дип
Әйтәлмәгән битараф ак кәгазь
Суд каршына тиеш басарга —
Ерткычлыкка юл сыздырган өчен,
Кул куйдырган өчен асарга...
Күпләр алар, күпләр — саный калсаң,
Сорый калсаң катгый җавапны.
Ерткычлыктан җир әрнегән өчен
Бик күп нәрсә җирдә җаваплы.

## Сильва Капутикян

●

Син мине озата барганда әемә,
Без бергә атлаган тузанлы юл хәтта
Күренә күземә язгы киң болындай —
Әйтерсең чәчәкле, әйтерсең ул хәтфә.

Озын бит, озын бит, җир шары, юлларың,
Аларның чиксез күп икәнен беләбез.
Нигә соң, нигә соң минем өй бик якын,
Иң кыска юл буйлап атлыйбыз менә без?

●

Йөрәгемнән һич тә зарланмыйм мин:
Авыртсын һәм күбрәк әрнеп типсен!
Сыкраулары дуслар өчен булсын,
Дус шатлыгын үз шатлыгы итсен.

Йөрәгемә бөтен дөньяны мин
Сыйдырыр өчен янып-көеп яшим!
Эшлим бары йөрәк кушкан эшне,
Тик йөрәктән үлим, диеп, яшим.

## Арташес Погосян

### Реквием

Үтерделәр мине таң атканда...
Нурлардан һәм таудан ычкынып,
Кинәт аудым мин караңгы төнгә,
Үлмәс тавыш белән кычкырып.

Ник аттылар минем алсу таңны?
Әнкәм сузган бишек җырыдай
Тын булганы өчен мәллә? Үлем
Ник ябырылды шашкан бүредәй?

Озак аудым. «Чү, чү, егылма!» дип
Тотты мине ипләп-җайлап җир.
Басмак булды ярам әрнүләрен
Шәфәкъ бинты белән бәйләп җир.

Яшен сыгып хәтта таш-тауларның,
Күктән сузып болыт толымын,
Теләде җир илдән аерылмавын,
Җан бирмәвен газиз улының.

Һәм мин яшим — ләйсән булып явам,
Җилләр булып сыйпыйм үләнне.
Яшәү матур! Сугышлар, дим, көчсез,
Үләмме соң, дуслар, үләмме!

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәләре.

Гали Халит

# ИҖАТ МЕТОДЫ ҺӘМ СТИЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**БЕРЕНЧЕ МӘКАЛӘ**

## 1

Иҗат методы һәм стиль кебек төшенчәләр тирәсендәге фикерләрнең бик төрле, катлаулы, хәтта каршылыклы икәнлеген башта ук искәртеп куярга кирәк. Бигрәк тә стиль — әдәбият белемендә иң тотрыксыз һәм шактый таркау төшенчәләрнең берсе. Аның чиген конкрет билгеләү бу көнгәчә бәхәсле хәлдә тора әле.

Иҗат методы белән әдәби стиль арасындагы мөнәсәбәтләрне, бәйләнешне һәм аерманы өйрәнү озак вакытлар көн тәртибенә куелмады диярлек. Сүз башлыча стиль турында барды, һәм стиль хәтта метод төшенчәсен дә үз эченә алган шикелле рәк каралды. Тик 30 нчы еллар башында гына, бигрәк тә социалистик реализм мәсьәләләренә игътибар көчәеп киткәч, совет әдәбият белемендә метод белән стиль арасындагы якынлык һәм аерманы билгеләү тирәсендә дә фикерләр кузгалды. Аннан соң кыза барган бәхәсләр иҗат методы һәм стиль мәсьәләләренә күп ачыклык кертте. Бигрәк тә иҗат методлары тарихын, аларның үзара бәйләнешен, типологиясен һәм үзенчәлеген өйрәнү юлында кызыклы адымнар ясалды. Шул юнәлештәге билгеләмәләрнең әчтәлеген җыебрак күз алдына китергәндә, берничә моментны күрсәтеп булыр иде: беренчедән, иҗат методы — ул чынбарлыкны, кешене сәнгатьле аңлап-белү һәм сурәтләрдә чагылдыруның төп принциплар бердәмлеге; икенчедән, бу бердәмлек тарихи шартларда барлыкка килә һәм язучыларның иҗат практикасында байый, җитлегә; өченчедән, иҗат методы төшенчәсендә идеялелек һәм сәнгатьлелек бер-берсеннән аерылгысыз. Менә шул өч моментны бер бөтен итеп караганда гына иҗат методының әчтәлеген тулы итеп күз алдына бастырырга мөмкин. Әдәбият белгечләре аеруча Б. Сучков билгеләмәсенә игътибар итәләр. Ул түбәндәгедән гыйбарәт: **«Метод — ул идея-художестволы танып-белүнең һәм тормышны сурәтле итеп гәүдәләндерүнең тарихи формалашкан һәм иҗат практикасында байый барган төп принциплар җыелмасы»** [1]. А. Овчаренко, тагын да кыскарак итеп, метод «дөньяны аңлауның һәм аны кабат иҗат итүнең идея-художестволы принциплар җыелмасы» [2], дип билгели.

[1] Б. Сучков. Исторические судьбы реализма, Рус телендә. 1973 ел. 339 бит.

[2] А. Овчаренко. Социалистический реализм и современный литературный процесс. Рус телендә, 1968 ел. 182 бит.

Байтак вакытлар иҗат методын язучының дөньяга карашы, идея позициясе белән генә чикләү сизелеп килде. Метод идея принциплары системасы итеп кенә каралды. Аның эстетик категория, сәнгать төшенчәсе булуы игътибарга алынып җитмәде.

Методны сәнгатьле чаралар һәм алымнар системасы итеп карарга, ягъни аңа стиль сыйфатларын йөкләргә тырышу да бар. Мондый караш метод белән стильне бер төшенчә итүгә алып бара. Метод белән стиль икесе ике нәрсә итеп карала башлагач та һәм алар арасындагы аерма билгеле күләмдә ачыклык алгач та, аларның эчтәлеген һәм функциясен аңлауда төрле якка ташлану бетмәде әле. Берәүләр методны тар, ә стильне киң итеп, икенчеләр исә стильне тар, ә методны киң итеп аңлыйлар. Мондый фактлар метод белән стиль арасындагы чикләрне катгый, төгәл итеп сызып кую бик үк җиңел булмавы, аларның үзара бәйләнеше нык, тирән булуы хакында сөйләсә кирәк. Шулай ук алар арасындагы чикләрне кискен төгәллек белән билгеләргә омтылуның да берьяклырак булганлыгы күренә. Әмма хәзер инде күпчелек очракларда иҗат методы язучының гомумән дөньяга карашы белән генә түгел, ә аның дөньяны художестволы аң итеп сурәтләү принциплары бердәмлеге белән билгеләнә. Бу караш, һичшиксез, бөтен әдәбият тарихында булып үткән иҗат методларының төп билгеләрен гомумиләштерү тәҗрибәсеннән үсеп чыккан фәнни-объектив эчтәлеккә ия дип әйтергә мөмкин. «Шулай итеп, иҗат методы — ул дөньяны художестволы үзләштерү процессын идарә итә торган принциплар системасыннан гыйбарәт. Ләкин бу принциплар, аерым алганда гына, эстетик **реальлек** булып тормыйлар әле. Тик теге я бу иҗат методы белән тудырылган художестволы иҗат җимешләре генә чын реальлеккә ия булалар» [1].

Мәгълүм ки, метод — кеше эшчәнлегенең төп юнәлешен билгели торган категория. Нинди генә эшчәнлек өлкәсендә булмасын, метод — закончалыклы объектив принципларның бөтенлеге, бердәмлеге, җыелмасы ул. Художникның чынбарлыкка мөнәсәбәте идея-эстетик принциплар аша чагыла. Совет әдәбиятының иҗат методы — социалистик реализм дибез икән, бу очракта дөньяга марксистик-ленинчыл караш белән коралланган язучының чынбарлыкны сәнгатьле итеп чагылдыру юнәлешен билгеләгән принциплар бердәмлеген күз алдына китерәбез. Бу принциплар СССР Язучылар союзы уставында түбәндәгечә күрсәтелде: «Партиялелек һәм халыкчанлык принципларына таяна һәм язучылардан чынбарлыкны революцион үсешендә дөрес, тарихи конкрет сурәтләүне таләп итә торган социалистик реализм совет әдәбиятының сыналган иҗат методы булды һәм булачак» [1].

Күрсәтелгән принциплар җыелмасы һәм бердәмлеге социалистик реализм методының эчтәлеген, төп юнәлешен билгели, совет язучысы башкарган иҗат эшенең гомуми нигезен тәшкил итә, әмма һич тә аның реаль нәтиҗәсе түгел әле. Аның нәтиҗәсе сәнгать әсәре үзе генә булырга мөмкин. Димәк, метод принципларының реаль гәүдәләнеше тик сәнгатьле чара һәм алымнар аша гына барлыкка килә. Менә шунда инде иҗат методының реаль төскә керүен, сәнгать әсәре булып әверелүен тәэмин иткән эстетик күренеш — стиль мәйданга чыга. «Манераның капма-каршысы буларак, чын методның нәтиҗәсе стиль дип атала. Аерым индивидуумны стиль иң югары ноктага күтәрә...» [2] — дигән Гёте. Язучы стильдән башлана, дигән Чехов. Һәм моның белән ул һәр язучының үзенчәлекле әдәби тавышы булырга тиешлеген белдергән. Шулай итеп, методның реаль нәтиҗәсе һәм гәүдәләнеше тик стиль аша гына, стиль формасында гына була ала икән.

Әгәр дә иҗат методы тормышны сурәтләрдә чагылдыруның төп принципларын, төп сызыкларын билгеләсә, стиль инде шул принцип һәм сызыкларны сәнгатьле сурәтләүнең, реальләштерүнең бөтен бер системасы булып тора. Димәк, стильгә мөнәсәбәттә караганда, методның шактый гомуми һәм абстракт төшенчә булуы аңлашыла. Шуңа күрә дә кайбер белгечләрнең методны стильдән башка күз алдына

---

[1] М. С. Қаган. Лекции по марксистско-ленинской эстетике. Ленинград университеты нәшрияты. 1971 ел. 722 бит.

[1] Четвертый съезд писателей СССР, Стенографический отчет. 1968 ел. 253 бит.

[2] Вольфганг Гете. Статьи и мысли об искусстве. Рус телендә. 1936 ел, 146—147 битләр.

бастыру кыен дип караулары һич тә гаҗәп түгел. «Иҗат методы,— ди В. Д. Сквозников,— тормышка ашырылганга кадәр котылгысыз хәлдә коры абстракциядә генә яши, ә инде тормышка ашырылгач та, аны әле ниндидер бер әйбер итеп сиземләве кыен. Аны сүзләрдән дә тотып алып, эләктереп булмый шикелле. Ул бөтен җиргә таралган, әрегән — һәм күренеп торган бер генә урында да юк. Без аны стильдән табабыз...»[1]. Шулай булгач, стильне иҗат методының формасы һәм индивидуаль гәүдәләнеше дип санау дөресме? Минә шушы урында метод белән стильнең үзара мөнәсәбәтен һәм аларның аермасын аңлаудагы фикер төрлелекләре үзләрен нык кына сиздерәләр дә инде.

Безнең әдәбият белемендә метод һәм стиль төшенчәләрен, аларның мөнәсәбәтен һәм аермасын билгеләгән карашлардан шактый киң таралганы — Л. И. Тимофеев карашы. Аның фикеренчә: «Стиль — ул методның индивидуаль чагылышы. Метод үзе генә иҗат эшенең индивидуаль үзенчәлекләрен түгел, ә аның тик юнәлешен генә билгели»[2]. Болай караганда, мәсьәләнең куелышы бик туры һәм аңлатылышы ачык булып күренә шикелле. Метод — әдәби иҗат эшенең бер төркем язучыларга уртак идея-художество принципларын, закончалыгын, ә стиль иҗат методының һәр язучыда күренгән индивидуаль якларын гәүдәләндерә. Мәсьәләне болай аңлатканда, һичшиксез, бу ике эстетик категориянең эчтәлеге дә, функциясе дә шактый ачылып китә һәм эчтәлек белән форма мөнәсәбәте кебек бернәрсә булып аңлашыла. Ләкин икенче белгечләр метод белән стиль арасындагы аерма һәм мөнәсәбәтне болай билгеләүдә артык гадиләштерү һәм схематизм күрәләр.

Әйе, әдәбият белемендә һәм тәнкыйть практикасында иҗат методын киң, гомуми төшенчә итеп, ә стильне индивидуаль күренеш итеп кенә аңларга теләү нык сизелә. Әмма болай аңлату гына мәсьәләне хәл итми әле. Бер үк чорда иҗат иткән язучыларда күп уртак яклар булырга мөмкин. Ләкин болар метод уртаклыгына гына кереп бетми. Жанрлар, шигырь үлчәме һәм строфалар уртаклыгын гына искә алыйк. Болар һич тә методка карамыйлар. Эчтәлектәге һәм методтагы уртаклык, бердәмлек форма һәм стильдәге уртаклык, бердәмлектән башка була алмый дигән фикер яши. Моны хак санасак, метод кына түгел, стиль дә үзенең уртак, гомуми сыйфатларын ачар. Бу моментны алмаганда, эстетик категория буларак, стиль үзенең ролен югалта һәм методның тик индивидуаль формасы гына булып кала, дигән шикләнүләр дә бар. Ихтимал, алар да бик үк урынсыз түгелдер. «Методның индивидуаль формасы,— ди А. Соколов,— метод булып кала, ә стиль була алмый»[3]. Чынлыкта исә стиль сәнгать әсәрен сәнгать әсәре иткән художестволы элементлар, чаралар һәм алымнар бердәмлеге, системасы булып, ягъни иҗат методының һәм, аерым алганда, сәнгать әсәренең **эчтәлекле формасы** булып тора диләр. «Стиль — ул эчтәлекнең формага әйләнү закончалыгы»[4],— ди В. Днепров. Стиль художестволы форманың барлык элементлары бәйләнешеннән, синтезыннан башка була алмый. Ул язучының дөньяга карашыннан, иҗат методыннан һәм әдәби әсәрнең эчтәлегеннән азыкланып формалаша. Шуңа күрә ул методның үзен генә түгел, ә тулаем художестволы, сәнгатьле эчтәлекне чагылдыра. Шул яктан ул үзенең эчтәлек мәгънәсе белән методтан шактый киң булып аңлашылырга тиеш.

Стиль эчтәлек белән форманың органик бәйләнеше һәм гармониясе җирлегендә генә үзенең камиллеген, бөтенлеген күрсәтә. Чөнки стиль — әдәби әсәр эчтәлегенең һәм формасының бер-берсеннән аерылмас төстә җитлеккән булу нәтиҗәсе. Сәнгать әсәре шул ноктага җитмәгән булса, аның стиле дә художестволы гармонияне, югарылыкны, сәнгатьчә матурлыкны чагылдыра алмый. Димәк, стильнең асыл мәгънәсе — язучы эстетик идеалының һәм иҗат методының сәнгатьчә эчтәлек һәм форма алуына реаль төс биргән, аларны әдәби әсәр иткән сурәтләр системасының, сурәтләү принципларының бөтен-

[1] «Страницы истории русской литературы» дигән җыентык, 1971 ел. 107 бит.

[2] Л. И. Тимофеев. Советская литература, Метод, стиль, поэтика. 1964 ел. 63 бит.

[3] А. Н. Соколов, Теория стиля, Рус телендә, 1968 ел, 162 бит.

[4] В. Днепров, Проблемы реализма, 1960 ел, 313 бит.

легендә икән. Менә шул сыйфаты өчен стиль эчтәлекле форма дип аталырга хаклы.

## 2

Стиль — әдәби алымнар системасы гына түгел, ә художникның сәнгатьле фикерләү үзенчәлеге. Моны инде дөньяга караштан, идея позициясеннән, эстетик идеалдан һәм әдәби әсәрнең конкрет эчтәлегеннән башка күз алдына китереп булмый. Әдәби әсәрнең барлык поэтик чаралары — тел, композиция, сюжет, метрик төзелеш, рифма һ. б. — һәммәсе әдәби әсәрнең эчтәлеген, идеясен ачуга юнәлтелгән эчке бердәмлек, бөтенлек тәшкил итәләр.

Стильнең дөньяга караш, идея белән бәйләнешен яссы һәм туры гына аңларга кирәкми. Стиль тел ярдәмендә барлыкка китерелә торган художестволы чараларның бөтен бер системасын эченә алу белән үк инде язучының идея позициясеннән, әдәби әсәр эчтәлегеннән аерылгысыз икәнлеген күрсәтә. Чөнки ул чараларның системасы һичбер вакытта да форманың үзе өчен генә түгел, ә шул формадагы нинди дер идеяне, эчтәлекне күрсәтү өчен тудырыла. Димәк, стиль методның эчтәлеген формалаштыру, сәнгатьчә бөтенлеккә китерү бурычын үти. Һәм шушында инде стильнең методтан, идеядән, дөньяга караштан башка була алмавы, бигрәк тә эстетик идеал белән тыгыз мөнәсәбәттә булуы күренә. Эстетик идеал исә художникның чынбарлыкка сәнгатьчә мөнәсәбәтендәге, карашындагы төп юнәлешне, аның үзәген билгели. «Эстетик идеал категориясе... Һәр вакыт художник теле белән «сөйли»[1]. Шуңа күрә эстетик идеал, иң актив, хәрәкәтчән категория булып, метод һәм стиль үзенчәлекләренә дә юнәлеш бирә. Язучы иҗатындагы метод һәм стиль үзгәрешләрен эстетик идеал хәрәкәтеннән башка аңлау кыен. Мәсәлән, Пушкинның бер үк вакытларда реалистик «Евгений Онегин» романы белән бергә романтик поэмалар язуын, Лермонтовның «Безнең заман герое» кебек психологик роман белән бергә «Мцыри», «Демон» шикелле романтик поэмалар иҗат итүен эстетик идеалның төрле яклары, төрле пафослы стильләре чагылышы итеп карарга кирәк. Шул рәвешчә, эстетик идеалның үзгәреше бер очракта аны романтик метод һәм стиль белән, ә икенчесендә реалистик метод һәм стиль белән тормышка ашыруны таләп иткән[1]. Моның башка төрле мисалларын хәзерге язучылар иҗатында да күпләп таба алырбыз.

Социалистик идеология белән сугарылган совет язучысының эстетик идеалы, чынбарлыкны эстетик аңлавы туктаусыз хәрәкәттә, үсештә, үзгәрештә. Шуңа күрә, гомумән совет әдәбиятында гына түгел, ә аерым совет язучысы иҗатында да реалистик һәм романтик стильләрнең күп төрле төсмерләре, бәйләнешләре урын ала. Мәсәлән, А. Фадеевның «Яшь гвардия» романы — социалистик реализмга хас романтик әсәр. Ул совет әдәбиятындагы тормышчанлыкның төп революцион рухын, пафосын чагылдыра. Аның бөтен эчтәлеге реаль чынбарлыктан үсеп чыккан. Әмма андагы вакыйгалар һәм характерлар эстетик идеалның романтик пафосы белән сугарылып сурәтләнгән. Чөнки әсәрнең эчтәлеге, тормыш материалының үзенчәлеге шуны таләп иткән. Бу очракта язучының эстетик идеалы шул эчтәлекне, үзенчәлекне сәнгатьле чагылдыруда романтик аспектны, карашны үзенә якын, тапкыр итеп санаган. Шуңа күрә аның стилендә дә романтик чаралар, алымнар мул кулланылган.

Конкрет алганда, стиль компонентларына, аны тудыручы элементлар составына нәрсәләр керә соң? Әдәби стильгә килгәндә, тел һәм сөйләм материалы беренчел, төп җирлек булып тора. Әнә шул җирлектә күп төрле сәнгатьле чаралар, алымнар барлыкка килә. Болардан башка тагын стиль составына идея, сюжет, композиция, характердан башлап жанр, интонация, тон, ритм шикелле элементларны кертәләр. Күренә ки, бу чара, алым һәм элементлар тел, сөйләм кысаларыннан күпкә киң булып, әдәби әсәрнең тулаем сәнгатьле

---

[1] «Эстетический идеал и проблема художественного многообразия» дигән җыентык, 1968 ел, 44 бит.

[1] Бер үк язучы иҗатында реализм белән романтизмның мондый мөнәсәбәтләрдә булуын дөньяны аңлауның бердәмлеге җирлегендә тормыш күренешләрен художестволы гомумиләштерүнең төрле формалары мәйданга чыгу дип билгеләү дә бар («Великая Октябрьская социалистическая революция и мировая литература» дигән җыентык, 1970 ел, 129—130 битләр).

әчтәлегенә һәм формасына карыйлар. Жанр һәм стильнең берниндн алымы да, аерым алганда, художестволы форма була алмый әле. Ул алымнар тик художестволы бина төзү өчен кирәкле материаллар булып кына торалар. Алар бер бөтенлек алып, тулы художестволы бина хәленә кергәч кенә, бу бинаның стиле турында сөйләргә мөмкин. Әйткәнебезчә, стиль составында тел чараларының, сөйләмнең роле хәтта хәлиткеч булса да, әмма стильне алар белән генә чикләп карауның тулы булмавы аңлашыла. Шуңа күрә дә күп белгечләр стильне поэтикадан аерып, стилистикага гына кайтарып калдыруның мәсьәләгә берьяклы килү икәнлеген күрсәтәләр һәм тәнкыйть итәләр.

«Үле җаннар»ның теленә һәм стиленә бәйләнгән тәнкыйтьчеләргә җавап биреп, Белинский болай ди: «...булдыксыз маляр-академик ясаган рәсемнең үле, механик дөреслеге белән даһи рәссамның оригиналь стиле арасындагы аерма ничек булса, **тел** белән **стиль** арасындагы аерма да шул кадәр үк чамасыз». Стильне телгә генә бәйләп карау, ахыр чиктә, формализмга да китерә. Хәзерге структуралистлар теориясендә дә стильгә мөнәсәбәттә шундый тенденциянең сизелүенә игътибар итүләр нигезсез булмаса кирәк.

Тел, мәгълүм ки, стильне формалаштыру материалы гына әле. Бу моментны искә алмаганда, ягъни стильне идеядән аерып яки телгә генә кайтарып калдырганда, мәсьәләгә формалистик карау белән дә килешергә туры килер иде.

Метод төшенчәсе кергәннән соң, стиль функциясен тарайтып аңлау көчәйде. Стильне сәнгатьнең сүз тукымасы, тел материалы итеп карау нык сизелде. Академик В. В. Виноградовның лингвистик стилистикага багышланган талантлы хезмәтләре моңа зур этәргеч бирде. Стильне сәнгатьле тел, сәнгатьле сөйләм төшенчәсе итеп билгеләү аның концепцияләрендә нык урын алды. Бу инде стильгә сүз белән сурәтләү чаралары системасы итеп караудан гыйбарәт. Виноградов концепцияләрен тәнкыйть итүчеләрнең фикерләреннән күренгәнчә, аның теориясе, «матур әдәбият стильләренең хәрәкәте барыннан да элек теге я бу телнең үсеш закончалыклары белән аңлатыла, бу закончалыклар язучыларның телдән файдалану характеры белән билгеләнә» [1], дип карый, ягъни стильне иҗтимагый-эстетик күренешләр сферасыннан чыгарып ташлый. Әдәби әсәрдә тел — сынлы сәнгатьтә буяу, музыкада тавыш, ритм, гармония кебек күренеш ул. Димәк, тавыш, аваз — шул хәлдә музыка стиле, буяу — сынлы сәнгать стиле, ә мәрмәр — скульптура стиле була алмаган шикелле, тел дә турыдан-туры гына әдәби стиль була алмый. Тик сурәтләү составына кергәч кенә һәм әдәби стиль элементына әверелгәч кенә, сүз искиткеч зур һәм тирән мәгънәле сәнгать чарасына әверелә. М. Шолоховның «Тын Дон» романы герое Григорий Мелехов каршында кара кояш сурәте пәйда булуын гына искә төшерик: «Коры җил китергән эңгер томанында кояш калыкты. Аның нурлары Григорийның куе чал чәчләрен көмешләндерде, агарынган, тораташ булып каткан куркыныч йөзен сыйпап узды. Гүя авыр йокыдан уянгандай, ул башын күтәреп карады. Баш очында кап-кара күк йөзен һәм күзләрне камаштырып янган кап-кара кояшны күрде» [2]. Менә шушы бер күренештә генә дә Григорийның бөтен фаҗигале язмышын аңлатырлык эчке, психологик мәгънә бар, диләр белгечләр [3]. Һәм чыннан да ул шулай.

Стильнең аерылмас өлеше һәм сыйфаты булсын өчен, тел, димәк, сәнгатьле сөйләмгә әйләнергә тиеш. Сүзгә бәйле күренеш булса да, стиль — тел үзенчәлеге түгел, ә сәнгатьле сөйләм үзенчәлеге. Әгәр дә стиль фәкать тел үзенчәлеге генә булса, һәрбер телнең үз стиле булыр һәм бер телдән икенчесенә тәрҗемәдә әдәби әсәр стиленең үзенчәлекләрен саклау мөмкинлеге дә калмас иде, диләр [4]. Ләкин моңа карап, милли телләрнең стильгә мөнәсәбәтләре, аны оештырудагы рольләре бертөрле яки битараф дигән нәтиҗә чыгарырга һичбер нигез юк әле. «Бит һәр телнең стильне оештыручы үз көчләре бар. Нигә соң Тарас Шевченко шигырьләрен украин теленнән аңа тугандаш булган рус теле-

[1] М. Б. Храпченко. Поэтика, стилистика, теория литературы. «Страницы истории русской литературы» дигән җыентыкта. 419 бит.
[2] М. Шолохов. Тын Дон. IV китап. Казан, 1964 ел. 499—500 битләр. Г. Ахунов тәрҗемәсе.
[3] «Проблемы художественной формы социалистического реализма» дигән җыентык. Т. 1. М., 1971 ел. 82 бит.
[4] Г. Н. Поспелов. Проблемы литературного стиля. 1970 ел. 7 бит.

нә тәрҗемә итү шундый авыр бирелә?» [1]. Шуның шикелле үк, мәсәлән, Тукай лирикасын русчага тәрҗемә итүнең дә шактый авыр булуы күренә. Аның шигъри стилен билгеләгән үзенчәлекләр тәрҗемәдә кимиләр яки югалалар. Монда сүз стильнең теге я бу телдәге милли үзенчәлектән башка булуы турында түгел, ә гомумән әдәби стиль категориясенең тик телдән генә тормавы турында бара. Шул рәвешчә, тик тел, сөйләм ноктасыннан гына әдәби стильне аңларга омтылыш бу төшенчәнең эчтәлеген һәм күләмен тулы итеп күз алдына бастыра алмый. Стильнең моннан башка тагын күп кенә компонентлары барлыгын һәм тик шул компонентлар белән сөйләм чараларының бердәмлегендә генә әдәби стиль барлыкка килүен истә тотарга кирәк.

### 3

Иҗат методларының нигезендә яткан субъектив һәм объектив башлангычлар стильләрне билгеләүдә дә зур урын тота. Язучының идея-эстетик карашларындагы бу беренчел башлангычлар стиль төсмерләренә дә йогынты ясый. Әйтик, романтизмдагы субъективлык яки реализмдагы объективлык романтик һәм реалистик стильләрнең экспрессиясен, төп пафосын, сурәтләү чаралары системасында нинди художестволы элементлар өстенлек итүен күрсәтә. Бу ике тенденция бигрәк тә лирикада көчле. Без монда кичерешләрнең төрле тип һәм төсмерләре белән очрашабыз. Беришә шагыйрьләр кичереш экспрессиясен биргән сурәтләр белән эш итәләр, аларның психологик һәм эмоциональ кискенлеген әзлиләр һәм табалар. Бу очракта субъектив башлангыч һәм романтик стильгә хас пафос өскәрәк чыга. Ә икенче шагыйрь чынбарлыкның һәм кичерешләрнең табигый, тормышчан агылышын күрсәткән иллюзияне тудырырга тели. Шуңа күрә монда аерым сурәтләргә басым ясау, аларның кискен, калку булып гәүдәләнеше түгел, ә әсәрдәге образлар бөтенлеге белән тәэсир итү беренче урында тора. Бу очракта инде объектив башлангычның һәм реалистик стильгә хас пафосның көчлерәк булуы күренә.

Классик романтизмга бик характерлы субъективлыкның төп мәгънәсе чынбарлыкны шәхеснең рухи дөньясыннан, гомумән кешеләрнең рухи мөнәсәбәтләре ноктасыннан чыгып аңлау һәм сурәтләүдән гыйбарәт иде. Монда ирекле кеше рухының объектив чынбарлык закончалыклары белән каршылыкка керүен күрсәткән антитеза — шәхес һәм җәмгыять арасындагы психологик антитеза романтик стильнең характерлы тенденциясе булып китә. Шуңа күрә романтизмда лирик жанрларның, гомумән эмоцияләргә бай лиризмның зур роль уйнавы да очраклы түгел.

Романтизмда кешенең тышкы дөньяга рухи мөнәсәбәте беренчел булу сәбәпле, шәхес эчке дөньясының тынгысыз һәм ярсулы, газаплы һәм шатлыклы, ашкынулы һәм каршылыклы кичерешләрен тасвирлау алга этәрелә. Менә шуннан инде романтик стильгә эмоциональ киеренке, күтәренке сыйфатларның күбрәк хас булуы килеп чыга. Аңа лирик экспрессия бик характерлы. Шунлыктан риторик алым һәм интонациянең ешлыгы да табигый. Сорау һәм эндәш интонацияләре белән сугарылган гыйбарәләрнең мул кулланылуы да — романтик стильнең эмоциональ-психологик акцентындагы бер үзенчәлек. Бу урында да үз рухының мөстәкыйльлегенә омтылган герой психологиясе гәүдәләнә.

Романтик стиль сәнгатьле чараларның гиперболизациясен, гадәттәгедән күп арттырылган, кабартылган булуын, шартлылыкны, метафора һәм символларга бай булуны таләп итә. Тик шулар ярдәмендә генә гадәттән тыш геройның эчке дөньясында гадәттән тыш булган сыйфатны, ягъни аның субъектив оригинальлеген ачу максатына ирешергә мөмкин. Димәк, романтик стиль кеше характерын һәм аның психологиясен романтик метод җирлегендә яңабаштан иҗат итүнең зарури ихтыяҗы булып мәйданга килә.

Реализмдагы, конкрет алганда, критик реализмдагы объективлыкның төп мәгънәсе чынбарлыкны кешеләрнең иҗтимагый мөнәсәбәтләре ноктасыннан аңлап сурәтләүдә. Шуңа күрә монда социаль детерминизм өстенлек итә, ягъни кеше белән тирәлек арасындагы мө-

[1] А. В. Чичерин. Идеи и стиль. 1968 ел, 8 бит.

нәсәбәтләрне чагылдыру иҗтимагый тормыш закончалыкларыннан үсеп чыга. Кеше психологиясен сурәтләүне дә шул детерминизм яктыртып тора. Реализмда эпик тасвирлау, хикәяләү стиле, прозаик жанрлар, роман, эпопея кебек киң колачлы әсәрләр зур урын алуы да әнә шуннан килә. Шушы ук моментлар реалистик стильнең дә төп тенденциясен билгелиләр. Реализмда инде төрле төстәге эпик стильләр мәйданга чыга, һәм индивидуаль стильләр чәчәк ата. Реализмда типиклаштыру һәм индивидуальләштерү принципларының башкалыгы да, аларның һичбер башка методта булмаган бердәмлеге, синтезы да реалистик әдәбияттагы стильләрне билгеләү өчен бик әһәмиятле. Реализмдагы стильләр типиклаштыру һәм индивидуальләштерүнең бердәмлеге нәтиҗәсе буларак формалашалар. Индивидуаль стиль исә язучының тормыш материалын никадәр мәгънәле итеп сайлавы һәм аның нинди үзенчәлекле якларын сурәтләве белән бәйләнештә генә мәйданга килә. Хәтта әдәби әсәрдәге ситуация, вакыйгалар һәм автор сөйләме белән герой сөйләме арасындагы мөнәсәбәт, бәйләнеш һәм аерымлык кебек мәсьәләләр дә реалистик стильдә тирән, кискен дифференциация алалар, типиклаштыру һәм индивидуальләштерү өчен бик кирәкле чара булып китәләр. Реалистик стильдә герой сөйләме белән автор сөйләменең бер-берсеннән аерылуы һәм мөстәкыйльлеге — бик әһәмиятле, характерлы күренеш. Монда инде герой сөйләме тормыш процессын, ситуациясен һәм кеше психологиясен күрсәткән алымга, чарага әверелә. Автор һәм герой сөйләмнәре арасындагы мөнәсәбәтләрнең ни дәрәҗәдә җитлеккән яки җитлекмәгән булуы аларның реализмга никадәр якын тору-тормавын күрсәткән билгеләрдән санала.

Әлбәттә, бу сөйләп үтелгән моментлар романтик һәм реалистик стильләрнең бер-берсенә якын килүенә тоткарлык булып торалар, дигән нәтиҗә ясарга кирәкми. Аларның аерым-аерым гына түгел, бергә һәм синтез хәлендә булган очраклары да аз түгел. Без монда романтик һәм реалистик стильләрнең үзләренә хас гомуми, типологик билгеләрен генә күз алдына китердек. Метод бердәмлеге — аңа хас стильләрнең бер-берсенә якынлыгы өчен нигез. Индивидуаль стильләр исә әнә шул метод бердәмлеге сәбәпле үзләренең гомумилеген, уртаклыгын саклый. Шул уртаклык җирлегендә стиль агымнары барлыкка килә. Реалистик әдәбиятта индивидуаль стильләр аңа кадәр һич күренмәгәнчә тәрәккый итсә дә, ул да гел индивидуаль стильләрдән генә тормый. Мәсәлән, социалистик реализм әдәбияты стильләрендә күпме генә аерма булмасын, аның метод бердәмлеге стильләрдәге уртаклыкны да саклый, бу уртаклык стиль агымнарында күренә. Хәзерге әдәбият белгечләренең күпчелеге социалистик реализмның художестволы байлыгын билгеләүче төп аспект, юнәлеш булып стильләр торуын күрсәтә.

Әдәбиятларның һәм иҗат методларының тарихында, бигрәк тә реализм чорында, индивидуаль стильләр үсеше көчәеп киту мәгълүм. Шуңа күрә иҗат методларына, әдәби юнәлеш һәм агымнарга хас гомуми стильләрдән башка тагын әле бер төркем язучыларга уртак булган стильләр һәм аерым язучыларның индивидуаль стильләре барлыгын да истә тотарга кирәк. Идеалистик эстетика методны художник ирегеи чикли, кыса һәм бетерә торган регламентация дип карый һәм аңа стильне каршы куя. Стильдә художникның чикләнмәгән индивидуаль мөмкинлекләре чагылырга тиеш дип аңлата. Бу караш, методны инкарь итүдән тыш, индивидуаль стильнең эстетик закончалыкларын субъектив башбаштаклык белән алыштыруны яклый. Материалистик эстетика индивидуаль стильләрне һич тә инкарь итми. Әмма ул моңа сәнгать закончалыклары ноктасыннан карап якын килә һәм бу закончалыкларның иҗат методы белән тыгыз бәйләнештә булуын аңлата. Бериште белгечләр, әйткәнебезчә, иҗат методын гомуминең чагылышы дип, ә аның һәр язучы иҗатында индивидуаль гәүдәләнешен стиль дип карыйлар. Әмма моңа каршы куелган дәлилләр стильләрнең һәм гомуми, уртак, һәм аерым язучыга гына хас индивидуаль билгеләре барлыгын да шактый нигезле һәм ышандырырлык итеп күрсәтәләр.

Стильне индивидуаль кысалар эченә генә бикләп калдыру аның бер метод эчендәге агымнар, чор стильләре һәм милли стильләр белән бәйләнешен ин-

карь итүгә китерә. Индивидуаль стиль аерым язучының үз табышы гына түгел, ул үзенә кадәрге традицияләр һәм үз заманының идея-эстетик казанышлары, традицияләре белән тыгыз мөнәсәбәттә туып, талантлы художникның үз иҗат оригинальлеге җирлегендә формалаша, индивидуаль төс ала. Һәм шул ук вакытта икенче художникларның стиленә дә йогынты ясый, димәк, ниндидер стиль агымына килеп керә. Индивидуаль стиль тарафдарлары фикеренчә, стиль агымы — индивидуаль стильләр уртаклыгы түгел, ә аерым талантлы язучы стиленең өстенлек алуы, башкаларның шуңа иярүе булып чыга. Моңа каршылар исә, бөек художник стиле — билгеле стиль агымының бер тармагы, диләр. Үз иҗат көченең мөмкинлегенә карап, һәр художник шул агымга өлеш кертергә һәм аның төп билгеләрен баетырга, тулыландырырга, көчәйтергә мөмкин.

Индивидуаль стиль белән стиль агымы сыеша алмый, аның бары тик берсе генә яшәргә хаклы дип карауччылар да бар. Мәсәлән, Г. Поспелов: «Стиль үзеннән-үзе индивидуаль күренеш була алмый»[1],— ди һәм стиль агымының характерлы билгеләре аерым язучылар иҗатында кабатлануын, ә һәр язучының үзенә генә хас сыйфатларны индивидуаль иҗади манера дип атауны дәгъва итә[2]. Ләкин хәзерге әдәбият белгечләре индивидуаль стиль төшенчәсен иҗат манерасы итеп карау гомумән бу мәсьәләне бөтенләй тарайта диләр.

Һәрбер зур художникның тормышка сәнгатьчә мөнәсәбәте һәм эстетик идеалы аның субъектив, ягъни үзенә генә хас идея-эстетик карашларыннан, принципларыннан башка була алмый. Бу момент аның иҗат методындагы индивидуальлекне дә гәүдәләндерсә кирәк. Стильдәге индивидуальлек исә шул моментның тагын да конкретрак һәм реальрәк нәтиҗәсе булып мәйданга чыга. Ләкин метод һәм стильләрнең индивидуальлеге аларның гомумилеген инкарь итми, чөнки гомумилек индивидуаль стильләргә уртак билге һәм принципларны үзенә туплый. Монда инде гомуми белән хосусыйның үзара диалектик мөнәсәбәттә булуы кебек закончалык бик ачык күренә. Ләкин иҗат методларының индивидуальлеген бик чикләп карауччылар да һәм хәтта инкарь итүчеләр дә юк түгел. Мәсәлән, совет әдәбиятларында дөньяга караш җирлегенең бердәм булуын истә тотып, кайбер белгечләр социалистик реализмда иҗат юнәлешләренең һәм индивидуаль методларның булуын кире кагалар, чөнки, диләр алар, мондый эстетик күренешләр дөньяга караш төрлелекләре белән бәйләнгән. Әйтик, критик реализм әдәбиятында дөньяга карашлары ягыннан төрле язучылар иҗат итә, шуңа күрә анда иҗат юнәлешләре һәм индивидуаль методлар өчен дә җирлек бар. Ә социалистик реализмда тик индивидуаль стильләр генә өстенлек итә диләр. Бу карашны яклаучылар: «Теория сүзлегенә» «индивидуаль иҗат методы» категориясен кертү мәсьәләне бутый: күпме художник булса, метод та шул кадәр була», дигән нәтиҗә чыгаралар[3].

Бу фикерләр белән килешмәүчеләрнең дәлилләре дә шактый кискен булып ишетелә. Язучының иҗади шәхесе, ди М. Б. Храпченко, «барыннан да элек аның художестволы фикерләү, тормышны поэтик күрү һәм чагылдыру үзенчәлегендә гәүдәләнә, шуңа күрә табигый ки, иҗади шәхес язучы иҗат методының индивидуаль үзенчәлекләрендә дә үзенең чагылышын таба. Бу үзенчәлекләр талантлы художникны тулаем әдәби хәрәкәттән аермыйлар. Аның иҗат методы гомуми белән индивидуальнең бердәмлеге булып тора. Бу инде механик кушылу гына түгел, ә һич бүленмәс эретмә булганлыктан, без үзебезне язучының индивидуаль методы турында сөйләргә хаклы саный алабыз...»[4].

Китерелгән фактлардан күренә ки, индивидуаль стиль һәм индивидуаль метод мәсьәләләре хәзерге көндә кызу бәхәс темасы булып тора. Бигрәк тә индивидуаль методның юклыгын яки барлыгын исбатлау шактый көч сарыф итүне һәм төпле дәлилләр белән фикер йөртүне сорый.

---

[1] Г. Поспелов. Проблемы литературного стиля, 111 бит.
[2] Шунда ук, 123 бит.

[3] В. Иванов. Художественный метод и творческая индивидуальность, «Литературная газета», 1973 ел, 4 июль саны.
[4] «Великая Октябрьская социалистическая революция и мировая литература» дигән җыентык, 1970 ел, 88 бит.

һичшиксез, һәр талантлы художник методны әзер кеенчә генә кайдандыр һәм кемнәндер алмый, ә үткәндәге һәм үз заманындагы әдәбият тәҗрибәләренә нык таянган хәлдә, иҗат методының индивидуаль стиль белән баетылган икенче, яңа, оригиналь төрен тудыра. Менә шул процесста индивидуаль метод, әллә индивидуаль стиль генә барлыкка киләме? Бу сорауга җавапны ачык калдырып, без художникның индивидуальлегеннән башка стиль үзенчәлеге турында сөйләү читен икәнлеген әйтүне кирәкле табабыз. Стильнең гомумилегеннән, уртаклыгыннан бигрәк, аның индивидуаль күренеш икәнлегенә игътибар итүнең ешрак булуы да шуны күрсәтсә кирәк.

### 4

Индивидуаль стильләрнең бердәмлек һәм төрлелек белән аерылып торганнары бар. Боларны тотрыклы һәм хәрәкәтчән стильләр яки бер стильлелек һәм күп төсмерле стиль мәгънәсендәге күп стильлелек дип тә атарга мөмкин. Беренче төр стиль язучы иҗатының идея-сурәт эчтәлеге һәм методы бер юнәлештәрәк тәрәккый итү җирлегендә бердәмлек һәм эчке бөтенлек алуы белән характерлана. Рус поэзиясендә, мәсәлән, Фет лирикасында шундый төр стильнең өстенлек итүен әйтәләр. Бездә Дәрдмәнд һәм С. Рәмиев лирикасына тотрыклы стиль, бер стильлелек хас кебек.

Индивидуаль стильнең төрлелеге, хәрәкәтчән булганы аның күпкырлы, үзгәрешле сыйфатын күрсәтә. Мондый стильгә ия язучының идея-эстетик һәм метод үсеше аеруча интенсив, катлаулы, күпьяклы була. Бу очракта стиль үсеше ноктaларында да көчешләр, алмашынулар көчле, киеренке һәм тирән. Рус әдәбиятында, мәсәлән, Пушкин, Лермонтов һәм Блок стильләрен шундый төргә кертәләр. Татар поэзиясендә моның мисалын Тукай, Гафури, Такташ һәм Җәлил стильләрендә күрергә мөмкин. Димәк, беренче төргә караган стильнең тотрыклы, ягъни кискен үзгәрешсез баруы, ә икенче төрдәгенең үсеш, үзгәреш тарихында характерлы борылыш, сикерешләр шактый күп, еш булуы сизелә.

Бер үк язучы иҗатында берничә стиль тенденциясенең булуы шулай ук очраклылык түгел. Үзләренең иҗат үсешләре юлында төрле стильләр белән очрашып, аларны үзләштереп, үз индивидуаль стильләрен тудырган художниклар сәнгать тарихында күп (Шекспир, Пушкин, Тукай һ. б.). Монда инде синтетик стиль мәйданга чыга. Бу инде төрле стильләрнең органик бердәмлегеннән, синтезыннан туган яңа индивидуаль стиль дигән сүз. Мәсәлән, Тукай иҗатында Көнчыгыш традицион шигъри элементлары белән Көнбатыш (бигрәк тә рус) поэзиясе элементлары һәм татар халык поэзиясе нык бәйләнешкә кереп, аның стилендәге үзенчәлеккә нигез булдылар, яңа сыйфатлар тудырдылар. Бу өч чыганактан килгән элементлар заман стильләре белән мөнәсәбәткә кереп, Тукай иҗат эчтәлегенең яңалыгы белән баетылдылар, үзгәртелделәр һәм заман рухы белән сугарылдылар. Романтизм һәм реализм синтезы Тукай стилендәге синтезның да төп юнәлешен билгеләде.

Зур художниклардагы стиль төрлелеге алардагы иҗат колачының киң, идея-эстетик эчтәлекнең бай һәм заман пафосының көчле булуыннан килә. Алар шул эчтәлекне һәм пафосны тулы итеп һәм иркен сулыш белән сурәтләү юлларын эзлиләр, табалар һәм шуңа ирешү осталыгын күрсәтәләр. Шул процесста алар башка әдәби юнәлеш һәм агымнарга хас әдәби стильләр ирешкән уңышларны, табышларны да кабул итәләр, иҗади үзләштерәләр һәм, ниһаять, синтетик стиль тудыралар.

Бер үк язучының төрле әсәрләрендә стиль башкалыклары да булырга мөмкин. Бу очракта инде без язучының яки иҗат үсеше белән бәйле, яки әсәр эчтәлеге, жанры һәм анда куелган сәнгатьчә максатлар белән бәйле стиль төрлелекләрен очратабыз.

Язучының идея-эстетик максатына, әсәрнең темасына һәм жанр үзенчәлегенә карап, индивидуаль стильнең тоны, интонация һәм төсмерләре үзгәрү еш очрый. Мәсәлән, Тукайның бер үк вакытта диярлек язылган «Туган илемә» һәм «Китмибез!» кебек шигырьләрендә ватанга мәхәббәт төп мотив булса да, аларның тема төрлелегенә нисбәтән, бу мотивка төрле идея-эстетик максат белән якын килү сәбәпле, ул шигырьләрнең стильләрендә дә башкалыклар, аерымлыклар чагылган.

Стильнең тормыш, тарихи барыш белән бәйләнештә үзгәрә баруын хәтта бер әсәр стилендә күрергә мөмкин. Мәсәлән, «Тын Дон»ның беренче кисәкләре белән соңгысы арасында стиль эволюциясе ярылып ята. М. Шолохов күп геройлылыктан һәм күп вакыйгалылыктан берничә герой, бигрәк тә Григорий Мелехов язмышын, аның эчке дөньясын күрсәтүгә күчә бара. Шул күчеш процессында аның стилендә сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килә; ул үзгәрешләр әсәр эчтәлегенең бөтен реалистик үзенчәлеге белән бәйләнгән. Әмма мондый күренеш язучының индивидуаль стилендәге чуарлык яки таркаулык турында сөйләми, ә стиль бөтенлегенең аерым билгеләре теге я бу әсәрдә калкурак чагылуын, төрле яклап ачыла баруын күрсәтә. Язучының стиле әсәрдән әсәргә үзенең төсмерләрен үзгәртә икән, димәк, бу инде индивидуаль стильнең, иҗади максатлар үзгәрүгә нисбәтән, бик динамик, хәрәкәтчән һәм күпкырлы була алуы да мөмкин дигән сүз. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның бигрәк тә совет чорындагы хикәя һәм романнары үзләренең тематик эчтәлекләре белән генә түгел, сюжет, композиция һәм хәтта хикәяләү манерасы белән дә бер-берсеннән шактый гына аерылып тора. Әмма бу аерымлык язучы стиленең теге я бу яклары аның һәр әсәрендә тагын да тулырак ачыла һәм җитлегә бару турында сөйли иде.

Бер үк язучының төрле иҗат методларына караган стильләрдә язуы мөмкинме? Мәсәлән, романтик язучы реалистик стильдә, реалист язучы романтик стильдә эш итә аламы? Иҗат методларының бер үк язучы иҗатында үзара бәйләнеше һәм хәтта янәшә торып урын алганлыгы әдәбият тарихында тулып ятканда, стильләр белән дә шундый хәлнең булуы бик табигый, әлбәттә. Монда да стиль кысаларының сәнгатьчә мөмкинлекләре киң һәм индивидуаль төсмерләргә бай булуы күренә. Совет әдәбиятларында социалистик реализм принциплары җирлегендә бер үк язучы иҗатында реалистик һәм романтик стильләрнең янәшә дә, бергә дә, аралашып, кушылып та яшәве һәм күп индивидуаль төсмерләр алуы — шул хакыйкатьнең җанлы мисалы ул. Димәк, методларның үзара бәйләнеше һәм традицияләрнең яшәүчәнлеге кебек эстетик закончалыкны истә тотканда, бер язучы иҗатында стиль төрлелегенең һәм төрле стильләрнең урын алу мөмкинлеген кире кагу читен. Дөрес, бу мәсьәләнең икенче ягы да бар әле. Һәр язучы, художник иҗатында стиль индивидуаль бөтенлек һәм үзенчәлеккә ия булмаска да мөмкин. Аңа ирешә алмаган язучылар да күп. Үз стилен таба алмыйча, төрле стильләргә ияреп яки стиль алмаштырып торган, ягъни стиль аморфлыгы белән авырган художник, әлбәттә, эпигон яки стилизатор булып та кала. Әмма әзер стильләрне кабул итү яки аларга ияру һәр очракта да кире, начар мәгънәсендә генә бәяләнергә тиеш түгел. Даһи художниклар тудырган стиль үрнәкләрен теге я бу төстә кабул итеп, аңа ияреп һәм үзләштереп иҗат иткәннәрнең һәммәсенә яман мәгънәсендәге ияручәнлек мөһерен сугу һич тә дөрес булмас иде. Мәсәлән, рус поэзиясендә Пушкин, бездә Тукай яки Такташ шигъри мәктәбе шәкертләре арасында, бу остазларының традицияләренә, стильләренә ияру белән бергә, аларны билгеле күләмдә дәвам иттергән һәм үстергән шагыйрьләр дә аз булмады.

Аннан соң аерым чорларда, бигрәк тә тарихи алмашыну, күчү вакытларында, стильләрнең буталышкан, аралашкан һәм хәтта җитлекмәгән хәлдә торулары да очрый. Мондый күренеш гадәттә иске стильдән яңа стильгә күчү белән характерланган, ягъни ике арадагы дәверләрдә сизелә. Яңа метод туганда, аның белән бәйле индивидуаль стильләрнең ачылып, ачыкланып җитмәве дә, яңа индивидуаль элементларның өлгермәгән булуы да табигый. Шуңа күрә андый чакларда әдәби юнәлешкә хас гомуми уртак стиль сыйфатлары күзгә бәрелебрәк тора. Мәсәлән, социалистик революциянең тәүге елларындагы поэзиядә әнә шундый стиль сыйфатлары шактый көчле булды. Алар, бер яктан, искегә ияруне§ тотрыклы икәнлеген, ә икенчедән, заманга лаек стильне тиз генә табу җиңел түгеллеген күрсәтәләр иде. Пролеткульт һәм «Кузница» шагыйрьләре иҗатын моның бер характерлы мисалы итеп карыйлар. Аларда индивидуаль стильдән бигрәк, әдәби юнәлешкә хас гомуми стиль билге-төсмерләре өстенлек

алды. Ике арада торган яки гомуми стиль күренешләре татар әдәбиятында да аз булмады. Моның өчен иске, традицион романтик стильләрнең никадәр яшәүчән булуын искә төшерү дә җитә. Аларны без күп кенә татар язучыларының иҗатында очратырбыз.

Мәгълүм ки, XX йөз башында тизләтелгән үсеш процессын кичергән татар әдәбиятында иҗат методларының һәм әдәби стильләрнең мөнәсәбәте тирәннән үзгәрде, катлауланды. Бу чорда реализм һәм романтизм юнәлешләренең төрле катламнары, төсмерләре барлыкка килде. Бер яктан, мәгърифәтчелек реализмы һәм критик реализм, ә икенче яктан, алар белән тыгыз мөнәсәбәттә романтизм тенденцияләре шактый калку булып күренде. Шул ук вакытта бу тенденцияләрнең Көнчыгыш әдәби традицияләре һәм XIX—XX йөзләрдәге Көнбатыш әдәбиятлары белән тирән бәйләнештә булуларын да истә тотсак, яңа татар әдәбиятындагы иҗат методларының һәм стильләрнең һич күренмәгән катлаулылык, хәтта чуарлык белән мәйданга чыгарга тиешлеге аңлашылыр. Иҗат методларының бер-берсеннән аерымлануына караганда, бу чорда аларның аралашу, керешү, якынлашулары күбрәк булганлыктан, стильләрнең дә шундый хәлдә гәүдәләнүе табигый иде. Ләкин болай дию белән без һич тә иҗат методлары белән индивидуаль стильләр арасына тигезлек билгесе куеп, алар арасындагы мөнәсәбәтне дә бер яссылыкта, турыдан-туры гына аңларга кирәк дигән фикерне якламыйбыз. Безнең карашыбызча, XX йөз башы татар әдәбиятындагы эстетик идеал һәм иҗат методлары структурасында мәгърифәтчел, антропологик һәм социаль принциплар төрле мөнәсәбәтләрдә [1], бер-берсе белән нык аралашып килүләренә карамастан, талантлы язучыларның индивидуаль стильләре үзләренә генә хас гаять үзенчәлекле сыйфат төсмерләрен дә күрсәтеп өлгерделәр. Бу очракта, бәлки язучының идея-эстетик дөньясындагы субъектив башлангыч, аның художниклык таланты нинди көчкә ия булуын да истән чыгармаска кирәктер. Югыйсә, индивидуаль стильләрне иҗат методы принципларының художник талантындагы субъектив мөмкинлекләрдән башка гына реальләшүе, тормышка ашуы дип аңлаткан беркатлы караш белән килешергә туры килер иде. Аеруча стиль өлкәсендә талантның индивидуаль сәләте, оригинальлеге үзен тулы күрсәткәндә генә, сәнгать әсәренең идея-эстетик дәрәҗәсе ничек булуы хакында сөйләргә мөмкин. Димәк, ике моментны — иҗат методы принципларының нинди эчтәлек, юнәлеш һәм дәрәҗә алуы, җитлегү-җитлекмәве һәм шуңа бәйләнештә язучы талантының индивидуаль мөмкинлекләре ничек, ни күләмдә ачылып китүе кебек моментларны күз алдында тотканда, иҗат методы белән стиль мөнәсәбәтләренең шактый катлаулы булуы аңлашылыр. Менә шундый катлаулылыкны күрсәткән үрнәкләр XX йөз башы татар әдәбиятында аз түгел иде. Реалистик стильләрнең дә, романтик стильләрнең дә төсмерләре әлек булмаганча күбәеп кенә калмады, ә алар индивидуаль стильләр булып формалашу дәрәҗәсенә күтәрелделәр һәм бер-берсеннән үтә аерылып торган үзенчәлек алдылар. Әйтик, реалистик поэзиядән Г. Тукай һәм М. Гафури, ә романтик поэзиядән С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд яки прозадан Ф. Әмирхан, Ш. Камал һәм Г. Ибраһимов стильләрен карыйбыз икән, барыннан да элек, без аларның бер-берсенә охшамаган әллә никадәр үзенчәлекле якларын табарбыз. Бу инде индивидуаль стильләр дифференциациясенең шактый тирәнлек алуы турында сөйли иде.

[1] Бу хакта карагыз: Ю. Г. Нигматуллина, Национальное своеобразие эстетического идеала, Казан, 1970 ел, Г. Халит, Әдәбиятның төп үзәнен һәм үзенчәлеген күреп, «Казан утлары», 1973 ел, 5 сан.

# ӘНВӘР ДАВЫДОВ

*(1919—1968)*

## Шагыйрь сүзе

*Шагыйрь сүзе...*

*Барлык әсәрләре үзе исән чакта ук басылып барган һәм тулысынча басылып беткән әдипләр була. Иҗатларының һәм әсәрләренең язмышы икенчерәк төрле булган әдипләр дә бар. Алар, үзләре үлгәннән соң да, укучыларны билгесез әсәрләре белән куандыралар, иҗатларыныңниндидер яңа хасиятләре белән ачыла торалар. Әнвәр Давыдов — шундый шагыйрьләрдән. Шагыйрь үзе төзеп биргән иң калын сайланма әсәрләр җыентыгын — «Дәверләр диалогы» дип исемләнгән шигырьләр һәм поэмалар китабын — үз кулына тотып укырга өлгерә алмады. Китап шагыйрь үлгәннән соң (1969 елда) басылып чыкты.*

*Шагыйрьнең әйтәсе сүзләре, сөйлисе сүзләре күп иде. Нәкъ үзе язганча:*

Ах, миңа бик күп сөйләргә кирәк.
Кешеләргә —
кешеләр турында,
Шәһәрләргә —
шәһәрләр турында,
Башкаларга —
үземнең туган яклар турында.
Илләргә —
илләр турында.
Дөньяларга —
дөньялар турында
Миңа бик күп сөйләргә кирәк.
Миңа ашыгырга туры килә.

*Әнвәр Давыдов иҗат эшен соңгы көннәренәчә туктатмый. Күңелендәген әйтеп калырга ашыга. Әйткәне исә үзенә «әйтергә теләгәненә пролог кына» булып тоела. Аның архивы белән танышучылар гаҗәеп бер табышка — шагыйрьнең «Йокысыз төннән соң» исемле зур күләмле шигъри романына тап булдылар. Шагыйрьнең бу романны байтак вакытлар дәвамында язуы, әсәрнең күп төрле вариантлары булуы һәм Октябрь революциясенең 50 еллыгына аны тәмамлавы мәгълүм булды. Үз иҗатына таләпчән каравы нәтиҗәсендә генә ул аны бастырырга ашыкмаган. Аның өчен иң әһәмиятлесе — әйтәсен әйтеп калырга өлгерү. Шуңа да ул язган, гадәттәгечә, каләмен сул кулына тотып, мөмкинлек туган саен аерым кәгазь кисәкләренә язган да язган. Авторның үз кулы белән кучерелгән нөсхәсенә тәмамланган вакыты «1967 ел» дип куелган. Шагыйрьнең генә түгел, бөтен татар поэзиясенең горурлыгы булып саналырлык әлеге романның аерым өлешләрен «Казан утлары» журналы редакциясе укучыларга тәкъдим иткән иде. 1972 елда Татарстан китап нәшрияты аны тулы килеш бастырып чыгарды. Шул рәвешчә, шагыйрь һаман укучысы белән сөйләшә, «диалогы» дәвам итә. Сөйләшергә үзе булмаса да, сүзе килә тора.*

*Әнвәр Давыдовның архивында шагыйрьнең дөнья күрмәгән әллә никадәр әсәрләре бар. Нина ханым аларны кадерләп саклый. Шагыйрь архивы... Шагыйрь сүзе... Бу үзе бер дөнья. Өйрәнеләсе, ачыласы шигърият дөньясы. Төрле жанрдагы әсәрләр, караламалар, вариантлар... Җыелышларда сөйләр өчен теркәлгән язмалар, тәнкыйть мәкаләләре, истәлекләр, газета яки нәшрият өчен язылган рецензияләр... Күп санлы көен дәфтәрләре... Хатлар... Болар — шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын, шулай ук поэзия тарихын, тәнкыйть фикере үсешен өйрәнү өчен бик тә кирәкле чыганаклар.*

*Менә, мәсәлән, аның Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты анкетасына җавап буларак язылган автобиографиясе. Бу язма инде хәзер үзе шагыйрь тормышын өйрәнүчеләргә ышанычлы таяныч, кыйммәтле чыганак булып хезмәт итә. Анда шагыйрьнең иҗат биографиясенә кагылышлы гаять күп яңа фактлар теркәлгән. Әнвәр Давыдов әдәбият белән бик яшьләй кызыксына башлаган икән. Сугышка кадәр ук бик күп шигырь, берничә поэма һәм пьеса, бер роман тәмамлаган, газета-журналларда шигырьләр, очерклар бастырган. Шагыйрь үзе язып калдырган ориентирлар буенча ул мирасының бер өлешен бәлки эзләп табарга әле соң ук түгелдер, мөмкиндер һәм кирәктер.*

*Үз вакытында газета-журналларда басыла торган мәкаләләре, рецензияләре Әнвәр Давыдовны поэзиянең шул чордагы торышы һәм киләчәк язмышы белән якыннан кызыксынган һәм борчылган, шигъриятнең бөтен дөньясын үз йөрәге аша үткәрә барган тәнкыйтьче дә итеп таныткан иде. Шагыйрь архивындагы материалларда Әнвәр Давыдовның эстетик карашлары тагын да тулырак ачыла. Поэзиянең җитди мәсьәләләре турында сүз барганда — ул туры сүзле һәм принципиаль тәнкыйтьче... Шагыйрьләрнең яңа әсәрләрен укыганда, яңа китапларын укучыга тәкъдим иткәндә — таләпчән дус һәм якын киңәшче... Көен дәфтәрләрендәге язмаларында — киң карашлы, эрудицияле, интеллектуаль шагыйрь...*

*Шагыйрь сүзе... Укучылар күрерләр, шагыйрьнең әйтәсе сүзе чыннан да күп булган. Ул аларны шигырь-поэмаларында гына түгел, төрле жанрдагы әсәрләрендә, төрле язмаларында да әйтеп калырга ашыккан. Укучыларга журналның бу санында Әнвәр Давыдовның шәхси архивында — Нина ханым Давыдовада сакланан мирасының бер өлеше генә тәкъдим ителә. Ул язмаларны журнал өчен шагыйрьнең туганы Альберт Нарбеков һәм шагыйрь Рөстәм Мингалимов хәзерләде.*

*Ә. Давыдовның әдәби мирас комиссиясе, әлеге форсаттан файдаланып, укучыларга бер үтенеч белән дә мөрәҗәгать итә: шагыйрьнең хатлары, төрле язмалары укучылар кулында да саклана. Шагыйрь сүзе — кирәкле сүз. Ул югалмасын иде. Мирас комиссиясе хәзерге вакытта Әнвәр Давыдовның яңа җыентыгын хәзерли. Ул китапта шагыйрьнең моңарчы басылмаган әсәрләре дә, хатлары да урын алачак. Шагыйрьнең әсәрләрен, кулъязмаларын түбәндәге адрес белән җибәрүчеләргә комиссия алдан ук зур рәхмәтен белдерә:*

*Казан, Бауман урамы, 19, Татарстан язучылар союзы, Ә. Давыдовның мирас комиссиясенә.*

НИЛ ЮЗИЕВ,
*филология фәннәре докторы.*

## Автобиография[1]

Мин 1919 елның 21 мартында дөньяга килгәнмен. Әти, крестьян малае, бу елларда аеруча интенсив рәвештә игенчелек белән шөгыльләнгән. Ул 1928 елда үлде. Олы абыем Мирза Давыдов[2] бу елда инде коммунистлар партиясенә кергән, илдәге совет дошманнары белән көрәштә шактый күп тәҗрибә туплаган, армиядә политик һәм командалык хезмәтләре үтәгән. Безгә

---

[1] Бу автобиография СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты анкетасына җавап буларак язылган.

[2] Мирза Давыдов (1898—1943) — күренекле татар совет журналисты, илебезнең төрле татар газеталарының редакторы, тәрҗемәче. Бөек Ватан сугышы елларында полк командиры, 1943 елда яраланып һәлак була.

җизни тиешле Халикъ Садриның[1] да бу елларда безнең семья белән элемтәсе нык булган.

Укып-язарга мин өйдә өйрәнгәнмен. Өч яшь тулгач, мичтән янган күмерләр алып, стеналарга хәрефләр төшерә торган булганмын, 4—5 яшьләрдә татар (конкрет алганда, Тукай) шигырьләрен һәм бик юка гына бүтән китапларны да укый идем, 6 яшемдә күзем авырып Казанга килгәндә русча да хәреф таный идем. Авыру күземне бер кулым белән каплап, медицина плакатларын башыннан ахырына кадәр укып чыгарга тырыша идем. Официаль укуны Камышлыдагы башта башлангыч, аннары җидееллыкка әверелгән мәктәптә дәвам иттердем. V класска, яше җитми дип, алмый башлагач, ул вакытта Рус Байтуганында урнашкан волисполкомның председателе Вольский иптәшкә гариза белән мөрәҗәгать итүем хәтеремдә. Җиденчене тәмамлау белән безне 1931 елда Камышлыга күчкән авыл хуҗалыгы техникумына тапшырдылар. Звено системасы вакытлары иде, мин звено башлыгы итеп билгеләндем. Математика, физика, химия, әдәбият дәресләрен гел яратып килдем. Әти үлгәннән соң семьябызда өлкән ир-ат булып калган Мәсгут абыем 1931 елның көзендә фаҗигале рәвештә үлде. Материаль хәлебез авырланды. Шуның өчендерме, мин техникумда тоташ укымадым. I курста бераз укыганнан соң чыгып колхоз бригадасында хисап эшләре башкардым. Икенче курска да кереп карадым һәм тагын шулай ук кабатланды.

Беренче шигырем 1931 елның 14 мартында Камышлы районының «Коммунага» газетасында басылды. Мин асылда Тукай, Такташка ияреп яза идем. Хәзер Ленинград академиясендә укытучы бер хәрби дустым архивында сакланган шул елның ике үрнәгенә караганда, минем шигырьләр җитәрлек грамоталы, ритмик дөрес һәм образлы сөйләмле булганнар.

Моңа кадәрме (алай булса, мөгаен, 1930 ел булырга тиеш), моннан соңмы (мин Мәскәүгә 2 тапкыр бардым, 1930 һәм 1931 елда) Мәскәүдә «Октябрь баласы» журналында минем бер битлек очерк һәм рәсемем басылып чыкты. (Журналның подшивкалары архивларда бар, бервакыт мин аны Гази Кашшаф абыйда да күрдем.) Сүз безнең оч малайлары оештырган һәм мин «рәислек иткән» балалар колхозы турында бара иде. Очерк жанрының мәгънәсен һич аңламастан, мин анда дөрес фактлар янына күп кенә уйдырма да өстәдем бугай. Очерк озын чыкты, буталчык та булгандыр, ахры, аны тышкы бер тәртипкә китерүдә Муса Җәлил ярдәм итте. Мәскәүдә булу дәверемдә Центриздатка (Никольская, 10) барып чыксам, аның янына кергәли идем.

Камышлыда мәктәп пионер оешмасында торсам да, грамотам аркасында, авыл комсомол оешмасы җыелышларына, аеруча аның культура-сәнгать үзешчәннәре эшләренә катнаша башлавым да шул елларга (1930 ел) туры килә. Мин 1931—32—33 елларда колхозның төрле бригадаларында һәм идарәдә хисап эшендә эшләдем. Авыл советына извещениеләр язу эшенә тагын да иртәрәк тартыла башлаган идем. Иң матур истәлек — кайда гына эшләсәм дә, авыл халкының ничектер аеруча җылы карашы, бала акылыма беркатлы ихтирамы. Бәлки моның бер сәбәбе шулдыр: 1929 елларда ук кешеләргә гаризалар язып бирә башлаган идем. Еш кына бу гаризаларга гадел җаваплар килә. Бу еллар дәвамында мин күп бригадаларда эшләдем. Стена газетасы чыгару да минем өстә була торган иде. Газета эшен оештырудан бер хәбәрем юк, мәчеткә йөргән яшьләрне комган тоттырып рәсем ясыйм, ялкауларга такмаклар чыгарып язам да стенага эләм. Үзешчән түгәрәктә бик яшьли суфлер булдым. Шунысы хәтердә, соңгы елларда (1932—33) Такташның «Күмелгән кораллар»ын күңелдән суфлировать итә идем. Үзем шул пьесада Рөстәм ролен уйный башлап, «әртис» тә булып киттем, ахырда берничә мөстәкыйль түгәрәк-спутниклар да (үсмерләрдән) оештырдым. Армиягә кадәр, армиядә хәтта сугыш вакытында да бу увлечениедән арына алмадым. 1934—35 елларда, Оренбург күчмә театры килгәндә, аның массовый сценаларына катнаша идек.

Бу елларда мин күчмә киномеханик булып та, район саклык кассасында бухгалтер яки район тегермәннәр комбинатында хисапчы булып та эшләп алдым.

---

[1] Халикъ Садри (1890—1955) — татар совет язучысы.

1936 елның азагында, абыем Мирза Давыдов чакыруы белән Новосибирскига барып, «Советская Сибирь» газетасына әдәби сотрудник булып эшкә кердем. 1938 елны мин Фергана шәһәрендә бер кардәшем янына киттем. Анда бик тиз рус өлкә газетасына урнаштым, аннан үзбәк өлкә газетасында, многотиражкаларда эшләдем. 1939 елны корсак тифе белән бик каты авырдым. Врачлар киңәше белән Рәсәйгә кайттым.

Апам һәм җизнәм (Нарбековлар) Ләмбрә районының Белозерье[1] тулы булмаган урта мәктәбендә укыталар иде, анда бардым. Рус теле укытучысына мәктәп бик мохтаҗ икән, аннары тарихчы да (минем җизни белән бергә) армиягә китеп барды. Мин бу фәннәрнең бөтенесен үз өстемә алып, укытучылык эшенә (бик яратып) керештем. Отличник укытучы исеме алдым.

Уку елы беткәч Казанга килеп, Фергана каналын төзүгә багышланган поэмамны Муса Җәлилгә һәм Тукай клубында тагын 3—4 кешегә (кемнәр булгандыр, белмим) укыдым. Хуплау, тәнкыйть, төзәтергә киңәшләр ишеттем. Канатланып Камышлыга кайттым. Әмма мин некрут идем инде, поэмага вакыт җитмәде, берничә саубуллашу концерты һәм постановкалар куйдык (мин татарча да, русча да катнаша идем), кызларны юаттык, армиягә китеп бардык. Баштан монгол границасы, Даурия, аннан, сугыш башланыр алдыннан (апрель-майларда) көнбатышка таба юл, аннары сугыш һәм турыдан-туры фронт. Безнең Башкомандующий резервындагы аерым зенит артиллериясе батальонын Смоленск тирәсендә бик нык «мунчалаладылар», җимерделәр, командирлар каушады бугай. Без десантлы Ярцеволар, Соловьевск переправалары, янып торган Дорогобужлар аша берәр орудиеле группалар, яки берәр отделение булып чигендек. Аннан мин машиналарга урнаштырылган җиңел орудиеле дивизион составында 44 нче (ә декабрьдан соң 7 нче гвардейский) танк бригадасына элэктем. Аның белән Көньяк-көнбатыш фронтында сугыша башлаган идек, Тихвинны дошман алгач, безне анда ташладылар, анда бер ай сугышып, дошманны урыныннан кузгаттык, карлы юллардан куып киттек.

Сугыш сугыш инде, мин аның башыннан ахырына кадәр солдат, ефрейтор, сержант званиеләрендә боевой частьларда үттем. Күп язарга туры килмәде. Армия газетасына берничә очерк, блокнотка язылган берничә шигырь һәм, солдатларның сорауларын үтәп, аларның өйләренә — сөйгән кызларына, хатыннарына, әниләренә «килештереп», кайчагында рифмалап язылган хатлар.

Сугышка кадәр мин бик күп әсәрләр язган идем — берничә поэма, бик күп шигырь, бер роман, бер пьеса һәм башкалар. Боларның берсе дә мин кайтканчы сакланмаган. Таш келәтебез ишелгән, әйтүләренә караганда, минем яраткан китапларым да, кульязмаларым да шуның ташлары, балчыгы астына тирән күмелеп калган.

1936—37—38 елларда район газетасында басылган һәм сугышка кадәрге дусларым архивында калган беркадәр шигырьләрне генә таба алдым.

Кайту белән (1946) район татар газетасына[2] редактор итеп билгеләделәр. Газетаны яхшырту буенча экспериментлар белән наборщиклар, печатникларны (эчтәлеге үземнән, хәбәрчеләр активы белән, халык белән бәйләнешемнән, чөнки штатта тагын секретарь гына бар иде) җәфалый башладым, әмма алар үзләре дә бу азартка тизияреп киттеләр, газета ясауны бик зур горурлык белән эшлиләр иде. Арада берничә ел ике газетаны да редакцияләдем. Үз газетамда («Югары уңыш өчен») шигырьләр дә, фельетоннар да бастырдым. 1947 елны Казанга берничә шигырь җибәрдем. Консультант Гыйззәтуллинадан җылы хат килде. Үз инициативасы белән язган шагыйрь Салих Батталның кырыс, әмма гадел хаты аеруча канатландырды. Шигырьләр, поэмалар яза башладым.

Яшь язучыларның икенче конференциясенә (1948 ел, 28 ноябрь) килдем. «Коммунизм таңы» колхозында» поэмасыннан бер тезмә укыдым, җылы сүзләр ишеттем.

Апрельдә бу поэма яңадан эшләнеп дөньяга чыкты. Ә көзен — «Алтын көз» поэмасы. Менә шулай район атмосферасыннан үзебезнең сөекле һәм чиксез ихтирам иткән зур әдәбиятыбыз орбитасына килеп чыктым. Аннан китаплар («Беренче бөртек», 1950 ел). Калганы сезгә мәгълүм инде. «Татар әдәбияты өчен шушысы

[1] Мордва АССРда бер авыл, хәзер Ромадан районына керә.
[2] Куйбышев өлкәсенең Камышлы район газетасы «Югары уңыш өчен».

әһәмиятле» дип бер әсәремне дә аерып әйтә алмыйм. Бөтенесендә максат — бүгенге поэзияне дөнья әдәбиятының (шул исәптә беренче урында, һичшиксез, үзебезнең әдәбиятыбыз тора) бөтен казанышлары нигезендә эшләргә тырышу, бертөрлелектән арынырга тырышу. Өметем — әсәрләрем зур мөстәкыйль әһәмияткә ия булмасалар да, әдәбиятыбызның, поэзиябезнең яңа буыннарына бер ярдәм, черновой бер эш була алыр бәлки.

Берничә җыр конкурсында катнаштым, берсендә беренче һәм икенче бүләкләрне алдым, срокларын, составларын хәтерләмим.

Союзга[1] 1953 елны алындым. 53—55 елларда ТАССР язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре, 1954—55—56—57 елларда правление члены, берничә ел шагыйрьләр секциясе җитәкчесе.

Моннан соң бирелгән сорауларның күбесенә югарыда җавап бирелде.

Форма өчен Мәскәүдә 1954 елда Муса Җәлил бәйрәмен үткәрергә җибәрелгән делегациянең җитәкчесе булуымны, әдипләр йортында[2] чыгыш ясауны, 1958 елда Уфада РСФСР язучылар союзы пленумында, 1955 елда Удмурт язучылары съездында, Алабугага барган зур бригадада (1954 елда, Сәйдәш тә бар иде) һ. б. һ. б. катнашуымны әйтергә **мөмкин**. Әмма мин Союзда эшләгәндә Гомәр абый[3] минем кая да булса чыгып йөрүемне Союз эшенә зыян китерә дип саный иде бугай. Хәер, мин үзем дә төп игътибарны Союзда секцияләрнең эшен оештыруга, язучыларның иҗат ихтыяҗларына ярдәм итүгә юнәлтә идем, вазифамны шулай аңлый идем. Гаделлек дигән нәрсә бар икән, күп иптәшләр (олыраклар да, яшьрәкләр дә) аларның аерым әсәрләрен эшләү, чыгару эшенә кулымнан килгәнчә ярдәм иткәнемне онытмаганнардыр.

Районда һәр вакыт (1946—1952) райком члены була килдем. Казанда, 1955 елда бугай, горком члены итеп сайландым.

Бүләкләрем — медальләр, благодарностьлар, почет грамоталары.

Әлегә җитеп торыр. Язсаң бик күп язарга мөмкин бит. Тагын сезне кызыксындырырлык мәсьәләләр тапсагыз, җавап бирергә (әлбәттә, гадәттәгечә соңгарып) әзермен.



*
* *

Дүрт ел буена барган авыр сугыштан миндә бик күп истәлекләр калган. Шулар арасында сугышның ике ноктасы — башлану һәм бетү көннәре күңелдә аеруча күренекле булып торалар.

1945 елның май башында безнең дивизион Ригадан төньяк-көнбатышка таба бер урманда тора иде. Волхов фронтыннан, Ленинград блокадасын җимерүдән башлап, Эстония, Латвия җирләрен азат итә-итә бик күп чакрымнар узылган. Бу көннәрдә дивизион чагыштырмача тынычрак урында, ләкин тиздән аны тагын алгы сызыкка таба күчерәчәкләр.

Моннан берничә дистә километрда гына бер төркем гаскәрләр, немецларны камап алган «Курляндия казаны» дип аталган боҗраны кыса-кыса, каты сугыш алып баралар.

8 май төне. Соңгы көннәрдә солдатлар арасында сугышның менә-менә тукталачагы турында күп сүз йөри. Шуңа күрә кичләрен батареяда тиз генә ятмыйлар, төркем-төркем җыелып сөйләшәләр, хыялланалар. Ләкин хәзер инде бик соң, сәгать ике, батарея тып-тын. Сакчылар һәм дежур командирлар гына йокламый. Ләкин мин дә үз землянкамда уяу, күзгә йокы керми. Мин — радист, кыска дулкынлы, көчсез, кечкенә радиостанциямне бора-бора, эфирны тутырган төрле сигналлар, хәрби приказлар, шифрлы морзянкалар аша Мәскәү дулкынына үтеп керергә тырышам. Тик барып чыкмый, станция көчсез, эфирда комачаулап торган авазлар бихисап. Ләкин менә кинәт Мәскәү дикторының таныш тавышы. Германия капитуляциясе дигән сүз колакка керә, һәм мин Германия властьларының капитуляция

[1] СССР Язучылар союзы членлыгына кабул ителү турында сүз бара.
[2] Әдәбиятчыларның Мәскәүдәге Үзәк йорты.
[3] Язучы Гомәр Бәширов. Ул вакытта Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе.

актына кул куюлары турында хәбәр тыңлыйм. Ләкин ахырына кадәр тыңларга түземем җитми, йөгереп батареяга чыгам да:

— Иптәшләр, җиңү, Германия капитуляцияләгән! — дип кычкырам.

Күрәсең, барысының да йокысы тирән булмаган, бер минутта бөтен батарея аякта, шау-гөр килә, кочаклашу, үбешү, кемдер, салют, дип, винтовкадан атып җибәрә, аңа бөтенесе кушыла, винтовка, автомат тавышлары яңгырый, кайсыдыр пушкадан да гөрселдәтеп һавага атып җибәрә. Таңны без әнә шундый гаҗәп тантана белән каршы алдык.

Аннан бер төркем солдатларга Ригага барырга рөхсәт бирделәр. Анда безнең тантана хисләре шәһәр халкының куануына, аналар һәм балалар шатлыгына барып кушыла. Менә шундый тантана белән бетте ул сугыш.

Ләкин аның башлану истәлекләре бик авыр. Ул минем өчен беренче тапкыр үлем белән, иң фаҗигале бер үлем белән очрашудан башланды.

Смоленск шәһәре тирәләрендә иде бу. Бер күчену вакытында безнең дивизион машиналары, берничә минут ял итәр өчен, солдатларның кипкән тамакларын салкын су белән чылату өчен, юл буендагы коелы бер йорт янына туктаган иде. Хуҗа хатыны үзенең 7—8 яшьлек кызы белән безгә чиләктән татлы кое суы эчерә. Кинәт күктә мотор тавышы, безнең өскә дошман самолетлары килеп чыга. Менә без нишләргә уйлап та өлгерә алмыйбыз, тирә-як гөрселди башлый. Минем күз алдында нинди фаҗига булганын соңрак мин «Кояшлы көн» дигән поэмада чагылдырдым. Дөрес, мин анда художество максатларыннан чыгып, вакыйганың урынын бераз үзгәрттем. Ләкин минем өчен сугышның беренче тәэсире, беренче күренеше бик дөрес бирелгән [1].

## Сөйләшәсе мәсьәләләр күп [2]

Совет язучыларының Икенче бөтен союз съезды алдыннан табигый рәвештә куерып киткән сөйләшүләрнең, бәхәсләрнең иң зур өлеше поэзия өстенә төшә. Минемчә, бу факт үзе үк безнең поэзиянең әһәмиятен күрсәтә һәм хәзерге торышын билгеле торган күренешләрнең берсе булып тора.

Ләкин, Сибгат Хәким әйткәнчә, шунысы гаҗәп, поэзия турындагы сөйләшүләр шау-шуында бер генә татар шагыйренең тавышы да ишетелми әле. Әйтерсең безнең поэзия үзенең бүгенге үсешендә бөтен совет поэзиясе кичергән кыенлыкларны кичерми, әйтерсең татар шагыйрьләре поэзия алдына бүген халык куйган таләпләрдән бөтенләй читтә торалар яки кешеләрдә канәгатьсезлек хисе тудыра торган җитешсезлекләрдән буй җитмәслек дәрәҗәдә югарылар.

Бу дөрес түгел, әлбәттә. Зур совет поэзиясенең бер өлеше буларак, татар совет поэзиясе дә үзенең үсешендә бөтен поэзия кичергән уңышларны һәм кимчелекләрне, уңайлыкларны һәм авырлыкларны кичерде һәм кичерә. Моңардан тыш, милли поэзия буларак, аның әле үзенә генә хас булган сыйфатлары, үсү юлында үзенә генә хас булган уңышлары һәм кыенлыклары бар. Үзара сөйләшкән вакытларда без бу хакта әллә нәрсәләр әйтеп бетерәбез, һәм күп мәсьәләләргә карашыбыз төрлечә икәнлеген күрәбез, ләкин үзебезнең фикерләрне ни өчендер җәмәгатьчелек алдына чыгарырга һәм шул юл белән бер гомуми хакыйкатьне булдырырга тырышмыйбыз.

Мин бүгенге сүземдә, әллә нинди төзеклеккә һәм эзлеклелеккә өмет итмичә, хәзерге вакытта матбугатта поэзиягә карата аеруча басым ясап әйтелә торган кайбер фикерләргә генә тукталырга һәм шул фикерләрнең дөрес яки дөрес түгеллеген күбесенчә үзебезнең поэзия практикасында билгеләргә тырышачакмын. Миңа сез барыгыз да ярдәм итәрсез дип уйлыйм.

Газета-журнал мәкаләләреннән һәм төрле җирдәге чыгышлардан аеруча теңкәгә тигән фикерләр нинди ләр соң?

---

[1] Бу мәкалә шагыйрьнең фронт көндәлегеннән алынды.

[2] Татарстан язучыларының III съездында сөйләр өчен хәзерләнгән бу докладта безнең бүгенге поэзия өчен кайбер каршылыклы фикерләр дә бар; әмма Ә. Давыдов күтәргән күп кенә мәсьәләләрнең әле һаман да әһәмиятле һәм актуаль булуын искә алып, редакция аны укучыларга тулы килеш тәкъдим итәргә булды.

1. Хәзер поэзиянең беренче дәрәҗәдә әһәмиятле әдәби жанр булуын шик астына кую бик еш сизелә. Моңарда, гомумән, әдәбиятның үсешенә дөрес булмаган караш чагыла. Поэзияне аерым бер халык әдәбиятының үсеш процессында иң түбәнге баскыч, башлангыч бер адым итеп карыйлар. Янәсе, халыкның рухи үсеше алга барган саен аның әдәбиятында да җитдиләшү, тирәнәю бара, нәтиҗәдә поэзия кебек җиңел жанр үзенең беренчелеген проза кебек җитди жанрга бирә бара. Бу — тарихка иң примитив карашның бер нәтиҗәсе. Беренчедән, поэзиянең әдәби жанр буларак алданрак барлыкка килүе һәм үсүе һәр очракта да дөрес дип әйтерлек исбат ителмәгән әле. Икенчедән, әгәр халык үзенең тормышында, көрәшендә рухи коралга мохтаҗлыкны сизә башлагач та, беренче чиратта, поэзияне барлыкка китерә икән, ул фәкать поэзиянең аеруча халыкчан, халык өчен беренче дәрәҗәдә кирәк бер жанр икәнлеген күрсәтә. Моннан соң әдәбиятның башка жанрларының барлыкка килүе һич тә поэзияне юкка чыгару исәбенә бармый, ә халыкның рухи үсешен чагылдырып, әдәбиятның киңәюен билгели. Поэзия исә, халык белән бергә, бөтен әдәбият белән бергә, үзенең үсешен дәвам иттерә, тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрелеп, халыкның идея көрәшендә сугышчан корал ролен тагын да зуррак көч белән үти. Поэзия башка жанрларның аны кысып чыгаруына бер дә зарланмый, башка жанрларны кире какмый, киресенчә, башка жанрларның үсүе поэзиянең үсешенә уңай йогынты ясый, аның форма һәм эчтәлек байлыгының артуына ярдәм итә. Сүзне озынайтмас өчен бер фактка гына күз салыйк: бүгенге поэма, проза, публицистика, драма кебек жанрлардагы үзе өчен кабул ителерлек якларны үз эченә алып, чыннан да яңа баскычка күтәрелде.



Бу мәсьәләдә тагын бер фактка төртеп күрсәтергә яраталар: янәсе, прозаик әдәбиятта үзенең беренче адымнарын шигырь белән башлый да, акыл керә башлагач, хикәяләр, романнарга күчә. Монда Пушкинның мәгълүм бер юлы китерелә:


**Лета к суровой прозе клонят...**

Әйтерсең Пушкин чыннан да поэзияне ташларга уйлаган да, аның җитди бер жанр була алмавына ышанып кул куйган. Әмма бу юлда шагыйрьләр өчен бик күп уйланырлык хакыйкать яшеренгән. Александр Сергеевич поэзиягә мәхәббәтеннән бер дә ваз кичәргә уйламый, ә таланты ныгыган саен тормышның авыр, җитди, зур мәсьәләләренә поэзия коралы белән тирәнрәк керергә омтылганын чагылдыра. Прозага күчүләрен поэзияне кирәксез бер шалтыравык итеп читкә ташлауда күрсәткән прозаиклар өчен мин бер нәрсәне генә әйтер идем: әгәр бүген безнең Әпсәләмов, яки Хәсни, яки башка берәр прозаик үзендә кинәт Пушкин таланты барлыкка килүен сизсә, ул, һичшиксез, иртәгә «Евгений Онегин»ны язарга керешер иде.

Югарыдан нәтиҗә килеп чыга ки, әдәбиятның башка жанрлары кебек үк, поэзия үзенең әһәмиятен һич югалтканы юк, ул халык кулында иң кирәкле сугышчан корал.

Уйлабрак караганда, поэзиянең роле дә, әһәмияте дә аның иң яхшы вәкилләренең гасырлар буена алып барган хезмәте белән генә түгел, социалистик илебезнең бөек әдәбиятын тудыру, үстерү практикасы белән, әдәбиятның илне социалистик үзгәртеп коруда катнашуы практикасы белән дә ачыкланган бит инде. Дворяннар Россиясенең иң авыр шартларында илнең намуслы улларының самодержавиегә каршы батыр көрәшен Пушкин иҗатыннан, Пушкинның бөтен эшчәнлегеннән һич аерып карап булмый. Үз чорының яшьләрендә революцион-демократик рух уятуда Некрасов иҗатының роле һәркемгә билгеле. Татар хезмәт ияләренең иҗтимагый аңнарының үсүе тарихында Тукайның роле шулай ук һич кем түгел. Ниһаять, Маяковский. Социалистик төзелеш өчен көрәштә аның сатирасы, лирик шигырьләренең һәм поэмаларының элек булган әһәмиятен әйтеп тормастан, бүгенге көннең кайбер фактларына гына күз салыйк: һәр көнне, безнең матбугат коммунистик төзелешнең теләсә кайсы мәсьәләсе буенча чыгыш ясаса да, халыкның, партиянең теләкләрен, таләпләрен, омтылышларын чагылдыру өчен иң дөрес һәм көчле юлларны Маяковский иҗатыннан китерә.

Мин һәркемгә билгеле булган бу хакыйкатьләрне бүген искә төшерү шуның өчен кирәк дип табам: кайберәүләрнең поэзиягә ялгыш карашлары тәэсирендә шагыйрьләребезнең дә кайберләре хәзер үз профессияләренә хөрмәт тойгыларын



*«Буыннар батырлыгы» шигыренең карала-масыннан фотокүчермә.*

югалтып баралар. Соңгы вакытларда безнең арада хөкем сөрә башлаган иҗат пассивлыгына сәбәпләрнең берсе, минемчә, шул. Безгә шуны искә төшерергә кирәк, әдәбият тормышында актив катнашу ул безнең аерым вакытлардагы кәефебезгә дань бирү генә түгел, ә безнең көндәлек бурычыбыз, мәҗбүри бурычыбыз.

Татар совет әдәбиятында да поэзия иң алдынгы жанрларның берсе булып килде һәм шулай булып кала да. Коммунизм идеяләрен сәнгатьчә гәүдәләндерүдә, уңай идеалларны раслауда, гаять бай эчке дөньялы, чын-чыннан югары рухи сыйфатлы совет кешеләренең үрнәк алырлык образларын тудыруда аның роле чиксез зур. Степан Щипачев үзенең «Правда» газетасындагы «Поэзиягә көчле канат» дигән мәкаләсендә кайберәүләрнең сугышка кадәрге рус поэзиясенә дөрес бәя бирмәүләренә, аңарда гражданлык мотивлары аз иде дип, бозып күрсәтүләренә каршы чыга. Щипачевның бу сүзләренә кушылып, без шуны әйтә алабыз: татар поэзиясендә исә сугышка кадәрге елларда гражданлык мотивлары үзәк урында торалар иде. Һади Такташ, Муса Җәлил, Нур Баян, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Шәйхи Маннур, Максуд Сөндекле, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким, Шәрәф Мөдәррис h. б. иптәшләрнең шигырьләре һәм поэмалары асылда совет кешеләрендә гражданлык, патриотлык хисләре тәрбияләүгә, иҗтимагый хезмәткә дан җырлауга юнәлдерелгән иделәр дә.

Бөек Ватан сугышы еллары безнең шагыйрьләребезнең иҗатына яңа бер этап булып керде. Ул елларда, халык тойгыларын, омтылышларын, теләкләрен чагылдыручы буларак, дошманга карата зур нәфрәт тәрбияләүче һәм тирән патриотик хисләрне кузгатучы корал буларак, поэзия яңа баскычка күтәрелде.

2. Менә шуннан инде теңкәгә тигән фикерләрнең икенчесе башлана. Кайбер кешеләрдә, хәзерге поэзиянең артка калуы турында сөйләгәндә, сугыштан соңгы поэзияне бөтенләй сызып ташлау тенденциясе бар. Гүя сугыш бетү белән, безнең поэзиягә ниндидер стихия бәласе килгән, аңарда талантлар югала бара, аның тормыш чишмәләре катастрофик тизлек белән кибә, поэзия котылгысыз һәлакәткә бара. Дөресме соң бу? Әлбәттә, һич дөрес түгел. Һичшиксез, халык поэзиянең бүгенге торышы белән канәгать түгел, ул аңарга үзенең таләпләрен куя, ләкин бу таләпләр белән (соңгы вакытларда модага кергәнчә) поэзияне берөзлексез сүгү арасында җир белән күк аермасы бар.

Халык шуңардан чыгып эш итә: совет әдәбияты, шул исәптән аның иң сугышчан жанры — поэзия, безнең бөтен чынбарлыгыбыз кебек үк, туктаусыз үсеш кичерә, алга бара, һәм хәзер, аның чиксез уңышлары булган хәлдә, инде ул яңа, тагын да катлаулырак бурычларны хәл итәргә әзер.

Чыннан да, сугыштан соңгы елларда поэзия ниндидер кибүгә, түбәнәюгә дучар

булмады гына түгел, киресенчә, аңарда яңа күтәрелеш барлыкка килде. Бу еллар кешенең — җирдә тормыш, бәхет иҗат итүче совет кешесенең җаны-тәне белән сагынган тыныч иҗади хезмәтенә кайтуы өчен азыкны сугыш елларының киеренке, утлы-давыллы шартларыннан кимрәк бирмәде. Мөхәммәт Садриның «Бәхет турында җыр»ы дошманга карата аяусыз булган совет кешеләренең тыныч хезмәткә кайту шатлыкларын, аларның тормышка чын мәхәббәтләрен һәм чын гуманистик идеяләр белән януларын югары пафос белән ачып бирә. Сугыш безнең тыныч төзелешебезгә, социалистик төзелешкә зур зыян китерде. Ләкин җәмгыятьнең үз эчендә үсеш процессы бөтенләйгә туктап калмады бит. Сугыш елларында ук, мәсәлән, колхозлар тормышында яңа проблемалар барлыкка килде. Тыныч хезмәтенә кайткан колхозчы (аеруча авыл коммунисты) тукталып калган эшен яңартып кына кала алмый, колхоз төзелеше алдында баскан яңа проблемаларны хәл итәргә һәм аларны сугыштан соңгы беренче елларның авыр шартларында хәл итәргә тиеш була. Салих Батталның бөтен союз укучысына барып җиткән «Олы юл буйлап» исемле шигъри повесте җанлы образлар аша менә шул процессны оста итеп ачып бирде.

Моңардан тыш, Бөек Ватан сугышы үзенең искиткеч нәтиҗәләре, совет строеның җимерелмәс көч икәнлеген раславы, безнең халкыбыз көч чыганакларының бетмәс-төкәнмәслеген күрсәтүе белән шагыйрьләргә философик гомумиләштерү өчен чиксез бай материал бирде. Сибгат Хәкимнең «Дала җыры», «Бакчачылар» поэмаларында без шуның шактый көчле чагылышын табабыз. Болардан тыш, без тагын сугыштан соңгы тормышыбызны, уйларыбызны, хисләребезне чагылдырган поэмаларны, шигырьләрне бик күп күрсәтә алабыз. Шуны уйлап карасак, поэзиянең бетүе турындагы сүзләрнең иң кимендә сукыр нигилизм булуын күрербез.

3. Ләкин, без югарыда әйткәнчә, халыкның поэзиягә югары таләпләре, аның бүгенге тормышындагы шактый күп җитешсезлекләр белән бик хаклы килешергә теләмәве бар бит әле. Бу хакта да сүз бик нык куертыла һәм мең төрле рецепт бирелә. Бүгенгә кадәр иң таралган версия шул: шагыйрьләргә, янәсе, тирән хис җитми, алар укучыларның күңелендәге иң нечкә кылларны чиерттерә белмиләр, ягъни безгә күбрәк лирика кирәк. Мондый сүзләрдән соңра совет кешеләренең күңелендәге нечкә кыллар нигездә мәхәббәт белән, сагыш белән генә, яки шундыйрак характердагы башка хисләр белән генә бәйләнгән дип аңлыйсың. Әле шушы көннәрдә генә зур шагыйрь Щипачев та үзенең мәкаләсендә лирика турында сөйләгәндә аны мәхәббәт һәм мәхәббәттә тугрылык турындагы, табигать турындагы шигырьләргә кайтарып калдырды. Дөрес, Щипачев моны беренче булып әйтми, моны инде без үзебезнең якларда да бик күп ишеткәнебез бар, бер зур шагыйрьнең мәсьәләне шундый җиңеләйтеп куюы мине бик гаҗәпләндерде.

Матбугатта шундый чыгышлардан мин тагын берсенә тукталып китәргә уйлыйм. Бусы инде үзебездә, Казанда. Мин Сибгат Хәким китабы турында Хатипов[1] рецензиясен әйтәм. Кайберәүләр бу статьяны Сибгат алдында подхалимлык күренеше дип гаеплиләр. Минемчә, монда эш безнең бер иптәшебезне бераз мактап алуда түгел, монда мин каравыл кычкырырлык бернәрсә дә күрмим. Статья шагыйрьнең иҗатын никадәр дөрес ачып бирә, аның иҗатындагы үстерелергә тиешле якларны никадәр дөрес күрсәтә, җитешсез якларын никадәр дөрес тәнкыйтьли? Төп эш менә нәрсәдә. Ә рецензент исә бу мәсьәләдә, минемчә, бик нык ялгыша. Ул шагыйрьнең шактый күләмле иҗатының үзәгенә «Фазыл чишмәсе» дигән җырны куя, ә Хәкимнең башка шигырьләрен, хәтта инде укучы тарафыннан мәхәббәт казанган билгеле поэмаларын да, икенче дәрәҗәдәге әсәрләр рәтенә кертеп, санап кына китә. Ә бит Сибгат Хәкимнең иҗади йөзен, хәтта Хатипов әйткәнчә, лирик шагыйрь буларак иҗади йөзен дә «Фазыл чишмәсе» билгеләми. Тукай турындагы поэмалар, «Курск дугасы», башка бик күп тирән эчтәлекле, гражданлык пафосы белән сугарылган шигырьләр Хәкимне совет шагыйре буларак тулырак характерлыйлар.

Ярый, теге мәсьәләгә кайтыйк. Бәлки, чыннан да, поэзиянең төп җитешсезлеге аның мәхәббәт, сагыш, табигать күренешләре турында аз әсәрләр бирүендәдер? Хәзер безнең практикада моның дөреслеген, дөрес түгеллеген тикшерү өчен җитәрлек материал бар дип уйлыйм. Соңгы вакытларда (кимендә менә бер ел инде)

---

[1] Тәнкыйтьче Фәрит Хатипов.

шагыйрьләребезнең күпчелеге диярлек мәхәббәт темасына йөзләрен тулысынча бордылар. Бу темага шушы кыска срок эчендә генә дә инде уннарча шигырьләр язылды. Ш. Мөдәррис «Совет әдәбияты»нда үзенең моңга манчылган сонетларын бастырып чыгарды. Н. Арслан көтмәгәндә яшьлегеи сагына башлады, маневренный паровоз гудокларын да инде ул хәзер тыныч кына тыңлый алмый. Сибгат Хәким, Зәки Нури, Мәхмүт Хәсәен, Әнвәр Давыдов һ. б.— һәрбер шагыйрь диярлек бу темага үзенең өлешен кертеп өлгерде инде. Бу шигырьләр арасында, һичшиксез, уңышлылары, матурлары, чын-чыннан күңел кылын тибрәтерлекләре бар. Югарыда әйтелгән ноктадан чыгып карасак, хәзер безгә инде поэзиянең яңа күтәрелеше башлануы турында хаклы рәвештә сөйләргә мөмкин була кебек. Ләкин чынлыкта шулаймы соң? Юк, әлбәттә. Киресенчә, без хәзер шуны әйтә алабыз, поэзиянең чын-чыннан, нығытып артка калуы безнең менә шушы кискен борылышыбыздан соң башланды да.

Халык, партия безне халкыбызның тормышын, аның рухи дөньясын тулырак чагылдырырга чакырды, шагыйрьләрнең күп очракта совет кешеләренең эчке дөньясын ярлыландырып, бер яклы гына итеп бирүләрен тәнкыйтьләде, безгә тормышны үткенрәк күз белән күзәтергә, аның эчендәге тирән процессларны да күрергә, горизонтыбызны да киңәйтергә кушты, ә без, киресенчә, тормышның күп кенә мөһим мәсьәләләреннән йөз чөереп, мәхәббәт, интим кичерешләр өлкәсенә ташландык, кыйбла ташына шул сүзләрне язып куйдык. Халык безгә тормышның бер кирәкле өлеше булган шушы мәсьәләне дә искә төшерергә кушты, ә без тормышның кадагы итеп шул бер мәсьәләне куйдык та тормышның, чынбарлыкның бөтен башка мәсьәләләреннән ваз кичтек. Нәкъ менә шушы факт, минемчә, хәзер безнең поэзиянең үсешенә комачаулап тора да һәм мондый карашлардан арыну поэзия язмышында иң беренче практик бурыч. Без моны хәл итмәсәк, тормыш белән поэзия арасындагы өзеклек, һичшиксез, киңәячәк кенә һәм поэзиянең чыннан да ярлылануына, тормыштан артка калуына китерәчәк.

Бер мисалны гына искә төшерәм: КПСС Үзәк Комитетының сентябрь, февраль — март пленумнары карарлары илебез тормышында әйтеп бетергесез зур роль уйнадылар. Алар илебездә яңа үзгәрешләр, яңа уңышларга таба халыкның бөек хәрәкәтенә куәтле этәреш бирделәр. Аларда безнең көннәрнең характеры, безнең эшләрнең бөеклеге чагыла. Менә шушы, бер караганда будничный гына булып күренгән эшләрнең бөек мәгънәсен, эчтәлеген мастерларча художество чаралары белән ачып бирү үзе поэтик әсәрләргә үлемсезлек китерер иде. (Ә мондый бәхет турында безнең кайсыбыз хыялланмый!) Ләкин шигырьләрнең кампанейский булуыннан курку безнең күп кенә сәләтле шагыйрьләребезне бу карарларга лаеклы отклик бирүдән тыеп калды. Күбебезнең иҗатында карар тудырган бөек күтәренкелекнең, бөтен халык хәрәкәтенең онытылмас көннәре берничә дә эз калдырмадылар.

Булган откликларга да интим поэзия өчен көрәшүчеләрнең карашлары үзләренең гарипләндергеч тәэсирләрен ясадылар. Бу темага язылган шигырьләр асылда бар да бер төрле: егет авылга китә, кызы шәһәрдә кала яки кызы китеп, егете шәһәрдә кала. Аларның очрашыр вакыты җитте дигәндә генә шигырь дә бетеп китә. Нәкъ «Сак-сок бәете»ндәге шикелле, егет белән кыз һаман очраша алмыйча йөриләр. Шундый «каргалган» кешеләрне без Зыя Мансур, Нур Гайсин шигырьләрендә күп очратабыз.

Ә бөек эшләрнең, бүгенге көннең бөек вакыйгаларының героикасы кая соң? Авылга бүгенге походның, нәкъ менә бүгенге геройның авылга кайтуының тирән мәгънәсе кая соң? Кыскачарак әйткәндә, коммунистик төзелеш рухы, авылны коммунистик үзгәртү рухы кая?

Дөрес булмаган карашлар поэзияне менә шулай гарипләндерәләр, аны үзенең төп бурычыннан — халыкның тарихи үсешенең билгеле бер чорында аның интересларын тирән чагылдыручы булу бурычыннан шулай читкә алып китәләр.

Димәк, поэзиянең артка калу сәбәпләрен безгә мәхәббәт, сагыш, интим хисләр турында безнең күпме, азмы язуыбыздан түгел, беренче чиратта, башка нәрсәдән эзләргә кирәк икән: бу — аның халык интересларын, халык тормышын никадәр тулы

чагылдыру мәсьәләсе. Монда үрнәк өчен Такташ иҗатына күз салып үтәргә мөмкин...

Тагын халыкның бүгенге поэзиягә таләпләре мәсьәләсенә кайтыйк. Без инде хезмәт турында да, илебезнең бәйрәмнәре турында да, коммунизмга бару турында да күп шигырьләр яздык. Аннан, югарыда әйткәнемчә, мәхәббәт темасына да ташланып карадык, ләкин әле халыкның таләпләренә җавап бирдек, поэзиянең артта калуын җиңдек дип әйтә алмыйбыз. Эш нәрсәдә соң? Әйдәгез, безнең кайбер шигырьләргә күз салыйк.

Сүзне мәхәббәт темасына язылган шигырьләрдән башлыйк, чөнки моңа кадәр безнең сүз шул тирәдә барды һәм бу, кайберәүләр аңлавынча, халыкның иң яраткан темасы булып кала.

Әгәр без халык таләпләреннән чыгып эш итсәк һәм халык мәхәббәт турында сөйләнүләрне генә түгел, әмма кешеләрдәге бу көчле хиснең бөтен катлаулылыгы, күпкырлылыгы һәм байлыгы белән ачып бирүне көтә дип аңласак, бу өлкәдә дә безнең уңышларыбыз чамалы икәнлеген күрербез. Мәсәлән, Әхмәт Ерикәйнең байтак шигырьләрендә былбыллар да, рушаннар да, ай да, бакча да, читлектәге кош та — бар да бар, тик мәхәббәт хисе генә юк. Мәхәббәт һәр вакыт кеше күңелен үзенең бөеклеге белән тетрәтә. Ул шундый хис ки, бик күп йомшак характерлы кешеләр аның йөге астында бөгелеп төшәләр, көчле характерлар өчен ул тау-таш актарырлык куәт бирә. Мәхәббәт кайгысы йөрәккә иң әрнеткеч яраларны сала, мәхәббәт шатлыгы еш кына тыштагы һава торышына да тәэсир ясый. Ә бит мәхәббәтне тулысынча ачып бирмичә, бер кешегә карата хисеңнең бер чагылышын әйтеп бирүне үз өстенә алган шигырьләр дә, талантлы кеше тарафыннан язылсалар, мәхәббәтнең әнә шул бөеклеге билгесе белән сугарылган булалар. Мәсәлән, мин Хәкимнең «Фазыл чишмәсе»н шундый шигырьләр рәтеннән дияр идем.

Ә Муса Җәлилнең «Ышанма» дигән шигырендә инде мәхәббәт һәм тугрылык мәсьәләсе зур иҗтимагый югарылыкка күтәрелә; ул ике йөрәк рамкасыннан чыга һәм совет кешесенең чын рухи сыйфатларын билгели торган эталон була, бу кешенең зур мәхәббәте бөтен туган илгә җәелерлек көчле ташкын кебек икәнлеген ачык тоясың.

Мәхәббәтнең кыенлыклары бар. Безнең күп кенә шигырьләрдә ул асылда егет белән кызның үзара аңлашмауларына кайтарылып калдырыла. Мәхәббәтнең бәхетле яки бәхетсез булуын билгели торган башка бик күп җитди мәсьәләләрнең әле бездә хәл ителеп беткәне юк. Аларның күбесен исемләп тә булмый әле. Николай Доризоның «Литературная газета»да басылган бер шигыренең эчтәлеге истә калган. Егет ир хатынын ярата. Ир хатыны да егетне ярата булса кирәк. Ләкин егет үзенең мәхәббәтен хатынга ачмый, чөнки ул үзенең яратуын белдерсә һәм алар аңлашсалар, тиле мәхәббәттән тыела алмаячакларын белә. Бу семья тормышын бозуга илтер, амораль факт булыр иде. Ләкин егет үзенең мәхәббәтен тиңсез көч белән саклый. Монда аның нинди көчле натура булуын һәм мәхәббәтнең бу сынавын үткәннән соң бу характерда тагын яңа көчләр артачагын тоясың. Тормышта менә шулай да була шул. Мин, мәсәлән, Доризоның бу шигыре кешеләрдә мәхәббәткә карата дөрес караш тәрбияләүдә, тугрылыкны һәм мәхәббәтне саклый белүне тәрбияләүдә, Щипачевның артык ялтыравык мораль белән бизәлгән кайбер шигырьләренә караганда, чагыштыргысыз зур роль уйный дип беләм.

Интим дигән шигырьләргә карата тагын бер чагыштыру ясыйсы килә. Мин инде Н. Арсланның яшьлеген сагына башлавы турында әйткән идем. Муса Җәлилнең шундый ук темага язылган «Чыныккан яшьлек» һәм «Соңгы үпкә» кебек шигырьләрен искә төшерик. Боларда тормышка карата чын, ачык характеристика, бер совет кешесенең үткән юлы, яшьлеге турында дулкынландыргыч хикәя табабыз, ә Н. Арслан шигырендә — бернинди сәбәпсез килә торган бер минутлык һәм әһәмиятсез моңаюның кемне дә дулкынландырмый торган авазы.

Мәхәббәт, сагыш темасына күбрәк тукталырга туры килде, чөнки соңгы вакытларда, югарыда әйткәнемчә, ул безнең поэзиянең хәлен күрсәтә торган фактор булып калды. Хәтта без һәрбер көндәлек вакыйгаларны да шуңа бәйли башладык бит. Аннан без әлегә кадәр искә алган шигырьләрнең төп җитешсезлекләре безнең барлык темаларга язылган шигырьләребез өчен дә бик характерлы булып торалар



Автошарж. 1964.

һәм асылда халыкның канәгатьсезлек хисен билгелиләр. Бездә тормышның теге яки бу күренешләренә багышланган шигырьләр дә, әлбәттә, бик күп булды. Ләкин күп очракларда без аларны ничек сурәтләдек? Мәсәлән, тракторчы җир сөрә. Без аның ничек утыруын, тракторның моторы гөрелдәвен язабыз да шунда өстәп куябыз: янәсе, ул йөрәк көчен дә мотор көченә куша. Экскаваторчы кызның җир казуын бөрәмтекләп сурәтлибез. Ягъни безнең күзебезгә нәрсә күренә, безгә нәрсә очрый, шуны түкми-чәчми кәгазь битенә күчерә барабыз. Ә бер нәрсә дә күрмәсәк, шундый ук примитив бер нәрсәне уйлап чыгарырга тотынабыз. Мәсәлән, Зыя Мансур гидростройга карап торган бер художникны сурәтли. Ул, әлбәттә, моны үзе күрмәгән, ә төзелеш турында язарга кирәк булгач, уйлап кына тапкан. Ләкин бит поэзиянең бурычы аерым күренешләрне яки хисләрне гади генә копировать итүдән тормый. Поэзия якты фикер белән тормыш күренешләренең эченә керергә һәм аларны, художество чаралары белән биргәндә, тирән фәлсәфи мәгънә белән балкытырга тиеш. Маяковский бик күптән үк инде входящий впечатлениеләрен исходящий журналларда теркәп баручы шагыйрьләрнең чын шагыйрь була алмаганлыкларын ачып салган иде. Тормышка иҗади караш хәзер безнең бөтен совет кешеләренең төп сыйфатына әверелде, ә нигә соң без, шагыйрьләр, үзебез өчен тормышка иҗади карашны мәҗбүри түгел дип саныйбыз? Коммунизмга таба көчле хәрәкәт пафосы белән янган бүгенге совет кешесе илдә бара торган бөек үзгәрешләрнең мәгънәсен бик тирәнтен аңлый, аларның бөек тарихи ролен белә һәм үзенең иҗади фикерен әнә шул үзгәртүләрне тагын да камилрәк итү өчен тирән уйлануларга юнәлдерә. Менә бүген бөтен дөнья алдына Терентий Мальцев образы басты. Аның образын копировка юлы белән генә биреп карагыз, нәрсә килеп чыгар икән. Юк, безнең бүгенге тормыш турында, киләчәк юлларыбыз турында, гомумән, тормыш күренешләре турында тирән уйлана белми торып, зур гомумиләштерү осталыгына ирешми торып, менә шундый совет кешеләренең образларын тудыру, шундый халыкның рухын һәм теләкләрен чагылдыру һич мөмкин түгел. Димәк, безгә, шагыйрьләргә, тормышны аңлауда, аның законнарын белүдә совет кешеләренең алдынгы вәкилләре дәрәҗәсенә күтәрелергә кирәк.

Менә шунда инде лирика мәсьәләсе килеп баса. Ләкин, Щипачев әйткәнчә, берьяклы мәхәббәт һәм табигать лирикасы гына түгел, коммунизм төзүче, җирдә тормыш һәм бәхет раслаучы, һәртөрле кыенлыклар белән һәр көнне мәгънәле көрәш алып баручы совет кешеләренең алдынгы сафында торган шагыйрьнең тирән кичерешләрен, уйларын, зур фикерләрен чагылдырган лириканы булдыру мәсьәләсе килеп баса. Безнең сөйләшүләр хәзер, минемчә, шул турыда барырга тиеш. Бөек Маяковскийның иҗаты, минемчә, асылда лирикадан тора. Ләкин аның әһәмияте мәхәббәт рамкаларыннан никадәр киңрәк икәнлеген сезгә аңлатып торуның кирәге юк, әлбәттә, һәм андый лириканың мәхәббәтне дә бөтен тирәнлеге белән эченә алуы һәркемгә ачык.

Бу мәсьәләне безнең ачык итеп аңлавыбызны мин поэзиянең киләчәк үсеше өчен беренче дәрәҗәдә кирәк шарт итеп тануымны тагын кабатлап әйтәм.

4. Кыска гына булса да башка кайбер мәсьәләләргә кагылып китик. Мин инде әйткән идем, сугыштан соң безнең шагыйрьләребез поэзиянең шактый әһәмиятле бер тармагы булган поэма өлкәсендә дә бик күп эшләделәр. Ләкин аларның югарыда әйтелгән яхшы үрнәкләре дә зур кимчелекләрдән азат түгел. Аларның, минемчә, төп кимчелекләре уку өчен кызыклы булмауларында. Ә бу үзе нәрсәдән килеп чыга соң? Без поэмаларда да шулай ук тормышның натураль копиясен генә бирәбез, теманы, материалны романтика белән сугармыйбыз. Конфликт урынына — стычкалар һ. б. һ. б... Сибгат Хәким поэмасы турында мин әйткән идем инде. Салих Баттал повестенда да шуңа охшаган җитешсезлекләр бар.

Поэзиядә милли форма һәм халыкчанлык мәсьәләләре дә, минемчә, бүген үзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора. Бу ике мәсьәлә берсе-берсенә бик тыгыз бәйләнгән, һәм аларның икесенә дә әле тулысынча ачыклык кертелгәне юк: милли форма һәм поэзиядә халыкчанлыкның чагылышын кайчак бездә бик примитив аңлыйлар. Мәсәлән, Гази абзый Кашшаф үзенең Муса Җәлил турындагы мәкаләсендә Җәлил иҗатының халыкчанлыгын исбат итәр өчен аның «Тик булса иде ирек» дигән шигырендә җил, аргамак, алтын балык образларының булуын күрсәтә. Ләкин бит иҗтимагый үсеш эзе халык иҗатындагы образларга тәэсир ясый, халык иҗатына яңа образлар китереп кертә[1].

## Блокнотлардан[2]

*

* *

«Такташ Маяковскийдан өйрәнгән», «Җәлил Маяковскийдан өйрәнгән», «Хәким Тукайдан өйрәнә», «Давыдов Маяковскийдан өйрәнә» — мондый катгый раслаулар дөрес түгел. Үзенә хәтле булган шагыйрьләрне, шулай ук дөнья поэзиясендәге чордашларын яхшы белгән **бер шагыйрь дә** укытучысы итеп **бер генә бөекне** сайламас, бик күп башкаларның гаять бай һәм гаять төрле тәҗрибәсенә битараф калмас.

*

* *

Заман каршыга күп төрле төгәл мәсьәләләр куя. Бу көн тудырган темаларда гына түгел, аерым темаларны чишүгә дә кагыла. Әйтик, сугыштан соң һәм хәзер авыл хуҗалыгын үстерү, хезмәт батырлыгы мәсьәләсе. Ни генә булмасын, шагыйрь, язучы **яңа — хәзер туган хисләрдән** читләшә алмый, шулай булгач, ул бу проблемаларны бүгенгечә, бөтенләй яңача эшләнелгән әсәрдә чишүдән котыла алмый.

*

* *

Кызыклы, дөрес, шулай да берьяклырак әйтелгән фикер: синтезлауда, күп кенә төгәл фәннәр очрашкан ноктада бүгенге бөек фәнни казанышлар туды. Әдәбият исә әле алга киткән бүгенге иҗтимагый фәннәрне синтезлау ноктасына җитә алмады. (Сүз асылда татар әдәбияты турында бара.)

Мин бу фикерне гадирәк (хәтта киңрәк тәдер) болай әйтер идем: безнең көн, әле яңа гына узган белән чагыштырганда да, бик югары дәрәҗәдә тора. Заманга лаек язучы булу өчен, беренчедән, заман дәрәҗәсендә интеллектуаль булу кирәк. Ягъни бүгенге фән казанышлары, сәясәт, иҗтимагый тормыш өлкәсендә җитәрлек мәгълүматың булу, бүгенге дәрәҗәдә марксистик-ленинчыл философия белән коралланган булу һәм шул нигездә дөньяга карашыңны синтезлый белү кирәк.

Икенчедән, дөньяның әдәбият-сәнгать өлкәсендәге бөек казанышларын (аеруча үзең эшләгән жанр тирән) тирән өйрәнеп, сәнгатьчә синтезлый белү осталыгы кирәк.

Шулар бергә чын новаторлыкка җиткерә.

---

[1] Моннан соң дәвам итәсе фикерләрен шагыйрь каралама план рәвешендә генә билгеләгән.

[2] Шагыйрьнең өстәл тартмаларында төрле елларда файдаланган бик күп кенә дәфтәрләре калды. Аларга шагыйрь төрле фикерләрен теркәгән. Арада гарәп шрифты белән язылганнары да, рус телендә язылганнары да шактый.

*

* *

Халык тормышын белү кирәк, ә бер группа кешеләр тормышын түгел (гәрчә ул группа зур гына коллектив булса да). Халыкның бүген нәрсәгә мохтаҗлыгын, аның экономик, политик, культура таләпләрен, аның тормышындагы хәрәкәтләрен аңларга кирәк. Гомер буе колхозда яшәп тә, колхоз хәрәкәтенең мөһим мәсьәләләренә төшенмәскә мөмкин бит.

Партия карарлары тормыш (яки әдәбият) кору өчен бер трафарет түгел, ә яшәешне тирән белгән хәлдә, сүз тормышның аерым бер өлкәсе турында бара икән, шул өлкәне тирәнтен белеп, аның халәтен, таләпләрен, кирәк-яракларын, үсеш тенденциясен, хәрәкәтен аңлап, тормышта куллану өчен чыгарылган карарлар.

Димәк, эш фәлән хәтле язучыны чирәм җиргә яки нефть районнарына җибәрүдә генә түгел. Эшнең асылы шул — язучыларның әсәрләре үзләренең сәнгатьчә булулары, идеяләре белән халык ихтыяҗларына җавап бирсеннәр.

**1956**

*

* *

Кешегә үз-үзен аңлап бетерү кыен булган кебек үк, милли язучыга үз әсәрендәге милли колоритны күрү кыен. Чөнки ул үз халкын читтән күзәтеп торучы түгел, ул халкы эчендә яши, аның фикерен йөртә, аның хәрәкәте белән атлый, аның холкы белән тормыш итә. Язучы үз әсәренә каяндыр алып «милли колорит» калҗасы кертә алмый. Язучы үз милләтенең тормышы белән никадәр бәйләнештә булса, аның иҗатындагы милли колорит укучыга шул кадәр сизелә. Әсәрдә башка милләт кешесе образын биргәндә эш башкачарак тора, бу очракта милли колоритның тышкы эффекты белән мавыгу ялган халыкчанлыкка, ярашуга китерә. Үз халкының геройларын ассызымлап, артык тырышып милли итәргә маташкан язучы да шундый хәлгә тап була.

**1956**

*

* *

Шулай да була: син тырышып-тырмашып стенага кадак кагасың, ә шул ук вакытта сине күзәтеп торучы мәрхәмәтле бер дустың киңәш бирә: «Син чүкечең белән кадакның башынарак сук!» Сүз юк, бик дөрес киңәш, тик килешәсездер, миндә бу киңәш ачудан гайре тойгы кузгатмый.

Безнең кайбер шигырьләр дә нәкъ шул киңәш кебек. Халыкны җир сөрергә, мал карарга, яшелчәгә су сибәргә өнди, ә бу вакытта халыкның без өндәгәннән артык эшләп, тиргә чумып йөргән чагы була.

**1957**

*

* *

Бер иске сорау — тормыштагы кире күренешләрне язаргамы? Язарга. Бар дә яхшы бара, ә бер каһәр сукканы сәүдә эшенә кереп утырган да таныш-белешне генә таный. Бу кеше күңелендә, халык күңелендә сызлану тудырамы? Тудыра. Бу хакта язарга кирәкме? Кирәк! Тик читкә посып кеткелдәүче булып түгел, дөнья прогрессы башында баручы көчле совет кешесе, галәмгә ясалма юлдаш җибәргән баһадир позициясендә торып язарга кирәк.

*

* *

Поэзиядә бүген нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнен, нәрсәне үстерергә, нәрсәгә каршы көрәшергә икәнен белү бик җиңел эш түгел. Дөрес, сәнгатьчә осталык, үлемсез әсәрләр, сүлмәс поэзия өчен көрәшергә тиешбез. Ләкин киң таралган һәм еш

кына ялгыш та аңлана торган «халык таләпләре» дигән төшенчә бар. Моңа гади генә мисал: әйтик, Тукайның моңлы яңгырашы белән, эмоциональ көче, фәлсәфи тирәнлеге белән тиңдәшсез, мәңгегә калырлык күп кенә гүзәл шигырьләре дә киң катлау халыкта, бигрәк тә яшь кешеләр арасында популяр түгел. Шушы ике юллыкны гына карыйк:

**Күз карашымда хәзер үзгәрде әшияләр төсе,**
**Сизелә: үтте яшь вакытлар, житте гомерем яртысы.**



Шагыйрь шулай кешегә житлегү килгәнен фикерли, бер үк күренешләр — әйберләр еллар үткән саен кеше аңы алдында бөтенләй яңа эчтәлек ала, шагыйрьнең өлгергән карашына тормышның яңадан-яңа манзаралары ачыла. Ә бит хәтта бу ике юллыкны укып чиксез дулкынлануга, чиксез моңга бирелүгә сәләтле кешеләрнең дә бик азы бу юлларның асылын — көчле фәлсәфи ягын аңлап уйлана.

Юкса, нәкъ шушы: шагыйрьнең яңа өлгереп житүе, тормыштагы үзгәрешләрне дөрес күрә һәм яңалыклар ача башлавы, тик гомеренең инде яртысы үткән булу һәм шагыйрьнең инде гомер сулу турында уйлануы укучы күңеленә авыр тәэсир итә бит. Ә кайчакта, сер түгел, шушы юллар, әйтик, М. Хәсәеннең кыска буе турындагы шигыренә караганда азрак алкыш ала. Күп кенә иптәшләр алкышка карап «халыкчан» дигән тану белдерә.

*
* *

Бер нәрсәне бик күп төрле вариантларда сурәтләү тәэсирне көчәйтми, ә тарата, вакландыра. Моңардан котылуның классик үрнәге Такташта бар, ул, мәсәлән, Зөбәйдә белән Мәхмүт мөнәсәбәтләре турында кыска гына әйтә дә, тәэсирне көчәйтәм дип, тагын да көчлерәк чагыштырулар, вариацияләр эзләп тормый, ә бөтенләй чит темага, икенче тонга — жиңел шаяруга күчә. Ләкин моңардан Зөбәйдә белән Мәхмүт мөнәсәбәтләренә кызыксыну кимеми, ә күңелне тырнап торган бер уй булып кала килә һәм шуның белән тәэсир көчәя.

*
* *

Поэмалар турында:

1. Поэма өчен материал булды. Тема түгел — материал. Темадан схема туа, материалдан — аны дөрес файдаланганда — кызыклы сюжет туа. Ә бездә тема табып, аны материал дип уйлап, поэма язалар.
2. Сюжет кору. Материалдан иң төп моментларны, иң кирәкле вакыйгаларны табып, узловой вакыйгаларны сайлап алу.
3. Композиция. Шул узловой вакыйгалар арасында кайсы мөһимрәк, шуны аерып куя белү, аларның эзлеклелеген билгеләү һәм логик бәйләү.
4. Геройлар үзләре яшәсеннәр, үзләре эшләсеннәр.
5. Форма.
6. Тел, динамикалы тел.

*
* *

Соңгы елларда безнең илебез поэзиясендә поэмалар шактый күп ижат ителде. Шул кадәр күп ижат ителде ки, хәтта ул жанрның кирәклеген шик астына ала башладылар. Бу хәл кеше йөрәгенә ятышлы, чын югары художестволы поэмаларның күплегеннән килеп чыкмый, әлбәттә. Эш шунда ки, «поэма» билгесе куеп дөньяга чыккан әсәрләрнең күпчелеге, яки поэмаң начар дип бәйләнмәсеннәр өчен «шигъри повесть», «шигъри роман» маркаларына яшеренгән әсәрләрнең аеруча күпчелеге, шагыйрьләрнең ижат лабораторияләреннән вакытсыз чыккан полуфабрикатлар иде. Аларга поэма яки шигъри роман, яки шигъри повесть булу өчен күп очракта чүпрә житми кала, яки башка кирәк нәрсәләр житешми, шуңа күрә укучы-

ның аларга аппетиты уянмый, ә кайчагында, камыры да булмыйча, аның урынына, балалар уенындагы кебек, балчык тутырылган булса, бу укучының ачуын да куптара. Мондый очраклар сирәк булмый. Шагыйрь бер схеманы — ягъни бер күмәч табагын ала да аңа балчыктан ипи әвәләп тыга, укучыны алдамакчы була.

Күп очракта без, шагыйрьләр, әлбәттә, иң яхшы теләкләрдән чыгып эш итәбез. Мәсәлән, безнең чирәмчеләр турында зур поэтик әсәр язасы килә. Чирәм җирләргә матур теләкләр белән китүче, анда яхшы эшләүче, барлык авырлыкларга түзүче яшьләр барлыгы безгә мәгълүм. Шулай ук андагы авырлыкларга түзә алмаучылар, чирәм күтәрүчеләр арасында таркаулык кертергә омтылучылар булуы да билгеле. Беренчеләренең җиңеп чыгуына һәм икенчеләренең хур булуына шикләнү мөмкин түгел. Без менә шушы схеманы рифмага салабыз да поэма әзер дибез. Бездә шуңа охшаган идея схемалары яки атаклы кешеләрнең көйгә салынган биография схемалары күп...

...Сүз поэма жанрының укучы алдында престижын яңарту турында, алай гына да түгел, бу жанрның киләчәктә үсеш юлларын билгеләү турында, аны укучы алдында тулы хокуклы һәм Пушкин, Есенин, Такташ, Маяковский, Некрасов, Твардовский поэмалары кебек үк сөекле жанр итеп, яңа баскычка күтәрелгән жанр итеп үстерү юлларын билгеләү турында бара. Моңа да без бөтен союз поэзиясендә яхшы үрнәкләр таба алабыз.

## Ярдәмең берлә синең[1]

...Кечкенә укучым, син ишектән чыгып тирә-ягыңа каравың булды, синең күңелең ниндидер бер таң калу хисе, ниндидер бер яктылык белән тулды. Әнә, еракта язгы урман нинди матур булып зәңгәрләнеп тора. Син моннан ук аның эчендә сулышка иркен саф һава булу, тормыш уянуын белдергән серле тавышлар барлыгын тоясың. Каршы яктагы өйнең тәрәзәсенә күз төшерү андагы танышларың, дусларыңның ачык йөзләрен синең күңелеңә китерә, син ул йөзләрне көләч итеп күрсәң — эчеңә шатлык, кайгылы итеп күрсәң — моң тула.

Нинди бәхет ул шулай тоя белү!..

Нинди бәхет бу, минем кечкенә укучым! Үз ягыгызның матурлыгына, мәһәбәтлегенә сокланасың да илнең бөеклеген тоясың. Ерак илләрнең серле матурлыкларын күз алдыңа китерә аласың. Туган телеңнең күзгә яшь китерерлек якын яңгырашы аша башка телләрне, аларның матурлыгын, байлыгын аңлый башлыйсың.

Каян килде соң әле сиңа бу бәхетле сыйфат?

Исеңә төшер әле: «Иң әлек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән, аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән». Менә син су буена төшеп су коенып мендең дә туган авылың урамыннан барасың. «Авылымның ямен, суы тәмен беләм, шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән». Әтиең белән беренче тапкыр төнгә юлга чыктың. «Кич иде, шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый, искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый».

Менә синең иң якты хисләреңнең, иң матур рухи сыйфатларыңның төүге чишмәсе кайда!

Тукай!

Бу исем синең күңелеңдә иксез-чиксез рәхмәт хисләре, соклану һәм ярату хисләре уята. Еллар үтәр, синең күңелеңә тагын бик күп матурлык, зирәклек һәм дәртлелек елгалары килеп кояр, син тагын бик күп яңа бөек исемнәрне ятларсың. Ләкин бу исем синең күңелеңә иң якын булып калыр.

Бүгенге татар поэзиясе күпкырлы булып үсә. Үзләренең шигъри алымнары, стильләре белән аерылып торган төрле-төрле талантлар өстәлә. Бу — яхшы күренеш, поэзиянең югары үсеш дәрәҗәсен күрсәткән күренеш. Ләкин бу төрлелек кайберәүләребезне аптырашка калдыра, моңа аңлатулар эзли башлыйбыз. Имеш: фәлән шагыйрь фәләннән өйрәнә.

[1] «Яшь ленинчы» газетасы өчен хәзерләнгән мәкалә.

Юк, шагыйрь бер кешенең генә (кем генә булмасын) өйрәнчеге була алмый. (Ул, гомумән, өйрәнчек була алмый. Шагыйрь — өйрәнчеклектән чыккач кына шагыйрь.) Ул күп буыннар һәм күп милләтләр, илләр шагыйрьләренең тәҗрибәсеннән оешкан дәртле, җанлы организм. Әмма татар шагыйре турында сүз барганда, кайсы шагыйрь генә булмасын, бу организмның җаны, йөрәге — Тукай.

Шигырь юлларын бик җентекләп, тәртип белән тезүче чын «кануни» шагыйрьме, яки рифма, ритм, үлчәм дигән нәрсәләрне иң «мөмкин булмаган» төстә кулланучы «новатор»мы — туган телнең шигъри мөмкинлекләрен гаҗәп көчле концентрациядә туплап калдырган Тукайдан башка — болар берсе дә булмас иде. Хәсән Туфан да, Роберт Әхмәтҗанов та, Гамил Афзал да, Равил Фәйзуллин да.

Телебез байлыкларын шул кадәр нәфис эшкәртелгән формаларга коюны кемнән өйрәнәсең? Нинди генә калыпларга салынса да, ургылып кайнап торган хис, һәр киртәне җимереп бара торган куәтле фикер агымы үрнәкләрен кайдан эзлисең?

Көтелмәгән яңгыравыклы рифма — «әшиләр төсе» — «яртысы» — шагыйрьнең йөрәк өзгеч сагышын тирән фәлсәфи мәгънә белән тутыра. Беркайчан да искерми торган новаторлык түгелмени бу? «Йөзләрең» — «күзләрең» кебек примитив рифмалар арасына бөтен халыкның язмышы турында моңлы бер хикәя сыя.

Татар кадими буржуаз тормышының бөтен асылын иң җанлы һәм иң типик образлар белән гәүдәләндергән, прогресс дошманнарыннан каһкаһәле көлүнең тиңсез үрнәге «Яңа Кисекбаш» әле һаман да үз заманының иҗтимагый тормышына тирән үтеп керүнең, аны ачуның, аның күренешләрен һәм кешеләрен типиклаштыруның классик дәреслеге булып кала.

Менә шулай Тукай безнең һәр поэзия көненә, һәр әдәби кичәгә иң бүгенге шагыйрь булып килеп керә. Ул чын новаторлар сафының башында бара.



## Рецензияләр

**«Ракеталар оча»** [2]**. Әхмәт Исхак. Шигырьләр һәм поэмалар.**

Җыентык кызыклы гына, аны чыгарырга кирәк дигән фикер белән килешеп була. Монда без Әхмәт Исхакның кеше күңелендәге кылларның төрле-төрлеләрен тартkалап карарга омтылуын, фикерләр, хисләр, уйлар, оттеноклар диапазонының киңәюен күрәбез. Совет кешесенең Галәмне яулап алуы турындагы югары пафослы шигырьләр белән бергә, бакчадагы сулган чәчәкләргә карап, киләсе яз турында уйлану яки диңгез дулкыннарының тавышын тыңлау турындагы парчалар совет кешесенең күңелен, уйларын ачып бирүгә шундый ук зур хезмәт итәләр.

Автор кульъязманы булачак җыентыкның проспекты гына дип атаган. Димәк, әле ул җыентык өстендә бик нык эшләүне, аның эчтәлеген (яхшы якка дип уйларга кирәк) үзгәртүне күздә тота. Җыентык өстендә эшләгәндә, безнеңчә, беренче чиратта, игътибарны нәрсәләргә бирергә кирәк соң? Күләмлерәк әсәрләрдән башлыйк. «Галләм бабай истәлекләре» поэмасын без бу килеш җыентыкка кертмәскә тәкъдим итәр идек. Беренчедән, ул бик озын. Поэманың шигъри үзәге булып торган һәм көчле генә итеп язылган урынга — Галләм бабайның кече кызы образы аша аның ярлылыгының бөтен трагедиясен тулы ачып биргән урынга — кадәр автор Галләм бабайны бик озак шамакайландыра, әллә ничә бит бер үк мотивларны кабатлаган һәм туйдырып бетерерлек дәрәҗәдә кешене елмайтырга тырышкан «шаяру»лар сузыла. Икенчедән, монда социаль-тарихи яктан кайбер нәрсәләр бәйләнеп җитми кебек, Галләм бабай сөйләгән вакыйганың вакыты төгәл әйтелеп бирелә: 13—14 еллар. Билгеле булганча, бу империалистик сугышка тоташкан вакыт, халык массалары арасында революцион хәрәкәтнең күтәрелә бару вакыты. Крестьяннарның алпавытларга каршы чыгышлары да нәкъ шушы елларда югары дәрәҗәгә җитә. Большевиклар партиясе, Ленин бу елларда крестьяннарның хәлен ачып бирү буенча күп эшлиләр. Крестьян массаларының күңелен яулап алу өчен политик партияләр арасындагы көрәш бу вакытта бик нык активлаша бара. Әхмәт Исхакның әсәрендә бу

---

[1] Нәшрият соравы белән язылган рецензияләр.
[2] Бу китап 1961 елда басылып чыкты.



*Әнвәр Давыдов гаиләсе белән: (сулдан уңга) тормыш иптәше Нина ханым Давыдова, улы Виктор, Әнвәр Давыдов, аның алдында улы Рөстәм, кызы Алсу һәм апасы Сәлимә Давыдова. 1954 ел.*

һич чагылмый. Меньшевик ниндидер бер пассив чудак итеп бирелә, Галләм бабай да үз чорының крестьянын типик гәүдәләндереп бетерә алмый. Подтекстта гына булса да, бу елларда крестьяннарның чын бәхете өчен көрәшүче большевиклар партиясе булуы тоелмый. Нәтиҗәдә әсәр ничектер почвасыз булып, һавада асылынып, вакыттан да, җирдән дә аерылып кала. Әсәрнең (югарыда әйткән озынлыклардан кыскарту исәбенә) социаль-тарихи якларын тулыландырырга кирәк.

«Бай абзыйның язмышы» турында бернична сүз. Мондый ияру формасындагы әсәрләр бездә еш кына бик очраклы, логик бәйләнешсез, уңышсыз итеп эшләнгән булалар һәм шуңа күрә мин аларга артык симпатия белән карамыйм. Ләкин Әхмәт Исхакның бу әсәрен андый уңышсыз әсәрләр рәтенә кертеп булмый. Ә. Исхак Тукай сатирасының гүзәл уңышларын бүгенге идеяләрне ачып бирүдә, бүгенге дошманнарга ук атуда зур осталык белән файдаланган. Ләкин бер-ике генә киңәш бар иде: әсәрнең сатирик көчен әллә кайчан инде бер мәхлук карачкы гына булып калган татар баен кәмиткә калдыруга түгел, ә бүгенге империалистик көчләрнең асылын ачып бирүгә, аларны камчылауга күбрәк юнәлдерсәң, яхшырак булыр иде. Тоеп торам, автор үзе дә шуны максат итеп куйган. Ләкин кайчакта байның комик образын күрсәтүгә багышланган юллары артык озынга сузыла һәм укучы әсәрнең идея җебен җуебрак торган урыннар килеп чыга. Башкача ясалмалыклар да бар. Бай, Гыйракта халык көче җиңгәч, Америка илчесенә ярдәм сорап бара, ләкин ахырда бу Америка илчесе булмый, Куба кешесе була. Бу урын Куба революциясен әсәргә ничек итеп булса да кертергә тырышу тәэсирен калдыра һәм шуннан соңгы вакыйгаларның ышанычлылыгын югалта. Аннан әсәр, гомумән, озынрак, аның эчендәге конкрет, кызыксындыра торган җанлы сюжеты азрак. Менә шушы несоответствие әсәрнең мавыктыру көчен киметә. (Әйтик, Тукай «Кисекбаш»ының сюжетын бер укучыга сөйләп бирергә кушсаң, ул тулы бер әкият сөйли ала, ә бит күләм белән ул зур түгел.) Киңәш бер: әсәрдәге сатираның төп юнәлештәге, бүгенге империализмны фаш итү юнәлешендәге удар көчен, сатирик тирән урыннарын саклап, аны озынлыктан, гомуми урыннардан арындырырга иде.

Кульязмада тагын кайбер билгеләр ясалды. Автор карар.

Авторның үз әсәрләре өстендә ничек эшләвен белгәнгә күрә, бу җыентыкның әһәмиятле булачагына шик тотмыйбыз.

**«Яңа җыр»** [1]**. Марс Шабаев. Поэма.**

Бүгенге көннең эчтәлеген ачып бирү өчен яңа формалар эзләү — бик мөһим, бик кирәк күренеш. Әдәбиятның чор белән бергә алга таба баруына мондый эзләнү бик кирәк. Шул яктан караганда, Марс Шабаевның «Яңа җыр» поэмасын бүгенге көн турында язылган күп кенә поэмалар арасында бер талпыну итеп карарга һәм котларга кирәк. Поэма җанлы итеп язылган, укыганда кызыксыну киеренкелеге ахырга кадәр саклана. Поэманың темасы актуальлеге турында әйтеп торасы да юк. Поэма безгә ошады, аны басарга кирәк. Бу рецензиядә «Ләкин...» дип башлана торган икенче кисәк тә әнә шул яхшы әсәрне тагын да яхшырту күзлегеннән карап әйтелә.



Димәк, ләкин әле поэмада төзәтәсе, эшлисе, очын-очка ялгыйсы урыннар бар. Беренче чиратта, әсәрнең үзәгенә — сюжетына кагылыйк:

1. Төйнәлеш (завязка) әсәрнең бөтен дәвамында барган киеренкелекне аклап бетерми, ул шигъри түгел, автор, Рәмзиянең Кәримәгә ничек «шпаргалкалар» белән ярдәм итәргә теләвен артык чәйнәп бирергә теләп, завязканың эмоциональ көчен ала. Тәкъдим шундый: IV—V бүлекләрдә кульъязмада күрсәткән кыскартуларны кертеп, завязканың яшерен киеренкелеген, эмоциональ көчен арттырырга.

2. Кәримәнең Әлфияне коткару турындагы Мулланур истәлеген дә җыйнаклатасы һәм ачык аңлаешлы итәсе иде. Шунысы аңлашылмый: Кәримәнең кулыннан ычкынып, бассейнның аргы очына барып, суга төшкән Әлфияне коткарыр өчен нигә Кәримәгә күпердән сикерергә кирәк булган? Аннан, үзе карап бетермәү аркасында суга төшкән баланы үзе коткарган Кәримәнең кешеләр алдында нинди хезмәте (заслугасы) бар икән соң? Гомумән, следователь протоколындагы бөтен детальләр поэзиягә туры килә алмыйлар. Шуның өчен бу бүлек турында автор уйларга тиеш.

**Урамда — бәйрәм.**
**Урамда — тантана.**
**Машинада —**
**ике юеш гәүдә.**
**Кан тама...**
**кан тама...**

Менә шушындый көчле тәэсирле юллары булмаса, бу бүлекне бөтенләй сызып ташласаң да зур зыян килмәс иде кебек. Чөнки көн саен Әлфия янына кереп, аны карап йөрүче кызга Рәмзиянең ярдәм итәргә тырышуы бу вакыйгадан тыш та бик аңлашыла. Бәлки бу бүлекнең уңышлы юлларын Марс башка әсәрендә файдалану өчен калдырыр?

3. Мулланурның Әлфиягә шалтыратып астыртын чәнечкеле сүзләр ташлавы артык... Мулланурның кичерүләрен бирү бер нәрсә, ә аны истеричный ханымнар кебек итеп күрсәтү икенче нәрсә. Бутамаска кирәк.

4. Чишелеш өлешендә — Кәримә әнисенең чәпчүен күрсәткән бүлектә — бер-ике кимчелек бар. Мәсәлән, бу мәсьәлә: Рәмзия үзенең эчке көрәшендә җиңеп чыга, Кәримәгә, автор теле белән әйтсәң, «шпаргалкалар бирми» бит инде. Шулай булгач, нигә соң ул, Кәримә анасы әйткәнчә, аның алдында «Мулланур да сиздә» дип аклана? Дөрес түгел бу. Рәмзияне тагын гайбәтче хатыннар рәтенә төшерергә кирәкмәс.

Аннан тагын бер киңәш: Мулланур Рәмзиянең түбәнлек эшләмәвен аңласын өчен, аңа Кәримәнең әнисеннән бер-ике генә сүз әйттерсә, (әйтик: «Их, сез, күршеләр, ярдәмчеләр... һ. б.) яхшырак булыр иде, Мулланурның рухи халәтенең үзгәреше укучыга аңлашыла төшәр иде.

Поэма өстендә эшләүдә төп киңәшләр шушы. Әсәрдә артык урыннар, мәгънәсе төгәл булмаган образлар һәм башка кимчелекләр кульъязмада күрсәтелеп барылды.

---

[1] Бу поэма 1962 елда, М. Шабаевның башка әсәрләре белән бергә, китап булып басылып чыкты.

**«Вәгъдә»[1]. Гәрәй Рәхим [Гр. Родионов]. Шигырьләр.**

Григорий Родионовның уңышлы шигырьләре мине бик куандыра. Аларда ниндидер таза реализмны, ирлек хисләрен, туган җиргә нык итеп баскан һәм шул җиргә нык тамыр җибәргән кеше хисләрен тоясың. «Беренче күкрәү» шигырен укып карагыз. Вакытында яуган яңгырга шатланган, сакалларыннан яңгыр тамчылары тамып торган, имән кебек таза крестьян образы никадәр җанлы итеп бирелгән анда. Кульъязмада әнә шундый җир кешеләренең күчле образларын, тирән хисләрен күрсәткән шигырьләр аз түгел. Менә алар: «Буыннан-буынга», «Рас», «Сагыш һәм шатлык», «Вәгъдә һәм кисәтү», «Сугышта югалган солдатлар», «Әниләр зары», «Игеннәр иләндә», «Мулланур эзләре» (соңгы строфаны эшкәртү турындагы тәкъдимне кульъязмадан кара), «Көзге урман», «Аерылу» (ләкин монда вагоннарны дөяләр белән чагыштыру дөрес образ бирми кебек), «Тизрәк кайт», «Чыгарсың», «Ә буш кырда буран улады», «Мактанчык тычкан», «Аңлады», «Күңелем яраткач», «Гел яңача».

Бераз гына эшкәртү нәтиҗәсендә дә шушы шигырьләр дәрәҗәсенә күтәреләчәк шигырьләр дә бар. Алар турында аерым-аерым сөйләшеп алыйк.

«Игенче турында баллада» — тарихка кагылган беренче бүлекләр бик схематик итеп бирелгән. Шигырь асылда өченче бүлектә генә. Чәчәк атып торган оазиста (археологик казынулар вакытында) кеше сөякләре янында кешенең шушы урынны чәчәк аттырудагы хезмәт кораллары табылу үзе бер баллада бит инде. Шигырьдә җыйнаклыкның файдасы турында Г. Рәхимгә аңлатып торасы юктыр.

«Мәхәббәт» шигыренең исә башында һәм ахырында шундый ук шигъри нагрузкасыз строфалар бар. Шигырьнең уртасында гына сурәтләү чаралары ныклы кул белән яхшы эшләнгәннәр. Әнә шул урыннарны эшкәртеп шигырьне төгәлләндерергә кирәк.

«Йөрәгеңдә янгын кабынсын дип» шигыренең беренче строфалары ачык фикер, төгәл образлардан торса, ахырда образлар таркау була башлый, фикер дөреслеге шик астында кала.

«Идел сизде» шигырендә комның моң гына шыгырдавын күңелгә китереп каравы бик кыен, шуңа күрә бу сурәт тәэсирсез кала.

«Бер фәлсәфә» шигырендә автор сәгатьнең кешеләрне мин буйсындырам дип уйлавыннан көлә. Әмма ахырда шул ук сыйфатны турыдан-туры шагыйрьнең күршесенә, ягъни кешегә күчерү пропорцияләрне бутый.

Башка шигырьләргә карата замечаниеләр кульъязмада күрсәтелде.

Җыентыкта әле йомшак, урынсыз кертелгән шигырьләр дә бар. «Әнкәй белән сөйләшү» дигән озын шигырь тәэсирсез, сөйләп бирү генә булып чыккан. «Кара кашлы йөзек» дигән шигырьдә бик ясалма ситуация алына һәм коры, ясалма итеп сурәтләнә. «Син һәм йолдыз» шигыре космик процесслар мөнәсәбәтен ялгыш аңлауга корылган. «Кояш һәм берәү»дә һич чагыштырмаслык величиналар чагыштырыла, бу шигырьне тәэсирсез итә. «Ничәнче гасырын яши җир» шигыре мәгънәсез сүз уйнатуга гына корылган. «Кеше һәм мәңгелек» коры рассуждение, «Ләтчә»дә бик күп кабатланган начар ферма мөдире турында көчсез генә итеп сөйләп бирелә. «Сергей Есенинга», «Миләш төбендә», «Нәфрәт, рәхмәт», «Шомарды», «Өйрәткәннәр», «Штурм» кебек шигырьләрне дә җыентыкка лаек дип булмый. Андыйларга мин минус билгесе куйдым.

Редакцияләгәннән һәм тулыландырганнан соң, минемчә, Гәрәй Рәхимнең шигырьләр җыентыгы укучылар өчен, аеруча яшь хезмәт кешеләре өчен бик шәп күңел азыгы булачак.

---

[1] Бу китап 1967 елда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыкты.

**«Җир һәм кеше»** [1]**. Ренат Харисов. Шигырьләр.**

Ренат Харисовның бу җыентыгы аны безнең поэзиягә соңгы вакытларда килгән яшь көчләрнең иң талантлылары рәтенә кертергә мөмкинлек бирә. Бу җыентык укучылар өчен бик кызыклы яңа фикерләр, яңа образлар алып килә, ул һичшиксез поэзиядә үзенчә яңгыраш табачак, үз бизәкләре белән күренәчәк.

Поэзиягә төрле яшь көчләр килә. Аларның берәүләре безнең традицион классик шагыйрь үрнәкләрендә тәрбияләнәләр, шуны алга сөрәләр, тирә-як күренешләрен, табигатьне образлы сөйләп бирү юлы белән гәүдәләндерәләр, күзәтүләрен турыдан-туры, анализсыз-нисез күрсәтергә тырышалар. Икенче берәүләре бүгенге фәнни казанышлар, дөньядагы катлаулы вакыйгалар, материяне һаман тирәнрәк танып белү идеяләре белән сугарылып, тирә-якны, тормышыбызны, эшебезне, хисләребезне фәлсәфи фикерләү аша, бүгенгенең зур вакыйгаларына бәйле рәвештә анализлау, хис һәм күренешләрнең асылына үтү белән ачып бирергә, күрсәтергә омтылалар. Р. Харисовны икенчеләренә кертергә кирәк. Бу җыентык нәкъ шуны күрсәтә.

Ул 5 бүлектән тора һәм бу бүлекләрнең һәрберсе бүгенге тормышыбызны танып белергә тырышуны образлы чагылдырган бер алка, бер түгәрәк булып тора, бу алкалар безне, спираль алкалары кебек, һаман тирәнрәк алып керәләр. Мәхәббәт, хезмәт, туган як, тынычлык, дуслык, кешелеклелек — шул темаларга уйланулар безне мавыктырганнан-мавыктыра баралар, яңадан-яңа зур фикерләргә илтәләр.

Әлбәттә, сүз җыентыктагы яхшы шигырьләр турында бара һәм күп шигырьләр өстендә тагын да нык эшләү, китапны артык йомшак әсәрләрдән арындыру шарты сөйләнелә. Нәшрият өчен дә, автор өчен дә иң мөһиме шулдыр, димәк, без шуңа күчик тә. Җыентыкны ача торган «Туган җирем» шигыренең беренче строфасы кирәкми, чөнки булмаган нигезгә фикер кору мөмкин түгел. Икенче строфа үзе генә дә туган якка мәхәббәтне бик лирик формада ачып бирә.

«Шигырьләр» диелгән шигырь болай яхшы гына. Ул әдәбият өлкәсендә ун-йөз еллар буена барган көрәшне чагылдыра: шигырь бизәнү әйбере кебек матур нәрсә түгел, ул — көрәш коралы да. Әмма кем соң «шигырь күңел чәчәге генә» дип раслый? Автор кем белән бәхәсләшә? Шушының тоелмавы шигырьне ничектер максатыннан мәхрүм итә. Моны уйларга кирәк.

Шамил Мәхмүдовка багышланган шигырь тормыштагы гаять матур фактларны искә төшерү белән башлана, әмма аннан бик абстрактлаша. Төшенчәләр бутала башлый, җир белән кеше арасындагы соотношение бутала. Шигырь урынсыз куелган өндәү билгесенә әверелә.

«Ядрәнең ике монологы». Ядрәдән кешегә, тормышка мәхәббәт сүзләрен әйттерү минем өчен табигый тоелмый. Беренче шигырьдә бик матур образлар бар... Икенче шигырь ялган трагик восклицание булып кына кала. Ядрәнең крокодил яшьләре түгүе булып чыга.

Дүртенче бүлек турында гомумән берничә сүз. Безнең чорда шигырьне проза белән аралаштыру тәҗрибәләре күренгәли. Кайберәүләрдә (Әйтик, Н. Хикмәт) моның бик көчле нәтиҗәләре дә бар. Шигырь кебек үк киеренке эшләнгән проза — шигъри проза яки прозаик шигырь — кайбер вакыйгаларны бөтен катлаулыгы, бөтен фаҗигалелеге белән ачып бирергә ярдәм итә. Әмма проза белән шигырьне бер максатсыз аралаштыру, бер дә бәйләнеше булмаган нәрсәләрне бер җепкә тезәргә тырышулар белән мин һич килешә алмыйм. Хәтта Ленин премиясе лауреаты Межелайтиста да бу хәлнең артык уңышлы булмаган урыннары һәм бөтенләй уңышсыз урыннары бар.

Р. Харисов китабындагы бишенче бүлекне дә уңышлы дип әйтеп булмый. Монда проза белән шигырь аралаштыру фикерне тирәнәйтүгә алып бармый. Кайбер очракларда, автор бер үк фикерне баштан кыска гына прозада әйтеп бирә, аннан шуны ук шигъри юлларга тезә. Бу бүлектә сүз атом сугышына каршы көрәш турын-

---

[1] Бу җыентык 1968 елда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыкты.



*Уфа шәһәрендә РСФСР язучылар союзы идарәсе пленумында катнашучы татар язучылары. Уфа, 1958 ел. Сулдан уңга: Хәсән Туфан, Габдрахман Минский, Нәкый Исәнбәт, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Әнвәр Давыдов.*

да бара. «Кереш» кызыклы конкрет образларның бик абстракт декларацияләр белән аралашуыннан тора. Әйтик, шагыйрьнең сейсмограф нервлары атом шартлавын тоюы белән башланган строфа үзе конкрет һәм аңлаешлы көчле бер шигырь кебек яңгырый. Әмма шуңа кат-кат «вакыт ага — ташкынында ак күгәрчен каурыйлары» дигән сүзләрне өстәү бер нәрсә дә бирми. Шуңа күрә шагыйрьнең дөнья өчен сызлануын әйткән соңгы юллары да коры декларация булып кала.

Соңгы шигырьдә бер каршылык бар. Автор: «Җирне бизәрлек эш эшли алмасам, син мине баскан урынымда тамырларым җәйдереп калдыр»,— дип мөрәҗәгать итә җиргә. Әмма нәкъ җирне бизәгән кешеләр генә бит җиргә тамыр җибәрәләр, һәйкәл булып җирдә калкалар, кешеләрне ышыкларлык көчкә ия булалар.

Монда күп шигырь тәнкыйтьләнде кебек, әмма җыентыкта шигырьләр саны бик күп бит, уңышлыларын санап китсәң, тагын берничә мәртәбә артыграк язарга туры килер иде. Анда да әле кульязмада шактый күп замечаниеләр ясалды. Китапның уңышлы булачагына ышану аның кимчелекләре турында шул кадәр күп сөйләргә мәҗбүр итте.

Нәтиҗә шул: Ренат Харисовның җыентыгы поэзиябезгә яңа нәрсә алып килә, ул укучылар күңелендә кайнар хисләр уятачак. Эшләргә, чыгарырга кирәк.

**«Язмыш»** [1]. **Хисам Камалов. Шигырьләр.**

Хисам Камаловның бу җыентыгы, аның иҗатында яңа баскыч булу белән бергә, безнең поэзиягә дә җитди бер өлеш булачак. Кульязмада, беренче чиратта, иҗтимагый фикерләүләр, гражданлык мотивлары, социалистик-гуманлык хисләре үзенә тарта.

Кульязманың үзәгендә, һичшиксез, «Күңелдәге язулар» дигән әсәр тора. Аның никадәр әһәмиятле икәнен менә бу факт та күрсәтә: бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин образы турында үз язмышың белән бәйләп, тирән фикер йөрткән, даһидагы кешелек сыйфатларын үз кичерешләре, үз уй-сагышлары белән бәйләп гади дә һәм дулкынландыргыч та итеп ачарга тырышкан шагыйрьләр безнең поэзиядә күп очраганы юк әле.

Автор Ленин тормышындагы иң мәгълүм вакыйгаларны ала, аларны арттырып та, көчәйтеп тә тормый. Ленин әсәрләрен, фикерләрен дә гади генә итеп, үз форма-

[1] Бу җыентык 1967 елда басылып чыкты.

ларында, әллә нинди күпертелгән шигъри образлар әзләмичә генә искә төшереп үтә. Әмма алар шагыйрьнең кичерешләренә, халыкның, илнең үткәне һәм үз язмышы турындагы уйлануларына аерылгысыз бәйләнеп, әсәргә килеп керәләр, әсәрне яктыртып, куәтләндереп җибәрәләр, укучы күңелендә бөек юлбашчының искиткеч кешелекле образын тудырырга ярдәм итәләр.

Әлбәттә, әсәрдә кайбер кимчелекләр дә бар. Бүлекләрдә композицион төгәлсезлекләр күзгә чагыла. Кайбер эпизодлар тормыштан түгел, китаптан килеп кергән төсле. Алар турында автор белән рецензияләү процессында ук сөйләшенде, автор бу кимчелекләрне бетерергә әзер һәм без поэзиябездә бөек Ленин турында уңышлы яңа лирик әсәр тууына шатбыз.



Тормыштагы төрле күренешләргә, әхлак, яхшылык һәм яманлык көрәше темасына, кешеләр арасындагы начар мөнәсәбәтләр өчен янып, андый мөнәсәбәтләрне тамгалап, матур мөнәсәбәтләрне раслауга, кешенең эчке сафлыгын раслауга багышланган шигырьләр дә күңелләргә нык тәэсир итәләр. Автор тормыштагы бик субъектив вакыйгаларны ала кебек, әмма аларны гомум кешелек, социалистик мораль дәрәҗәсеннән торып яктырта, һәм шигырьләр гражданнарча яңгыраш алалар, шатлык һәм ачыну хисләрен шәхси рамкалардан алып чыгалар.

«Шулай инде», «Мин барысын да», «Син соңыннан», «Бер арбада», «Ул — туган ил», «Бер әзләнүче сөйләвеннән», «Сандал», «Летчик» һ. б. һ. б. шактый күп шигырьләр нәкъ шундыйлардан. Алар җыентыкны көчле, салмак, тәэсирле итәләр.

Әмма кульъязмада бер үк мәсьәләне артык субъектив яктан алып кат-кат кабатлаган әсәрләр, фикере ачык булмаган һәм нәтиҗәдә шигъри эшләнешләре дә сыек булган әсәрләр юк түгел. Аннан бер үк теманы кабатлаган шигырьләр, никадәр генә яхшы булмасыннар, янәшә торганда, алар туйдыралар, нык тәэсир итә алмыйлар. Менә шул күзлектән караганда һәм чын күңелдән җыентыкның уңышлы булуын күрү теләге белән без кайбер әсәрләрне бөтенләй төшереп калдырырга ук киңәш бирер идек. Алар турында автор белән сөйләшенде, килешенде...

# Хатлар

## ХӨРМӘТЛЕ ЛЕОНИД[1]!

Сәлам сиңа Казаннан, миннән, Нинадан[2], безнең бөтен гаилә әһелләреннән. Бүген Николай Николаевичтан[3] «Ташу» поэмасының тәрҗемәсен алдым, болай тиз һәм яхшы эшләвең өчен рәхмәт. Тәрҗемә миңа ошады, русча яңгырый, җитәрлек җитди, мавыктыргыч чыккан. Тик минем берничә фикерем бар, шулар хакында ихлас уйларсың дип ышанам. Хәтерлисеңдер, декада вакытында[4], матбугат битләрендә һәм фикер алышуларда бу поэма шактый югары бәяләнгән иде. Чынлап та, аны мин иҗатымдагы үзәк әсәрләрнең берсеннән саныйм.

Еллар үткәч, һаман үзеңнән канәгать булмау сәбәпле, сирәк әсәреңне кабат кызармыйча укып була. «Ташу»ны мин әнә шундый әсәремнән саныйм, һәм рус укучысына да ул шулай, мин шатланырлык, татар укучысы бәяләгән дәрәҗәдә барып җитсен иде. Минем аерым замечаниеләр зур түгел, тик поэманы юлга-юл тәрҗемә белән кабат бер чагыштырып чыксаң, синең сизгерлек андагы төшеп калган, минем өчен кадерле, русча поэмага керергә тиешле детальләрне тояр.

Конкрет күрсәтүләр:

1 бит. «Недоступный, как Северный полюс» — чагыштыру минеке түгел һәм дөрес тә түгел.

2 бит.

«Словно главное что-то найти
Помогает сегодня природа.
Ты как будто готова в полет».

---

[1] Бу хат Әнвәр Давыдовның «Ташу» поэмасын русчага тәрҗемә иткән Ленинград шагыйре Леонид Хаустовка язылган.
[2] Нина — шагыйрьнең тормыш иптәше.
[3] Николай Сидоренко — рус совет шагыйре.
[4] Сүз 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы турында бара.

Мондый фикер дә, мондый күтәренкелек тә анда юк, мин бары үз уйлары белән генә калган, яр буенда дөньясын онытып торган, боз киткәнне күзәткән хатын-кызны гади генә сурәтләдем. Бу битнең икенче яртысында син, поэманы кыскартып, эзлеклелеккә зарар китергәнсең. Сүз Мәймүнәгә инде 30 яшь булуы, тик аның әле чын шатлык, чын язны күргәне булмавы хакында; моңа сугыш сәбәпче. Яңа кайнар тойгылардан Мәймүнәнең күкрәге күтәрелеп килгәндә, сугыш башлана. Тәрҗемәдә — Мәймүнәнең йөрәге хәзер генә тибә башлый, күкрәге хәзер генә калка. Моннан соң, 3 нче битнең беренче юллары:

«...Большая радость к Маймуне
Могла прийти бы той весною»,—

дөрес түгел. Сугыш бит яз башланмады.

Тагы шул ук биттә:

«...Ее надежды и мечта,
Что из души рвались наружу,—
Все потеряло смысл тогда...»

Мин алай әйтмәдем. Юлга-юл тәрҗемәдә болай: сугыш башлануга, ил һәм туган җир Мәймүнәнең беренче тойгысына әверелә, шуларсыз — хыял мәгънәсез. Димәк, хыял мәгънәсен югалтмый, ил язмышына ныграк бәйләнә икән.

«...Перед собой признаться — ей
В сердечной тайне не решиться...»

Аңлашылып та җитми һәм бөтенләй үк дөрес тә түгел.

4 бит. «Громогласно» — минем сүз байлыгыннан түгел.

«...Другая молодость взошла,
Другая заиграла сила».

Бу юлларның икенчесе килеп җитмәгән.

6 бит. Төп нөсхәдә автор Мәймүнәне нигәдер-нәрсәгәдер ышандырырга теләми, үгет бирми, ә бары аның хәленә кереп, кайчан соң ул тынгы табар икән, ди.

8 бит. Габдулланың килүен тасвирлаган берничә юлны юкка төшереп калдыргансың, алар кирәк.

11 бит. Икенче кисәкне тәмамлаган 4 юлны тәрҗемә белән чагыштырсаң, аларны яңадан уйлап карасаң иде.

13 бит. Гариф хатынының исемен дөрес язмагансың. «Айсла» түгел, мондый исем юк. «Айслу», юлга-юл тәрҗемәдә мин шулай яздым.

16 бит. Мәймүнәнең ялгыз газапта торганын сөйләгән юлларны, шулай ук 19 битне, январь аенда кинәт елгада су калкуын яңадан карасаңчы? Калыккан суның кинәт көтелмәгән салкын ихтыярына әләгүен әйтергә иде бит. Биредә Мәймүнә дә нәкъ шундый халәт кичерә.

21 бит түбәндәге юллар белән тәмамлана:

«...С газетной свежей полосы
Еще звучит Абдуллы имя».

Моннан соң килгән:

«...Вот так весенних вод поток
Подтачивает берег снизу»,—

тиешле мәгънәдә яңгырамый.

29 бит.

«Передо мною матери портрет —
Ведь Родина и мать для нас — одно».

Болай матур әйтелгән булса да беренче юл бөтенләй үк дөрес түгел. Бу рәсем, ни әйтсәң дә, ана рәсеме түгел шул, ил-ана рәсеме.

Синең белән берничә сәгать бергә утыра алсак, тәрҗемәне бөтен кимчелекләрдән җиңел арындырып булыр иде. Татар әдәбияты атналыгы көннәрендә

(1—7 октябрь) Мәскәүгә килеп чыга алмассыңмы? Үзеңне дә күрәсе, тәрҗемә хакында да сөйләшәсе килә.

Билгеле, тәрҗемә ошады, җитди чыгышы белән бик ошады, тик шагыйрьгә яраткан әсәренең һәр детале кадерле, бигрәк тә мин бу тәрҗемәнең эшләнеп җиткән вариант була алуын телим. Шуңа күрә тәрҗемәне кабат карап чыгуыңны, аны юлга-юл тәрҗемә белән чагыштыруыңны сорарга мәҗбүрмен. Леня, үзеңне күреп сөйләшәсе килә! Мәскәү ягына сентябрь ахырларында чыгарбыз бугай, шуңа хәтле, әлбәттә, мин Казанда.

**Рәхмәт һәм ихтирам белән, Әнвәр Давыдов.**

**1964, сентябрь.**

## КАДЕРЛЕ АЛЕКСАНДР ТРИФОНОВИЧ [1]!

Күптин-күп сәлам сезгә Казаннан.

Сезне түбәндәге мәсьәлә белән борчырга мәҗбүр булдым. «За далью-даль» дигән поэмагызны татарчага тәрҗемә иткән идем. Билгеле, үземә ошаганга тәрҗемә иттем. Хәзер аны нәшриятка тәкъдим итәргә уйладым. Поэманың вакытлы матбугатта чыккан вариантларын асылда тәмамланган дип кабул итәргә мөмкинме (мәсәлән, роман-газетаның 8 саны, мин шуннан тәрҗемә иттем)? 14 нче кисәкне XXII съезддан соң кабат карап чыгарга дигән уегыз юкмы? Нәшриятның шундый соравы бар.

Җавап хатыгызда поэманың 14 кисәгенә карата фикерегезне алсак, поэманы нәшир итү эшен тизләштерер идек. Миңа, иҗади сәбәпләр аркасында, бу эшне тизләштерү бик кирәк.

**Хөрмәт белән татар шагыйре Әнвәр Давыдов.**

## ҺАҖӘР [2] АПА!

Келәүледән [3] күп сәлам. Мин моны Уфага узышлый салып калдырам. Өйдә әле бар да исән-саулар. Мин дә бераз рәтләнәм, ахры, инде. Уфада РСФСР язучылар союзы пленумы утырышы була. (Башкорт әдәбиятын тикшерәбез.) 3 ндә башлана. 5—6 көн торылыр. Кайтканда берничә иптәш (Туфан, Зәки, Еники һ. б.) белән Камышлыга кереп чыгу ихтималы да юк түгел, ләкин райком Келәүлегә транспорт чыгара алырмы икән? Әгәр шундый мөмкинлеге булса, Зиннәт [4] абый миңа Уфага берәр төрле хәбәр җибәрсен иде. (Уфа, Союз писателей, татарскому писателю Давыдову.) Аннан мин кайчан кайтуыбыз турында телеграмма бирер идем. Әгәр инде мөмкинлек юк икән, үзем генә кереп тормам.

**Ярый, әлегә хуш, барыгызга да сәлам. Әнвәр.**

**31. VI. 58.**

## ҺАҖӘР АПА!

Сиңа барыбыздан да күп сәлам. Шулай искечә торабыз әле, беркайда да артык зур үзгәрешләр юк.

Син мине гафу ит инде, теге көнне, бик тиз кайтарабыз дип, мине Юдинога озатышка алып киттеләр, ләкин анда баргач, алай бик тиз генә булып чыкмады, озак торылды, үзем генә кайтып китәргә машина булмады. Шулай итеп, соң гына кайтып җитә алдым.

Минә Хәлимә [5] артыннан таныш-белешләргә, туганнарга китаплар җибәрәм, син таратырсың инде.

Шушы көннәрдә Нәкый Исәнбәтнең 60 еллыгын уздырдык. Бик зур күләмдә узды. Аликка да билет биргән идем, авырдым диде, бара алмады. Без Исәнбәтләрнең өендә дә мәҗлестә булдык, күңелле генә үтте.

Квартира артыннан һаман йөрибез, очы-кырые күренми әле. Булса да, артык зур булмас, ахры. Нишлисең бит, булганынча булыр инде.

**Ярый, хуш, сәлам белән Әнвәр.**

**16. I. 1960.**

---

[1] Хат атаклы рус шагыйре Александр Твардовскийга язылган.
[2] Һаҗәр — шагыйрьнең апасы.
[3] Келәүле — тимер юл станциясе.
[4] Зиннәт Абдрашитов (1906—1972) — ул чорда Камышлы район газетасы редакторы.
[5] Хәлимә — шагыйрьнең олы апасы Җәүһәрнең кызы.

Мәхмүт Нигъмәтҗанов

# ОЛЫ МАКСАТКА ЙӨЗ ТОТЫП

*Музыка фольклористикасының мөһим проблемалары*

Татар халкының музыкаль иҗатын өйрәнүнең ярты гасырга якын тарихы бар. Музыка фольклористикабызның барлыкка килүе С. Г. Рыбаков, В. А. Мошков, Гайса Еникеев, Солтан Габәши исемнәренә бәйле. Халыкның музыкасы, җыр иҗаты турында Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани һәм Габдулла Тукайлар тирән фикерләр әйтеп калдырганнар.

Ләкин милли музыка фольклористикасының чын тарихы бары тик совет чорында, хезмәт халкы тудырган рухи байлыкны туплау һәм өйрәнү дәүләт эше югарылыгына куелганнан соң гына башлана [1].

Композитор А. С. Ключарев, В. И. Виноградов һәм шагыйрь М. Садри 1941 елда Казанда җырлар җыентыгы бастырып чыгардылар. Татарстанда язып алынган татар халык көйләре тарихта беренче тапкыр бу китапта үзләренең халыкча яңгырашын таптылар. Нотага язу өчен катлаулы булган озын көйләр җыентыкта зур урын алып торалар. Ул хезмәт яшь татар композиторлары, музыкантлары һәм җырчылары өчен күп еллар буе иҗади чыганак булып хезмәт итте. Китапның кереш сүзендә милли фольклорның кайбер үзенчәлекләре турында җитди фикерләр дә әйтелде.

Халык көйләренең А. Ключарев хәзерләгән икенче томы 1955 елны дөнья күрде. Ул татар музыка мирасын тагын да баетты, ә китапка кергән кайбер себер язмалары, Гайса Еникеев материаллары милли көйләрнең үзенчәлекләренә булган карашны шактый киңәйтте.

Илленче елларда татар профессиональ музыкасы турында җирле һәм үзәк матбугатта кайбер тикшеренүләр, хәтта китаплар чыкты. Ләкин халык музыкасына карата аларда әллә ни яңа фикерләр әйтелмәде дисәк, зур хата булмастыр.

Халык җырларының жанрларын тикшерү, башкару мәсьәләләре буенча бу елларда Әзһәр Абдуллин эшләре билгеле [2]. Аның мәкаләләрендә халык музыка кораллары турында да кызыклы мәгълүматлар бар.

1964 елда фольклористикабыз тарихында өченче җыентык дөнья күрде. Бу юлы моның төп авторы — күренекле татар композиторы, татар халык көйләрен тирәнтен белүче һәм оста башкаручы Мансур Мозаффаров иде. Җыентык студентлар өчен хрестоматия буларак әзерләнде. Җыентыкка Ю. В. Виноградов аңлатмалары һәм З. Хәйруллина сайлаган текстлар өстәлде. Дөрес, монда урнаштырылган җырлар инде нигездә бастырылып чыгарылган иде, әмма җыентыкның кыйммәте андагы көйләрнең төгәл һәм чын халыкча яңгырашлары белән язылуларында булды.

Әлеге халык җырлары китапларында төп урынны, нигездә, популяр әсәрләр

[1] Бу турыда кара: «Казан утлары», 1964 ел, 3 сан.

[2] Ә. Абдуллин. «Татар халык көйләре». М, 1964 ел. Рус телендә.

алып тора. Татар халык җырларының территориаль, тарихи, жанр һәм стилистик төрлелеген чагылдыру ягыннан караганда, ул җыентыкларның чикләнгән булулары да шуның белән аңлатыла. Аларның төп максаты артист-музыкантларның һәм киң музыка сөючеләрнең популяр халык җырларына булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү иде. Бу хезмәтләр үз чоры куйган таләпләргә җавап бирә алдылар. А. Ключарев, М. Мозаффаров һ. б. ларның хезмәтләре бүген дә татар халык музыкасының төп һәм бай хәзинәсен эченә алган җыентыклар булып кала.

Халык җырларын фәнни максат белән җыю һәм өйрәнү СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты эшчәнлегенә бәйле. 1940 еллардан алып бу институт фольклорчылары Хәмит Ярми җитәкчелегендә халык көйләрен язу эшен башладылар. 1959 елда институт каршында музыка кабинеты оештырылу белән бу эш систематик һәм музыкаль-профессиональ характер алды.

Яңа оештырылган кабинет алдында җитди практик һәм гыйльми проблемалар килеп басты. Кабинетның фәнни юнәлешенә бер факт хәлиткеч этәргеч ясады. Институтта этнографлар тарафыннан «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» исемле коллектив хезмәт әзерләнә иде. Аның халык музыкасына багышланган бүлеген язу миңа йөкләнде. Алга бөтенләй диярлек уйланмаган, өйрәнелмәгән җитди сораулар килеп басты. Татар халык музыкасының үзенчәлекләре, тарихи планда алып караганда, нидән гыйбарәт? Башка халыкларның музыкаларыннан аны нәрсә аера? Татарларда рус һәм башка халыклардагы кебек хезмәт, йола көйләре бармы? Керәшеннәрнең, мишәрләрнең музыка иҗатына нинди үзенчәлекләр хас? Борынгы заманнарда татарлар җырлаганмы, биегәнме, уйнаганмы? Әллә ул, бераүләр әйтмешли, гомер буе «мунчада посып» кубыз быжылдатканмы?.. һәм башка күп төрле сораулар туды. Халык музыкасы турында без, консерватория тәмамлаган яшь белгечләр, бары тик әле югарыда искә алынган хезмәтләрдән белә идек.

«Фән» нәшриятында чыгачак, бөтен бер халыкка багышланган монография өчен ул мәгълүматлар, әлбәттә, җитәрлек түгел иде.

1960—1967 елларда төрле төбәкләргә оештырылган махсус экспедицияләр бу юнәлештә көтелмәгән бай материаллар бирде, халыкта әле дә яшәвен дәвам иткән күп кенә борынгы көйләр, җырлар табылды. Барлык иген иккән халыклардагы кебек, бездә дә махсус стильле календарь (йола, туй) җырлары булуы расланды. Татар музыкасының этнографик яктан да төрле стиль һәм диалектларга бай булуы ачылды.

Бу материаллар нигезендә VII халыкара антропологик-этнографик конгресста доклад ясалды, төрле журналларда мәкаләләр басылды[1]. Яңа карашларның төп эчтәлеге «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (Мәскәү, 1967), «Татарские народные песни» (Мәскәү, 1970) исемле хезмәтләрдә чагылыш тапты[2]. Ләкин халыкның бай музыка хәзинәсен киң планда, фәнни күзлектән чыгып өйрәнүдә бу әле беренче адымнар гына иде.

Илебезнең төрле-төрле почмакларында яшәүче татар халкының музыкасын җентекләп өйрәнү озын гомерләр сорый, ул күп кешеләр, фәнни коллектив эше. Әлеге 1960—67 елларда башкарылган эшләр моңнарыбызның тарихын һәм катлаулы дөньясын беренче тапкыр күздән кичерү, аның төп тенденцияләрен билгеле дәрәҗәдә ачыклау гына иде, ләкин мондый киң пландагы күзәтү киләчәк эзләнүләр өчен билгеле нигез булды.

1967 елдан соң Себер, Урал буе татарлары музыкасын җыю һәм өйрәнү эшенә Илгиз Кадыйров һәм Нәркиз Мөштәриевалар шактый өлеш керттеләр. Институтның гыйльми чыгарылышларында бу иптәшләрнең мәкаләләре инде дөнья күрде. Шәһәр музыка фольклоры һәм революция чоры җырлары турында музыка белгече Земфира Сәйдәшеваның мәкаләләре җирле матбугатта басылды.

Композитор Җәүдәт Фәйзинең хәзерге заман халык музыка иҗатына багышланган хезмәте аерым игътибарга лаек. 1971 елда Татарстан китап нәшриятында аның «Халык җәүһәрләре» исемле китабы чыкты. Монда композитор тарафыннан күп еллар эчендә тупланган җырлар, аларга карата авторның аңлатмалары, фикер

---

[1] М. Нигмедзянов. Стилевые особенности музыкального фольклора татар-кряшен. М., Наука, 1964.

[2] M. Nigmedzianov. Some Style Characteristics of Tatar-Michar Musical Folklore — «Studia Musicologica». T. XI. f. 1—2. Budapest. 1967.

һәм күзәтүләре урын алган. Китапта нигездә җырчылар репертуарында яшәп килгән, ләкин әле күп очракта матбугатта чыкмаган популяр әсәрләр бирелә. Анда җырларның соңгы еллардагы яшәү тарихы да яктыртылуын күрсәтергә кирәк. Бу зур хезмәтнең әле күләмле һәм тәфсилле рецензия күргәне юк. Шуңа күрә, кыскача булса да, аның кайбер кимчелекләрен дә әйтеп үтү кирәктер.

Билгеле булганча, халык авыз иҗаты күп вариантта яши һәм конкрет стиль үзенчәлеген чагылдыра. Җыентыкта урнаштырылган әсәрләр, көйләрнең кабатланмас җирле колоритлары исә монда әлегә тиешле чагылышын тапмаган. Салмак, хәтта кайбер озын көйләр гадиләштерелеп, тигез үлчәүле размерга сыештырып нотага төшерелгән. Мәсәлән, «Таһир-Зөһрә» көенең мелизмнарга бай беренче өлеше квадрат ритмда, орнаментсыз язылган.

Автор «Кереш» өлешендә фольклористларны җырның тексты белән кызыксынучыларга һәм «коры» мелодия тикшерүчеләргә бүлә, җырның ике элементын бергә карарга өнди. Ләкин җыентыкның төзелешендә көйнең, җырның төп үзенчәлекләре искә алынмый, бүленеш нигездә текстлар эчтәлегеннән (тематикадан) чыгып хәл ителә. Җырларның тарихы турында сөйләгәндә, китапта күбесенчә көй-музыка турында сүз алып барылмый, ә җырның сүзләре яки җырчыларның мәгълүматлары критерий итеп алына. Ләкин халыкта җырланган җыр тексты белән көйнең абсолют берлеген мондый юл белән дәлилләү мөмкин түгел, алар алышыналар, үзгәрәләр. Икенчедән, башкаручы мәгълүматы җырның соңгы елларда (күп булса 30—50 ел) яшәвен генә тасвирлый, ә көйләр тарихы гасырларга сузыла...

Ниһаять, татар көйләрен жанрларга бүлү аның тарихи-стилистик үзенчәлекләреннән чыгып хәл ителмәгән. Нигездә аларның номенклатурасы саклана, әмма конкрет әсәрләрнең теге яки бу бүлеккә кертелүе бик тә бәхәсле. Мәсәлән, «Таң атканда», «Ялгыз каен», «Уйланам», «Сарман», «Арча» һәм башкалар озын көй үрнәкләре итеп күрсәтелгән. Автор китапка бирелгән кереш сүзендә «бу китап чын мәгънәсендә фәнни тирәнлеккә дәгъва итми. Аны — бары халык иҗаты сөюче композиторның күп еллар буе үзе җыйган «халык җәүһәрләре»... үз күзәтүләреннән чыккан тәэсирләрне тупланган бер хезмәт дип кенә карарга кирәк», ди [1]. Ләкин шунысын да әйтергә кирәк, 1971 елга кадәр басылып чыккан хезмәтләрдәге фикерләр дә, җыентыкта, әлбәттә, билгеле күләмдә чагылыш тапмый калмады. Моны Җәүдәт ага үзе дә әйтеп китә [2].

Җыентыкның исеме турында. Җәүдәт ага китаптагы җырларны гына түгел, җырчыларны да, көй язган, эшкәрткән композитор, шагыйрьләрне — барысын да «халык җәүһәрләре», ди (кара: 3 бит). Китапта әле халык иҗаты дәрәҗәсенә җитмәгән, аның тарафыннан кабул ителмәгән, камилләштерелмәгән әсәрләр шактый зур урын алып тора. «Җәүһәрләр» дигәч, ничектер «антология» тибындагы әсәр көтәсең. Халкыбызның көйләр антологиясен төзү әле алдагы бурыч.

Киләчәктә бу хезмәт әле җентекләп тикшерүгә ирешер дип уйларга кирәк. Тулаем алганда, Җәүдәт ага Фәйзи калдырган хезмәтнең объектив кыйммәте һәм әһәмияте һичшиксез зур. Ул — әле бер фольклорчының да кулы җитмәгән хәзерге заман фольклорына багышланган беренче хезмәт. Анда музыка көнкүрешенә караган бай мәгълүматлар урнаштырылган, күп кенә (хәзерге буын музыкантларына таныш булса да) җыр материалы тупланган. Киләчәктә совет чоры музыка фольклорын өйрәнүне дәвам иттерү өчен ул китап әһәмиятле таяныч булып торачак.

Соңгы елларда халык музыкасын җыю һәм өйрәнү эше шактый җанланып китте. Казан дәүләт консерваториясе каршындагы «Идел буе халыклары музыка кабинеты» да композитор Шамил Шәрифуллин җитәкчелегендә системалы рәвештә фольклор экспедицияләре оештыра. Көйләрне нотага төшерү һәм студентларның фольклорга игътибарын юнәлтүгә зур әһәмият бирә башлады. Консерваториядә инде шактый фонд туып килә.

Республиканың халык иҗаты йорты да бу эшкә киләчәктә зуррак әһәмият бирер дип ышанасы килә. Фольклор буенча халык иҗаты йорты тарафыннан 1974 елның апрелендә Арчада оештырылган Республика семинары әһәмиятле башлангыч булды.

Казанның яшь культура институты, пединститут, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеге дә музыка фольклоры белән шөгыльләнә. Бу шартларда халык

[1] Күрсәтелгән хезмәт. 28 бит.
[2] Шул ук хезмәт, 70 бит.

музыкасын, җырларын җыю, өйрәнү, бастырып чыгару һәм пропагандалау эшләрен координацияләү, үзара планлаштыру һәм оештыру мәсьәләләре аеруча актуаль булып тора.

Бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында көй-җырларыбызның дүрт меңгә якын фоноязмасы тупланды. Бу — халкыбызның олы фәнни-эстетик байлыгы. Фольклористиканың колачы көннән-көн киңәя, фондларыбыз байый. Ләкин әле оештырыласы экспедицияләр һәм тикшереләсе проблемалар күп һәм җитди.

Иң мөһим мәсьәләләрнең берсе — халыкның музыка мирасына сак карау, җыелган һәм тупланган фондларны фәнни хисапка алу, тәртипкә салу һәм аңа композитор, белгечләр һ. б. кызыксынучы кешеләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкинлекләр булдыру. Гайса Еникеев, Гыйләҗетдин Сәйфуллин, Солтан Габәши, Антон Эйхенвальд, Хәсән Гобәйдуллин, Александр Ключарев, Василий Виноградов, Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров кебек музыка эшлеклеләренең архивы һәм радиокомитет, халык иҗаты йорты архивлары аерым игътибарны таләп итә. Кыйммәтле халык музыкасы материалларын, уникаль язмаларны тиешле шартларда саклау бик тә җаваплы эш.

Соңгы 10—15 елда көйләрне магнитофон тасмасына язу кулланыла. Әмма ул 7—8 елдан бозыла башлый, ә гасырлар буе халык күңелендә яшәгән күп җырлар карт җырчылар хәтерендә генә саклана бит... Бу көйләрне саклауның бердәнбер чарасы — аларны пластинкага төшерү. Күрәсең, бездә дә башка халыклардагы кебек, бу эшне тиешле дәрәҗәдә хәл итәргә кирәктер.

Бүген фәннең барлык өлкәләрендә методика камилләшү процессы бара. Гуманитар фәннәрдә математик, акустик һәм кибернетик методлар инде киң урын алдылар. Музыка өлкәсендә бу бигрәк тә нәтиҗәле. Чөнки көй — акустик күренеш, милли музыкада интонация, лад, ритм үзенчәлекләрен һәм җырчы-музыкантларның башкару осталыгын тикшергәндә, объектив нәтиҗәләргә бары тик бу яңа төгәл методика ярдәмендә ирешергә мөмкин.

Фәннең нигезе — дөрес фактлар. Бездә факт — көй-җырларның яшәеше. Аларны дөрес итеп мәңгеләштерү кирәк. Ләкин халык иҗаты — процесс. Ул халыкның узганы, бүгенгесе, уй-хисләре, үзе кебек үк — даими үзгәрештә, камилләшүдә. Хәзерге заман иҗатында үзгәрешләр аеруча тиз бара. Без ашыкмасак, халкыбызның бүгенге иҗатыннан да күп кенә нәрсәләрне югалтуыбыз ихтимал. Иң актуаль мәсьәләләрнең берсе — булган киң мөмкинлекләргә таянып, һәр районда, һәр авылда халык музыка иҗатын язып чыгу. Тупланган материаллар нигезендә киләчәктә җыентыклар әзерләү. Бу эшкә иң якын киләчәктә тотынмасак, кыйммәтле хәзинәбезне, чорыбызның музыкадагы елъязмасын тулы килеш саклый алмавыбыз мөмкин.

Югарыда искә алынган башкарыласы эшләр, экспедицияләр һәм тикшеренүләрнең төп һәм перспектив максаты — күп томлы татар халык музыкасы җыентыгын барлыкка китерү. Ул гасырлар буе халкыбызның төрле төбәкләрдә, төрле социаль-тарихи шартларда иҗат иткән мирасын үз эченә алырга тиеш. Анда татар совет фольклористикасының тәҗрибәсе, казанышларына лаек рәвештә, йола һәм хезмәт, уен һәм бию көйләре, бәетләр һәм башка эпик әсәрләр, озын көйләр, авыл һәм шәһәр көйләре, хәзерге заман җырлары, музыка кораллары көйләре һәрберсе үз урынын алыр.

Һәр томның тикшеренү өлеше, фәнни кушымтасы, иллюстрациясе һәм башка телдә резюмесы булырга тиеш.

Халык көйләренең гомуми генераль каталогын төзү бу олы эштә беренче адым булыр иде. Аның нигезендә тематик, этнографик, жанрлар буенча һ. б. каталоглар кирәк булачак. Шул ук вакытта әлеге олы коллектив хезмәтнең фәнни нигезләрен ачыклау да — кичектергесез бурыч.

Гармония, полифония кебек башка музыка фәннәренә караганда, халык музыкасы фәне, ягъни музыка фольклористикасы, фән буларак әле бик яшь. Күп гасырлар буена, бүгенге көй язу системасы барлыкка килгәнче, халык музыкасын язу һәм өйрәнүгә әһәмият бирелми. Европада чиркәүләр тирәсендә тупланган музыкантлар «кара халык» иҗатын мәҗүсилек һәм гөнаһ нәрсә дип караганнар. Фольклорга игътибар романтизм чорында көчәя. Фольклористика барлыкка килү Европада XVII—XVIII, Россиядә XVIII—XIX гасырларга туры килә. Ләкин музыка фольклористикасы махсус белем тармагы булып бары тик гасыр чамасы элек кенә үзен танытты. Аның яңа чоры XX йөз

башыннан, фонограф уйлап табылганнан соң, башлана. Әле бүген дә музыка фольклористикасын камилләшеп беткән, предметын һәм методын тулысынча ачыклаган фән дип булмый. Хәтта бер музыка культурасында, мәсәлән, рус фольклористикасында, берьюлы төрле тикшерү методлары яши. Моның объектив сәбәпләре дә бар. Халык музыкасы — катлаулы күренеш. Бер культура эчендә параллель төстә төрле музыка диалектлары яши, бер үк этнографик группада төрле принциплар нигезендә туган жанрлар очрый. Ләкин һәр милли культурада, мәгълүм ки, билгеле бер стиль мөстәкыйльлеге, бердәмлеге бар. Музыка фольклористикасы, үз нәүбәтендә, милли музыканың гомуми стиль үзенчәлекләренә ярашлы булган, шуңа таяна торган тикшерену методикасын, анализлау принципларын барлыкка китерә. Болар белән бергә, фольклористиканың, фән буларак, кайбер халыкара уртак принциплары, методлары булуын да күз алдында тотарга кирәк. Әмма башка фольклористика мәктәпләренең тәҗрибәсен механик рәвештә күчерү уңышка китерә алмый һәм моның тискәре үрнәкләре бездә инде юк түгел. Татар совет фольклористикасы туплаган тәҗрибә хәзер махсус өйрәнүгә, гомумиләштерүгә мохтаҗ.

Билгеле булганча, җыр күп яклы феномен. Монда сүз, көй, хәрәкәт, башкару да бар. Ул музыкант, этнограф, лингвист һәм башкалар тарафыннан һәрберсенең үз аспектында өйрәнелә [1]. Җыр элементларының үзара мөнәсәбәте бер бәйләнештә генә була алмыйлар. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, бу бәйләнеш төрле жанрларда төрлечә.

Җырларны тикшергәндә, классификацияләгәндә аның элементларының иң әһәмиятлесен, әсәрнең асылын билгели торганын аерып алу таләп ителә. Мәсәлән, бию көендә — хәрәкәт, бәеттә — сүз, эчтәлек, озын көйдә — көй өстенлек алып торалар.

Музыка фольклористикасының төп объекты — музыка, көй, аның ритмик, лад һ. б. төзелешләре. Бию көенең әһәмиятле компоненты хәрәкәт, бию дип, музыкант хореограф эшен башкара алмый, яки, бәетне тикшергәндә, филолог лингвистны алыштыра алмый. Ә менә бу жанрларда музыканың стилен, семантикасын һәм генезисын тирәнтен тикшерү — музыкантның бурычы. Димәк, музыкант-фольклорчы иң башта җырның музыка өлешен тикшерә, ә калган элементлары турында лингвист, филолог һ. б. лар хезмәтләренә таянып фикер йөртә.

Фольклористикада көй белән сүз җырда органик бердәмлектә яшиләр, дигән бернинди дәлилсез (a priori) тезис модага кереп китте. Моннан теләсә нинди нәтиҗә чыгарып була [2].

Җырда сүз белән көй мөнәсәбәте — зур һәм катлаулы проблема. Монда без аның кайбер якларына гына тукталабыз. Көй һәм сүз җырда бергә яшиләр дисәк, бу чыннан да дөрес булыр иде. Ләкин әле бу һәр көйнең үзенә генә хас тексты була дигән сүз түгел. Халык иҗаты практикасы күрсәткәнчә, бер үк көйгә төрле эчтәлекле, хәтта структуралары төрле булган текстлар җырланырга һәм, киресенчә, бер үк текст төрле көйләр белән башкарылырга мөмкин. Төрле текстларга җырлана торган «Кәләү Гайшә» җырын гына алыйк. Алар арасында 9—10 һәм 7—8 үлчәүлеләре бар. Музыкасының төзелеше белән бу, һичшиксез, озын көй. Димәк, текстның төзелешеннән чыгып кына җырның формасын билгеләп булмый. Шулай ук фәлән көйгә фәлән эчтәлек кенә туры килә дип тә булмый.

Көйнең мондый эмоциональ киңлеге, төрле эчтәлекле текстларны тәэмин итә алуы музыканың спецификасы — образының конкрет булмыйча, ә гомумилеге һәм мөстәкыйльлеге белән аңлатыла. Еш кына көй җырда гомумиләшкән билгеле бер настроение тудыра, текстларның эчтәлеге урыны-урыны белән аны конкретлаштыра.

Бер көйнең төрле эчтәлекле җырларны тәэмин итүенә мисал буларак, революция һәм гражданнар сугышы чорларында борынгы татар көйләренә яңа җырлар башкарылуын искә төшерик. Бу күренеш барлык халыкларга һәм чорларга хас.

---

[1] Бу сыналган методны инкарь итү дә очрый. Имеш, комплекслы метод кына хаклы. Ләкин элементлар тиешле дәрәҗәдә һәм профессиональ тирәнлектә өйрәнелми торып, «комплекс»лы метод объектив мәгълүмат бирә алмый.

[2] Профессиональ сәнгатьтә мондый карашлар күп төрле аңлашылмаучылыклар китереп чыгара. Без әле еш кына җыр белән шигырь үзенчәлекләрен аермыйбыз, аларга бер үк таләп куябыз. Берәүләр халык тарафыннан танылган җырның сүзләрен аерып алалар да аның шигырь буларак бик йомшак булуын исбатлыйлар. Икенчеләр тирән эчтәлекле шигырьләргә композитор тарафыннан язылган әсәрләрнең җырланмый ятуларына гаҗәпләнәләр. Бу аерым һәм махсус сөйләшү таләп итә торган мәсьәлә.

Шулай итеп, көй белән шигырь арасында гомум настроение туры килү-килмәү турында гына бәхәс булу мөмкин. Хәтта бу ике компонент бер-берсенә контрастлы булуы да әле начар дигән сүз түгел. Шигърият тә, музыка да мөстәкыйль сәнгать өлкәләре. Аларның үзара мөнәсәбәте катлаулы, аны бары тик «бердәмлеккә» кайтару сәнгатьләрнең үзара диалектик бәйләнешен примитивлаштыру булыр иде.

Ләкин бу әле шигырь белән көй арасында структур һ. б. бәйләнешләр юк дигән сүз түгел. Җырчы яңа текстны традицион озын көйгә яраклаштырып башкара: җитмәгән җөмләне өсти, артыгын кыскарта. Бу элемтә конкрет текст һәм конкрет көй арасында түгел, ә бәлки гомумән татар шигыре һәм көй арасында туа. Төрле жанрларда элемтә төрле характер ала. Бәеттә, мәсәлән, шигырь структурасы көйнекен билгели, такмакта бию ритмы өстенлек ала. Татар телендә басым сүзнең ахырына туры килү аркасында татар көйләрендә гомумән ямб ритмы зур урын алып тора.

Киң планда караганда, җырларда көй һәм сүз үзара комплиментар бәйләнештә яшиләр. Зур эчтәлекле, сюжетлы текстның көе, мәсәлән, примитиврак була (бәет, дастан, такмак), киң музыкаль колачлы, тирән хисле озын көйнең текстлары бик гади һәм кыска була. Озын көйдә шигырь ритмикасының көй өчен әһәмияте булмаса, башка жанрларда көй ритмын шигырь билгели.

Халык музыкасының стиль үзенчәлекләре жанр һәм тарих-этнографиягә бәйле, тотрыклы фактор буларак, җыр классификациясенә ышанычлы нигез, төп критерий булып хезмәт итә ала. Җырның күп өлешле феномен булуын истә тотып, җыентыкларда тематик, структур, ритмик, территориаль, этнографик һ. б. төр классификацияләр булдыру мәҗбүри.

Халкыбызның күп томлы музыка иҗаты җыентыгын хәзерләү — иҗтимагый-культура тормышында зур вакыйга. Ул фольклористика фәненең төрле тармакларын тагын да үстерү, күп проблемаларны ачыклау, яңадан-яңа экспедицияләр оештыру, махсус белгечләр әзерләү һәм барлык иҗади көчләребезне туплауны таләп итә.

## Җәүдәт Дәрзаманов

### Солдат булдым

Каеш будым билемә,
Тасма тактым җиңемә,
Йолдызлы бүрек кидем,
— Мин солдат булдым, — дидем.

Иңемә мылтык астым,
Әти каршына бастым.
— Килдем, иптәш командир,
Әйдә, берәр боерык бир!

— Смирно! — ди әти дә, —
Печән ашат бәтигә.
Бераз утын ярырсың,
Аннан суга барырсың!

— Була ул! — дим кырт кына
Һәм борылам фырт кына.
Солдат булгач, нишлисең,
Куштылармы, эшлисең...

### Куян бүрек

Башында куян бүрек,
Каралган уйнап йөреп.
Орышты соң әнисе
Беркөн шул хәлне күреп.

Баскан җирдә таптанып,
Тәлгать тора акланып:
— Кечкенә зыян ла бу,
Соң әни, куян ла бу!

Яз җитә бит, җәй җитә,
Менә шуңа күрә, — ди, —
Минем куян бүрегем
Соры төскә керә, — ди.

## Заһирә Гомәрова

### Бабай тарта шалканны

Бабай, әби, кыз — бергәләп,
Әй, тарталар шалканны.
Әллә соң инде аларны
Шалкан үзе тартамы?

Чыкмый шалкан,
Ничә көннәр
Карыйм да шул рәсемгә,
Үзем йолкыймны дип йөрим
Картина тирәсендә.

Кул көче белән ник инде
Шул кадәр интегергә?
Була ич бер нәни генә
Трактор китерергә...

### Кем кулы матур?

Бик матур, бик алсу
Алсуның куллары.
Каралткан вакыты
Бөтенләй булмады.

Идән дә юмый ул,
— Буяла кулым, — дип,
Кояштан яшерә,
— Ой, яна кулым, — дип.

Ләләнең кулын күр,
Каралган, тырналган.
Эш эшләп кайткан ул
Бакчадан, кырлардан.

Ник инде өлкәннәр
Шуны да белмиләр.
Ләләнең кулларын
— Иң матур кул! — диләр.

# УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

«Казан утлары»ның 7—8 саннарында Миргазиян Юнысның «Тозлы җил» повесте басылып чыкты. Әдәбиятыбызда аз яктыртылган диңгезчеләр тормышы хакында әсәргә тотынып автор бик дөрес эшләгән. Бу турыда, юл язмаларыннан, очерк һәм хикәяләрдән тыш, кулга алып укырлык китапларыбыз бик аз иде.

Әсәр язылган. Күренеп тора, язучы аңа күп хезмәт куйган. Темасы актуаль. Әмма повестьның, минем уемча, кимчелекләре дә шактый. Шуңа күрә аерым китап булып чыкканчы, аның күзгә бәрелеп торган кимчелекләрен күрсәтәсе, шулардан арындырасы, кыскасы — китабын яхшырак итеп күрәсе килә иде.

Иң элек әсәрнең исеме турында. «Тозлы җил» дип атала ул. Шактый зур күләмле булуына карамастан, аның исеме җисеменә туры килеп бетми сыман. Повесть ахырында күрсәтелгәнчә (анда фәкать беренче китапның бетүе турында әйтелә), чыннан да, ул әле бер бөтен әсәр дәрәҗәсенә җитмәгән, язылган өлешендә диңгез үзе дә, аның тозлы җилләре дә, гомумән, диңгезче дә юк әле.

Диңгез хезмәтенең авырлыгын күрсәтү өчен, «тозлы җилләрнең» тәмен татыр өчен байтак гарасатлы штормнарда чайкалу, океанның кырыс гадәтләре белән бик озак көрәшү кирәктер ул.

Болай әйтеп мин авторның диңгезче булу-булмавына шик тудырырга һич җыенмыйм. Иҗат кешесе өчен анысы мәҗбүри дә түгелдер. Җир асты, су асты, күк һәм җиһан тормышын тасвирлап язган мәшһүр язучылар шуннан торып иҗат итмәгәннәр бит. Әйтергә теләгән нәрсә шул, диңгез һәм диңгезче турында сүз кузгаткач, әсәрдә дә шуларга ныграк басым ясарга иде.

Моннан берничә ел элек тәнкыйтьче Р. Мостафин, «Муса Җәлил» корабында сәяхәт ясап, юл язмалары бастырган иде. Билгеле, ул анда «Тозлы җил» геройлары сыман романтика эзләп китмәгән. Яхшы хәзерлек үткән тулы канлы экипаж да аның ярдәменә мохтаҗ булмагандыр. Аның хезмәте бөтенләй башка. Сәяхәт тәэсирләрен, бөек шагыйребез исемен йөрткән корабль экипажының героик хезмәтен безгә — меңәрләгән китап сөючеләргә җиткерү. Һәм ул аңа ирешкән иде дә дияси килә. Алай гына да түгел, автор анда ерактан торып Ватаныбызны тагын да якынайта, зурайта төште. Төрле ят илләрнең, ят җирләрнең «оҗмах ишекләрен» ачып күрсәтте.

Ә «Тозлы җил» исә романтика, экзотика, диңгез маҗаралары белән мавыгучы Феликс белән Габдрахманның Одессага килеп, пароходка эшкә керүләре белән очлана.

Ярый шулай да булсын, ди. Димәк, «Тозлы җилләр» алда исәчәк. Язган булса, диңгезче булырга омтылган яшьләр алар белән киләчәктә очрашыр. Сүз ул хакта түгел. Әсәрнең укучыларга тәкъдим ителгән өлеше генә әнә шул матрос булырга ашкынган яшьләргә ни бирә? Диңгезче һөнәренә ниндирәк мөнәсәбәт уята, гомумән, тормышка яңа аяк басучы яшь буын вәкилләренә нинди рухи байлыклар өсти?

Язучының Габдрахманы гаҗәп сәер кеше. Авылда 7 класс бетергәч, җирен дә сөргән, печәнен дә чапкан. Башка эшләрдән дә чирканып тормаган. Аннары — армия хезмәте. Авиация, хәрби юридик академия. Тагын авиация. Госпиталь. Демобилизация. Университет. Азак килеп — диңгезче.

Бу урыннарның, эшләрнең кайсын алып карасаң да, һәркайсы почетлы да, мактаулы да. Бигрәк тә яшьләр өчен кызыклы һәм мавыктыргыч. Тик менә Габдрахман гына аларның берсеннән дә ләззәт таба белми. Чәчкә сайлаган назлы күбәләк сыман. Ул хәтта бар хыялына ирешеп, очучы булгач та эш урыннарын алыштыра-алыштыра, 20 ләп шәһәрдә яшәргә өлгергән. Бу яраткан һөнәрен ташлап юрист булырга да ымсынып караган. Гәрчә авиациядә калу мөмкинлеге булса да, аны бөтенләйгә ташлап китеп, «ялгыш» университетка ки-

леп эләккән. Шул хатасын ул хәзер диңгезче булып төзәтмәкче. Ай-һай, моңа хәтле үз кыйбласын тапмаган, тормышка, хезмәткә карата төпле акыл утыртмаган Габдрахманнан чын диңгезче чыгар микән?..

Шунысы яхшы, ул үз хаталарын белеп, сизеп килә, үкенә, үткәннәрен сагына. Ләкин, кызганычка каршы, шул хаталарны яңадан кабатлый. Одессага килеп, хыялый планнары җимерелә башлагач, мәсәлән, ул кире кайтып, укуын дәвам иттерергә дә әзер. Тик җиде юл чатында торганда, әллә аның бәхетенә, әллә бәхетсезлегенә каршы, Эдик дусты очрый. Мәскәү студенты, ниһаять, диңгезчеләр коллективына элгә: «Илләр гизәчәкмен, дөнья күрәчәкмен!..»

Әмма шулай булып кына бетсәче. Монда да Габдрахман үзенең тотнаксыз характерына, йөгәнсез ихтыярына «хыянәт» итми. «Ләкин,— дип дәвам итә ул,— күңелдә бушлыктан башка бернәрсә дә юк. Нигәдер мин бу хәлгә куана алмый идем. Бу бәхет мине шатландырырга тиеш иде бит! Нигә болай ямансу булып китте соң әле?»

Тормыш сукмагын кешеләр шулай сайларга, үз бәхетләрен шулай эзләргә тиеш була микән инде? Яшьләргә хас сыйфатмы бу? Түгелдер.

Сүз дә юк, Габдрахман кебек иләсмиләс күңелле кешеләр дә була. Инде әсәрдән өметлерәк, гыйбрәт алырлык кешеләр эзләп карыйк.

Менә Габдрахманның күңеленә беренче тапкыр диңгез вәсвәсәсе салган студент Феликс. Күп икеләнүләрдән соң аларның уйлары берегә. Укуны ташлап, бергә эшкә урнашырга сүз куешалар, билет алып юлга чыгалар һәм, «дусны» ташлап, Феликс вагоннан төшеп кала. Икенче «дус» Эдик белән дә шулайрак була. Икәүләп укырга керергә, аннан эшкә урнашырга план корыла. Ләкин Эдик укуны кичектереп, танышлары аркылы үзе генә эшкә урнашып, Габдрахманны ташлап китә. Атналар буе укудан качып, башкала урамнарында килеп сарып йөрүче Багратны әйтәсеңме, шулай ук занятиеләрен калдырып, атаклы кешеләрнең тәмәке төпчекләрен җыеп гомерен уздыручы Маштаковны телгә аласыңмы — берсе дә безнең яшьләргә, атап әйткәндә, студентларга хас сыйфатларга ия түгелләр.

Укытучы, булачак тәрбияче Валерия Трифонованың киләчәк язмышы тагын да күңелсез.

— Мин,— ди ул,— Элам Харниш шикелле бер шәхескә кияүгә чыгып, шуңа аш пешереп, керен юып яшәү турында хыялланам.

Дөрес, әсәрдә укучы күңеленә хуш килерлек геройлар да күзгә чалына. Алар — студент Өметгали, Галя белән Нина. Ләкин алар — күләгәдә, ышыкта, ниндидер төшенке күңелле, бушлыктан урын һәм бәхет эзләүче шәхесләр тарафыннан кысрыкланганнар.

Шуны да әйтергә кирәк, Габдрахманның шәхси тормышы гаять авыр шартларда тасвирлана. Тәүлек әйләнешенә ризык капмау, алмаш киемсез йөрү, кесә кагып, соңгы тиеннәр исәбенә берәр пирожки белән туклану һ. б. элекке очучы офицерга, бүген килеп Ленин стипендиясе алу дәрәҗәсенә җиткән студентка ничектер ябышып бетми. Без бу хәлне В. Нуруллинның Равиле («Шинельсез солдатлар»), Ә. Баяновның Әнисе («Яшьлегемне эзлим») аша да шактый ару татыган идек инде. Сугыш һәм аннан соңгы еллар авырлыгын бөтен ил, бөтен халык үз иңендә күтәрде. Сыкранмады, мескенләнмәде. Гәрчә ул чын дөреслек булса да, үз язмышыңны каһәрләп, кемнәрдәндер шуңа гаеп эзләп лаф ору нигезсез. Гомумән, безнең халыкка рух төшерү, мескенләнү сыйфатлары хас түгел. Моны шуның белән дә дәлилләп була.

Менә «Тозлы җил» белән янәшә (8 сан) А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» повесте. Күләме ягыннан «Тозлы җил»нең чиреге чамасы гына булса да, бу әсәрдә авыр елларда тоташ бер колхозның хәле тасвирланган, андагы кешеләрнең тормыш, яшәү, киләчәк өчен җан аямый көрәшүләре һәм шул көрәштә ныгый, чыныга барган бердәмлек, туганлык мотивлары күңелләрне тетрәтерлек итеп сурәтләнгән.

Колхоз башлыгы Хәкимҗан хәлне болай аңлата:

— Менә мартка да кердек. Калхуз келәтендә бөртек симәнә юк. Күзгә кырып салырга бер бөртек җурна юк! Атлар барысы өрлектә...

Сукранамы Хәкимҗан карт? Һич тә юк. Аяныч хәл булса да, авылдашларына чын дөреслекне әйтә һәм шуның белән халыкны зур тәвәккәллеккә әйди — орлыкны 65 чакрымнан бәләкәй чана белән ташырга кирәк бит!

Халык аны яхшы аңлый һәм бердәм күтәрелә. Кемнәр генә юк ул гадәти бул-

маган кәрвандаʔ Үз тамагыннан элек атларныкын кайгыртучы Дамир белән Ибраһим, йөрәге авыру Сабираттәй, сыңар куллы фронтовиклар, җитеп килгән кызлар, үсмер егетләр... Әмма боларның берсеннән дә офтану сүзләре ишетмәссең. Тешләрен кысып атлый бирәләр, шаярып күңел күтәрәләр, бер-берсенә ярдәмләшәләр, ялга туктаганда алабутадан пешерелгән соңгы икмәк кыерчыкларын, күмгән бәрәңгеләрен уртак табынга салалар, иңне-иңгә терәп, бер идәндә йоклыйлар. Менә бит халкыбызның асыл сыйфатлары! Авыр булса да тормыш үзенчә ага. Шунда ук бәләкәй чана тарткан ике яшьнең өлгереп килгән мәхәббәтенә карагыз. Нинди табигый, нинди самими ул Ибраһим белән Әдилә дуслыгы! Ә инде «Тозлы җил»дә бу җәһәттән телгә алырлык нәрсә дә чамалы. Габдрахман белән Валерия, Феликс белән Элеонора эч пошканнан гына бергә вакыт уздыралар. Эдик белән Лариса арасында да классташларга хас мөнәсәбәт сизелми. Теләсә нинди чибәр кызга күз атып йөрүче Баграт һаман үз идеалын эзли...

Яшьләр арасындагы мөнәсәбәтне күрсәтү өчен Габдрахман тарафыннан әйтелгән бер-ике сүзне күрсәтү дә җитәр, мәгаен: «Крокодиллар, минем өлешне кем ашады?», «Варварлар, вөҗданыгыз кайда сезнең?»

Моны ул үзенә калдырылган кавын кисәген студент дуслары ашагач әйтә, һәм тегеләре уңайсызланып чыгып китәләр.

Әсәрнең тәрбияви ягын истән чыгармыйча, яшьләр арасындагы дуслык, мәхәббәт мәсьәләләренә дә саграк карарга, тормыш чынбарлыгыннан читкә тайпылмаска иде.

**Шәйхи ШӘЯХМӘТОВ,**
**Башкортстан, Стәрлебаш.**

## Фәнис Яруллин

### Сөбханалла!

Өйдә бүген зур тантана,
Һәрбер йөздә шатлык яна.
Аяклары җиргә тими —
Биеп йөри ата-ана.
Әбисе әйтә: «Сөбханалла!
Зур үскән бит безнең бала!
Тфү, тфү, күз тимәсен,
Сабыебыз әнә үзе
Тагып куйган җиң төймәсен!»
Зур куаныч әнкәсенә,
Сөеп карый бәбкәсенә:
«Үзе таккан, үзе таккан,
Энә-җепне үзе тапкан!
Бармагына кадамаган,
Бер җире дә канамаган».
Гаҗәпләнгән ата кеше,
Ай-яй, шәп ди кызның эше.
Куанышкан һәркем шулай,
Инде эшләр китәр уңай.
Сөбханалла! Сөбханалла!
Күлмәгенә төймә таккан
Унсигездә бер кыз бала.

### Сәрби әби

Сәрби әби телевизор карый,
Кич җиттеме, утырып диванга:
— Тагын шушы оятсызлар икән,—
Дип әйтә ул балет булганда.

Футболын да карый, хоккеен да,
Вакыты күп — нигә җәлләсен!
— Өрлек кебек ирләр шар суга,— дип,
Сүгә-сүгә карый һәммәсен.

Опералэрны да калдырмый ул,
Һичнәрсәгә түгел битараф:
— Бугазларын болай ерта-ерта
Акыралар икән ни карап?

...Сәрби әби шундый кеше инде,
Бөтенесен сүгә, пырдымсыз.
Ләкин үзе тик бер генә көн дә
Тора алмый телевизорсыз.

## Гамил Афзал

### Очкыннар

●

Регламентсыз җиләс җилләр исә,
Җанлы дөнья якын-тирәдә —
Якты көнгә сөенеп каен үсә,
Ярарга тырышмый кемгә дә.

●

Бозылды да китте көннең яме,
Үзгәрде дә китте чәйнең тәме.
Чыбык белән намус сыртка суга,
Арган акыл акланмакчы була:
— Бер мин генә дурак түгел әле...

●

Кемнең язы, кемнең көзе,
кемнең кышы инде.
Туйлар уза, туннар туза —
тормыш шушы инде.

●

Малайлар сакал үстерә,
Картлар сакал кыра;
Бер елмаеп, бер көрсенеп,
Заман карап тора.

●

Язын да, көзен дә күп сөйләп, чүп сөйләп,
Үтте бер адәмнең гомерләре.
Һөнәре булмагач, планы тулмагач,
Бичара тел белән көн иләде.

●

Ай башында, ай-яй, дибез,
эшләр бара, дуслар!
Азагында, ай-вай, дибез,
план яна, дуслар.
Ай-яй дию, ай-вай дию
кая барып туктар?..

●

Һоп, егетләр, башка илһам иңде,
Үзе көнчел, явыз, үзе дәртле.
Бу чабышта узып китсәк иде
Гомәр Хәям белән Дәрдмәндне!

## Шикаять

Мәсәл

Арысланга Куяннан шикаять килгән,
Төлке явыз мине бик җәберли, дигән,
Минем бәбиләрне ашый көн дә берсен,
Абзыкаем, шул Төлкегә җәза бир син!

Ә Арыслан утыра иде план уйлап,
Шикаятьне укыды да, тирән сулап,
Язып куйды: «Фактлар юк кулымда,— дип,—
Тикшерергә, ачыкларга урында!» — дип.

Шул шикаять, чакырмаган кунак төсле,
Аю абзый өстәленә килеп төште.
Язды Аю: «Мондый хәлләр булганда,— дип,—
Фактларны тикшерергә урманда!» — дип.

Шул шикаять, бер ай үткәч, көчкә генә,
Килеп төште Бүре абзый өстәленә.
Язды Бүре: «Фактлар юк кулымда,— дип,—
Тикшерергә факт булган урында»,— дип.

Шул шикаять, шикләндереп тирә-якны,
Төлке абзый өстәленә килеп ятты.
Укыды да Төлке абзый сытып йөзен,
Тикшерергә тотынды Куянның үзен:

— Ах, оятсыз, ялганчы син, азгансың син,
Минем өстән Арысланга язгансың син! —
Диде дә ул Куянны сыртыннан тотты,
Шауламыйча, тиргәмичә, кабып йотты.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ АЧЫК ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан язучылар союзы партия оешмасының һәр ачык җыелышы бүгенге әдәби хәрәкәтнең нинди дә булса берәр мөһим мәсьәләсенә багышлап уздырыла, һәр җыелышта язучылар коллективы алдында торган актуаль проблемалар күтәрелә. 1974 елның 27 ноябрендә уздырылган ачык партия җыелышы, мәсәлән, «Әдәбиятта коммунист образы» дигән темага багышланган иде.

Җыелышта катнашучылар башта филология фәннәре кандидаты Ф. Мусинның «Татар совет әдәбиятында коммунист образлары» турындагы докладын тыңладылар. Доклалтан соң фикер алышулар башланып китте. Фикер алышуларда язучылардан Х. Вахит, Р. Мостафин, Г. Ахунов, «Азат хатын» журналының җаваплы редакторы А. Хәсәнова катнашты. Докладчы да, чыгыш ясаучылар да татар язучыларының коммунист образларын иҗат итү өлкәсендәге уңышларын билгеләп үттеләр, коммунист образларын иҗат итү буенча язучылар коллективы алдында торган бурычларга тукталдылар.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Билгеле булганча, Татарстан язучылар союзы каршында сигез секция эшләп килә. Соңгы вакытларда ул секцияләрнең хокуклары тагын да арта һәм зурая төште. Нәтиҗәдә иҗат секцияләренең эше җанланып китте, алар әдәби хәрәкәткә конкретрак һәм нәтиҗәлерәк йогынты ясый башладылар.

Тәнкыйтьчеләр секциясенең 15 ноябрьда уздырылган утырышы мәрхүм журналист Исмәгыйл Рәминең «Әдәби сүзлек» исемле хезмәтен тикшерүгә багышланган иде. Утырышта күренекле язучылар, галимнәр, Татарстан китап нәшрияты вәкилләре катнашты. Анда язучылардан Н. Исәнбәт, С. Хәким, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, Т. Миңнуллиннар, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре Ә. Кәримуллин һәм Р. Гайнанов, Татарстан китап нәшриятының баш редактор урынбасары Н. Габитов һәм башка иптәшләр чыгыш ясады. Фикер алышуда катнашучылар бу кулъязманың иҗтимагый кыйммәте хакында сөйләделәр, аны кирәкле һәм файдалы хезмәт дип таптылар. Кулъязманы китап итеп чыгару өчен махсус редколлегия билгеләнде.

*
* *

1974 елның ноябрь башларында проза секциясенең чираттагы утырышы булды. Анда бүгенге татар совет прозасының теле турында зур сөйләшү алып барылды. Әсәрләребезнең теле хакында язучы Хәсән Сарьян эчтәлекле һәм мисалларга бай доклад ясады. Казан дәүләт университеты тел галимнәре, язучылар, әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр аерым прозаикларның әсәрләренә анализ ясадылар, тел-сурәтләү чараларына тукталдылар. Сөйләшү кызыклы һәм файдалы узды.

*
* *

Шул ук секциянең ел ахырында уздырылган икенче бер утырышында А. Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар» һәм М. Юнысның «Тозлы җил» исемле повестьлары тикшерелде. Фикер алышуларда язучылардан М. Әмир, А. Расих, М. Мәһдиев, филология фәннәре кандидаты Ф. Хатипов, тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин, Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы укытучысы Ф. Ганиева һәм башка иптәшләр катнашты. Алар һәр ике повестьны яратып укулары хакында сөйләделәр, ул әсәрләрне әлеге прозаикларның иҗади уңышы дип билгеләп үттеләр.

*
* *

25 октябрьда шагыйрьләр һәм тәрҗемәчеләр секцияләренең берләштерелгән утырышы булды. Ул соңгы 5—6 ел эчендә татар теленә тәрҗемә ителгән шигъри әсәрләрне тикшерүгә багышланган иде. Утырышны, шигъри тәрҗемәләр хакында кереш сүз сөйләп, тәрҗемәчеләр секциясе председателе Т. Нурмөхәммәтов ачты. Соңгы еллардагы шигъри тәрҗемәләр, аларның сыйфаты турында докладлар белән Р. Мингалимов һәм Ә. Синегуловлар чыкты. Докладлар буенча фикер алышуларда С. Хәким, Ш. Маннур, Н. Дәүли, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, филология фәннәре кандидаты Р. Юсупов катнашты.

*
* *

Тәрҗемәчеләр секциясенең 11 ноябрьда уздырылган утырышында ике мәсьәлә каралды. Беренчесе — Мәскәүнең М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укучы тәрҗемәчеләр группасы турында белдерү. Икенчесе — Ә. Еникинең рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре, ул тәрҗемәләрнең сыйфаты турында сөйләшү.

Беренче көн тәртибе буенча К. Миңлебаев, Т. Нурмөхәммәтов, Ш. Рәкыйпов, Р. Фәйзуллин һәм Әдәбият институты студентлары Л. Гайнанова белән Л. Хуҗиналар чыгыш ясады.

Ә. Еники әсәрләренең тәрҗемә сыйфаты турында фикер алышуда Н. Мальшакова, М. Рафиков, Р. Мостафин, Р. Такташ, М. Зарецкий һәм Л. Ихсановалар катнашты.

*
* *

Драматурглар секциясенең чираттагы утырышында Т. Миңнуллинның «Канкай улы Бәхтияр» исемле пьесасы укып тикшерелде. Утырышта И. Юзеев, Ә. Камал, М. Госманов, М. Гайнетдинов, Г. Рәхим, А. Гыйләҗев, Һ. Мәхмүтов, Н. Ханзафаров, К. Дәүләтшин, Х. Вахит һәм башка иптәшләр чыгыш ясады. Алар драматургның кирәкле темага тотынуын билгеләп үттеләр, аңа пьесасын тагын да камилләштерү юнәлешендә файдалы киңәшләр бирделәр.

*
* *

Балалар әдәбияты секциясенең Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе белән бергәләп уздырылган утырышында яшь язучы Ә. Галиевнең «Әткәм пилоткасы» исемле повесте тикшерелде. Фикер алышуларда Г. Бакиров, Б. Камалов, Ф. Ибраһимова, М. Мазунов, Х. Сарьян, К. Котдусова, Л. Ихсанова, Ш. Рәкыйповлар катнашты. Авторга әсәрен яхшырту юнәлешендә күп кенә тәкъдимнәр әйтелде.

*
* *

Шул ук секциянең 15 ноябрьда уздырылган утырышында М. Госмановның «Таулар, үзәннәр илендә» исемле әсәре тикшерелде. Авторның бу әсәре Тува якларына оештырылган фәнни экспедицияләр тәэсиреннән чыгып язылган. Сүз анда бу якларның үзенчәлекле табигате, тарихи истәлекләре хакында бара.

Утырышта Н. Фәттах, Г. Хәсәнов, Ф. Ибраһимова, А. Тимергалин, С. Сибгатуллина, Ш. Рәкыйпов, Л. Ихсановалар чыгыш ясады. Алар әсәрнең күп кенә кимчелекләрен күрсәттеләр, ул кимчелекләрне бетерү буенча авторга файдалы киңәшләр, эшлекле тәкъдимнәр әйттеләр.

*
* *

«Казан утлары» журналы каршындагы яшь рецензентлар түгәрәгенең чираттагы утырышы университет студентлары янында үткәрелде. Башта IV курс студенты Б. Антоновның тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләре тикшерелде. Соңыннан Р. Мостафин һәм Ф. Миңнуллин бүгенге татар прозасы турында сөйләделәр, студентларның сорауларына җаваплар бирделәр.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

«Азнакайнефть» идарәсенең профсоюз китапханәсендә М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да» дигән повесте буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Конференциядә автор үзе дә катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ КЛУБЫНДА

Татарстан язучыларының Габдулла Тукай исемендәге клубы үзенең яңа сезонын узган елның октябрь аенда ук башлап җибәргән иде. Сезон ачылган көннән алып, һәр җомга саен биредә төрле темаларга багышланган әдәби кичәләр үткәрелеп килә.

Беренче кичәдә шагыйрьләр һәм прозаиклар үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Җырчылар татар композиторларының яңа җырларын башкардылар. Кичә әдәбиятыбызның, музыка сәнгатебезнең бүгенге көндәге үсешен күрсәткән иҗат отчеты төсен алды.

«Яңалыклар, ачышлар, табышлар» дигән темага багышлап уздырылган кичәдә сүз СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты фольклорчыларына, этнографларына һәм музыка белгечләренә бирелде. Алар соңгы ике ел эчендә фәнни экспедицияләрдән алып кайткан халык авыз иҗаты җәүһәрләре — экиятләр, бәетләр, мәкаль-әйтемнәр, риваятьләр, борынгы җырлар турында сөйләделәр.

Танылган мәгърифәтче Риза Фәхретдиновның иҗатына багышланган кичә дә тамашачыларда зур кызыксыну уятты. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре, филология фәннәре докторы, профессор Мөхәммәт Гайнуллин матур әдәбият сөючеләргә Риза Фәхретдинов мирасының фәнни кыйммәте, энциклопедист галимнең яңа табылган кулъязмалары турында сөйләде.

Клубта уздырылган кичәләрнең берсе композитор Бату Мулюков иҗатына багышланган иде. Тамашачылар Татарстанның атказанган артисты Йосыф Гыйззәтуллин, популяр җырчылар Н. Теркулова, Г. Шаһиев, Г. Дәминов, М. Галиев һәм Казан культура институты студентлары чыгышын яратып тыңладылар.

Декабрь аенда уздырылган әдәби җомгада әдәбият-сәнгать сөючеләр Казан шәһәренең югары уку йортларында укучы студентлар белән очраштылар. Сәхнәдән алар язган шигырьләр һәм хикәяләр яңгырады. Ахырдан үзешчәннәр көче белән концерт бирелде.

## ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

29 ноябрьда Мәскәүнең әдәбият музеенда Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил иҗатына багышланган әдәби кичә үткәрелде. Кичәдә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми сотруднигы, филология фәннәре кандидаты В. Воздвиженский М. Җәлилнең үлемсез шигырьләре һәм героик тормыш юлы турында сөйләде. Мәскәү шагыйрьләре С. Липкин һәм И. Френкель Җәлилнең үзләре тәрҗемә иткән шигырьләрен укыдылар.

*

* *

«Кругозор-74» журналының 9 санында Муса Җәлилнең моңа кадәр билгесез булган дүрт шигыре («Родина», «Клятва», «Разлука», «Волжанке») басылган. Аларны шагыйрь Спартак Әхмәтов Үзбәкстанда яшәүче Гарәф Фәхретдиновтан язып алган һәм тәрҗемә иткән.

*

* *

1974 елда Донецк шәһәрендә «Вечный пламень» дигән җыентык чыкты. Аңа төрле милләт шагыйрьләренең хезмәткә багышланган шигырьләре тупланган. Бу җыентыкка татар шагыйрьләреннән Муса Җәлилнең «Төзүче» исемле һәм Ә. Баяновның «Икмәк» дигән шигырьләре кергән.

## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 30 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

1974 елда Петрозаводск шәһәрендәге «Карелия» нәшрияты «Белыми скалами линия фронта легла...» дип исемләнгән хикәяләр һәм истәлекләр китабы чыгарды. Бу җыентыкка Г. Әпсәләмовның «Хәйбулла солдат» дигән хикәясе кергән.

*

* *

«Комсомолец Заполярья» газетасында Г. Әпсәләмовның «Ватан солдаты» дигән мәкаләсе басылган. Газета шулай ук язучының фоторәсемен урнаштырган, аның тормышы, иҗаты турында белешмә дә биргән.

*

* *

Свирь буендагы сугышларга 30 ел тулды. Шул уңай белән партиянең Лодейное Поле шәһәр комитеты, шәһәр советы һәм комсомол комитеты Г. Әпсәләмовка котлау җибәрде, Лодейное Поле шәһәрен фашистлардан азат итүдә катнашкан өчен аңа рәхмәт белдерде.

## ХИКӘЯГӘ БҮЛӘК

ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм «Яшь ленинчы» газетасы редакциясе 1974 елның май аенда кыска хикәяләргә ябык конкурс игълан иткәннәр иде. Декабрь аенда конкурска йомгак ясалды.

Җюри конкурска килгән хикәяләр арасында беренче һәм икенче бүләккә лаек әсәрләр юк дип тапты, ә өченче ике бүләкнең берсен «Сугышчан бурыч» исемле хикәянең авторы Фаил Шәфигуллинга бирергә карар итте.

## РУС ГАЛИМЕ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА

Мәскәүнең «Советский писатель» нәшриятында Е. Горбунованың бүгенге совет әдәбиятын өйрәнүгә багышланган «Яңа чынбарлык каршында» («Перед лицом новой действительности») дигән хезмәте басылып чыкты. Монография авторы, башка милли әдәбиятлар белән бергә, татар әдәбиятын өйрәнүгә дә күп урын биргән. Е. Горбунова хезмәтендә нигездә татар язучыларының сәхнә әсәрләре тикшерелә. Ул Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, Ш. Камал, Т. Гыйззәт, Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт, М. Әмир кебек язучыларның әсәрләренә югары бәя бирә.

## ГАЛИМНӘР ӨЛЕШЕ

Мәскәүнең «Наука» нәшриятында «Күп милләтле совет әдәбияты тарихы»ның бишенче һәм алтынчы томнары басылып чыкты. Һәр ике томга татар галимнәренең дә хезмәтләре кергән. Бишенче томда Х. Хәйринең бүгенге татар әдәбияты турындагы зур мәкаләсе бар. Алтынчы томга татар совет әдәбиятының хроникасы урнаштырылган. Аны филология фәннәре кандидатлары А. Әхмәдуллин һәм Р. Сверигиннар төзегән.

## ФРАНЦИЯДӘН ХАТ

1971 елда Татарстан китап нәшрияты филология фәннәре кандидаты Әбрар Кәримуллинның «У истоков татарской книги..» дигән китабын бастырып чыгарган иде. Китап республикабыз җәмәгатьчелеге һәм укучыларда зур кызыксыну уятты һәм тиз арада сатылып та бетте.

Күптән түгел нәшрият исеменә Франциядән хат килде. Университетлар буенча дәүләт секретариатының китапханәләр һәм халык укучылары дирекциясе тарафыннан җибәрелгән бу хатта Ә. Кәримуллин китабына уңай бәя бирелә, шул төрдәге хезмәтләр арасында аның әһәмияте билгеләп үтелә.

Түбәндә без шул хатны урнаштырабыз: *«Франция китапханәләре Бюллетененнән өземтә. 19-том — n° 4 апрель 1974 ел.*

*1917 елга кадәрге татар китабы тарихын чагылдырган зур булмаган бу хезмәт— шул темага багышланган тикшеренүләрнең беренче тәҗрибәсе. Чынлап та, әлегәчә татар китабы тарихына караган нинди дә булса җитди хезмәт барлыгын белми идек кенә түгел, татар телендәге китапларны теркәп бару да гамәлгә кертелмәгән иде. Биредә автор гарәп шрифтындагы кулъязмалардан башлап (бу кулъязмалар урта гасыр чорында югалганнар, бары XVII гасыр башыннан XXI гасыр азагынача вакыт эчендә алынган күчермәләре генә сакланган) гарәп яки кириллик хәрефләр белән татар телендә чыккан басма китапларгача татар китабының тарихын күздән кичерә. Рус авторларының гарәп хәрефләре белән язылган беренче әсәрләре Бөек Петр заманында күренә башлый, һәм унсигезенче йөздә алардан файдалану арта, әмма Иделдәге татарларның башкаласы Казанга типография бары 1800 елда гына килә.*

*Рус һәм татар интеллигентларының һәм революционерларының өзлексез тырышлык күрсәтүләренә карамастан, 1809 елдан бирле татар телендә бер генә периодик басма да дөньяга чыкмаган. Бары тик 1905 елда гына (беренче революциядән соң) патша цензурасы татар телендә газетага нигез салырга мөмкинлек бирә. Бу башлангыч шул кадәр уңышлы булып чыга ки, 1917 елда инде, Октябрь революциясеннән соң, һәртөрле 63 журнал һәм газета дөньяга килә.*

*Артык зур булмаган бу монография китап тарихы буенча белгечләр өчен генә түгел, Россия империясенең политик һәм колониаль тарихын чагылдыру ягыннан да кызыклы».*

Ә. Кәримуллин татар китабы тарихы буенча эзләнүләрен дәвам иттерә. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1974 елда аның «XX йөз башында татар китабы» дигән икенче хезмәте басылып чыкты. (А. Каримуллин. Татарская книга начала XX века. Казань. Таткнигоиздат. 1974.)

## ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАРЫНЫҢ VI СЪЕЗДЫ

1974 елның 13 декабрендә Казанның Пресса йортында Татарстан журналистлар союзының VI съезды булып үтте. Отчет чорында Татарстан журналистлар союзы идарәсенең эше һәм КПССның XXIV съезды карарлары яктылыгында республика журналистларының бурычлары турында доклад белән Татарстан журналистлар союзы идарәсе председателе Ш. Х. Хамматов чыкты.

Докладлар буенча фикер алышуда уннан артык кеше катнашты.

КПССның Татарстан өлкә комитетының икенче секретаре Ф. И. Панин съездда речь белән чыкты.

Съезд Татарстан журналистлар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составларын сайлады.

Оештыру пленумында Ф. И. Әгъзәмов, Ш. М. Вәлиев, Е. А. Лисин, В. Н. Михайлов, Ф. Г. Надыйров, Н. С. Пушкарев, Ш. Х. Хамматов, А. Ф. Хәсәнова, Г. Н. Шәрәфетдинов составында идарәнең бюросы сайланды. Татарстан журналистлар союзы идарәсенең председателе итеп Ш. Х. Хамматов, җаваплы секретаре итеп В. Н. Михайлов сайланды.

Шул ук көнне ревизия комиссиясенең дә утырышы булды. Аның председателе итеп М. В. Спиридонов сайланды.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

1974 елның 26 һәм 27 ноябрь көннәрендә СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының конференц-залында Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышына 200 ел тулуга багышланган фәнни конференция булып үтте. Конференция эшендә Татарстан галимнәреннән тыш, Мәскәү, Ленинград, Ижевск, Ульяновск, Уфа, Йошкар-Ола һәм Ставрополь шәһәрләреннән килгән күп кенә тарихчылар катнашты.

Беренче көнне тарих фәннәре докторы Е. Индованың (Мәскәү) «XVIII йөздәге сыйнфый көрәшне өйрәнүнең нәтиҗәләре һәм бурычлары», тарих фәннәре кандидаты С. Алишевның (Казан) «1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышы буенча яңа документлар», тарих фәннәре кандидаты М. Госмановның (Казан) «1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышы вакытында татар телендә язылган документларның тарихи чыганак буларак әһәмияте» дигән докладлары һәм башка докладлар тыңланды.

Икенче көнне тыңланган докладлар арасыннан филология фәннәре докторы, профессор Х. Госманның «1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышының татар әдәбияты үсешенә тәэсире», тарих фәннәре кандидаты В. Корецкийның (Мәскәү) «Идел буендагы беренче крестьяннар сугышы буенча чыганаклар», филология фәннәре кандидаты Ф. Фасеевның (Казан) «1773—1775 еллардагы эш кәгазьләрен тикшерү тәҗрибәсеннән» һәм филология фәннәре кандидаты Ф. Хисамованың (Казан) «Пугачев восстаниесе вакытында татарча язылган документларның кайбер морфологик үзенчәлекләре» дигән докладлары галимнәрдә аеруча зур кызыксыну уятты.

Соңыннан конференция делегатлары Казанның Е. Пугачев исеме белән бәйле тарихи урыннарында булдылар.

## СЫНЛЫ СӘНГАТЬ МУЗЕЕНДА

Татарстан АССРның Сынлы сәнгать музеенда танылган скульптор, М. Җәлил премиясе лауреаты В. Маликов әсәрләреннән төзелгән күргәзмә ачылды. Күргәзмәгә скульпторның агачтан, мәрмәрдән, металлдан һәм гипстан эшләнгән 150 ләп әсәре куелган. Алар арасында статуялар, бюст-

лар, лингравюралар, скульптур һәм график эскизлар бар. М. Вахитов, Ш. Усманов, М. Җәлил һәм Һ. Такташларның скульптур портретлары аеруча уңай тәэсир калдыра.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры тамашачыларга «Кан кардәшләре» исемле яңа спектакль күрсәтә башлады. Танылган драматург Юныс Әминов комедиясе буенча эшләнгән бу спектакльдә эшче намусы, гаилә, туганлык мөнәсәбәтләре кебек мәсьәләләр күтәрелә. Әсәрне сәхнәгә режиссер Р. Хаҗиәхмәтов куйган, декорацияләрне ТАССРның халык художнигы Ә. Тумашев ясаган.

*
* *

Татар дәүләт республика күчмә театры И. Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» исемле яңа комедиясен күрсәтә башлады. Әсәрне сәхнәгә театрның баш режиссеры, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Р. Тумашев куйган. Художнигы — П. Баландин.

## ДУСЛЫК КОНЦЕРТЛАРЫ

27 ноябрьдан 30 ноябрьга кадәр М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында Башкортстан һәм Татарстан сәнгать осталарының берләштерелгән концертлары барды. Башкорт һәм татар опера-балет театрларының танылган артистлары көче белән бирелгән бу концертларны Казан тамашачылары зур кызыксыну белән һәм яратып каршы алдылар.

## ЯЗУЧЫНЫҢ МИРАС КОМИССИЯСЕННӘН

Башкортстан язучылар союзы идарәсе тарафыннан Гариф Гомәринең әдәби мирасын туплау буенча комиссия төзелде. Аның составына филология фәннәре докторы, профессор Гайса Хөсәенов (председатель), язучы Азат Магазов, яшь шагыйрь Айдар Хәлим, язучының тормыш иптәше Кәфия ханым Гомәрова, язучының улы Әнвәр Гомәровлар кертелде.

Комиссиянең беренче утырышы үткәрелде. Анда Гариф Гомәринең әдәби мирасын туплау мәсьәләсе тикшерелде. Мәрхүмнең Башкортстанда һәм Татарстанда яшәүче бик күп язучылар, яшь авторлар, танышлары, дуслары һәм туганнары белән хат аша нык бәйләнештә булуы, шулай ук әдипнең байтак күләмдә әлегәчә басылмаган әсәрләр булуы ачыкланды. Язучының әдәби мирасы буенча комиссия мәрхүмнең хатлары, истәлекле башка язмалары сакланган иптәшләрдән аларны: «Өфе каласы, Совет урамы, 16. БАССР язучылар союзы, Г. Гомәринең әдәби мирасы буенча комиссиягә» дигән адрес белән җибәрүләрен үтенә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210